

# КАЗАН УТЛАРЫ

2
ФЕВРАЛ
1981

## БЕЗНЕҢ ПАРТИЯ

Табигатьнең чиксез зур көче бар —
Җир тетрәтә, таулар ишә ала.
Партиянең көче аннан да зур,
Ул көчтән тау хәтта үсә ала.

Табигатьтә туган яңа диңгез
Меңәр еллап шаулый-ярсый ала.
Ә партия исә ел эчендә
Шундый диңгез тудыра — ясый ала.

Күктә балкый зур һәм нурлы Кояш,
Матур итеп Җирне яктырта ул.
Партиянең эше аннан да зур —
Күңелләрне ямьли, яхшырта ул.

Галәм чиксез, аның киңлекләрен
Һичбер кем дә үлчи-иңли алмый.
Партиянең даны аннан зуррак —
Киң галәмгә күңел тиңли алмый.

Кояш белән һава — аерылгысыз,
Партия һәм халык — бердәм, бергә.
Кояш сүнсә тормыш булмас иде,
Ә партия — безнең кояш җирдә.

Дмитрий Гулиа

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**2**

ФЕВРАЛЬ
1981

## *Бу санда*

СЪЕЗДГА — ШАГЫЙРЬЛӘРЕБЕЗ

**Х. КАМАЛОВ.** Фикер уты. Шигырьләр . . . . 3
**Ф. САФИН.** Яңа таң. Шигырь . . . . . . . 5
**Г. РӘХИМ.** Иген өчен — илең өчен. Шигырь . . . 5

**Ф. ШӘФИГУЛЛИН.** Өй салуның ние бар. Повесть 7
**Р. МИҢНУЛЛИН.** Киләчәккә таба. Шигырьләр . . 74
**Р. ВӘЛИЕВ.** Гөлмәрҗән мәкләре. Хикәя . . . . 81
**И. БЕЛЯЕВ.** Тимер юлда уйлану. Шигырь . . . 101
**С. ШӘМСИ.** Соңгы юаныч. Хикәя . . . . . . 102
**Н. АКМАЛОВ.** Таң. Шигырьләр . . . . . . . 112

КПССның XXVI СЪЕЗДЫНА

**В. ШӘРИПОВ.** Сынаулар аша . . . . . . . 114
**Р. ФӘТХУЛЛИН.** Гап-гади Халиков. Очерк . . . 118

**Н. ХӘКИМУЛЛИН.** Арктика киңлекләрендә . . . 120

МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

**Н. АРСЛАНОВ.** Безнең Муса . . . . . . . 130
**Р. ХАРИС.** Ватандарлык тамырында . . . . . 131
**Р. ФӘЙЗУЛЛИН.** Еллар үткән саен биегәя . . . 133
**Ә. ГАФФАР.** Дастанчылар . . . . . . . . 134
**Г. БРОВМАН.** Муса Җәлил белән фронтта очрашу 136
**Р. МОСТАФИН.** Серле йомгак эзеннән . . . . 140
**Р. ЕНАКАЕВ.** Бер шигырьнең тарихы . . . . 142

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Ф. УРМАНЧЕЕВ.** Дастаннарга лаек замана . . . 144
**Ф. МУСИН.** Тормышка актив мөнәсәбәт . . . . 151
**Т. МИҢНУЛЛИН.** Яшьләр колагына бер сүз . . . 157
**Кечкенә рецензияләр** . . . . . . . . . 161

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Н. ВӘЛИЕВ. Юллар чатында . . . . . . . . 165

ТӨРЛЕСЕННӘН

Р. ӘМИРХАНОВ. Социалистик идеаллар чишмәсе 168

ФОЛЬКЛОР

Л. АРСЛАНОВ. Карагаш халык авыз иҗаты . . 172

Ш. ГАЛИЕВ. Хикмәтле сүзләр . . . . . . . . 178

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

С. СИДОРОВ. Г. Паушкинга 60 яшь . . . . 185

Әдәбият һәм сәнгать

**Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ**

**Редколлегия: ӘХСӘН БАЯНОВ** (баш редактор урынбасары), **ШАМИЛ БИКЧУРИН, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА** (җаваплы секретарь), **СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Шакирҗанова*

**Редакциянең адресы:** Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.
**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 23/X-1980 ел. Басарга кул куелды 20/I-1981 ел. ПФ 09001. Кәгазь форматы 70×108[1]/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 102 948 экз. Заказ У-441.
Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1981 ел.

## Хисам Камалов

### Фикер уты

Көрәшкән ул фикер олимпында.
Бәхәсләшкән, җиңгән, күндергән:
Күпме җанга кап-караңгы мәлдә
Якты фикер уты элдергән.
Ул һәр эшнең асылын ачып салган,
Батырлыкка моны юрамый,
Һәм хөкемдар фикер афәтләрен
Тетеп аткан рәхмәт сорамый.
Һәр шарлатан фикерне ул бары
Көчле акыл белән җиңалган.
Ул заманның ахмак уй агышын
Акыллы эзгә борып җибәргән!

### Акылы күпнең...

Һәркем уйлый үз гаменнән чыгып,
Үз «тавыннан» карап ни бары...
Тик тарихи уйлый белгән Ленин,
Өметләре очкан югары.
Төн эчендә кабынып бер шәмдәй
Юл яктырткан, сүнми чыдаган.
Хөр фикере яктылыгы белән
Тарткан илне, төннән чыгарган.
Акылы күпнең кайгысы күп була.
Даһиларның менә кайсысы
Шулай түгел? Ленинның да инде
Күп булгандыр авыр кайгысы...
Тик ил өчен кайгырган ул. Хәлләр
Китереп кыскан чакта янәдән,
Сабыр ирдәй салкын акыл белән
Йолып калган илне бәладән...

### Бөек көч

Партиянең тугры, чын уллары,
Һәр яладан өстен, пакь торып,

Партиянең йөзен акладылар,
Ышанычны аңа арттырып.
Һәм яңаны кору максатларын
Шәхси максат итеп, инанып,
Иң хәлиткеч төштә җиңде алар
Партиядән, илдән көч алып.
Партия — ул миллионнарның аңы,
Юнәлдерде безне хак юлга...
Аның сафы таза булса, безне
Җиңә алмас берни асылда.
Юк, партия — карьера өчен түгел,
Зур җаваплык алу өстеңә.
Читкә куеп шәхси мәнфәгатьне,
Төпкә җигелү бөтен көчеңә.
Миллионнарның ихтыярын бергә
Туплый ул партия! Әгәр дә
Юлбашчылар чоры үткән икән,
Бөтен хикмәт җитәкчеләрдә!
Җитәкчеләр аңлы, зирәк булса,
Ялгышларга һич тә юл куймас.
Уңышлардан башы да әйләнмәс,
Мир уеннан бер дә аерылмас!
Һәр нәрсәгә реаль, аек карар,
Бер пафоска гына таянмас...
Төп көч безнең аңлы бердәмлектә,
Таркауларны дөнья аямас.
Һәм Ватанга игелек итүдән тыш,
Кайгыртудан ил һәм халыкны,
Коммунистның бүтән мәнфәгате
Юк, булмады! Һәм бу бик хаклы!

## Дөнья иңләп...

Дөнья иңләп һаман йөри Ленин,
Я, кем әйтер аны үлгән дип?
Барча ирек даулаучылар сафы
Ал байракка аны элгән бит!
Ул аларга аң һәм рух бирә,
Акылларын ныграк үткенләп,
Киртәләрдә туктап калдырмыйча,
Алып чыга хәтәр үткелдән...
Йә, кем аны әйтер үлгән дип?
Ленинны бит тарих тудырган!
Бер гаделлек яклаучысы итеп,
Тарих аны үзе булдырган!
Шуңа тарих аны гел яшәтә
Яшәткәндәй ана баласын!
Шуңа тарих аны гел яшәртә
Яшәрткәндәй ана баласын!
Я, кем аны әйтер үлгән дип?
Инкыйлаблар һаман ул ясый!
Аның идеяләре магниты
Ныграк тарта эшче дөньясын!

## Фәннур Сафин

### Яңа таң

Мәңге истә тотып
Узган көннең
Даны сүнмәс батыр җаннарын,
Байракларын җилфердәтеп Казан
Каршы ала яңа таңнарын.

Халкыбызның сизгер әкиятләрен
Чынбарлыкка әверелдереп,
Килә таңнар кешеләрне назлар
Тылсым көче булган җыр кебек.

Чын коммунист сыман борчылганда
Туар көннәр өчен һәр кеше,
Могҗизалар иҗат итә-итә,
Килә, илем, мәңге яшисе!

Батырлыклар, матурлыклар белән
Чал тарихның бизәп һәр битен
Яшәр өчен, халкым, зур эшләрнең
Уртасына басып яшьнисең.

Иген кыры хәтле куанычлар,
Заманга тиң безнең уңышлар.
Үрләрдән таң булып карый-карый,
Көтә безне яңа бурычлар.

Шуңа күрә изүләрен чишеп,
Ачык йөзле якты Казаным,
Байракларын җилдә җилфердәтеп,
Каршы ала нурлы ал таңын.

## Гәрәй Рәхим

### Иген өчен, илең өчең

*КПССның Илеш район комитеты беренче секретаре Социалистик Хезмәт Герое Тәлгать Лотфуллович Рахманов*ка

Мин дә булдым Илеш якларында —
Европаның түгә таң ягы.
Җырлый анда башкорт курайлары,
Чыңлый анда татар тальяны.

Анда иген шавы илгә шаулый,
Күрдем анда шундый ир барын —
Зур максатка илтә якташларын,
Көрәш кыры итә кырларын.

Егерменче гасыр кешесе син,
Егерменче гасыр көчлесе.
Гаҗәп түгел сине олылавы
Туган илнең олы-кечесе.

Синең даның илләр буйлап йөри,
Чагылтауда тора чагылып.
Сөн сулары мәңге чылтырап агар
Яшьлегеңне синең сагынып.

Сине котлый сары иген кыры,
Базы буендагы каеннар.
Син батырсың Тимерханнар белән,
Көчле итә сине Каюмнар[1]:

Күзләреңдә тирән уйлар күрдем...
Синең күзләр моңсу да кебек.
Бераз моңсуланмый нишләсен соң
Алтмыш яшьлек дәртле ир-егет.

Уйлан, батыр, синең күзләреңдә
Якты моңсулыклар сүнмәсен.
Якташларың, «Иген, иле өчен
Моңлана ул!» — диеп сөйләсен.

Иген өчен, изге илең өчен,
Илеш өчен яндың, талмадың...
Мин дә булдым Илеш якларында —
Европаның аяз таң ягы.

---

[1] Башкортстанның Илеш районындагы атаклы колхоз председательләре Социалистик Хезмәт Герое Т. Нәҗмиев һәм Ленин ордены кавалеры К. Хабибов.

## Фаил Шәфигуллин

# ӨЙ САЛУНЫҢ НИЕ БАР...

**ПОВЕСТЬ**

## җа мәхәббәт



Күпме газапланып йөрергә мөмкин? Эңгер төшсен дә менә, я кичке уенга [illegible], я чишмәгә суга барганын сагалап торып, тотам да әйтәм. Тәслимә, мин сине яратам, дим. Кем белә, шәт ул да мине ярата торгандыр. Сөю турында кызлар башлап әйтмәс бит инде! Шулай булсын иде ул, җир йотсын, шулай булсын иде. Тәслимә урамга чыкканымны көтеп торсын иде дә, миләүшә чәчәге төсле шәмәхә зәңгәр күзләрен алсу танкеткаларына төбәп: «Рәсим, мин сине үлеп яратам бит, нигә күрмисең, нишләп шул кадәр игътибарсыз син?!» — дисен иде. Шунда мин аны, шунда мин аны... Төймәдәй түгәрәк борын очыннан, яки тиешлсә дә, ни өчендер алка киертелмәгән колак яфрагыннан үбеп алыр идем. Шорник Гыйззәт бабай әйтә, кызлар алар иреннәреннән үпкәнне яраталар, ди. Ай-яй! Тәслимәнең иреннәре бигрәк тә матур шул. Ничек инде үбеп рәнҗетергә мөмкин шундый гөнаһсыз, саф иреннәрне? Күршебез Хәбир сөйләгәнгә дә ачуым килеп бетә. Агыш авылы мәктәбендә укып йөргән елларда бик юаш, бик әдәпле, хәтта, әйтер идем, кирәгеннән артык әдәпле иде Хәбир. Ә хәзер әллә нишләде. Буйга да, әнисе әйтмешли, гернадир кебек үсеп китте, тазарды да. Хәбирне әйтәм, колак төбенә иплэп кенә берне бирмәсәң, әллә нинди сүзләр сөйли кызлар турында. Син Тәслимәңне караңгырак почмакка китереп кыс, сулый да алмасын, мәми авыз булып йөрмә, Гыйззәт бабай дөрес әйтә, кызлар алар атлар кебек, каты куллы егетләрне яраталар, ди. Хәер, башкаларны өйрәтергә генә оста ла Хәбир үзе дә. Беркөннәрдә завклуб Фирдәүсәне озата кайткан, ди. Иртәгесен Фәтхулла сөйләде. Фәтхулла бик үткен егет ул. Үзе кызлар белән йөрми. Ә үзе кичке уеннанмы, кинодanмы, кемнең кемне озатып кайтканын, кемнең кемгә гашыйк булганын энәсеннән җебенә кадәр белеп тора. Менә шул Фәтхулла әйтә, Фирдәүсә читәннең ишегалды ягында, Хәбир бу ягына баскан, үзләре болай сөйләшәләр, ди:

— Синең миңа сүзең бар, ахры, Хәбир? — (Монысы Фирдәүсә була инде).

— Сүз барын бар инде ул, — дип әйтә ди дә Хәбир, черт итеп чирәмгә төкерә, ди.

— Керәп сөйләш, читәннең бу ягына кер, — ди икән Фирдәүсә.

— Кергән чаклар да булыр әле, — дип әйтә ди Хәбир.

— Әллә күзең төштеме миңа, Хәбир? — дип сорый икән моннан Фирдәүсә.

— Күзем төшсә дә гаеп түгел, — дип әйтә икән Хәбир һәм тагын черт иттереп чирәмгә төкерә икән...

Ә менә мин алай булмам. Юкса, төн йокыларымны качырды инде бу Тәслимә. Чынлап та, болай оялып йөрергә ярамас...

· Туктасана, Тәслимә белән Гөлнур узып бара түгелме соң тәрәзә каршыннан? Җир йотсын, шулар. Кичке уенга чыгарга бик иртә бит әле. Кая баралар икән, ә?

Әле дә яхшы, әни кәҗә саварга чыгып киткән, урындыкны аудара язып, бер читкә тайпылганымны күрсә, әллә ни уйлар иде. Гармуныңны тезләрең өстенә куеп, башыңны гармуныңа салып, мәрткә китеп утыр менә! Бәлки әле Тәслимәнең, Рәсим күренмәс микән дип, юри безнең турыдан үтеп барышыдыр.

Кыюланып, тәрәзә янынарак бардым, яран яфраклары арасыннан урамга карадым. Кызлар туктаганнар, безнең өй түбәсенә текәлеп, көлешә-көлешә, нәрсә турындадыр сөйләшәләр иде.

Нәрсә күрделәр икән соң болар безнең өй түбәсендә? Шул кадәр текәлеп карап тормасалар. Әллә морҗабыз ауган микән, ходаем? Алай дисәң, учагыбыз төтен кайтармый, дулап кына яна. Коры чыбыкларның чатыр-чотыр килгәне бүлем такталары аша да ишетелә әнә.

Бер урында озак, бик озак тордылар сыман тоелды миңа Тәслимәләр. Моңарчы, моңарчы инде, ачуым бер килмәгәе, ата казга күкәй салдырып булыр иде... Уф, киттеләр.

Атылып урамга чыктым. Уңга-сулга каранып алдым. Бәхеткә каршы, урам буш инде. Юл читендә аунап яткан кирпеч кисәген урамның теге ягына тәгәрәтеп җибәрдем, үзем дә кирпеч кисәге артыннан атладым. Күрше-тирәләр күрә-нитә калса, аны-моны уйламасыннар, янәсе.

Барып бастым әлерәк кенә Тәслимә белән Гөлнур сөйләшеп торган сукмакка, үзебезнең өй түбәсенә күз сирпедем — кадалып кына киткере икән: баеп барган кояшның күз чагылдыргыч нурлары ишегалды ягындагы түбә ярыкларыннан кергән дә урам ягындагы ярыклардан чәчрәп чыккан. Безнең чормадан урамга уннарча пулемет ут яудыра, диярсең.

Менә нигә көлгәннәр икән Тәслимәләр. Менә сиңа мәхәббәт! Менә чап кызлар артыннан икенче! Авылда безнекеннән дә искерәк йорт юк икән инде, болай булгач. Хәбирләрнең дә әтиләре юк әнә, шуңа карамастан, олы йортларын кечерәйтеп, Нәфисәттәй әйтмешли, курчак өе ясап куйдылар. Ә безнең, безнең!.. Тәрәзә капкачлары, карнизләре матур үзенең. Әмма түбә-түшәмнәрен, тәрәзә араларын, нигезләрен адәм күзенә дә күрсәтерлек түгел. Моннан берничә ел элек, мин әле җиденчедә укып йөргәндә, эчтән калтыраса да, тыштан ялтырый иде, ичмасам. Быел инде, тыштан да калтырый башлаган.

Моңарчы ничек уйламый йөргәнмен соң мин өй турында? Яңгыр яуган саен әниенең чормага күмәч табаклары, тазлар, ләгәннәр тезеп төшүен күрә идем ләбаса. Кыш көне түшәм такталары бәсәргәне дә, идән астында бәрәңгеләр өшегәне дә онытылмаган бит инде.

Мин як-ягыма каранып алдым һәм тизрәк өйгә сыпырттым. Өйгә кергәч, шау чәчәктә утырган яраннар каршына барып бастым да, үз-үзем белән киңәшергә, планнар корырга тотындым.

«... Менә шулай, Рәсим агайне, иң әүвәле өй салырга кирәк. Аннары кызлар артыннан чапсаң да ярый.

Өй! Ләкин нидән башларга соң әле өй салуны? Әлбәттә, бүрәнәдән. Ә бүрәнәне кайдан юнәтергә? Станциядән яки урманнан, билгеле...»

Уйларымны бүлеп, ишек ачылды, бусага төбендәге сайгак шыгырдады.

— Җылы сөт эчәсең килмиме, улым? — диде әни, мич арасыннан кече якка узып.

— Әни, — дидем мин аның сүзләрен колагыма да элмичә, — кил әле монда.

Әнинең казан капкачын ачып ашка су өстәгәнеме, сөт салганымы ишетелде. Бераздан тагын сайгаклар шыгырдады.

Әни кыш көннәрендә өйрәнгән гадәте буенча, мичкә килеп сөялде, яргаланган, тамырлары бүлтәеп-бүлтәеп чыккан куллары белән ябык беләкләрен кысты.

— Әни, — дидем мин түшәмнең калҗайган такталарына ымлап. — Өебез беткән бит, өй салырга кирәк безгә.

Әни авыр итеп көрсенде, күрегe ачылган көе урындыкта җәелеп киткән гармунны өстәлгә алып куйды. Гармун шул чагында гүяки өй тагын сезгә, дип шыңгырдады.

— Син, улым, өй салырга дисең. — Әни яулык читен бөтерергә кереште. — Мин дә бик күп уйлыйм бу хакта. Быел гына түгел, атаң үләгәннән бирле уйлыйм. Үзенчә матур итеп салган иде дә бит, мәрхүмкәем, бу йортны. Үзе балта остасы булгач, бизәкләп сырлап эшләде. Яңа чагында кызыкмаган кеше юк иде дә соң... Туздык шул... Авыз тутырып ипи ашый башладык, биргәнеңә шөкер, ходаем. — Әллә картая инде әни: соңгы елларда алланы бик еш искә төшерә. — Өй турында сүз кузгатуыңны көткән идем, улым, рәхмәт. Ходайның кодрәте белән үсеп буйга да җиттең менә. Җиде класс белемең бар, колхозда җир җимертеп эшлисең. Аз булса да, мал асрыйбыз — сарыгын-кәҗәсен дигәндәй. Казыбыз да бик унган. Ел саен унике-унөч бәбкә чыгарып, шуларны исән-сау үстерә. Тагын килеп, тавык-чебеш. Налогларны киметкәне өчен хөкүмәтебезгә мең рәхмәт — аз булса да, янга акча калдырып була.

— Әни, — дидем мин түземсезләнеп. — Әни, безгә быел салырга кирәк ызбаны. Менә иртәгәдән тотынырга, белдеңме, иртәгәдән!..

— Әстәгыфирулла, улым, син ни сөйлисең?! Олыгайгач та чәче агармаган кешеләр турында, ул нигә картайсын, йорт та салганы юк аның, бала да үстергәне юк, диләр. Йорт салырга хәл кирәк бит, бик күп хәл кирәк... Нигә шул тиклем кабаланасың әле, улым? Өйләнергә җыенмыйсыңдыр ич? Әллә күзең төшкән кыз бармы?

Бетерде әни, үтерде. Авырткан сөялемә басты. Кызардым бугай кызаруын, шулай да сер бирергә ярамый.

— Сөйләмәсәнә, әни, тузга язмаганны, — дидем мин уңайсызланып һәм өстәлдәге гармунны шыңгырдатып кыстым. — Шул гына калган иде. Үзең беләсең, киләсе елга армиягә китәм. Нишләрсең бер ялгызың мондый өйдә.

Әни:

— Тукталe, улым, ашымны карап килим, — дип, кече якка әйләнеп чыкты да, карават читенә утырды.

— Син, улым, мин әйткәннәргә үпкәләмә инде, яшь чагында була торган хәлләр. Ә өй салуга килгәндә, мин үзем болай уйлыйм: иң әүвәле, бисмилла итеп, буаз башмак алыйк без. Тире җыючы Хәйрулла ярты бәясен түләсәгез, яртысын көзгә кадәр көтеп торам, ди ана. Бик кыйбат та сорамый бугай.

— Син әллә нәрсә сөйлисең, әни. Мин өй салыйк, дим, ә син башмак алыйк, дисең.

— Башмагын алсаң, өен салабыз да салабыз инде аның, улым. Үзең уйлап кара менә. Көз көне сарыкларны, казларны суеп сатабыз. Язга башмак бозаулый, сыер була. Бозавы бер хәзинә. Шуның янына сөте, мае, эремчеге. Буралык акча җыябыз, алла боерса, ничек тә киләсе җәйгә.

— Бүрәнәләрне быел алып, бурасын быел бурап куйыйк без, әни

— Әй, улым, бура бурап куйган белән генә түгел бит әле ул. Аның янына матчалыгы, әллә никадәр тактасы кирәк. Бурасын да тигенгә бурап бирмиләр бит аның. Ярый ла атаң үзе кул белә иде.

Уф! Яңа өй салу насыйп түгел икән болай булгач безгә. Күренеп тора, әни белән бәхәсләшүдән бер мәгънә дә чыкмаячак. Ни өчен шыпырт кына йөри дисәм, алдан ук ниятенә кереп куйган икән. Ә нишләп? Сыерлы булу да начар түгел инде анысы. Сыерлы кеше, ни әйтсәң дә, сыйлы кеше инде, тик менә өй салу гына бик озакка сузылачак.

Авызны пешерә-пешерә сөтле токмач чөмергәндә, әни һаман да әле ишегалдына кайтып күренмәгән башмакның сыер булгач сөт-май бирәчәген, маен сатып кына барсаң да, эремчеге-катыгы үзебезгә ашарга житәчәген, татлы бер төшен сөйләгән сыман, ярым елмаеп, хыялый тавыш белән тезде дә тезде.

Мин әнине артык шаккатмыйча гына тыңладым. Тәлинкәмне кутәреп, төбенә чаклы ялап куйдым да, рәхмәт әйтеп, урынымнан кузгалдым.

Әле караңгы төшәргә байтак вакыт бар. Әле Кизләү тавына менеп, чалгы белән ялмансаң, байтак кына үлән чабып төшә алам. Әнә бит, әни башмак тана алабыз, дип тора. Димәк, курмы күп кирәк булачак быел. Шушилә тулып килә инде анысы. Процентка бирелгән печәнебез дә кешенекеннән ким чыкмады.

Еракта, авыл артындагы басу иңендә бытбылдык кычкыра: «Хур булдык, хур булдык!» ди. Әйе, чынлап та хур итте мине бүген Тәслимә, әлек тә ояла торган идем күзенә карап сөйләшергә. Хәзер нишләргә инде менә?

Амбарга кереп, чалгыны кулыма алдым. Божралары буцаган икән— чөен ныгытып кактым, чалгының очын җиргә терәп, агач саплы беләү белән чаж-чож китереп янарга тотындым.

Янап бетергәч, йөзенә бармагымны тидереп карадым; Гали батыр пәкесе дә болай ук үткен булмагандыр. Мәгәр Кизләү тавына аягым тартмый иде бүген. Кизләү тавына менү түгел, капканы ачып, урамга да чыгасым килми иде. Чалгыны шушилә читеннән бүселеп торган печәнгә кададым. Амбар стенасындагы ярыктан шәфәкъ кызыллыгы төшкән иде, моңсу нурлар иске такталарны, җепсәләрне, шул җепсәләрнең иң өстәгесенә кыстырып куелган шома саплы бәләкәй балтаны яктырталар иде.

Балтаны кулыма алдым. Әтидән калган бердәнбер корал. Калганнарын колхозга сорап алганнар. Фермада терлекчеләр ызбасын салышырга да ярдәм иткән әтинең пычкылары, ышкылары, бораулары, каравыл өен төзәтергә дә, келәтләрне үзгәртеп корырга да.

Әти нинди эшләр майтарды икән бу балта белән? Үзе җиңел, үзе үткен. Балтаны тотып ишегалдына чыктым. Шәфәкъ нурлары сүнде.

Балтаны тотып йорт почмагына килдем. Нигездән алып кәрнизгә чаклы булган бүрәнәләрне күздән кичереп чыктым. Барысы да әти куллары. Ничек пөхтә өелгән. Бүрәнә башларын такта белән теккән. Тәрәзә капкачлары [illegible] анатларына охшатып ясаган.

Дөрес әйтә әни — [illegible] ында кәртинкә кебек булган шул бу өй. Хәзер аның түбәсе дә, тәрәзә [illegible] нигез бүрәнәләре дә [illegible] ртайган.

Балтаны т[illegible]
кадәр мендем дә тагын уйга калдым. Ызбасы [illegible]
булачак бит әле аның. Әти, мунча салырга хыялланып, нигезенә ташлар тезеп йөргән көннәрдә сугыш башланган. Мунча кайгысы онытылган. Ташлары әнә бүген дә, җимерелгән хыял харәбәләре сыман, җирдә аунап ята.

Миңа нидер әйтергә теләгәндәй, баш очында каен яфраклары шыбырдашып куйды.

Бу сукмак, бу каен, бу ташлар күргәннәр бит инде этине, әллә ничә мәртәбә күргәннәр...

Эңгер куера. Яртылаш җиргә иңгән ташлар агарыбрак киткәндәй булалар, каен мин белмәгән телдә нәрсәдер сөйли дә сөйли.

Балтаның салкын йөзенә бармагымны тидердем.

«Син эти кулларының җылысын тойгансың бит, балта! Аның уйларын тормышка ашырышкансың. Миңа да ярдәм ит өй салырга!»

## Егет кешегә ни кирәк?

— Хәят апа, Рәсимне уят әле, бүген люцерна җыярга барабыз.

Мөнәвәрә апа бу. Һәркөнне шулай кычкырып уза ул тәрәзә каршысыннан. Димәк, әле иртә. Димәк, әле тагын биш-алты минут төлдереп алырга вакыт бар.

— Ярар, ярар, Мөнәвәрә. Карале, әй, Мөнәвәрә, туктале, әйтергә дә онытып торам икән. Бүген башмак алырга барабыз бит без. Кич иртәрәк кузгалсын әле Рәсим, яме. Арба төбенә люцерна да салсын бераз. Коры арбага утыра да дангыр-доңгыр йөри, югыйсә. Бөтен холкы, бөтен кыланышы этисенеке. Булса да булыр икән бу кадәр!..

Мөнәвәрә апа бик ашыга иде, ахры. Ат, башмак, люцерналарның барысын бергә буташтырып бетерде. Соңгы сүз итеп:

— И яхшы булган ла, Хәят апа, мәйтәм, башмак алуыгыз, бер елдан гөжләтеп сыер саварсыз менә, и яхшы булган ла, — дип кабатлады. — Ярый, Хәят апа, уят Рәсимне.

Йокым ачылган иде инде. Сикереп торып киендем дә ишегалдына чыктым. Кәҗә белән сөзешергә әзерләнгән карт сарыкка карагач, көлеп җибәрдем. Мондый батыр сарык бездә генәдер, мөгаен. Тамагы ачса, гел абзар ишеге астын тырнап казый. Һәм үзе казыган чокырга башын тыгып ишекне өскә күтәрә — шылт итеп кенә ачылып китә ишек бигe. Күр инде, күзләрен ничек яшелләндергән. Башмак белән сөзешергә дә күп алмас бу акылсыз сарык. Башмак кәҗә түгел, башмак сөзешеп вакланмаячак инде ул моның ише ыбыр-чыбырлар белән, башмак акыллы булачак.

Әни, кәҗә-сарыкларны көтүгә чыгарган арада, ишегалдын себереп ташладым, абзарны чистарттым. Башмакка дигән почмакны тазартып, көл сибеп, коры салам җәеп куйдым.

Иртәнге чәйдән соң, өй түбәсе турында уйламаска тырышып, капканы ачтым, коймаларга, читәннәргә сыена-сыена гына дворга юл тоттым.

Каһәр, ни генә уйларга тырышсам да, уйларым үзебезнең өй түбәсе ярыкларына кереп югала да тора. Аннары Тәслимәнең астыртын елмаюы күз алдыма килә.

Хәбир «Маруч»ын җигеп тә куйган, арбасына менеп тә кунаклаган инә, Кизләү тавы итәгенә җыелган хатын-кызлар төркеменә таба китеп бара.

Ат җигүгә килгәндә, мин дә эт каешы ла аңысы. Биш-алты елдан бирле колхозның Карлыгач исемле иң шәп алашасын җигеп йөрим.

Аранда йөгән киертеп тә маташмыйм Карлыгачка — аркылы агачын алып куюга, алашам үзе теркелдәп чыга артымнан. Җир йотсын, эт белән бер. Тәртә арасына да үзе керә. Куллары булса, камытын да үзе кияр иде әле ул.

Атым акыллы, арбам тимерхут. Сбруйларым яңа, беләкләремдә көч-куәт ташып тора. Шуннан бүтән ни кирәк тагын егет кешегә? «Юләр Рәсим! Шуннан бүтән ни кирәк тагын, дигән булып торасың. Өй кирәк егет кешегә, сыер кирәк, әйбәт өс-баш кирәк». Кем әйтте бу сүзләрне? Синме, Карлыгач? Колакларыңны уйнаткалап, мине мыскыл итеп тор-

масана син дә! Киттек, әйдә. «Егете егет булса, ишеге кабык булса да ярый», — дигәннәр безнең борынгы бабайлар. Ә синең борынгы бабаң ишәк булгандыр әле, тикшереп баксаң. Араныңнан чыктың гына лабаса әле, хайван, нишләп ул якка каерасың? Кырга барабыз, люцерна җыярга.

Иртәнге салкын белән тау кадәр бер эскерт өеп куйдык та, көннә эсселәтеп, кигәвеннәр котыра башлагач, атларны басу читенә туарып җибәрдек, үзебез әрәмәлек буенда әбәт ашарга утырдык.

Хәбирнең күзләре иләс-миләс ялтырый иде бүген. Димәк, ниндидер бик мөһим сүз сөйлисе бар аның миңа. Югыйсә, ул ризыгын болай ашыгып чәйнәми, борынын да бертуктаусыз мышкылдатмый ул әйтәсе сүзе булмаса. Әллә Тәслимә турында бер-бер хәбәр ишетте микән? Курыкканга куш күренә, ди, әллә, югыйсә, Тәслимә: «Өйләре черегән Рәсимнәрнең, ничек яшиләр икән анда?» — дип сөйләп йөри микән.

Әмма сүзне шактыйерактан башлады әле Хәбир.

— Да, малай, бик тәмле булды әле бу бәрәңге кәлҗемәсе, ишеткәнсеңдер инде, озакламый колхозларны берләштерәләр икән бит.

— Берләштерсәләр ни.

— Тракторларны, комбайннарны колхозларга сатачаклар, ди. МТСлар да бетә икән.

— Бетсә ни.

— Без гомер буе шулай ат койрыгына карап йөрербез микән?

— Армиягә китәбез ич тагын бер елдан. Яз туганнарны быел ук чакыртачаклар икән комиссиягә.

— Без армиядән кайтканчы бөтен малайлар тракторист я комбайнер булып бетәрләр инде. Безгә тагын шул, атлар калыр. Шәһәргә сыпыртсак кына инде, белмим.

Хәбир, кулларын җилкәсенә кушырып куйган килеш, соңгы кабым ризыгын ашык-пошык чәйнәп йотты да минем янгарак күчеп утырды, сүзен дәвам итте:

— Син китмисең инде калага, беләм мин. Тәслимә китмәгәч, китмисең. Тәслимә дә бик китәр иде — әтисе Борһан җибәрми. Һе, Борһан Кукамай баласы булырга, алла язмасын! Әтисез яшәвең мең өлеш артык.

Юк әле юк, Хәбир һаман да иң кирәкле сүзне әйтми, һаман да суза. Мин дә дәшмим. Дәшәр идем, ачуым килми. Сөйләсен иде Хәбир, Тәслимә турында тагын сөйләсен иде. Әйтергә теләгән сүзен әйтмәсә дә, Тәслимә турында сөйләүдән туктамасын иде ул.

Хәбир рәхмәт төшкеренең теле бу юлы да мин теләгәнчә тибрәнде. Тиктомалдан гына:

— Чибәр шул Тәслимәң, ничек ташлап китмәк кирәк шундый кызны, — диде. — Кызганасың түлке син аны. Кызганма, кызлар алар кызганган саен ялындыралар. Берәр караңгырак почмакка китереп кыс та... Хәер, минем Фирдәүсә дә чибәр инде, ие бит, малай. Шундый моңлы җырлый, матур бии. Мин шундый иттереп китереп кысам Фирдәүсәне, сөякләре ничек түзә торгандыр мескеннең. Без Фирдәүсә белән рәхәтләнеп үбешәбез. Төне буе, таңга кадәр. Тәслимәне бер мәртәбә дә үпкәнең юктыр әле синең? Һе, үбәрсең! Борһан күрсә, колһу алланы укытыр...

— Нишләп булмасын, әллә ничә мәртәбә үбештек инде, ул үзе мине үбә, — дип ялганладым мин Тәслимәнең куш җиләккә охшаган иреннәрен күз алдыма китереп.

Хәбирнең күзләре әле һаман да сәер елтырый, борыны да мышкылдаудан тукталмаган. Тагын ни генә әйтәсе калды икән соң инде моның? Әһә, әһә, килеп җиттек бугай, ниһаять, Мәскәуский вокзалларга! Хәбир кирәкле сүзен әйтергә авызын ачты бугай.

— Да, малай! Ашадым-ашадым — бер якка да йокмады бу бәрәң-

ге кәлҗемәсе. Ишеттеңме әле быел МТСта бер айлык курслар оештыралар, ди. Уракка төшкәнче комбайнер ярдәмчеләре әзерлиләр икән, мин китәргә булдым.

Хәбирнең «китәргә булдым» дигән кискен сүзләрен ишеткәч, авызым ачылды да калды.

— Ничек инде китәргә булдың? Кем җибәрә анда сине?

— Һи, сорап торды, ди! Үзем китәм. Буш трудадинга селкенеп йөргәнче, кесә тутырып акча алырмын, ичмасам. Өс-башымны карармын.

— Ярый ла, колхоз җибәрсә...

— Һи, сорап торды, ди!

— Мин барыбер киталмим. Без бүген буаз башмак апкайтабыз. Киләсе язга бозаулый да сыерыбыз була.

Инде Хәбирнең колаклары тырпайды, авызы ачылып калды.

— Сыер?

— Сыер шул.

— Сыерыгыз булса соң! Безнең дә сыер бар ич, шулай да китәм. Башмагыгызны әниең карар әле, ул да колхозда эшли ич.

— Курмы аз безнең, курмы җыярга кирәк.

— Ә мин барыбер китәм. Тракторда, я комбайнда эшләмичә, ызба салырлык акча җыеп булмый, ди, әни әйтә.

Маңгаема салкын тир бәреп чыкты.

— Сезгә нигә ызба? Йортыгыз таза ич әле, — дип кычкырганымны сизми дә калдым.

— Булса соң! Олысын, шифер түбәлесен салабыз. Әтиле кешеләрнең борыннарына чиртәбез әле менә, әйтте диярсең.

Һм, һм! Алай! Эшләр әнә кая таба бара икән.

Шифер түбәле йорт авылда бер генә кешедә — Борһанда гына. Врачлар Борһанга инвалидность биргәннәр хәзер. Шуңа күрә кыш буе каравыл өендә кәрт сугып ята да, яз житәрәк Ерак Көнчыгышка китә. Врачлар аңа диңгез һавасы суларга кушканнар, имеш. Анда баргач, диңгез һавасы гына сулап утырмый, күрәсең, Борһан. Югыйсә, ике елда шифер түбәле, мәчет биеклеге нарат йорт житкерә алмас иде.

Ярар, Борһан Ерак Көнчыгыштан акча эшләп кайтсын, ди. Ә менә Хәбир Ерак Көнчыгышка барып диңгез һавасы суламыйча гына салырга җыена шифер түбәле йортны. Вәт, ичмасам, егет!

Мин Хәбирнең, тырпайган колакларына, таш маңгаена, елтыр күзләренә көнләшеп карадым.

Ә нишләп? Салгач-салгач, чынлап та, йортның шифер түбәлесен салырга кирәк инде безгә дә. Такта-мазар белән вакланып маташырга ничу. Такта түбәне ел саен буяп торырга кирәк. Буямасаң, мурпая. Ә саламны йортка якын да җибәрмим, исән булсам...

## Кияү чыкмый кызларга

Менә инде без Түбән авылның тире җыючы Хәйруллаларыннан башмак алып кайтып киләбез. Арба төбенә люцерна салуым бик әйбәт булды. Бер дә тарткалашмый «Йолдызкай» (тире җыючы Хәйрулла исем дә куша белми икән малларына, мин авыл башына чыккач ук исем табып өлгердем) люцерна умыртып каба да арба артыннан үз көенә тыраклый бирә. Мин дә кумыйм алашамны. Хәйрулланы әйтәм, яши бела — ел саен бозау алып кайта да икән базардан, шуны үстереп башмак итеп сата икән.

— Акчасын ике айдан түләп бетермәсәгез, карагыз аны, башмакны кире алып китәм, — дип кычкырып калды әле арттан, җитмәсә. Мин

аның урынында булсам, ике ел, алай гына да түгел, биш ел күтәр идем. Ни кирәк инде аңа тагын? Йорты патша сарае кебек. Каралты-курасына керсәң, әйләнеп чыгарлык түгел. Капкаларына эһ тә итми трактор кереп китәрлек. Никадәр сарык ишегалларында, сыер, ике бозау, кош-кортның саны-чуты юк.

Әнинең йөзе бу кадәр якты булганы юк иде бугай әле. Сөенеченнән сүзләрен дә юньле-башлы әйтә алмый хәтта. Күзе башмакта гына. Әле люцерна йомарлап каптыра «Йолдызкай»га, әле аның маңгаеннан сыйпый.

Хәйрулланы әйтәм, көзгә кадәр көтеп торам, көз көне мал-туарларыгызны, кош-кортларыгызны әвеш-тәвеш иткәч түләрсез, дисә, килешер дә иде әле. Ике айдан ничек юнәтербез икән соң без шул кадәр акчаны?

Әллә әни бөтенләй уйламый инде бу хакта? Әһә, авылга кергәнбез икән. Очраган кешеләр елмаеп: «Игелекле мал булсын, Хәят апа, рәхәтен күрегез», — дип теләк теләп узалар. Мин тупыл ябалдашларындагы карга ояларын күзәтеп кайтам. Үзем авыз эченнән генә җырлаган булам. Бернәрсәгә дә исем китми, янәсе, арба артыннан тыраклаган «Йолдызкай»га да, түбә такталары муртайган йортка да. Ике дөнья — бер морҗа миңа!

Тыкрык читендә Тәслимәләр өе ялтырап күренә. Ул якка бер генә күз ташлап алдым да карашымны тагын тупыл башларына юнәлттем.

Хәйрулланы әйтәм, ни дип ашыктыра икән соң шул кадәр? Башмакны кире алып китәм, имеш. Бер биргән әйберне кире алалармы инде, я?..

«Йолдызкай» бер дә ятсынмады безнең ишегалдын. Капкадан кергәч, шул буламы инде мин яшәячәк йорт-җир, дигәндәй, ягымлы гына итеп мөгерәп куйды. Аннары ашыкмый гына абзарга таба атлап китте.

Алашамны туарып кайттым.

Әни табын янында да башмак турында сөйләде, табак-савыт юганда да башмак турында сөйләде.

— Хакы кыйммәтрәк булды, дип курыккан идем. Шул хакка торырлык икән малкай. Бик акыллы, бик күндәм күренә. Иртә буаз булырга охшый. Мартлардан да калмас, бозаулар, аллаһы боерса. Хәере-насыйбы белән игелеген күрергә язсын инде, ходаем...

Башмак турында төне буе сөйләр, ахры, әни. Аны тыңлап торсаң... Өстәл янына барып утырдым да, лампаның филтәсен күтәрә төшеп, район газетасын кулыма алдым. «Байрак» колхозына электр керткәннәр. «Җиңү»гә дә. Эшләр болайга китсә, безнең колхозны да читтә калдырмаслар инде, шәт. Яңа өй дә салып җибәрсәң, электр дә керсә, шунда радиосы да сөйләп торса... «Яңалиф» колхозы комсомоллары терлек азыгы әзерләүдә тырышып эшлиләр...» Ә безнең «Маяк» комсомоллары? Хәер, бармы соң әле безнең авылда комсомоллар? Нигә булмасын? Без җиденчедә укыган елны Гали Нәбие клубта җыелыш үткәргән иде бит. Кемнәрдәндер взнос та җыйган иде. Безне дә комсомолга алырга вәгъдә биргән иде. Ләкин озак та үтми, Гали Нәбие Казагыстанга китеп барды. Ник бер генә җыелыш җыйсыннар шуннан бирле.

Армиядә керербез инде комсомолга, исән булсак. Күп калмады... Менә монда нәрсә язганнар тагын? «Станциягә цемент килде. Йөкчеләр кирәк. Түләү бушатылган вагоннар хисабыннан...»

Алай! Менә монысы кызык. Хәйруллага бирерлек акча эшләп кайтсаң, бер дә эчне төртеп тишмәс иде. Башмак өчен җаның тыныч булыр иде хет. Үзебезнеке, дип күкрәк киереп йөрер идең.

Хәбир МТСка китәргә планлаштырып куйган ич әле әнә. Ни өчен миңа да берәр ай станциядә эшләп кайтмаска ди? Китәм, җир йотсын, иртәгә үк китәм.

Әнигә иртә белән әйтермен. Югыйсә, нишләп алай, син уйлап чыгарасың инде тузга язмаганнарны, эшләрсең акча, хәстәрләп куйганнардыр анда сиңа, дип эчне пошыра башлый. Үзе дә йокламый аннан соң, мине дә йоклатмый. Тәвәккәл түгел шул мин. Тәвәккәл булсам... яратуым турында әллә кайчан әйткән булыр идем инде Тәслимәгә дә. Борын заманда бер егет: «Алты ай буе шундый яшертен йөрештек, кыз үзе дә сизмәде», — дип мактанган бит әле. Мин дә шуның кебек.

Бигрәк ямансу киче. Фирдәүсәнең ял көне бүген. Клубны ачмый. Хәер, клубка барып, гәжит-журнал актарып утырудан ни мәгънә? Домино уйнарга яратмыйм, шахмат-шашкага чират. Китапханәгә кереп, китап укысаң гына инде.

Шулай уйланып утырганда, капка тавышы ишетелде. Баскыч такталары шыгырдады. Өй ишеге ачылды.

Хәбир. Күңеле күтәренке, тавышы көр.

— Исән-сау гына торасызмы, Хәят апа? — дип әнигә сәлам бирде. Аннары минем янга узды.

— Башмак алгач урамга да чыкмый башладың инде әллә, күрше?

— Урамда трай тибәр вакытлар үткән инде.

— Армиягә киткәч сагынырсың әле авылны. Әйдә, ал гармуныңны, урам әйләнеп кайтыйк бер.

Урынымнан теләр-теләмәс кенә тордым, гармунны култыгыма кыстырдым.

— Әйдә соң, алайса...

Хәбирнең тавышы моңлы түгел. Шулай да «Алмагачлары», «Баламишкин» кебек кыска көйләргә ярыйсы җырлый ул. Миңа көеннән бигрәк Хәбир җырлый торган җырларның сүзләре охшый. Бер ишеләре шаян, бер ишеләре моңлы яңгыраса да, нәкъ кирәкле урында, тиешле кешегә төбәп җырлый Хәбир җырларны.

Бүген дә тальянымны берничә мәртәбә сузып-сузып, «Алмагачлары» көен эзләп табуыма, Хәбир, бер кулын минем җилкәгә салып, янәшә атлый-атлый, кычкырып җырлап җибәрде:

Үскән чакта үскән идек
Тал тамырлары кебек.
Үсеп җиткәч таралыштык
Кош балалары кебек...

Бу вакытта без Хәбирләр капкасы төбендә чатыр кебек җәелеп үскән пар тупыл яныннан үтеп бара идек.

Тыкрыкка борылгач, зәңгәр энгер эченнән колхоз хисапчысы Вәсимә апа йорты калкып чыкты. Вәсимә апаның шахтадагы малае маржага өйләнгән, дип сөйлиләр иде.

Хәбир мин сыздырган көйгә берничә мәртәбә: «Бакчасы-ы, бакчасы», — дип кабатлады да җырның соңгы өч юлын Вәсимәләр ихатасының буеннан буена җырлап барды. Кизләү тавын ай нурлары яктырткач, чираттагы җырын тулган айга багышлады.

Фирдәүсәләр турысына житәрәк, Хәбир берничә тапкыр тамак кырып алды. Җырын сузыбрак җырларга тырышты.

Әй, җанкаем, нихәл итим,
Кәләсең бит атларга.
шем кебек,
Салыр янган утларга.

Колхоз председателе Галимулла абыйлар яныннан узганда Хәбирнең нинди җыр җырлаячагын белгәнгә күрә, үзем уйнаган көйгә үзем үк:

Тау башы куак кына,—

дип суздым. Хәбир күтәреп алды:

Күпсенмәгез, күп тормабыз,
Без монда кунак кына...

Борһаннар йорты янына җитәрәк, гадәттәгечә, тез буыннарым калтырый башлады, ә гармун какмалары бармакларымны пешергәндәй тоелды.

Монда инде көн саен бер үк җырны җырламый Хәбир. Монда ул көн саен яңа җыр җырлый. Хәер, җырларның иске ләре дә яңа булып яңгырый Тәслимәләр турысында. Монда җырларның һәркайсы минем күңелне телгәли.

..Магазинга балык кайткан,
Мичкәләр юк тозларга,
Шту такуй безобрази,
Кияү чыкмый кызларга...

Мин башта Хәбир җырлаган җырның мәгънәсен аңламый калдым. Аңлагач, гармуным бер якка салынып төште. Җилкәмнән Хәбирнең кулын селкеп ыргыттым, үзен иңбашым белән биек коймага кысрыкладым.

Хәбир төнге буш урамны яңгыратып пырхылдады да караңгы тыкрыкка йөгерде. Тальянымны елата-елата, Хәбир артыннан чаба торгач, куып җиттем тәки. Йөгергән хутта колак артына томырдым — мәтәлеп китә китте. Гармунымны чирәмгә ташладым да... тотындык тәгәрәшергә, тотындык тәгәрәшергә! Ахырдан икебез дә алҗып, әлсерәп, чирәм өстенә җәелеп утырдык.

Инде мин шаркылдап көләргә керештем. Хәбир көлмәде, борынын мышкылдата-мышкылдата, айга карап утырган көе:

— Аерылышкач, сагынып сөйләрбез әле шушы кичләрне, малай, ие бит? — диде.

Бераздан икебез дә тынып калдык. Инеш буенда ялгыз каз кычкырды. Тау буендагы мунчаларның берсендә ут җемелдәп сүнде. Төн җиле кыр ягыннан әрем, серкәләнгән арыш исләрен алып килде, бакча буендагы шомырт яфраклары моңсу гына шыбырдаштылар, чирәм өстендә караеп яткан гармунның жиз бизәкләре алтын йолдызчыклар сыман җемелдәште.

Матур шул безнең авыл, их, матур! Дөньяның бер генә почмагында да юктыр мондый матур җир...

Хәбир өйләренә кереп киткәч тә, үзебезнең капка төбендә шактый озак басып тордым әле мин. Аннары урамның каршы ягына чыктым. Ай яктысында түбә тишекләре үтәли күренми иде. Төнне матурлаганы өчен генә түгел, авылдагы барлык йортларны да таза, төз, әкияттәгедәй серле итеп күрсәткәне өчен айга рәхмәт укыдым.

# Җенең дәшәдер

Таң беленүгә станциягә юл тоттым. Иңемдә иске букча, букчада чирек ипи, бер шешә сөт, биш йомырка. «Йөрисең шунда подрядка җон тетеп, колхозда гына басылып эшләмичә»,— дип әни тиргәп калды калуын. Әнидән гайре мине авылның эте дә күрмәде. Кизләү тавына туры сукмактан гына мендем. Күн итекләрем балтырларына кадәр чык суында коенды. Тау башына менеп җиткәч, авылга борылып карадым. Анда-санда, ишегалларында, тыкрыкларда казлар-үрдәкләр агарып күренгәли. Тәслимәләр ызбасын таллар каплаган. Хәбирләр морҗасыннан урлып төтен чыга. Нәфисәттәй ипи сала, ахры.

Хәбиргә дә әйтергә уйлаган идем кичә, станциягә барып акча сугып кайтыйк дип. Вакытында телемне тешләп калдым. Мөнәвәрә апа күзенә ничек күренерсең аннан соң. Үзең качкан гына җитмәгән, Хәбирне дә котырткансың, дип күзеңне ачырмас. Аннары, әллә уңам, әллә туңам бит әле: «Алга килми белеп булмый алдагы язмышларны...»

Арыш серкә очыра. Уракка төшәр вакыт та җитә икән инде. Ничә көн генә эшләп калырмын соң мин станциядә? Урак өстендә тегендә-монда йөреп булмас бит. Басылып колхозда эшләргә туры килер.

Таш юлга чыккач, бер машина килгәне күренде. Кул күтәрдем — туктады. МТС полуторкасы икән. Сәләх абый. Таныш кеше. Урак өстендә колхоздагы комбайннарга иләктер, полотнодыр, пычкыдыр — барысын да Сәләх абый ташый. Үзе әйбәт шофер, мәгәр кабинасына утырган кешедән допрос алып кинәнә инде. Шуңа күрә безнең як кешеләре аны Сорау Сәләх дип йөртәләр.

Эт оясыннан аз гына зуррак кабинасына кереп утыруым булды — тышы ертылып, картуз катыргысы ыржаеп торган кәпәченә майлы кулы белән баскалап алды да тотынды сораштырырга, тотынды сораштырырга, җавап биреп кенә өлгер.

— Ә-ә, син мени әле бу?
— Мин.
— Кая барасың таң тишегеннән?
— Барам әле шунда. Район үзәгенә булырмы, станциягәме.
— Нәрсәгә?
— Йомыш белән.
— Нинди йомыш?
— Тәк шунда, вак-төяк.

Сәләх үзе руленә ябышып юлга караган, үзе башы белән минем якка ымлый.

— Нәрсә ул?
— Кайда нәрсә?
— Букчада дим.
— Ипи, нәрсә булсын.
— Ничәнчедә укыйсың?
— Укымыйм хәзер, эшлим.
— Йөргән кызың бармы?
— Бар... әй, юк.
— Кайчан өйләнәсең?

«Бетерә бит бу мине, җәяү киткән булсам, болай ерак кебек тоелмас иде станция дигәннәре».

— Нигә эндәшмисең? Кайчан өйләнәсең, дим.

«Тел бистәсе, лыгырдык, сиңа нигә инде алары?»

— Кем кызы йөри торган нәмәрсәң?
— Әлмән бабайныкы.
— Кайсы Әлмән?
— Син белмисең аны, Кайбыч районында ул.
— Кошманнанмы?
— Түгел.
— Ябалактанмы?
— Түгел.
— Бәрле башыннанмы?

«Телеңә тилчә чыккыры».

— Кече Кайбычтанмы?
— Олы Кайбычтан.
— Кайсы урамда яшиләр?
— Түбән урамда.

— Ә-ә-ә, тегермәнче Әлмән кызымыни?

— Шул.

— Бер мәртәбә барып кайткан түгелме соң инде ул кияүгә?

Мин Сәләх абыйның соңгы соравын ишетмәгәнгә салышып үзем һөҗүмгә күчтем.

— Әле кайсы авылдан кайтасың, Сәләх абый?

— Никанорга бүрәнә алып кайттым.

— Бүрәнә? — дип кайтарып сорадым мин Сәләх абыйның авызына күердәй булып.

— Ие.

— Нинди бүрәнә?

— Нарат.

— Ә кайда саталар аны?

— Кузлаука затонына сал белән китереп саталар. Әллә сезгә дә кирәкме?

— Һәй, Сәләх абый, кирәкмәгән кая ул!

— Акчагыз бармы?

— Бераз бар инде.

— Бераз булса, бер машина бүрәнә апкайтып бирәм мин сиңа. Уракка төшкәнче түгел. Апкайтканга акча да алмыйм, бушлай апкайтам. Минем малайга гармун кирәк. Былтырларда сайлауга менгәч, синең теге җиз телле тальянына кызыгып кайткан. Теңкәне корытты инде тәмам. Шул гармуныңны минем малайга бирсәң, ярты буралык бүрәнә апкайтабыз сиңа... Яртысын инде көз көне, урак беткәч. Ризамы?

«Нигә болай шәфкатьсез кыланасың син, Сәләх абый? Әтинең эш коралларын сатып алып бирде ич әни миңа ул гармунны. Әти мәрхүм, урамда гармун тавышы ишетелгән саен, үзем өйрән[illegible]м инде уйнарга, исән-сау яшәсәм, улыма алып бирәм әле шул гармунка [illegible]ыкайны, өйрәнсен әле, дип әйтә торган булган...»

— Ризамы? — дип кабатлап сорады Сәләх абый.

— Ул гармунны... — дидем дә мин тотлыгып калдым. Инде юл аермасына җиткән идек. Сәләх абый машинасын туктатты. Мин, әни белән киңәшеп карыйм әле, дип, рәхмәт әйтеп, җиргә сикердем. Кулына каптачлы чиләк тоткан бер апа минем урынга — күне ертылып, пружинасы күренеп торган тар утыргычка менеп утырды. Кабина ишеге ябылып җитмәгән иде әле. Сәләх абыйның бер-бер артлы:

— Нишләп йөрисең чиләкләр күтәреп? Чиләгеңдә нәрсә? — дип сораганы ишетелде.

Машина кузгалып киткәч, тирә-ягыма күз салдым. Биек водокачка янында вокзал бинасы кызарып утыра. Тимер юл буенча складлар, конторалар тезелешеп киткән. Тупикка кертеп куелган шыксыз вагоннар арасыннан әйләнә-тулгана бара торгач, кычытканнарына кадәр мазутка буялган тар гына мәйданчыкка килеп чыктым. Берничә ир кеше көрәкләренә таянганнар да тәмәке пыскыталар. Алай, урысча сөйләшәләр икән болар, сер бирергә ярамый. Кулларымны чалбар кесәләренә тыгып, теш арасыннан гына читкә төкердем дә тегеләрдән:

— Здесь разгружает симет? — дип сорадым.

— Здесь, — диде җитен керфеклесе, тәмәке суырган көйгә күзләрен кыса барып. — Здесь контора. Иди, Нурулла там.

Нурулла дигәннәре дә җитен керфекле икән. Чәчләре бөдрә. Ак халат өстеннән кара халат киеп куйган. Бертуктаусыз кулларын бутый. Өстәлдәге кәгазьләрне күз иярмәс тизлек белән бер урыннан икенче урынга күчереп йөртә. Үзе өстәл каршында тезелешеп торган кешеләр белән сөйләшә, шул ук вакытта колак артына кыстырылган карандашын алып, өстәл буенча әле теге, әле бу якка шуышкан кәгазьләргә ниндидер тамгалар төшерергә, нәрсәдер теркәп куярга, ниләрдер язарга да өлгерә.

— Синең... тәк... исемең? Синең түгел. Синең? Син бригадир булырсың, Хәйруллин. Язып куйдык. Ишекне ябыгыз әле. Син, почмак каравылчысы, чыга тор. Көрәкләр бирдем. Тачка складта. Синең фамилияң? Нәрсә карап каттың, сиңа әйтәм. Аю биетмиләр ич сиңа монда. Фамилияң ничек? Мәнә бирегә кулыңны куй.

— Кемгә әйтәсез? — дип сорарга мәҗбүр булдым мин Нуруллаңың карашы йөземдә бер мизгел дә тукталып тормаганга аптырап.

— Сиңа булмыйча, озын койрыклы җенгә әйтмәм тагын. Фамилияң ничек? Мәнә монда кулыңны куй, Якимов бригадасында эшләрсең. Әнә ул, ишегалдында тәмәке тарта. Нигә әйтергә кирәк, ябыгыз ишекне. Вагоннарны бушатып бетергәч, идәннәрен, стеналарын кырып себермичә, сәмән турында авыз да ачмагыз. Фамилияң?..

Почмакка сөяп куелган көрәкләрнең иплерәген сайлап алдым да житен керфекле агай хозурына килдем.

— Меня к вам послали, — дидем.

— К нам так к нам, — диде житен керфекле агай, минем тетеп урысча сөйләшкәнемә исе китми генә.

Боларның беренче мәртәбә генә бушатулары түгелдер, күрәсең, цементны. Вагон йозакларын шалтыр-шолтыр китереп кенә ачып ташладылар, трапларны да күз ачып йомганчы беркетеп куйдылар.

— Ташыйсыңмы, төяп торасыңмы? — диде миңа агайларның озын буйлысы, кылыч борынлысы һәм цементка буялырга өлгергән иске пилоткасын басыбрак киеп куйды.

— Миңа вҫяровно.

Шулай булмый тегә. Көрәк тә тоткан бар, урманнан тачка белән утын да ташыган бар.

Бер кыенлыгы да юк икән лә цемент бушатуның. Якимов агай белән мари егете алмаш-тилмәш төяп торалар. Без исә кылыч борынлы агай— Кечакау Алешасы белән тачкаларны трап буенча дуылдатып йөртәбез. Тачка тартәләрен тигез тотсаң, йөгең үзеннән-үзе төшә. Төшеп житкәч йөгеңне әкрен генә бункерга аударасың. Вагонга менгәндә инде буш тачка...

Тирләтер инде анысы. Күңел биреп эшләгәч, колхоз эше дә тирләтә. Тирләтүенә дә, беләкләрне тартыштыруына да түзәр идең әле анысы, — тузаны бик каһәр икән цементның. Туздырмаска тырышып төясәләр дә, сакланып кына бушатсаң да, ургылып өскә күтәрелә, күзләргә, борын тишекләренә, теш араларына тула. Эшли башлаганыбызга ярты сәгать булды микән, юк микән — вагон белән склад арасын карасу тузан болыты каплады. Кешене ике адымнан таный алмыйсың. Үзебез таштан катырып ясаган сыннарга охшап калдык. Кайсыбыз Якимов агай, кайсыбыз мари егете, кайсыбыз Алеша, кайсыбыз мин — шайтан да аермас. Ташыйбыз-ташыйбыз — кимеми цемент вагонда, ташыйбыз-ташыйбыз — сулыш алу һаман-һаман авырлаша; ташыйбыз-ташыйбыз — авызда бер дым калмады. Күз төпләрен дә цемент ачыттыра, иреннәрне дә цемент кисә. Эш арасында цемент болыты аша кояшка күз салдым — мунча пары эчендәге сукыр лампа кебек кенә. Үзара сөйләшмибез диярлек. Һе, сөйләшерсең, ачарсың авызыңны! Тамак төбеңә бөке булып утырырга гына тора цемент.

Тачкаларны санап йөртә башладым. Илле жиденче тачканы алып төшкәндә сөрлегеп егыла яздым. Тачка тәгәрмәче трап читенә төшеп китте. Алеша агай тотып калмаса, үземне каерып ата иде өрәңге тартә.

Анысы, кеше түзә, мин дә түзәм инде. Тирләтмәгәе, тирләтсен, күзләр дә күрмәсен, муен да кычытсын, колаклар да ишетмәсен. Башлаган эшне ярты юлда калдырып китә торган гадәтем юк минем. Кими башлады ич, әнә, цементы да. Эшләгәч, эш карулашамы соң? Карулашмый, билгеле.

Тагын бер-ике тачка алып төшеп бушатам да водокачкага барып су эчәм, башыма салкын су коям, дип юанып йөргәндә, (әллә колагыма ишетелде инде) кемдер миңа кычкыргандай тоелды. Туктап, тыңлап тордым. Җенең дәшәдер, ди минем әни андый чагында. Цемент бушатасың килми синең менә шуңа күрә котырта җенең.

Тачканы җилтерәтебрәк этеп киттем. Кычкыралар инде. Җир йотсын, кычкыралар. Цемент болыты аша тавыш килгән якка текәлеп карадым. Атка да, сыерга да охшашлы карамчык шәйләнә. Әһә, җигүле ат икән — авызлык тимере чылтырады, арба тәгәрмәче шыгырдады. Ул арада тагын бер карамчыкның аттан аерылып болайга таба килгәне күренде. Килә-килә мин аның ир кеше икәнлеген абайладым. Һәм бары тик трап янына килеп җиткәч кенә танып алдым. Галиулла абый ич.

— Нинди җәһәннәм базына эләктем, дисәм, цемент бушаталар икән, понимаешь. Ат булып ат чыдамый. Адәм ничек түзә монда? Фу...

Галимулла абыйның да өсте-башы, каш керфекләре цементка буялып өлгергән иде инде.

— Рәсим, син бит, — диде ул, ирен очлары белән як-ягына төкергәләп. — Мунча пәрие булгансың чистый, ай-яй. Ташла әле тачкаңны, чыгыйк әле моннан, сөйләшик әле, әйдә.

Мин Якимов агайга карадым. Ул, бар, дигән мәгънәне аңлатып, кулын селтәде.

Тузан стенасының теге ягына чыгуга, энә күзе юанлыгы гына калган сулыш юлларымнан үпкәләремә саф һава сызгырып керде. Ат тире катыш люцерна исеннән җаннарым рәхәтләнеп китте. Цементының да кирәге юк, башмагының да, дип уйладым мин күзләремне ияген тәртә башына ышкып торган Җирән Кашканың акыллы күзләреннән аера алмыйча, — кайтам да китәм Галимулла абый белән.

— Эш күп, понимаешь, — диде Галимулла абый, Җирән Кашканың аркалыгын рәтли-рәтли. — Районнан кайтыш менә. Андин ары августта яңгырлар буласы икән. Уракны тиз тотарга кушалар. Әйдә, утыр. Мөнәвәрә апаң шалтыратты. «Карлыгач»ың сагынып көтә икән анда сине.

Аны-моны дәшмичә генә тарантаска менеп люцерна эченә кереп чумдым.

— Фу, — диде Галимулла абый тарантас өстендә бетерелгән тузанны куллары белән кугандай итеп. — Кагып кына бетәрлек түгел икән синең монда. Кулдә коенып чыгарсың.

Дилбегә очын бер генә селтәп җибәрде Галимулла абый — Җирән Кашка йөгерү тәмен белгән атларга гына хас кутәренкелек, җиңеллек белән юыртып китте.

Тарантас рессорлары арган тәнгә рәхәтлек биреп йомшак кына тибрәнде. Озакламый станция ташкүмер төтеннәре, цемент тузаннары артында калды.

— Мөнәвәрә апаң сөйләде, кетәсеңгәр башмак алгансыз икән, — дип сүзгә керешге Галимулла абый урман полосасы буена җиткәч. — Анысы әйбәт булган, курмы белән ярдәм итәрбез. Ә менә киңәшмичәнитмичә, әниең сүзенә колак салмыйча, станциягә чыгып сызуың бер дә әйбәт булмаган. Нурулладан кесә тутырып акча алып кайта, имеш, бу. Бирер Нурулла! Синең ишеләрне генә түгел, станция юлында йөри-йөри каешланып беткән агайларны да төп башына утырткалый әле ул. Хәйрулла күпме котәргә булды соң?

— Ай ярым, ди.

— Шунлык кына акчагыз бардыр ич инде?

— Ызба искергән безнең, Галимулла абый, бура алып куймакчы идек.

— Соң, урак беткәч, Кайбыч кардонына барып карарсың менә, анда яңа делянка ачканнар.

— Кайбыч кардонындагы бүрәнәләрне бер дә мактамыйлар шул. Галимулла абый. Булгач-булгач, нарат бүрәнә аласы иде.

«Нарат» сүзен ишеткәч Галимулла абый гына түгел, Жирән Кашка да колакларын тырпайтты.

— Нинди нарат тагын?

— Кузлаука затонына китереп саталар икән. — МТС шоферы Сәләх абый Агыш авылы Никанорына төяп кайткан әнә.

— Ну, ну, — дип әллә атына, әллә миңа эндәште шунда Галимулла абый.

Бераз сүзсез бардык.

Сүзнең дәвамыннан аңладым: Галимулла абый миңа эндәшкән булган икән.

— Ну, ну! Монысын кем белән киңәштең инде?

— Кеше апкайтканны без дә апкайтырбыз әле, — дидем мин Галимулла абыйга үпкәләбрәк.

— Ну, ну, — дип кабатлады Галимулла абый башын селкеп. — Кем, апкайтмыйсың, ди сиңа. Төнге эш караңгы эш, ләкин, шуны гына искәртеп куймакчы булам. Әнә күл буена килеп җиттек, понимаешь, коеныл чык та төштән соң люцернага, аңлашылдымы?

— Аңлашылды, Галимулла абый.

— Аңлашылса, шул. Мин киттем. Ерак калмады, җәяү дә кайтып житәрсең.

Озак, бик озак карап тордым мин Галимулла абый артыннан. Киң кара дуга, тузгып барган кызгылт яллар, тарантас өстендә тирбәлгән юан гәүдә, калын җилкә, олы башка килешле генә чәпәп куелган кәпәч...

Күл өсте тып-тын. Галимулла абый да ышанмый миңа. Чукынсын, җәл түгел гармуны да. Сәләх абый кире уйламаса, тотам да тәвәккәллим Кузлаука затонына.

## Өй салу шуннан башлана

— Хәерле юл гына булса ярар ие, ярабби, — дип озатып калды безне әни.

Бүрәнә төяшергә Түбән урам егетләре Исхак белән Нурисламга әйттем. Рәхмәт, тыңладылар. Хәбир чакырмыйча ук кереп житте.

Кичке ашны аннан-моннан гына капкаладык та машина янына чыктык.

Молодец Сәләх абый — прицепның шәбен тагып килгән. Арканнары да ипле. Күренеп тора, бүрәнә ташуның рәтен белә кеше.

Машинаны кабызып кузгалып киттек дигәндә, капкада әни күренде. Ашыга-ашыга килде дә кулындагы төенчеген кабина тәрәзәсенә тыкты.

— Карыныгыз ачар, мә, ал әле... Аннары, улым карап кына йөрегез инде, берүк. Аягыгыз-кулыгыз бүрәнәгә кысылмасын. Акчаңны эчкә тыктыңмы?

— Тыктым, әни, тыктым.

Бала-чагалар читкә тайпылды, машина җиңел генә гөжләп тизлеген арттырды. Артта кузов капкачлары, прицеп терәкләрен бәйләгән юан тимер чыбыклар шылтырады.

Менә Тәслимәләр турысыннан да узып киттек. Суга төшкән булган, ахры, Тәслимә — ачык капка авызында ак чиләкләре, ак бөрчекле зәңгәр көянтәсе, үрмичә генә иңнәренә туздырып җибәргән дулкынлы чәчләре, алсу танкеткалары чалынып калды.

Күрде микән безне Тәслимә? Тәслимә белән күптән очрашканыбыз юк инде күзгә-күз, ай-һай, бик күптән. Соңгы мәртәбә кайчан очраштык

соң әле? Сабан туеннан кайтканда бугай. Шулай шул, Мамадыш Сабан туеннан кайтканда. Мин Карлыгачны җигеп барган идем. Арба тулы яшьләр. Хәбир дилбегә тоткан. Мин гармун уйныйм. Кызлар-егетләр генә түгел, арбадагы яңа чабылган хуш исле печән дә, печән арасыннан елтырашып күренгән каен җиләкләре дә җырлыйлар сыман.

Тәслимә минем уң ягыма туры килде. Әллә үзем туры китердем микән? Танкеткалары юл буендагы зәңгәр чәчәкләргә орынгач, Тәслимә матур аякларын арба астына яшереп тора. Кайчагында сиздерми генә кулымны Тәслимәгә табарак сузам. Кулым Тәслимә беләгенә орынгач, бармакларым миңа буйсынмый башлый, гармун тавышы акрыная. Тәслимә дә сизә сыман шундый чакларда минем сәер халәтемне. Яңакларындагы алсулык куера, күзләре тәгәрмәч эзләренә төбәлә. Үзе, гармун уйнарга комачауламыйм дигән сыман, читкәрәк авышып утыра. Акрын гына җырласа да, башка кызларныкына караганда матуррак Тәслимәнең тавышы.

Барысы да әле кичә генә кебек. Барысы да күз алдында. Шул көнне Тәслимә иптәш кызларына кичке уенга чыгаргә вәгъдә бирде. Үз колакларым белән ишетмәсәм, ышанмас идем. Чыгам, кызлар, чыгам, диде. Ә үзе чыкмады. Кич, өйләргә ут алынгач, әллә ничә урадым Тәслимәләр турысыннан. Бик якын килеп булмады, хәер, тәрәзәләренә — капка төбендә ярты төнгә кадәр Борһан йөткергәләп утырды...

— Синнән сорыйм ич. Саңгырауландыңмы әллә?

— Ә? Нәрсә сорыйсың, Сәләх абый?

— Гармунны әйтәм. Уен-муен булмасын, әйткән сүз — аткан ук. Юлыбыз уңса да, уңмаса да бирәсең минем Хәмискә гармуныңны. Гармунны әйтәм, бирәсеңме?

— Бирәм, дидем бит инде, Сәләх абый.

— Син уйлама теге... раз машинада эшли дә теләсә кая куарга ярый икән моңа машинаны, дип. Гараж мөдирен майларга кирәкме?

— Кирәктер инде, Сәләх абый.

— Механикны ризалатырга кирәкме?

— Кирәктер инде, Сәләх абый.

— Әниеңә әйттеңме гармунга килешкәнне?

«Кайткач та өлгерермен әле әйтергә».

— Әйтми теге, кабат-кабат әйттем, биш куллап риза булды. Болай да туеп беткән иде инде тавышыннан.

— Бүрәнә булмас, дип куркасыңмы?

— Курыкмыйм.

— Алайса, нигә сөмсерең коелып бара?

— Болай гына.

— Гармуныңны кызганасыңмы?

— Кызганмыйм.

«Шулай да әйбәт дус иде гармун. Күп кайгы-сагышларымны уртаклашты ул минем. Кирәк чагында елатты, кирәк чагында юатты. Дусны бүрәнәгә алыштыргач, әшәке егет инде мин. Ихтыяр көчем дә шунын кадәр генә икән, җитмәсә. Бер вагон цемент бушатырга түзмәгәч, сөйләп торырга ничу. Минем кебек җебегән егеткә түгел ул андый әйбәт гармун. Шул кирәк миңа...»

— Кызганма шул. Сиңа барыбер тиздән армиягә китәсе. Син киткәч күгәреп кенә бетә ул монда. Ә минем малай гармун дип колак итемне ашады. Синең гармун тавышы безнең авылга да ишетелә бит, әйткәннәре бармы?

— Юк.

— Әллә гармуның шәп, әллә үзең шәп уйныйсың инде шунда. Алсын әле малай, уйнап карасын. Рәт чыгарлык булса, бер-ике елдан баян алып бирермен.

Бишбатман астында яңгыр явып үткән икән — машинаны уңга-сулга чайкарга тотынды. Сәләх абый ертык картузлы кәпәчен басыбрак киде, рульгә ныклабрак ябышты.

Пычрак юл ничек кинәт кенә башланса, шулай ук кинәт бетте дә. Фаралардан сузылган нур көлтәсенә чакрым баганасы уелып керде, алда ташлары бодай кабартмаларыдай күперeп-күпереп яткан шоссе күренде.

Шоссега җиткәч Сәләх абый башын тышка чыгарып кузовтагыларга кычкырды.

— Әй, сез! Җаныгыз бармы? Коелып калмадыгызмы?

— Калмадык, калмадык! Әйдә, куала! Газуй! — дип гөрләштеләр егетләр.

Кузлаука юлына борылгач, безгә сыртына тау кадәр бүрәнә төягән «Урал ЗИС» очрады. Моторы елый, рессорлары шыгырдый.

— Күрдеңме? — диде Галимулла абый әлеге машинаның прицебы кабина белән тигезләшкәч. — Вәт төягәннәр...

Йөрәгем дөпелдәп тибәргә кереште. Күңелдә, куәтле «Урал ЗИС» безгә насыйп бүрәнәләрне төяп кайтмыймы икән дигән борчу кузгалды.

Акрын барабыз бугай ла. Әллә машинасын җәлли инде Сәләх абый шунда. Болай кыймылдасак, төн уртасына да барып житә алмабыз.

Ниһаять, шоссе бетте. Машина, тормозларын сызгыртып, тау астына юл алды.

Әле дә ярый, монда яңгыр яумаган, йөксез дә мена алмас иде машина мондый текә юлдан.

Тормозларны зар елатып, нур көлтәләре белән төпсез караңгылыкны капшый-капшый төштек тә шулай, ниндидер комлы-ташлы юл аермасына килеп кердек. Машина туктады. Фара утлары сүрәнләнде.

— Килеп җиттек, — диде Сәләх абый кабина ишеген ачык тоткан көе. — Дальше ярамый, дальше җәяү төшәбез.

Машинадан чыктык. Егетләр дә җиргә сикерешеп төштеләр. Тирә-як тып-тын. Караңгы бушлыктан салкын җил өрә.

Шактый җир киткәч, юл тигезләнде, аяк астында ташлар шыгырдавы кечәйде, су чупылдавы ишетелде, әле тегендә, әле монда тәмәке утлары җемелдәште.

Бераздан күзләребез караңгылыкка иялəшеп житте бугай — якында гына чем кара су көзгесе ялтырап алды да шунда ук тагын соры томан эчендә калды.

Тәмәке көйрәтә-көйрәтә, гәпләшеп торган кешеләр янына бардык.

Сәләх абый монда күптән үз кеше, ахры — килеп житү белән ярым татарчалап, ярым чувашчалап сүз катты:

— Абани, Чтепан пиччә?

— Абан әле, Сәләк туган.

— Киләләрме?

— Килүен киләләр дә, — дип караңгы Идел ягына борылды кыска буйлы, төп кебек юан гәүдәле Степан пиччә. — Пиде хаклы сорыйлар мертәтләр.

— Күпме сорыйлар?

— Берсе пиллек сом диер.

— Алучылар бармы?

— Әле генә бер машина төяп киттеләр. Агышлар диер.

Сәләх абый боларга кабат сорау биреп маташмады, икенче төркемгә таба атлады. Ләкин барып житә алмады — Идел ягыннан пыты-пыты мотор тавышы ишетелгәч, лып туктап калды, минем җиңемнән тартты.

— Мотор тавышымы?

— Шулай бугай.

— Акчаң готовыймы?
— Монда карагы ич, ничек акча саныйсың?
— Фонарьлары бар аларның. Иллешәр сум сорасалар да аласыңмы?
— Алыйммы соң?
— Кесә ягың ничегрәк?
— Егерме-утыз бүрәнәлек рәт бар.

Мотор тавышы якынайды. Соры томан эчендә әллә нинди күләгәләр чайкалды. Аннары яр буена сузылып көймә борыны килеп чыкты. Көймәдәгеләр барысы да башлыклы кожаннар кигәннәр, ничә кеше икәнен әлегә аерып булмый иде.

Көймә ярга килеп җитәрәк, пыты-пыты килеп борылды, туктагандай тирбәлеп торды һәм ярга орыныр-орынмас йөзеп китте.

Шунда гына мин көймә артына тагылган бүрәнәләрне күреп алдым.

Кожанлы кешеләрнең берсе нәкъ безнең турыда ярга сикереп чыкты. Кулындагы бауны тарта-тарта, яр буенча йөгерде. Бүрәнәләр йөзеп килгән хутта бер-берсенә ышкылып, борыннары белән сөзәк ярга шуышып менделәр.

Көймәдән тагын ике кеше чыкты. Аларның берсе, кесә фонаре яктыртып, безнең йөзләребезне, буй-сыннарыбызны карап алды да якынрак килде.

— Утызны алып килдек. Унбише монда, унбише инеш тамагында. Алсагыз аласыз. Алмасагыз... бүген соңгы көн. Юлны бикләделәр.

— Ничә сумнан бирәсез? — дидем мин алгарак чыгып.

— Шул инде. Үз бәясе. Алтмышар сум.

— Йөз түгелме тагын? — диде Сәләх абый ачулы тавыш белән.

— Товарны карагыз сез башта, аннары әйтерсез. Пароход ясыйлар мондый бүрәнәләрдән бик беләсегез килсә. Судострой дип атала ул.

Кожанлы кеше шулай диде дә Степан пиччәләр төркеменә таба кузгалды.

— Алыйк, Сәләх абый, — дидем мин каушый-каушый. — Икенче, чынлап та, әллә китерәләр, әллә юк, алыйк. Әй, абзый кеше, туктале, алабыз.

Кожанлы кеше туктады, иптәшенә эндәште:

— Коля, трави!

Көймә хуҗалары ни өчендер бик ашыгалар иде. Үзара мыгыр-мыгыр нәрсәдер сөйләшеп алдылар да безнең янга килделәр.

— Әйдәгез, инеш тамагына кайсыгыз бара?

Инеш тамагына Нурислам белән Хәбирне җибәрдем.

Үзем мондагы бүрәнәләрне санап чыктым.

Ул арада Хәбирләр дә килеп җитте. Анда да шундый ук юан-юан нарат бүрәнәләр икән.

Кожанлы кешеләр салны бәйләгән бау очын Сәләх абый кулына тоттырдылар.

— Ну, старик, давай, монет гони, бүрәнәләрнең рәхәтен күр, — диделәр.

— Хаҗәйн мин түгел, менә хаҗәйн, — диде Сәләх абый, минем якка ымлап.

— Ә-ә, бәләкәй булса да, уңган егет икән, товарның асылын эләктерде,— дип мине мактап алды көймәчеләрнең берсе.— Әйдә, егет, хисапны өзик тә, без сине белмибез, син — безне.

Кесә фонаре яктысында көймәчеләргә акча санап биргәндә кулларым калтыранды. Юк, әнинең башмак өчен тире җыючы Хәйруллага түләргә дип җыйган акчасын кызганудан түгел, дулкынланудан, тыелгысыз шатлыктан...

«Менә бит, исән-сау алып кайтып җиткерсәк, ярты бурага җитә яза. Өй салу шуннан башлана инде ул».

Ашыгалар иде шул, бик ашыгалар иде кожанлы кешеләр. Акчаны да бер генә мәртәбә санадылар. Кай арада көймәләренә сикереп менделәр, кай арада моторларын кабыздылар.

Күз ачып йомганчы, көймәне караңгылык йотты, мотор тавышы ераклашты...

Әллә тагын әйләнеп киләләр инде? Еракლашмый ич мотор тавышы, киресенчә, якыная.

Шул чагында Идел ягыннан күз камаштыргыч ут көлтәсе сузылды һәм шунда ук сүнде. Без, су читенә үк килеп аңлы-минле торган арада, ут тагын кабынды. Көймә моторы гына түгел бугай монысы — бик яман дөпелди...

— Катер, катер! Качыгыз! Китегез ярдан! — дип кычкырдылар безнең артта кемнәрдер.

Китәргә? Кая китәргә? Үлсәм үләм, бүрәнәләрем яныннан бер адым да китмим.

Катер дигәннәренең прожекторлары бик зәһәр икән — күзне сукырайта да тора, иблис.

Зур кара көймә су читенә килеп туктады. Прожекторлар уты ташлы ярны, су өстендә тирбәлеп яткан гәрәбәдәй сары бүрәнәләрне яктыртты.

Башларына фуражкалар, өсләренә ялтыр кара плащлар кигән кешеләр сал янына килгәндә, мин юеш арканны кулларыма чорнап тоткан килеш, яр читендә чүгәләп утыра идем. Тирә-ягыма күз салдым — берүзем калганмын.

Болар бик ачулы кешеләр иде. Үзәкләргә үтеп, бәгырьләрне телә иде аларның сораулары.

— Калганнарыгыз кайда?

— Белмим.

— Кем алып чыкты монда бүрәнәләрне?

— Белмим. Киттеләр алар.

Фуражкалы кешеләрнең яшьрәге минем кулдагы аркан очына үрелде.

— Бирмим! Минем бүрәнәләр алар, — дип кычкырдым мин прожекторлар яктысында тагын да карансыланып күренгән яр буен яңгыратып.

Тегеләр кычкырмадылар, тартышмадылар. Усал итеп көлделәр генә.

— Ничек синең бүрәнәләрең? Каян алдың? Документларыңны күрсәт әле безгә рәхим итеп.

— Документларым юк минем, — дидем мин еларга җитешеп. — Сатып алдым мин бу бүрәнәләрне, акча түләп сатып алдым.

— Ә без сиңа теге яктан урлап чыккансың, дибез. Завод затоныннан урлап чыккансың, белдеңме? Хәзер менә шул хакта акт төзибез, үзеңә дә безнең белән барырга туры килер.

Мин бөтенләй югалып калдым, ни әйтергә дә белмәдем.

— Митя, бер партиясен таптык, — дип кычкырды ул арада фуражкалы кешеләрнең өлкәнрәге.

Катердан беләк юанлыгы тимер аркан сызгырып төште. Фуражкалы кешеләр озын балтырлы резин итекләр белән шапор-шопыр суга керделәр дә салны, күз ачып йомганчы, тимер арканга эләктерделәр.

— Син урламаганын беләбез, — диде өлкәнрәге ярга чыккач. — Тик барыбер урланган бүрәнәләр болар. Теге яктан пароход тарттырып килерләр монда? Ә син алырсыңмы? Рәхмәт әйт әле, үзеңне алып китмибез.

Катер кузгалды, трос тартылды. Бүрәнә башлары ком ерып суга кереп беттеләр дә, артларыннан ямьсез эзләр калдырып, ярдан еракლаша башладылар.

Мин салга бәйләнгән юеш арканны әле һаман да җибәрмәгән идем — очып диярлек суга кереп киттем. Тездән кердем, бил тиңентен...

Шул чагында каяндыр сыегая барган караңгылык эченнән Сәләх абыйның:

— Җибәр арканны, Рәсим, арканны җибәр, батасың ич! — дип өзгәләнеп кычкыруы ишетелде.

Аркан очы кулымнан шуып чыкты. Мин тавышсыз гына салкын суга егылдым, ләкин шунда ук сикереп тордым да, авызыма тулган суны төкерә-төкерә, ярга ташландым.

«Инеш тамагындагы бүрәнәләрне алып китмәсеннәр тагын, инеш тамагындагы бүрәнәләрне» дигән уй, киемнәремнең манма су булуын да, тәннәремнең калтырануын да онытырды.

— Хәбир, Нурислам! Сез кайда? Сәләх абый, алып төш машинаңны, инеш тамагындагы бүрәнәләрне чыгарып төярга кирәк тизрәк.

— Их, ашыгыбрак ташладык бугай, ашыгыбрак,— диде Сәләх абый минем янга килеп җитәр-җитмәс. — Казалы юлга чыкканбыз икән, хәерсез юлга.

— Сөйләшеп торма инде, Сәләх абый, саруны кайнатып. Алып төш машинаңны. Әнә, яктырып килә, тегеләрен яр өстенә тарттырып куйыйк, ичмасам.

— Каударланма, Рәсим энем, каударланудан мәгънә юк хәзер. Алып төшеп булмый монда бүген машинаны. Күрәсең ич, облава. Бөтен яр буенча прожекторлар уйнап тора. Машина номерын язып алсалар, эш харап аннары.

Бераз арырак Хәбир мышык-мышык килә иде. Сәләх абыйны читкәрәк этеп җибәрдем дә Хәбирнең беләгеннән эләктереп алдым.

— Әйдә, күрсәт әле теге бүрәнәләрне. Машинасыз да чыгарам мин аларны ярга.

Хәбир берсүзсез миңа иярде. Комлы чуерташларны шыгырдатып байтак йөгердек. Яр кинәт текәләнде. Хәбир ни өчендер артта калды.

— Анда түгел инде, Рәсим, — дигән сүзләре ишетелде аның бераздан.

Борылып, Хәбир янына килдем. Хәбир, су читенә иелеп, агач төбе сыман тырпаеп торган ташны учлары белән капшап маташа иде.

— Я, кайда бүрәнәләр! — дидем мин сулуым кабып.

— Менә шул ташка гына бәйләп куйганнар иде, малай...

Хәбир сүзен әйтеп бетермәсә дә, барысы да аңлашылды.

Юеш чалбарым белән чапылдап вак ташлар өстенә тезләндем. Бер тамчы да елыйсы килми иде хәзер. Тәнем түгел, җаным туңа иде. Бик яман калтыранып, дерелдәп туңа иде җаным...

## Саламторхан

Авылга таң аткач кына кайтып төштек. Бүрәнәгә дигән акчаны «суга салып» кайтуым турында кешегә-карага шауламагыз, дидем егетләргә аерылышканда.

Гармунны арыш капчыгына салып машина кабинасына кертеп ташлаганда, мал буларак түгел, дус буларак кызганыч тоелды ул миңа. Мәче баласын шулай капчыкка салып адаштырырга илтәләр безнең авылда.

Ярар, булды бу. Машина китте, егетләр таралышты. Нәкъ шул чагында аңуны китереп Тәслимәләр тыкрыгында бер көчек чәңгелдәргә тотынды.

— Ләң, ләң, ләң... Баерга киткән абыкай бөлеп кайта түгелме...

Юеш киемнәремне чоланда салып калдырдым.

Бая, гармунны алып чыкканда, әни йоклый кебек иде, торып та өлгерде микәнни — өй ишеге шар ачык. Бусаганы атлап, юка чаршауны

күтәреп өйгә кердем. Әни, чынлап та, торган, сәке читендә оек ямап утыра.

Аны-моны дәшмичә, урынга менеп яттым.

— Булмады, ахры, бүрәнәгез, — диде әни байтак кына сүзсез утыргач.

— Көттек, көттек тә Идел буенда, бүрәнә китермәделәр. Янгыр яуды, чыланып беттек.

Әни артык төпченеп маташмады. Энәсе тәрәзә төбенә төшеп чылтырады, үзе «Безгә килеп тәрәлгәч, шул булыр инде», — дип көрсенде дә идән сайгакларын шыгырдатып, чоланга чыгып китте.

Гармун күреге сыман сырланып калҗайган түшәм такталарына карап ята-ята гына үземнең бик тә күңелсез казага дучар булуымны төшендем. Нигә генә авылга кайтып йөрдем соң әле мин? Иделгә батып үләсе калган аны. Үле гәүдәмне судан тартып чыгарырлар иде. Хәбир ясалма сулыш алдырып маташыр иде. Әмма мин терелмәс идем инде.

Менә Сәләх абый машинасы белән авылга кайтып керә, капка төбенә килеп туктый. Мине кузовтан акрын гына күтәреп төшерәләр. Әни, мине күргә, һушсыз булып, өстемә егыла. Һушына килгәч, акчасы табылыр иде әле, улкаем харап булган икән, бердәнбер улкаем, дип үксиүксең елый. Галимулла абый да килеп җитә.

Борынын мышкылдатып торган Хәбирдән хәлне сорашып белә дә, әйттем мин аңа, Кайбыч кардонына барырсың бүрәнәгә, дип әйттем, тыңламады ич. Шул вакыт: «Рәсим энем, нишләвең бу?» — дип капкадан Мөнәвәрә апа килеп керә. Изелеп пешкән шомырт төсле чем-кара күз алмалары дымлы... Менә инде мине югаппар, зиратка күтәреп баралар. Бөтен кеше елый. Капка төпләрендә Борһан гына көлеп тора. Ак бөрчекле зәңгәр көянтәсенә ак чиләкләрен асып, Тәслимә судан кайтып килә. Җеназага очрагач, чиләкләрен сукмак читенә куя, суы чайпалып чирәмгә түгелә. Үзе косынкасын йолкып алып йөзен каплый да җеназага ияре. «Нишләп болай яшьли дөнья куярга уйлады икән соң?» — дип сорыйлар кешеләр бер-берсеннән. «Акчасын югалткан, әнисе башмак алырга дип акча җыйган булган, монысы шул акча белән бүрәнәгә киткән. Акчасын да суытканнар Кузлаука затонында, бүрәнәсен дә бирмәгәннәр». «Акча югалткан саен суга ташлана башласаң монда...»

Монысын кем әйтте тагын?

Юк, монысын беркем дә әйтмәде, монысын мин үзем әйттем...

Ике кешегә билгеле булган сер бөтен дөньяга тарала диләр. Рас икән. Йокылы-уяулы ята идем, әни:

— Хараплар гына булганбыз икән,— дип сәкегә ауды.

Мин, сулыш алырга да куркып, сүзнең дәвамын көттем.

— Дөресме шул хәбәр?

Әнинең тел төбен чамалый алмыйм әле. Дөресен әйтсәм ни була — билгесез.

— Нишлибез инде хәзер?

Әни мине тиргәргә җыенмый ич. Уртак хәсрәт итеп кабул иткән түгелме соң ул мин китергән казаны?

Әкрен генә торып, әнинең баш очына килдем. Борчулы күзләренә карадым.

— Кайгырма инде, әни, зинһар, кайгырма. Баш бәласе түгел лә ул кадәр. Ике кулым, ике аягым бар, эшләрмен, табармын акча.

Әллә ышанды әни минем сүзләргә? Күзләренә мөлаемлык инде. Чигә тамырларының тибеше салмакланды.

— Үзеңне ничек алып китмәгәннәр әле,— диде әни, башын тәрәзә ягына борып.— Үзеңне алып китеп ябып куйсалар да, бер хәл эшли алмас идең, ходай сакласын.

Әнине юатып, көйләп бетердем дигәндә генә тагын теге сорау бәгыремне көйдереп узды:

— Дөресме шул хәбәр, Рәсим энем? — Бусагада күзләре урыныннан купкан Мөнәвәрә апа басып тора иде.— Инде хәзер нишләмәкче буласыз?

— Аллага тапшырган,— диде әни, идәнгә төшеп, яулыгын бәйлибәйли.— Баш бәласе түгел, җае табылыр. Хәйрулла гына нишләр менә?.

Мөнәвәрә апа, әнинең мәсьәләне шулай җиңел генә хәл итеп куюына гаҗәпләнгәндәй, иңбашларын җыерып торды да миңа эндәште:

— Галимулла абый кәнсәләргә килергә кушты, сиңа, Рәсим энем.

Итекләремнең эче лычма су иде әле. Көч-хәл белән генә сыйдырдым аякка. Тик ишеккә таба бер адым атлауга бөгелеп төштем. Су эчендә йөргәндә ташмы, кабырчыкмы кергән, ахры, итек балтырына. Итекне салып тегеләй каккаладым, болай. Бернәрсә дә күренмәгәч, чолгауны чишеп атып, аяк табанына карадым, тырнак очы кадәр генә яра. Нишләп шул кадәр авырта соң ул? Сыңар итектән ишегалдына чыктым — бик каты авыртмый. Чолгауны чорнап, итекне кидем — басар хәл юк. Эзли торгач таптым, ниһаять. Итек табанына ярты шырпы озынлыгы кадак кергән. Машина шины дип белгән әллә тагын минем итекне. Келәшчә белән эләктереп тарткач та чыкмыйча азапланган була, иблис.

Итектәге кадакны суырып аттым, бәгырьгә кереп кадалган ямьсез тойгыларны ничек суырып атарга менә? Аз гына аксаклап кәнсәләргә барам. Очраган кешеләргә күтәрелеп карамыйм. Сәлам бирүчеләр белән баш кагып кына исәнләшәм.

Нәрсә дип әйтергә инде Галимулла абыйга? Станциядән апкайтып китмәгән булсаң дияргәме? Анда эшләсәм, мондый хурлыклы хәлгә дучар булмас идем әле мин. Нәрсә дип әйтергә соң шулай да?

Барып җиттем кәнсәләргә. Баскыч такталарына текәлеп карый-карый өскә мендем. Баскычны юмаганнар, ни өчен генә акча алып ята торгандыр бу җыештыручы? Үземне юату өчен, игътибарымны читкә җибәрү өчен генә шулай уйлаган булам инде. Үзем дер-дер калтыранам.

Тимер тотканы тарттым. Ишек ачылды. Кулына ниндидер кәгазь тоткан хисапчы Вәсимә апа телефон колагын борып маташа.

Галимулла абый да аяк өстендә. Кулларын кая куярга белмәгәндәй, әле кесәсенә тыга, әле, йодрыклап, ияк астына куеп ала.

Бусаганы атлап керүем белән, мин почмактагы урындыкка иңдем.

Вәсимә апа, телефонның колагын борып-борып та эш майтара алмагач, авыл Советы ягына чыгып китте.

Галимулла абый башта миңа игътибар бирмәгән кебек тоелган иде. Баксаң, ул ишек ачканымны да, аксый-аксый урындык янына килгәнемне дә искәреп торган икән. Һаман да шулай, кулларын кая куярга белмичә, әрле-бирле йөргән уңайга, тавышын күтәрми генә сүз башлап җибәрде:

— Я, нәрсә, герой, ранен булырга да өлгердеңме? Тормыш өйрәтә ул, понимаешь. Алдыңны-артыңны карап йөрергә дә, олылар әйткән сүзгә колак салырга да өйрәтә. Авыртамы?

Мин каш астыннан гына Галимулла абыйга карап алдым.

— Авырта.

— Кай турың авырта?

— Аягым.

— Ә җаның, җаның авыртамы?

Мин башымны тагын да түбәнрәк идем. Сайгак ярыклары ыржаеп миннән көләләр иде.

— Кеше күзенә күренергә дә ояласың инде хәзер, понимаешь.

Әллә минем күнелемдәге уйларымны укып бара инде Галимулла абый.

— Эшкә барырга да кыенсынасың инде, шулаймы?

Көлә бит Галимулла абый миннән, астыртын гына көлә. Өстәл төя-төя әрләсен, аяк тибә-тибә орышсын иде, ичмасам.

— Никләргә генә Иделгә төшеп үлмәдем икән, дип уйлыйсын.

Галимулла абый тәрәзә янына барып, төк баскан җыерчыклы яңагын бәләкәй учы белән сыйпаштырып алды. Аннары имән бармагын бөгеп, мине үзе янына чакырды.

«Әллә тәрәзәдән атырга җыенамы? Атсын, атмагае...»

Курка-курка гына тәрәзәгә таба атладым. Галимулла абый имән бармагын тәрәзә пыяласына терәде.

Утын сарае почмагында Карлыгач башын чайкап тора иде. «Кем иярләгән инде аны?»

— Әнә күрәсеңме?

— Күрәм, Галимулла абый... Карлыгач.

— Аягың нишләде?

— Кадак кадалды.

— Бик авыртамы?

— Бик авыртмый.

— Бик авыртмаса, Карлыгачыңа атлан да әнә, өстәл читендә яткан пакетны районга илтеп кайт. Телефон эшләми, кадалгыры, сәгать дүрттән бирле азапланам...

Өстәл читендә яткан пакетны алдым да ишеккә борылдым.

— РИКны беләсең ич. Менә шунда, икенче катта, уң якта беренче ишек. Иптәш Ямаловка, диярсең... Озын булса, өзәңгеңне кыскарт. Әй, туктале, кая чабасың? Әйтергә оныткание. Ашыгып йөрмә. Беррәттән башындагы җуләр уйларыңны да коеп кайт, ишеттеңме? Яңа өлгергән кәбестә кебек чистарып калсын башың.

...Нинди генә рәхмәтләр әйтим икән инде Галимулла абыйга моның өчен? Карлыгачымны җиңелчә генә юрттырып ындыр артына чыгуга, җаннарым җиңеләеп китте. Йокы да ачылды, аяк авыртуы да бетте. Җиләс, рәхәт, тояк тавышы күңелне кытыклый, озын яллар битләремне сыйпый. Юл буенда бака яфраклары тирбәлә, катыкура чәчәкләре чайкала.

Ләкин белеп барам, сизеп барам — иркенлек тә, киңлек тә, басу һавасы да ахырынача бетерә алмаячак минем борчулы уйларымны. Тәслимә миңа насыйп яр түгелдер инде, күрәсең. Әтү гелән-гелән кара язмыш чыгып басмас иде юлыма. Әллә мин үзем пешмәгән микән? Шулайдыр, үзем кулымнан бер юньле эш килми торган адәм имгәгедер, мөгаен, мин. Беркөннәрдә станциядән кайтып китмәскә кирәк иде миңа, түзәргә кирәк иде. Сынаттым. Менә хәзер инде кыенлыкларга очрагач, гел чигенәсе килеп торачак. Эх, сынаттым.

Үзем дә сизмәстән, Карлыгачыма тезген очы белән чирттереп җибәрдем. Очабыз. Яллар инде битләремне сыйпамый, бөтен йөземне пешерел сибелә. Юл йомшак, тояк тавышлары ишетелми дә диярлек.

Әнә Балан әрәмәлеге, әнә Якты күл, әнә кәбестә җире. Башың яңа өлгергән кәбестә кебек чистарып кайтсын, дип берәр этлек белән әйтмәде микән бая Галимулла абый?

Әле иртә, әле килмәгәннәрдер. Күл буендарак ак сыннар шәйләнә түгелме соң? Карлыгачны тыя төшеп, ияргә тураебрак утырдым. Ялкын яллар битләремә килеп җитә алмый инде хәзер. Тезгенне тагын да катырак тарттым. Уйсулык аша узганда, ак сыннар күздән югалып торганнар иде, үр менгәндә бөтенләй якында, мин узасы юл читендә генә пәйда булдылар. Ияргән мәтәлеп төшим, Тәслимә белән Гөлнур. Кулларын каш өстенә куйганнар бит әле җитмәсә. Әйтерсең, танымыйлар. Күптән таныдылар бит инде, югыйсә. Хәзер генә танып алдылар, янәсе — бөгелә-сыгыла чыркылдашырга тотындылар. Монда безнең түбә ярыгы күренми ич, нидән көләләр икән инде тагын?

Якынрак килдем, рәт-рәт булып, арпа басуына таба сузылып киткән кәбестәләргә ымлап:

— Сәлам кызларга! Кәбестә үстерәбезмени? — дип сүз каттым.

Кызлар икесе дә яшел чәчәкле кыска күлмәк кигәннәр. Туфлиләре кәбестә төбендә аунап ята. Тезләре дә, балтырлары да кояшта янган. Аяк бармаклары йомшак туфрак арасына коелган чәчәк таҗлары сыман агарып күренә.

Кызлар көлеп аргач кына минем якка борылдылар. Тәслимәсе миңа бер генә күз сирпеп алды. Гөлнуры иреннәре арасына кәбестә яфрагы чеметеп капты да аны шунда ук җиргә төкерде, үзе, пырхылдаудан тыела алмыйча:

— Әллә, әллә, уф, үләм инде бүген көлә-көлә, әллә председатель итеп сайладылармы сине, Рәсим? — диде.

— Сайласалар ни әйтерсең?

— Әбәү, сөйләшүен күр әле, Тәслимә. Председатель ияренә атландым, дигәч тә... алашасы үзеңнеке ич, әлләкем булма ул кадәр.

— Кем әлләкем булган?

— Син! Кичке уеннарга да чыкмый башладың. Гармуныңны алып калырлар, дип куркасыңдыр инде.

«Әллә гармун турында ишетеп тә өлгерделәр микән, ходаем? Арыш капчыгына салып бирдем ләбаса Сәләх абыйга, ничек күрсеннәр...»

— Уен кайгысы түгел әле монда.

Тәслимә сүзсез генә Гөлнурның беләгенә орынып алды, тик Гөлнур моңа игътибар итмәде, берсеннән берсе ачу китергечрәк сүзләрен борчак урынына сибә бирде.

— Ишеткән идек шул. Уен кайгысы түгел икән синдә хәзер. Ызба салырга йөрисең, диләр.

Тәслимәнең бит алмалары алсуланып чыкты, мин, кызлар каршысында оеп торган алашамның ялларын сыйпаштыргаладым.

Гөлнур тагын да ачу китергечрәк итеп пырхылдады.

— Кичә сине бүрәнәгә киткән, дип сүләгәннәр иде лә. Эшкә баргандә, нишләптер, капка төбегездә бүрәнә-фәлән күренмәде. Ишегалдыгызга кертеп өймәгәнсездер ич?..

Мин Тәслимәне дә, Гөлнурны да күрми идем инде. Карлыгач тезген очын селтәп җибәрүгә, җилдереп китте. Мин кызышкан яңакларымны ат ялларыннан кыйнaта-кыйната, үз-үземне тиргәдем:

— Шул кирәк син Саламторханга, кызлар янына бармаска бер генә мәртәбә ант итүең түгел. Әләктеңме менә?! Сөйләшә белмәгәч, кызларга сүз кушмыйлар аны. Сиңамы соң кызлар! Теге көнне цемент бункерына төшеп тончыгасың гына калган да бит... Җаның кадерле, үләсең килми. Ни калган инде сиңа бу дөньяда. Я? Адәм рәтле һөнәрең юк, кием-салымың кеше янына киеп чыгарлык түгел, бердәнбер юанычың — гармунын бар иде, инде анысыннан да колак кактың, Борһан дөресен әйтә синең хакта Саламторхан, дип. Чынлап та Саламторхан син, башка беркем түгел...

Күгелҗем-кара урманнар, яшел әрәмәлекләр, саргаеп килгән иген басулары артта калды. Тирә-ягымда матур капкалы өйләр пәйда булгач кына район үзәгенә килеп җитүемне төшендем. Карлыгачымны ике ягына да калын такта җәелгән урам буенча РИК бинасына таба әйдәдем.

РИК янына җиткәч, аттан егетләрчә генә сикереп төшәргә теләгән идем — аягым җиргә тию белән кычкырып җибәрә яздым. Сыйрак сөягенә тимер кучәр башы бәрелгәндәге кебек авырту бөтен буыннарымны сыкрандырып узды. Конвертны кәпәч эченә тыгып кигән идем. Шуны караган булып РИК бакчасы буена утырдым да хәл җыйдым. Аннары, авырта торган аягымны көч-хәл белән генә сөйрәп, текә баскычтан икенче катка күтәрелдем. Тиешле ишектән кереп, конвертны күзлекле кызга

суздым. Күзлекле кыз конверт тышындагы язуга күз йөгертеп чыкты дә түрдәге ачык [illegible]ккә борылып:

— Иг[illegible]ович, «Маяк»тан сводка,— диде.

Минем кир[illegible]ем юк инде, күрәсең, боларга. Ишек яңагын озак кына терәп т[illegible]ам да, ни, тегеләй, ит, ни болай ит, диюче булмады. Менгәндәг[illegible]келле шыпырт кына төшеп киттем баскычтан.

Кайтыр юлда Карлыгачымны куаламадым. Галимулла абый ашыкмаска кушты ич, нигә ашыгырга. Әллә яңгыр яумакчы инде — урман өстеннән шалакма читле кара болытлар ташып чыкты. Болытласын, әйдә, коеп яңгыр яусын! Авылга кергәч, кеше-кара очрамас, ичмасам.

Урман авызында сакланып кына үлән өстенә төштем. Алашаның тезгенен муенына чорнап уйсулыкка җибәрдем. Ял итсен, әйдә, ул да, сусыл печән ашасын.

Итекләремне салып, чолгауларымны сүтеп аттым. Алай, аяк табанындагы яра тирәсе агарып шешә башлаган. Бармак белән дә орыныр хәл юк — берьюлы дистәләрчә энә кадалган кебек. Алай, шул гына җитмәгән иде, шул гына җитмәгән иде. Калганнары ал да гөл бит!

Җиргә йөзтүбән капланып, битемне үләннәргә яшердем. Җир салкын идеме, җылы идеме — сизмәдем. Агач яфраклары шаулый идеме урман өстендә, яңгырмы — аера алмадым. Яттым да яттым шулай бер[illegible]ка тырышып, яттым да яттым.

Баш очында гына нәрсәдер чытырдап ярылды. Сискәнеп күзләремне ачсам, көн караңгыланган, урман ач ерткыч сыман үкерә. Юл буендагы арышлар тәгәрмәч эзләренә кадәр иелеп чайкалалар. Каһәр генә суксын, «Серле балдак» әкиятендәге солдат хәленә төшә язганмын икән. Ул да бит йокы белән булышып, алтын пароходка утыра алмыйча калган. Тояк эзләре бар үләндә — Карлыгач үзе юк. Менә монысы, чынлап та, шәп булмаган. Тагын эләгә инде миңа Галимулла абыйдан. Ирдән егылып калган, диячәкләр инде мине хәзер авылда. Бигрәк тә пешмәгән инде бу Хәят малае, диячәкләр... Бәлки, шул тирәдә генә йөри торгандыр әле, бәлки, авылга кайтып китмәгәндер.

Үләннәр арасыннан ямьшәйгән кәпәчемне алып кидем дә ашыга-кабалана сикереп тордым... Һәм киселгән агачтай кире егылдым. Иблис! Таг[illegible] оныткамын аягымның авыртканын.

Имән төбенә утырып, итекләремне кияргә тотынгач, күзләремне камаштырып, яшен яшьнәде, урман өстеннән колак тондыргыч чытырдап яңгырап узды, чиләкләп яңгыр коярга кереште. Әлләлә-лә! Әйткән иде аны Галимулла абый, башың яңа өлгергән кәбестә кебек чистарсын, дип. Чистара менә хәзер, бик шәп чистара.

— Карлы-га-ч! Син кайда? Аягым авырта бит, кайтып булмый! Һәй, Карлыгач! Һәй!

Яңгыр пәрдәсе ябынган юеш урман ухылдап көлде:

— Ух-ха-ха, ух-ха-ха...

Чатанлый-чатанлый юл читенә чыктым. Арыш кыры тын калып, оеп китеп яңгыр суы эчә. Тәгәрмәч эзләреннән гөрләвекләр йөгерә.

Карлыгачның мине ташлап качуына әле һаман ышанасы килми иде. Ат белән эт беркайчан да яхшы хуҗаны ташлап китми, ди. Яхшы хуҗаны бит ул, Саламторханны түгел.

Тешләремне кысып, урманнан читкәрәк китеп үскән карт юкә янына кадәр бардым да яңгыр чылатып өлгермәгән кытыршы кәүсәгә ябыштым һәм бар хәлемә:

— Кар-лы-гач! — дип кычкырдым.

Бөтенләй якында гына, чикләвек куаклары артында өздереп ялгыз ат кешнәде. Тавышыннан таныдым — минем Карлыгачым иде бу.

# Аша менә

Урак бетереп кайткан көн иде.

Эштән кайтып ашап-эчкәч, безгә Хәбир йөгереп керде. Кулында район газетасы, күзләреннән әйтелмәгән шатлык түгелергә тора.

— Рәсим, карале, малай, безне газетага мактап язганнар. Менә укы, комбайннан ашлык ташуда «Маяк» колхозы егетләре Шәймәрдәнов Хәбир белән Исламгәрәев Рәсим бигрәк тә тырышып эшләделәр...

Газетаның Хәбир бармагы каралтып өлгергән өлешен игътибар белән укып чыктым. Шулай, дөрес. Безнең хакта язганнар газетага. Менә бит эшләр кая таба китте! Тәслимә күрде микән әле моны? Мәкаләне тагын бер кат укырга җыенган идем — Хәбир ирек бирмәде.

— Китер әле, китер, әнигә дә күрсәтим, әнигә күрсәтмәгән,— дип газетаны кулымнан тартып алды да ишеккә ташланды.

Хәбир чыгып киткәч, әни көрсенеп куйды:

— Әни дип өзелеп тора инде шул бала. Бигрәк тә ана җанлы булыр икән.

— Кара, безгә нишләп газета китермәделәр икән соң? — дидем мин әнинең Хәбирне мактавын ошатмыйчарак.

Шулай әйтеп бетерүем булды, ишегалды тәрәзәсеннән почтальон Сабирҗан агайның салам эшләпәсе тирбәлеп узды, карлыккан тавышы ишетелде:

— Рәсимуллау! Син өйдәмү?

Мин чоланга чыкканда, Сабирҗан агай иплэп кенә сумкасын актара иде.

— Сиңа повестка җибәргәннәр менә, Рәсимулла. Берсекөнгә военкоматка каралырга барасыз.

— Ходавәндәм, ходавәндәм,— дип, юа торган савыт-сабаларын ташлап, кулын алъяпкыч итәгенә сөртә-сөртә, безнең янга әни чыгып житте.

Хуш, кул куеп алдык повестканы. Сабирҗан агайны күз карашы белән капкага кадәр озаттык, сүз каттык:

— Ходавәндәм түгел инде, әни. Солдатка китәсе егетләрне ел саен шулай җиде-сигез ай алдан каралырга чакыралар.

Әни кытыршы кулы белән иңемә орынып алды.

— Ходавәндәм, әтиең күргән булса иде бу көннәрне. Үсеп беттең бит чистый. Елларга гына тынычлык, иминлек бирсен инде ходай... Ярар, тапшырдык аллага, иртәгә мунча ягарбыз. Уракны бетереп кайтуыгыз яхшы булды әле.

Әни ашыгып капкага таба китте.

Әйбәт тә кеше инде минем әни, дип уйлап кына бетердем, басма алдында Хәбир тавышы колакны ярды:

— Рәсим, малай, Рәсим!

— Нигә акырасың шул кадәр?

— Миңа повестка китерделәр. Әни елый. Һич юатыр хәл юк, нишлим икән?

— Елар-елар да туктар әле.

— Әллә сиңа повестка китермәделәрме?

— Китерделәр.

— Әниең еламыймы?

— Еламый.

— Ә нишли?

— Бану апаларга кереп китте. Мунча сорарга. Иртәгә мунча ягабыз.

— Кара! — диде Хәбир һәм, ишегалдында ук салып калдырган галошларын кияргә онытып, капкага йөгерде.— Мин дә әйтим әле әнигә, су ташысын, бергә керербез мунчаны.

Мин тирече Хәйруллага бирәчәк бурыч турында уйланып утырдым да кулымдагы повестканы дүрткә бөкләп кесәгә тыктым, ишегалдына чыктым, букәнгә чабып куелган бәләкәй балтага, аннары өй кыегында сөялеп торган баскычка карадым.

Амбар почмагында утын сарае ясарга дигән такта бар иде. Шуларны нигез төбенә китереп өйдем дә баскыч буенча берәмләп-берәмләп өй түбәсенә менгердем.

Ниһаять, кадак әрҗәсе дә, әтидән калган балта белән келәшчә дә өй түбәсендә.

Бигрәк беткән икән шул, чәнчелгере. Баскан саен чытыр-чытыр килә. Кадак сугарлык та рәте калмаган. Шулай да, томалана тишекләр.

— Нишлисең анда, улым? Чормага убылып төшмә инде, сакланып кына йөри күр,— дип әни кычкырып узды.

— Өй түбәсе ябасыңмыни, малай, булышырга менимме? — дип Хәбир килеп җитте.

— Кирәкми,— дидем мин Хәбиргә.— Түбә япмыйм бит мин, тишекләрен генә томалаштыргалыйм.

— Томалаштыргалыйсың гынамыни? — диде Хәбир үзен түбә ябышырга чакырмаганым өчен шатлангандай.— Әллә башмагыгызны сатып такта алдыгызмы?

— Ник?

— Башмагыгыз күренми, шуңа күрә әйтәм.

— Башмак абзарда. Көтүдән качып кайткан ул бүген.

— Кайдан акча табып бетерерсез икән инде, Рәсим малай?

— Хәйруллага яртысын башта ук биреп куйдык ла без.

— Яртысы да күп бит аның.

Алла, бармагыма суктым. Балтам Хәбир башына төшеп китә язды.

— Хәбир, бар әле, әниең елый бугай.

— Еласа, нишләтим инде аны. Мин военкоматта моряк итеп алуларын сорыйм, малай, ә син?

— Белмим әле,— дидем мин сөйләшәсем килмичә.— Бармагыма балта түтәсе белән суктырдың менә. Язмаганнарны лыгырдыйсың да торасың.

Хәбир артыннан капка ябылгач, морҗа читләренә ябыша-ябыша, өй түбәсенең икенче ягына чыктым. Әнә ул... кояш нурлары качышлы уйный торган чәнчелгере ярык. Такталарның иң киңе, иң шәбе белән томаларга кирәк монысын.

Мин шулай уйлап, исәп-хисап кылып утырганда, түбәндә акация куаклары артында кемдер йөткерде. Кемдер түгел. Борһан иде бу, Борһан. Шуны танымыйча теге, Борһан йөткерүен беренче генә мәртәбә ишетүем түгел.

Балта күтәргән кулым кадакка сукмыйча, һавада асылынып калды. Киң такта урыныннан кузгалды да теге ямьсез ярык ыржаеп янә урамга карады. Мин балта сабын кысып тоткан килеш, тиз генә ярык өстенә утырдым.

Киртә буендагы акация куаклары селкенеп куйды. Яшь шомырт ябалдашы астында кара кәләпүшле, озын муеклы баш пәйда булды.

Борһан авыл кешеләре белән бик сирәк әңгәмә куерта торган иде. Нәрсә булыр икән бу? Ул арада кичке һаваны:

— Алла куәт бирсен түбә ябучыларга! — дигән сүзләр яңгыратты.

— Түбә ябучы юк әле монда,— дип мыгырдандым мин балтамны артыма яшереп. . .

Борһан тагын йөткергәләп алды.

— Картаела. Атаң мәрхүм белән бергә уйнап үскән малайлар бит без. Әле менә сине өй түбәсендә күргәч, атаңны күргән кебек булдым. Дәртләнеп-дәртләнеп ябып йөргән иде, мәрхүм, шушы йорт түбәсен.

Үзенә рәхәтен күрергә язмаган икән. Атаң исән булса, мондый хәлгә төшерә идеме соң йортыгызны. Авыр туфрагы җиңел булсын, кулы алтын иде мәрхүмнең.

Борһан әйткән сүзләр башта елыйсыны китергән иде, инде хәзер ачуны китерә башлады. Синең кулыңнан бер эш тә килми, утырган буласың ичмасам өй түбәсендә кабак әләме кебек, янәсе. Һе, этине искә төшерә, имеш. Исеңә төшсә дә, әйтмәс идең әле. Эч сереңне кешегә чыгара торган адәм түгел син.

Мин үзем әнә шулай уйладым, ә үзем, тагын ни әйтер икән, дип колагымны Борһан ягынарак тырпайттым.

— Алай кадаклыйсың да син, яңгыр үтә ич инде барыбер,— диде Борһан, көтеп-көтеп тә минем авыздан ләм-мим бер сүз чыкмагач.

Тактасына әйтер идем, җил юк, фәлән юк, тиктомалдан шуды да төшеп китте ал бакчага.

Борһан тагын кһм, кһм йөткеренде. Моннан йөзе ачык күренми, мыштым гына көлеп тора иде, ахры, ул.

— Осталар кайчан килә соң әле?

— Нинди осталар? — дип ихтыярсыз сүзгә катнашып киттем мин.

— Балта осталары. Сине бүрәнә апкайткан, дигәннәр ие ич. Буратып куясыздыр, буратып куймасаң, бүрәнә чери башлый...

Балта сабы кулымны пешерә. Әллә морҗадан, әллә көндез кызып калган такталардан йөземә эсселек бөркелә.

— Буратып куярга хәл җитеп бетми әле, Ерак Көнчыгышка барып, акча эшләп кайтам башта. Аягым да авыртып йөри какраз. Кадак кергән ие, докторлар диңгез һавасы суларга кушалар.

«Тыгылдыңмы?! Кешене мыскыл итмәссең мәнә икенче. Тәслимә атасы, дип тормам мин, әйтәсемне әйтермен бер авызымны ачтырсаң».

Һаман китми, һаман тора Борһан. Инде утырган такталарым чана башы кебек бөгелеп керде. Аз гына селкенсәм дә бөтен түбә чытырдый, харап эшләр.

— Җырак Көчыгышка барып җитәргә тәтекәчем, ай-һай,— дип авыр сулады бераздан Борһан.— Алашага атланып кына барып җитәрлек түгел ул Җырак Көнчыгыш. Аннан соң Җырак Көнчыгышка баргач, өй түбәсенә менеп, Саламторхан кебек алан-йолан каранып утыра алмыйсың. Анда баргач җиде тир чыкканчы эшләргә туры килә.

— Җиде тир чыкканчы эшли ала торган кешеләр колхозга да бик кирәк тә бит...

Сүземне әйтеп бетерәлми калдым — мин утырган такталарның берсе җепсәсеннән куптымы, сындымы — һәрхәлдә мин, тигезлегемне югалтып, морҗа читенә ябыштым.

— Тире җыючы Хәйруллага бурыч түлисем юк әле, колхозда эшләмәсәм дә ач үлмәм...

Нигә дип Борһан Кукамайның авызына карап, мөкиббән китеп утырам соң әле? Тәслимәсе дә үзенә булсын, хаҗәте юк. Алмасы алмагачыннан ерак төшмәгәндер.

Сабы дымланып, кайнарланган балта түтәсе белән морҗа төбендәге калайдан тырпаеп торган кадак башына кизәнеп сугыйм дигәндә генә утырган урыным убылып китмәсенме. Башта терсәгем, аннары маңгаем нәрсәгәдер бәрелде. Туфрак җәелгән түшәм өстенә төшкәнгәдер инде — сыртым ул кадәр үк авыртмады. Күзләремне ачканда, өй түбәсендәге өстәл кадәрле ачыклыктан бөтерелеп-бөтерелеп тузан күтәрелә, сынган такта башлары тырпаеп тора, ә тышта буыла-буыла Борһан көлә иде.

Кулымдагы балтаны чорма почмагына тондырдым да авызыма уч тутырып коры туфрак каптым.

«Аша менә, кеше төсле яши белмәсәң!..»

## Башы да авыртмый...

Комиссия бүлмәсеннән чыккач, шатлануын күрсәгез Хәбирнең. Сүзен дә әйтә алмый егет. Сүзен әйтер иде, авызын җыя алмый. Авызын җыяр иде, эчендәге шатлыгы ирек бирми.

— Я, әйт инде, әйт тизрәк,— дип түземсезләндем мин, Хәбирне башка егетләр яныннан аерып китәргә тырышып.— Алдыларммы?

Хәбир минем сүзләрне бөтенләй ишетми дә. Күзләрен уйната, башын чайкый, күкрәген угалый. Киемнәре янына барып баса, тик үзе нигәдер киенми, тәрәзә янына килә, авызын ерып ак рамнарга карап тора.

Җилкә тамырына кундырып алгач кына бераз анга килде Хәбирең. Ә-ә-ә, син дә дөньядамыни, дигәндәй, минем якка борылды. Бик, бик югарыдан, җиде кат күк артыннан карап торадыр сыман тоелды бу минутта миңа Хәбир.

— Су асты көймәсенә годен, диделәр, малай, вәйт! Ишеттеңме, су асты көймәсенә!

Кайчагында түл җыеп бетергән тавык, үзенең көрлегенә чыдый алмыйча, сәер генә кычкырып куя. «Су асты көймәсенә»,— дип кабатлаганда, Хәбир тамагыннан да шундыйрак авазлар чыкты.

— Һич тә башыма китермәгән идем, малай, ай-һай, су асты көймәсенә бит... Нишләп җиде класс белән генә калдың, дальше укымадың,— дип сорадылар түлке... Авылда унъеллык мәктәп юк, мама одна, работать, надо дидем...

Чынлап та, бик харап икән бу комиссия дигәннәре. Карамаган җирне калдырмыйлар икән бер дә. Яшь кенә кызлар утыра бит әле шунда, җитмәсә. Төкермиләр дә. Әллә шыр ялангач егетләр йөри алар тирәсендә, әллә алашалар...

Тезләремә бәләкәй чүкеч белән суккалап карадылар — әйбәт. Йөрәгемне тыңладылар.

— Геракл,— дип мактады ак чәчле ачык йөзле апа,— йөрәгеңне сакла, мондый йөрәк белән яшәргә дә яшәргә кешегә. Тәмәке тартасыңмы?

— Юк.

— Молодец, тартма.

Күзләрем тары ярмасы зурлыгы хәрефләрне дә таныды, колакларым ирен тибрәтеп әйтелгән пышылдау сүзләрен дә ишетте.

Кан басымын кара бөдрә чәчле, сипкелле хатын үлчәде. Ак тасмасын беләгемә чорнап, кызыл тубын пош-пош китереп кыскалады да тагын бушатты, тагын пош-пош китерде. Күзләрен кара тартма эчендәге пыяла көпшәгә төбәгән көе, миннән берничә мәртәбә:

— Башың авыртмыймы? — дип сорады.

— Авыртмый.

— Тәмәке тартасыңмы?

— Юк.

«Нәрсә пошкылдата инде бертуктаусыз, тапкан кызык...»

Алай икән әле, тиз генә җибәрергә исәбе юк икән әле моның мине. Тасмасын сул беләгемнән чишеп алып, уң беләгемә урап куйды. Тагын пошкылдатырга тотынды.

Бер карап озатты көпшәдәге сыекчаны, ике. Болай да юка иреннәрен кысып, башын чайкады. Зур өстәл артында нәрсәдер язып утырган кардай ак халатлы юан кешегә эндәште:

— Василий Петрович, карагыз әле бу яшь кешенең басымын.

Василий Петрович дигәннәре, урыныннан авыр гына кузгалып, кыштыр-кыштыр килде дә резина шарны үзе кыскаларга тотынды, пыяла көпшәне үзе күзәтте.

— Тәмәке тартасыңмы? — дип сорады, ниһаять, бусы да.

Минем өчен кара чәчле хатын ашыгып җавап бирде:

— Тартмый. Башы да авыртмый.

— Авыртмаса, авыртыр әле,— диде Василий Петрович, үзалдына сөйләнгәндәй.— Сугыш галәмәтләре болар бар да. Питание җитмәгән. Юкса, бу яшьтән гипертония выявляться итәме адәм баласында.

— Тәмәке тартма, аракы эчмә,— диде кара чәчле хатын, Василий Петрович кыштыр-кыштыр үз урынына киткәч. Өстәге юлына минем фамилия язылган кәгазь битенә озаклап нәрсәдер сырлады да кара бөдрә чәчле хатын, сипкелләрен балкытып аяк өстенә торды.

— Ә хәзер туган кохозыңа кайтып әйбәт кенә эшлә. Кирәк булса, без сине үзебез чакыртырбыз.

«Туган колхозың», «Гипертония», «Аракы эчмә»... Нәрсә булды инде бу?

Башымны тәмам бутап бетерделәр болар. Ишекнең теге ягына чыккач, аякларымның икесен дә чалбарымның бер балагына тыгып азапландым.

Шул чагында, чөй өстенә тукмак дигәндәй, Хәбир килеп җитте:

— Йә, ничек? Нинди частька яздылар?

— Гипертония!

— Һәй,— диде Хәбир чын күңелдән борчылып,— су асты көймәсенә сорарга кирәк иде. Су асты көймәсендә океан төпләрендә йөрисең, акулалар күрәсең. Өстә йөз баллы давыл, ә син пылт—су төбенә төшәсең дә утырасың.

Ни өчендер сөмсере коелып торган Карлыгачның аркалыгын күтәреп, түшлеген тарттырдым. Арбага менеп утырдык.

Хәбир шоссе беткәнче, су асты көймәсендә хезмәт итүнең өстенлекләрен, хәвеф-хәтәрләрен сөйләп китте. Шоссе бетеп авыл юлына борылгач кына:

— Онытып да инде, сине нинди частька язганнар әле? — дип сорады.

— Гипертония... Ракетный войсканың бер төре шунда.

— Су асты көймәсендә барыбер кызыграк,— дип сүзгә кереште тагын Хәбир һәм яңадан үзенең хыялый океан-диңгезләренә китеп адашты.

Әллә чынлап та чигәләрем авыртырга тотынды инде? Каһәр генә суксын, гипертония башланадыр. Кара, сорамадым да, хәрби хезмәткә ярамыйсың, дип әйтүләре булды микәнни боларның миңа. Түбә, бүрәнә, башмак кайгылары пүчтәк кенә булган икән ул гипертония белән чагыштырганда. Кичә Югары урамда моңлы бер җыр ишетелгән иде.

Хәсрәт күрергә өйрәнгән, түзәрсең, йөрәккәем, — дигән сүзләре колагымда әле дә чыңлап тора.

Атны туарып, ишегалдына кайтып керсәм, басма алдында дүрт төргәк толь ята. Бүтән вакытта сөенгән булыр идем мин мондый байлыкка, бүген исә, башымны кая куярга белмичә, ишегалды буенча әрле-бирле йөргәләдем дә чирәмгә сузылдым.

Өй алдына әни чыкты. Җеп башмагы белән толь төргәгенә кагылып:

— Әллә күрмәдең дә,— дип тынып торды, мин аны-моны дәшмәгәч, ялгап китте,— өй түбәсенә җитә диделәр. Паратски шуферларыннан сатып алдым.

Мин янып күмергә калган бүрәнә кисәүләрен хәтерләткән төргәкләргә бернинди шатлыксыз-куанычсыз карадым да карадым.

— Әллә бер-бер авыруыңны таптылармы? — диде әни миңа якынрак килеп.

— Тапмадылар, җен кебек таза, диделәр. Юлда кызу сукты, ахры, бераз башым әйләнә.

— Бар, алайса, өйгә кереп ят. Бану апаң сепарат сөте керткән ие. Катык оеттым. Яратсаң, аша.

Әнинең дә ниндидер кайгысымы, борчуымы бар бугай. Сездерергә генә теләми. Толебез булганга сөенеп бетә алмас иде, югыйсә.

— Хәйрулла карун көтүгә килеп башмагын алып киткән,— диде әни минем янда шактый вакыт чирәм таптап торганнан соң.— Кечкенә малае артыннан биреп җибәргән безнең акчаны, яхшы булды әле толь алырга. Калганы сиңа кәчтүн-чалбар юнәтергә җитәр. Район кибетенә барып, үзеңә ошаганын сайлап алырсың.

Чирәмгә торып утырып, әнине юатырга, җылы сүзләр әйтергә кирәк иде дә бит. Ләкин бу минутта минем телемне дә, аякларымны да гипертония «богаулап» куйган иде шул.

## Авыл тын түгел

Галимулла абый, бәләкәй, йонлач куллары белән яңакларын кысып, тәмәке савытында пыскып яткан төпчекләргә текәлеп шактый озак утырды.

Инде бригадирлар да, идарә членнары да таралышканнар, тәбәнәк түшәм белән идән арасына тулган тәмәке төтене ачык ишеккә генә сыеша алмый, саргайган матчаларга ышкылып, асылмалы лампалар тирәсендә бөтерелә, болай да сөремләнгән куыкларны тагын да төмсәләндереп күрсәтә.

Галимулла абый, рәттән берничә мәртәбә тамак кырып алганнан соң, кулларын өстәлгә куйды да:

— Түбәгездән яңгыр үтмидер инде хәзер,— диде.

— Белмим, өй түбәсен япканнан бирле яңгыр яуганы юк бит әле.

— Әнием җибәрәме соң?

— Җибәрә.

— Риза булып җибәрәме?

— Нишләп риза булмасын? Кыш чыгарлык утын әзерләп калдырдым мин аңа. Курмы да кәҗә-сарыкларга җитеп ашкан.

Галимулла абый учлары белән янә яңакларын кысты.

— Ә без сине авыл хуҗалыгы техникумына кодаларга йөри идек. Идарәдә дә сүз булды шул хакта.

— Әй, Галимулла абый! Торырга өең булмасын. Нинди техникум, ди ул? Укырмын әле кайткач.

— Ай-һай тиз генә кайта алырсың микән? Находкага ук китәм, дисең.

— Кайтырмын,— дип борынымны тарттым мин һәм, күңелемнең тулуын сиздермәс өчен, караңгы тәрәзәгә борылдым.

Галимулла абый:

— Егетләр кайта хезмәт иткәч,
Кызлар кайтмый бер киткәч,—

дип көйләп алды да урыныннан торды.

— Находкага кем янына барасың соң син?

— Газетада белдерү бар. Балык тотарга эшчеләр җыялар.

— Син шул белдерүгә ышанып китәргә булдыңмы, тиле?

— Китәм, Галимулла абый, барыбер китәм. Яхшылык белән җибәрмәсәгез, качып булса да китәм.

Галимулла абый ишек төбеннән түргә узышлый кара калай белән тышланган мичкә шапылдатып сукты.

— Билләһидер, җибәрми идем мин сине. Аерылганны аю ашар, бүлengәнне бүре ашар, диләр. Бергә-бергә салган булыр идек әле йортыңны да. Сыерсыз да итмәс идек. Гипертония, дип котны алдың бит әле, понимаешь. Армиягә алмасалар, миңа үпкәләрсең тагын. Сез җибәрмә-

дегез, мена мин фәлән вакытта фәлән итә идем, җибәргән булсагыз, диярсең. Синеке дә дөрес. Яшь чагында бер дә мишәйт итми ул дөнья күреп, җилләнеп кайту. Йөргән таш шомара, яткан таш мүкләнә, диләр бит. Кем әйткәнди, җиргә мәхәббәте булган, җир эшенә күңеле яткан кеше китсә дә кайта ул. Адәм баласының җиргә мәхәббәте юк икән раз, чылбырлап куйсаң да кача. Дөрес әйтәмме?

— Дөрес,— дип мыгырдандым мин күзләремне ашалган сайгакларга текәп.

— Андин ары,— дип дәвам итте Галимулла абый минем мыгырдануыма әһәмият бирмичә,— ызба салырлык акча эшләрсеңме, юкмы киткән җиреңдә, хикмәт анда түгел. Бозык кешеләргә ияреп юлдан язмасаң, мондагы кебек тырышып эшләсәң, югалмассың, дим. Ә әңү билгеле, җиңел булмас. Цемент бушатып карадың ич әнә беркөннәрдә...

— Шуңа күрә ераккә китәм дә инде бу юлы, Галимулла абый. Кыен, дип борылып кайтырлык булмасын.

— Ярар, бездән — хәер-фатиха, дип әйттек, ди.— Галимулла абый минем янга килеп, кулларын иңбашларыма тиереп алды.— Ә гипертония дип котың очмасын. Кан басымы күтәрелеп киткән кешенең, понимаешь. Кемнең күтәрелми ул? Паспорт алып бирдек инде без сиңа былтыр ук. Бармадың бит умартачылыкка укырга, бал гына ашап ята идең менә хәзер умарталыкта. Нотфулла бабай ашына таракан булып төшмим, имеш. Тьфу, үзегездән дә акыллырак булып кыланасыз кайчагында. Аңа китсә, Нотфулла бабаң сиксәнне түгәрәкләде инде ул, бер аягы гүрдә, димәсәң... Карале, понимаешь, паспортың да булгач, безнең рөхсәтнең нигә кирәге бар соң әле сиңа?

— Әни кала ич монда, Галимулла абый.

Галимулла абый әрле-бирле йөрүеннән туктап, миңа озаклап, сынап, көлемсерәп карап торды да кулларын кәчтүн кесәләренә тыкты, телен шартлата-шартлата, айайли-айайли янә идән буенча китте.

— Ай-яй-яй-яй, күр әле син аны, хәйләкәрнең дә хәйләкәре икәнсең, әй. Төлке. Идарәдән рөхсәт сорый, имеш. Шулай, шулай, Галимулла абый, мин колхоздан качарга булдым, әнине ташламагыз инде, тәрбияләгез, карагыз, дип турысын әйтергә ярамыйдыр аны.

Тегесе баласы гына булган икән, менә кайчан башлана икән әле аның анасы! Йөземә искәрмәстән камчы белән суктымыни Галимулла абый! Тирләп чыктым хәтта. Нәрсә әйтим, дөрес сүзгә җавап юк, телемне тешләп, урындыгымда утыра бирдем.

— Кызарма, кызарып утырудан толк юк хәзер,— диде Галимулла абый һәм мине читен хәлдән коткарырга теләгәндәй, лампа филтәсен кысыбрак куйды.— Бер тәвәккәлләгәнсең икән инде, чигенмә. Мин шаярттым гына. Әниең әле үз тамагын үзе туйдыра ала. Аның өчен борчылма, ташламабыз. Үзең дә онытып бетермәссең. Кайтышыйк, иртәгә бәйрәм түгел.

— Рәхмәт, Галимулла абый!

Кечкенә булса да, кулы көчле икән Галимулла абыйның. Саубуллашканда бармакларымны өзеп чыгара, дип торам...

Инде төнге авыл урамында мин берьялгызым гына. Йолдызлар, йолдызлар. Бөтен күк гөмбәзе йолдызлар белән чигелгән. Әнә берсе атылып та китте. Кем йолдызы булды икән? Күктә һәркемнең үз йолдызы бар, имеш. Йолдыз атылгач, кемнең дә булса гомере киселә икән. Ә, миңа калса, йолдызлар кешенең шатлыгы булганга атылалардыр сыман. Шатлыгына чыдый алмый кешеләр, менә шуңа күрә аларның күңелләреннән йолдызлар атыла.

Минем шатлыгым гади шатлык кына түгел. Минем шатлыгым ямансу, минем шатлыгым сагышлы шатлык. Ныклабрак уйлап карасаң, шатлык хисе дә түгелдер әле бу. Ә нәрсә булсын шатлык булмыйча! Шатлыгы булмаган кешенең йөрәге шулай сулкылдап тибә ди мени? Шат-

лыгы булмаган кешенең, кошка әверелеп, төнге авыл өстеннән очып үтәсе килә ди мени?

Кинәт кенә Түбән авыл ягында ялгыз гармун үксеп куйды. Минеке ич, минем гармун. Әле син дә исән мени, гармуным? Кичер мине, Саламтәрханны, күрешмәсәк, бәхил бул!

Әллә юри бер генә көй уйнадылар инде. Бик бирелеп тыңлап торсам да, таныш моң кабат ишетелмәде.

Гармунсыз гына җырлап карыйм микән әллә? «Поезд килә ду-ду-ду, Әлмәленең кызларына кланяться не буду».— дип җырларга Хәбир дә юк, ичмасам. Җырлатырсың хәзер Хәбирне. «Су асты кеймәсе моряры булганнан» бирле диңгез турында романнар гына укып утыра китапханәдә. Тагын бер елдан ерак диңгезгә китәсен күрше авыллар да белә хәзер. Кызлар турында әйткән дә юк. Алар Хәбирне «Моряк Хәбир» дип кенә йөртәләр.

Тукта, нинди җыр килгән иде соң әле тел очына.

Басмастында бала үрдәк,
Бодай сибик, симерсен.
Китик ерак, калсын елап,
Бер күрергә тилмерсен.

Тамак төбенә кайнар төер тыгылды. Тиле шикелле барам урам буенча, берни күрмим, берни ишетмим.

Кем тилмерсен, ә? Кемне тилмертмәкче буласың соң син ерак китеп? Тәслиманеме? Тилмерер инде бик! Исе китә сиңа Тәслиманең. Астыртын гына көлеп йөри.

Киткәнче, бер генә мәртәбә булса да, күреп каласы иде Тәслимәне. Китәм инде мин, дип әйтәсе иде хет.

Авыл уртасыннан кире борылганмын икән инде, Тәслимәләр тыкрыгына кереп барам.

Клуб ягында кемдер ваемсыз гына шаркылдап көлде. Доминочылар таралыша булса кирәк. Хәбир хәзер китапханәдән чыккандыр, Фирдәүсәсе тирәсендә сырпалана торгандыр инде.

Авыл тагын тынлыкка чумды. Юк, алай ук тын түгел икән лә әле. Кайдадыр зират агачлары артында бер хатын-кыз «әбәү мәхәббәтсез» дип тыелып кына хихылдап куйды. Шул якта леңгер-леңгер ир кешеләр сөйләшкәне дә ишетелде. Нишләп йөриләр икән, нигә йокламыйлар икән бу төнгә чаклы.

Тыкрык якты — тыкрыктан кермәдем бакчага. Төрле якка авышып үскән таллар астыннан инеш буенча төшеп киттем. Инеш буеннан бардым-бардым да рәшәткә башыннан Тәслимәләрнең бәрәңге бакчасына сикердем. Котырып үскән бәрәңге сабакларын аера-аера, абзар-куралардан читтәрәк агарып күренгән утын сараена юл алдым.

Тәслимә җәйнең җәй буе сеңлесе яки берәр иптәш кызы белән шул сарайның печәнлегендә йоклый иде. Бәлки, бүген дә шундадыр. Йоклаган булса, сулышын ишетермен, йокламаган булса, күз күрер әле.

Сарай артына баганалык туйралар өеп куйган Борһан. Рәхмәт инде, тырышкан. Килер әле бу егет, дип, минем өчен әзерләп куйган, диярсең.

Акрын гына агачлар өстенә мендем. Беравык тынлап тордым. Тавыш-тын юк. Кырпу астындагы киртәләрне күтәреп карадым. Аралап була. Киртәләрнең берсен суырып чыгардым. Калганнарын як-якка авыштыргаладым.

Эһе, баш сыйды. Борынга кипкән кузгалак исе килеп бәрелде. Шул чагында бөтенләй якында гына ишек шыгырдап ачылды.

— Тәслимә, кызым, салкын түгелме сезгә? — дигән елак тавыш ишетелде.

Беттем. Тәслимәнең әнисе Хәдичә апа. Борһан, хатынын йоклатмый

икән төнлә, кызларын каравыллата икән, дип сөйлиләр иде, тәки дөрес, ахры.

— Түгел, әни, түгел, туңмыйбыз.

Монысы Тәслимә. Димәк, чынлап та, монда икән Тәслимә. Монда, монда, монда! Кит инде, Хәдичә апа, туңмый Тәслимәң, мондый бөркүдә кеше туңа диме соң?

Их, Хәдичә апа, тәки китмисең бит, бигрәк үзсүзле икәнсең син дә...

— Шулай да таң алдыннан салкын булыр, алыгыз әле кызым менә бу юрганны.

Хәдичә апа чыжылдатып шырпы сызды. Печәнлек почмагындагы ак урын җирне, кызларның ялангач иңбашларына таралган толымнарын секундның күпмедер өлешендә күреп калдым да... Аннары аяк астындагы туйра баганалыкларның кайсыдыр читкә авышты, бакча сукмагына башта мин тәпәләнеп киттем, минем өскә саллы гына бер кирпә килеп төште. Ләкин аны-моны карап, тикшереп торырга вакыт юк иде — Хәдичә апа Борһанны уятканчы яки Тузикны өстереп җибәргәнче, сызарга кирәк иде биредән. «Кем ул, кайсы каһәр суккырысы йөри төн уртасында?» — дигән нәзек тавыш ишетелгәндә, сарайдан шактый ерак китеп өлгергән идем инде.

Ятам бәрәңге буразнасы арасында, ятам йөзтүбән. Куучы юк. Эт өргәне дә ишетелмәде. Тәмлерәк ашатканнардыр, йоклыйдыр, күрәсең. Бәрәңге сабаклары арасыннан башымны аз гына чыгарып карыйм әле, дигән идем — нәкъ минем аяк очында яфраклар кыштырдап китмәсенме. Борһан үзе яисә Тузиклары! Тузик булса, дөнья ярып чәңгелдәр иде. Димәк, Борһан үзе. Эләктем, каптым. Никләргә генә урамга чыгып йөгермәдем икән? Рәхим-шәфкать көтмә инде хәзер Борһаннан. Тукта, хатын-кыз тавышы ич. Хәдичә апа микәнни?

— Чык инде, Рәсим, күрдем бит.

Ходаем, Тәслимә бит бу... Яткан урынымнан торып йомшак туфракка тезләндем.

Миннән ике-өч адым гына тапталган бәрәңге сабаклары өстендә яланаяк Тәслимә басып тора. Эчке күлмәктән. Кашларын да, күзләрен дә чәчләре каплаган. Әллә йөгергән инде, әллә курыккан — сулышы тигезсез.

— Рәсим, тор!

Мин акрын гына тордым.

— Мин, мин, мин бит, Тәслимә... Мин китәм... Сине күреп саубуллашыйм, дигән идем...

— Әйдә, рәшәткә буенарак, монда әни күрер...

Беттем мин, җебедем, исердем, бөтенләй харап булдым. Тел тибрәтеп сүз әйтерлек тә дәрманым калмады.

Тәслимә мине һаман үзенә таба тарта, мин аяк терәп карышам.

— Кил, курыкма, якынрак кил, мин сине ашамыйм. Ә хәзер коч мине... Менә шулай... Иреннәрең яргаланып беткән... Мескенем, кыюсызым...

— Тәслимә, бәхетем минем, мин сине үлеп яратам...

— Беләм, Рәсим, беләм. Таш йөрәкле кыз икән бу, дип уйлама. Җибәр инде хәзер, җибәр... Әх!..

— Тәслимә, син елыйсың. Елама, зинһар. Югыйсә, минем дә елыйсыны китерәсең.

Тәслимә мине читкәрәк этәрде, йодрыклары белән күзләрен сөртеп алды.

Бәхет шулай буладыр инде, бәхет шуннан артык булмый торгандыр...

— Рәхмәт, Тәслимә,— дип пышылдадым мин тыелгысыз бер кайнар-

лык белән.— Минем моңарчы беркемне дә үпкәнем юк иде. Ишетәсеңме, Тәслимә?

— Ишетәм, Рәсим, ишетәм. Синнән дә әйбәт егет юк авылда, ә хәзер мине тыңла. Авылдан китәргә йөргәненне белмәсәм, чыкмаган да булыр идем мин синең яныңа бүген. Син дөреслекне белеп китәргә тиеш, Рәсим... Син әйбәт егет, ләкин... ләкин... ничек әйтим, ничекләр аңлатыйм икән. Синс тиз генә яратып китә алмамдыр кебек тоела иде миңа. Рәсим. Хәзер чынлап төшендем: шулай икән, дөрес сизгән икән күңелем... Хәтерлисеңдер, яз көне Әхмәт абый кайткан иде отпускага... Офицер Әхмәт абый. Син, Рәсим, зинһар эллә ни уйлый күрмә. Ләкин... тыкрык очында Әхмәт абыйның шинеле шәйләнү белән һуштан язар дәрәҗәгә килеп дулкынлана идем мин. Әхмәт абыйның киемнәреннән килгән исне клуб ишеген ачмас борын тоя идем. Әхмәт абый погоннарындагы йолдызлар бер генә кызның да буе җитмәслек биек булып тоела иде миңа. Аннары, курка идем мин Әхмәт абыйдан, очраша башласак, яшь усак яфрагы кебек дерелди идем. Ул клубта чакта беркайчан да беркемгә дә авыз ачып бер сүз катканым булмады минем. Авылга ул кайтып ул киткәнче суны Чишмә тыкрыгыннан әйләнеп ташыдым. Хәзер менә, үтер, аның күзләре нинди булуын хәтерләмим. Безнең күзләребез беркайчан да очрашмады. Белмим, Рәсим, белмим, бу хакта дус кызларыма да, сердәшләремә дә сөйләмәгән идем әле. Димәк, сине дусларымның барысыннан да дусрак итәм, якынрак күрәм. Мәхәббәт түгел бугай бу, Рәсим. Мәхәббәтне узмый торган чир, диләр бит. Ә бу акренләп уза. Узганына сөенәм дә мин аның. Әхмәт абый миннән күп яшькә олы бит. Ул киткән көннәрдә бик ямансыладым шулай да. Кичләрен урамга чыксам, һавадагы йолдызларның һәркайсы Әхмәт абый погоннарындагы йолдызлар булып күренә иде. Боларны сөйләгәнем өчен ачуланма син. Кыен яшәдем мин быел, хәзер дә җиңел яшәмим. Сине дә кызганам. Ләкин нишлим? Шәт, әле син дә кайчан да булса минем кебек кыен яшәрсең, шәт, әле син дә кыен яратырсың...

Мин, чигәләрем кызышуын тоеп, беркавым рәшәткәгә сөялеп тордым да Тәслимәгә таба атладым.

— Син ни сөйлисең, Тәслимә?! Мин сине кайчан ярата башлаганымны хәтерләмим дә инде... Тәслимә, син ни сөйлисең? Телисеңме, Тәслимә, мин китмим. Син мине яратсаң, миңа бернәрсә дә кирәкми. Мин синең өчен менә хәзер үк үләргә риза...

Минем Тәслимәгә сузылган кулларым һавада асылынып калды — Тәслимә артка чигенде, үзәк өзгеч итеп сулкылдап куйды.

— Сөйләмә, Рәсим, кирәкми, сөйләмә. Онытырмын мин Әхмәт абыйны, барыбер онытырмын. Син минем яныма бер елдан, юк, ике, өч, дүрт, биш елдан кайт. Ул чагында онытан булырмын инде мин Әхмәт абыйны. Грин китабындагы яшь капитан кебек ал җилкәннәр корып кайт син минем яныма. Мин сине иртәнге зәңгәр томанда саф күңелле Ассоль кебек кулларымны сузып, елмаеп каршыларммын. Син бик юаш, Рәсим, кыюрак бул, яме. Ә хәзер хуш, хуш, Рәсим...

Тәслимә, учлары белән яңакларын кыскан көе, кисәк кенә кузгалып, өйләренә таба йөгерде.

Исемә килгәндә мин тагын йомшак туфракка тезләнеп тора идем. Тырнакларымны учларыма батырган хәлдә, караңгы бакчага, аннары йолдызлы күк йөзенә карадым. Тавышсыз гына тагын бер йолдыз атылды.

— Ярата! — дип кычкырып атылды бугай ул йолдыз. — Тик сине түгел. Онытмаячак ул аны. Тиз генә онытмаячак!

Кычыткannар чыштырдатып, рәшәткә буеннан абына-сөртенә атлаганда, Түбән авыл ягында тагын минем гармун сызланып куйгандай булды.

Чөеп кенә капканы ачтым, чөеп кенә чолан, өй ишекләрен ачтым. Мич каршыннан лампаны табып калтыранган кулларым белән филтәсенә ут кабыздым.

Әнинең ястык өстендә яткан тамырлы беләкләренә, яулык читеннән таралып чыккан сирәк чәчләренә, ярым йомык керфекләренә бер генә күз төшереп алдым да, ярсуымны тыеп:

— Әни, мин китәм! Бүген үк, хәзер үк китәм,— дидем.

Әни йөзен минем якка борды, башын күтәрде, ябык терсәкләренә таянды. Авыз эченнән генә нидер укынып алды да миңа ишетелерлек итеп:

— Бәндәнең ниләр күрәчәге алдан ук маңгаена язылып куела икән. Шуларны башыннан кичермичә, бәндә гүргә керми икән. Аллага тапшырган, ни язган булса, шуны күрербез,— диде.

## Урак өстендә безнең шахтада

Кызык яши икән вагонда халык. Өсталләрендә шешәләр, ачылган консервалар, алмалар, әфлисуннар, тагын әллә ниләр — ну, ашап та күрсәтәләр икән. Ак җәймәләргә төренеп гырылдауларын күр әле син аларның — буржуй кебек йоклыйлар.

Итекләремне эләктереп китмәсеннәр тагы. Калырсың аннары авыз ачып. Өске ятактан сузылыбрак карадым да, таныш итек кунычларын күргәч, чалкан әйләнеп яттым. Бер дә каты түгел әле. Әнә ничек сәлендереп кенә бара. Шәһәр халкыннан урын-җир сорасаң әҗәрен түләп бетерә алмассың. Урын-җирсез дә бик әйбәт әле, бер дә кыек китми, көн артыннан көн үтеп кенә тора.

Зур икән Рәсәй, чынлап та. Ул дала, ул урман, ул авыллар, ул шәһәрләр, ул биек-биек чуен күперләр, ул дөм-караңгы җир асты юллары. Бер дә сөйләп-аңлатып бетерерлек түгел инде.

Карлыгач белән саубуллашмыйча киттем. Шунысы үкенечле. Кем җигәр икән инде хәзер аны? Картаеп та килә, берәр рәхимсезенә эләгеп, кыерсытып кына бетермәсәләр ярар иде.

Хуш, Карлыгач, хуш, сау бул!

Хуш, гармуным!

Кичерегез мине, Саламторханны.

Хуш, авылым!

Әни яктырыр-яктырмас авыл урамында, кошлары да, яфраклары да уянмаган тупыл төбендә басып калды.

Әни түзде, еламады. Яулык читен тешләп иреннәрен генә ныгытып кысты. Ә мин еладым.

Кайнар яшьләр, битләремне пешереп, коры тузанга тәгәрәштеләр, чайкалган уңайга, бәләкәй чемодан тоткан кулыма тамдылар...

Чемодан дигәннән, кайда соң әле ул бәләкәй чемодан? Иң түргә, әйбәт чемоданнар рәтенә куйганмын икән...

Вагонга станция саен яңа кешеләр керә, кичә яисә өченче көн утырганнары төшеп кала.

Чәчләре керпе энәләренә охшаган таза егет кенә Свердловск каласында ук утырган иде. Төшәргә исәбе дә юк бугай әле, һаман бара. Ресторанннан сыра шешәләре күтәреп килгән. Ә тәмәкене алып та тормый иреннәреннән. Сагыз кебек чәйни. Үзе кешеләр белән аралашмый, бер ялгызы уйланып утырырга ярата. Уйчан булса да, йокының көен китерә үзе мәгәр. Кичтән мендәренең урта бер җирен чокырайтып ята һәм бары тик иртә белән генә башын чокырдан чыгара. Чикләвек төше дә оясында шул кадәр җайлы ятмый торгандыр.

Бер көнне йокысыннан торып, тәмәкесен тартып кергәч, минем каршыма килеп утырды бу, тиктомалдан гына:

— Тартмыйсың, ахры? — дип сорады.

— Өйрәнеп булмый әле,— дидем мин сөйләшәсем килмичә генә.

— Безнең эштә бер көн дә чыдый алмыйсың тартмыйча,— диде таза егет ничектер мактаныбрак.

— Кайда эшлисен соң син?

— Кайда булсын? Диңгездә. Балык тотабыз.

Минем колакларым үрә торды. Нәкъ миңа кирәкле кеше түгелме соң инде бу?!

— Ерак Көнчыгыштамы?

— Әйе, безнең тагарак Находка портына терәлгән.

— Нәрсә соң ул тагарак?

Таза егет, әй, шуны да белмәскә инде дигәндәй, миңа сәерсенебрәк карап алды.

— Нәрсә булсын, судно. Судноны аңламасаң, траулер.

Тирә-юньдәге кешеләр игътибар итмәсен өчен, мин тавышымны бөтенләй акрынайттым.

— Ә кемнәрне алалар соң ул тагаракка эшкә?

Таза егет җавап бирмәде, әңгәмәне тәмамланганга хисаплап тәмәке тартырга чыгып китте. Мин дә тагылып чыктым. Фасон өчен генә бер папирос алып кабыздым. Теге егет, эре тешләрен күрсәтеп, көлде.

— Тартмыйм, дигән була, бич! Кеше ышандырырсың.

Мин берничә мәртәбә тәмәке төтененә тончыксам да, сер бирмәдем:

— Ташлаган идем, дә яңадан башларга исәп,— дидем.

— Исемең ничек?

— Рәсим.

— Фамилияңне сорамыйм ич мин, исемеңне сорыйм.

— Исемем Рәсим.

— Расин? Һе, кызык исем. Ә минеке Жора.

— Сезнең пароходка эшчеләр кирәкмиме, Жора?

— Матрослар, диген, Христофор токымы!

— Әһе, матрослар.

Жора, мине әле генә күргәндәй, башымнан аягыма кадәр карап, тикшереп чыкты.

— Ә моңа кадәр кайда эшләдең соң әле син?

— Кол... әйм, шахтада?

— Бр-р,— дип иңбашларын калтырандырды Жора.— Тау кадәрле алтын бирсәләр дә эшләмим мин җир астында.

— Диңгездә рәхәтрәк, билгеле,— дидем мин тәмәке төтенен борын тишекләреннән пошкытып.— Саф һава...

— Рәхәт сиңа,— диде Жора, чәнчә бармагы белән папиросының көлен каккалый-каккалый,— штормга эләксәң, үпкә-бавырларың авызыңа килә, үзең мүкләнгән таш кебек яшелләнеп катасың. Балык сезонында нибарысы өч сәгать йокы эләгә безгә.

— Анысы, урак өстендә безнең кол... әй, безнең шахтада да... күмер сезонында йокы белән булышырга ирек бирмиләр.

— Шуңа күрә качкансыңдыр әле шахтадан.

— Туйдырды һаман-һаман бер урында эшләү.

— Дөрес әйтәсең. Диңгездә дә туйдыра. Диңгездә ярны сагынасың. Ярга чыккач — диңгезне.

— Син тәки әйтмәдең әле, Жора, сезнең пароходка барсам, эшкә алырлар микән мине?

— Белмим шул,— диде Жора.— Команда ничектер бит, тулгандырмы, юктырмы. Ремонтта тора әле ул безнең тагарак. Мин үзем отпускадан гына киләм.

Жора тәмәке төпчеген тимер иләнгә салып таптады да җиз пераш-

кәсен төзәтеп куйды. Телняшкасын сыпыргалады. Сүзләрен теш арасыннан гына сөзеп чыгара-чыгара:

— Отдел кадрга барып карарсың, может алырлар. Безнекенә булмаса, башка суднога. Шахтерлар нык халык, ник алмасыннар икән? — диде.

Мин эчемнән генә, була инде болайга киткәч, дип уйладым. Әмма сөенүемне Җорага сиздерәсем килмәде. Ирен очларым белән генә сызгыргалап:

— Ну, парень, тельняшкаң зәһәр дә соң! — дидем.

— Минем әле моннан калынрагы да бар,— диде Җора тельняшкасына сокланып карый-карый,— анысын кыш көне киям. Ярда торганда каюталар салкын була безнең. Двигательләр эшләсә генә җылына судно. Баргач, үзең күрерсең әле менә. Дракон рөхсәт итсә, кунып та чыгарсың. Драконның кәефле чагына туры килүеңне телә инде. Кәефле чагында фәрештә безнең дракон. Ә настроениесе булмаса, у-у-у, акула.

— Кем соң ул дракон?

— Боцман, кем булсын. Палуба патшасы. Кэп — капитан, чиф — капитанның өлкән ярдәмчесе, дед — өлкән механик, ревизор — икенче ярдәмчесе...

— Безнең шахтада алай түгел.

— Шахта — шахта инде ул,— диде Җора сөйләшәсе килмичә генә.— Ә бу — диңгез. Әйдә, капкалап алыйк та йокы симертик. Диңгездә сагынып сөйләргә генә кала мондый рәхәтләрне.

Ярты төнгә кадәр әле тегеләй, әле болай боргаланып ятканнан соң, азрак изрәп киткәнмен. Җора төртеп уятты:

— Нәрсә син, бөтен вагонга шәрран ярасың. Кем соң ул Таслима? Чувихаң что ли?

Төш күрмәдем бугай ич. Саташып кычкырдым микәнни?

— Әнә диңгез,— диде бераздан Җора һәм киң маңгаен таң нуры алсулаткан пыялага терәде.

Яткан килеш кенә ашыгып пәрдәне күтәрдем. Каршымда ялангач таш кыялар белән уратып алынган яп-якты алсу-зәңгәр киңлек ачылып киткәч йөрәгем кысылып куйды. Кайда икән соң монның чиге? Әллә һавага ук менеп киткән инде... Офыкка күпме генә текәлеп карасам да, су белән күкнең кушылган урынын тапмадым.

## Шулай була ул

— Драконның кәефле чагына туры киләсең,— диде Җора йорт капкасыннан кереп причалларга таба атлаганда.— Ишетәсеңме гитара тавышын? Безнең дракон бәйрәм итә.

Мин гитара тавышын ишетмәдем. Чөнки гаҗәпләнүем чиктән ашкан иде. Булса да булыр икән бу кадәр кораб! Күр инде яр буенда чайкалып торган мачталарны — урманмыни! Корабларның кайберләрендә шым да юк, палубаларында кеше-фәлән күренми. Кайберләреннән бөтен яр буена музыка тавышы агыла. Өсте майланган шикелле ялтырап торган диңгез култыгының теге ягында тагын да зуррак кораблар тезелеп киткән. Әкиятләрдәге гыйфритләрне хәтерләткән пәһлеван краннар, салмак кына хәрәкәтләнеп, яр буена әле теге якка, әле бу якка йөреп торалар. Тау битендә ап-ак йортлар тезелеп киткән. Никадәр алар! Шундый матур йортларда яшәүче кешеләрнең дә йорт салу кайгысы булдымы икән?

— Нәрсә карап каттың, киттек тизрәк, чиф килгәнче дракон белән танышып кал,— дип мине бетон причалларның берсенә әйдәде Җора.

Килеп туктадык бортларын чем-карага, мачталарын һәм палубадагы

корылмаларын ап-акка буяган кораб янына. Палубадагы причалга трап сузганнар. Трап төбендә минем яшьләрдә булырмы юкмы, һәрхәлдә буйга миннән дә тәбәнәгрәк бер егет кисәге күкрәк киереп каршы алды безне.

Бер-берсенең иңнәренә шап-шоп бәргәләшеп, сәлам Жорик, чучка танау, Петя, бетле карга, сине күрер көннәр дә бар икән диешеп үзләренә генә таныш булган «ярату» сүзләренә һич тә саранланмыйча күрештеләр болар.

Күрешү тантанасы тәмамлангач, Жораның «бетле каргасы» башын минем якка борды.

— Ә сиңа ни калган монда, авыл гыйбаты? Юлында бул. Нәрсә бәбәкләреңне акайттың? Мотай моннан, мотай!

Жора эре тешләрен ялтыратып алды да Петянең бөеренә җиңелчә генә төртте.

— Авыл гыйбаты түгел ул, Петя. Шахтер. Минем кореш Расин. Пароходка урнашырга килде. Дракон үзендәме?

Мине борып чыгара алмавына кәефе китте бугай Петяның — Жорага да, миңа да карамыйча гына очлы нәкен мачта ягына чөеп алды.

— Ишетмисеңмени?

Шул чагында гына минем колагыма гитара, җыр тавышлары килеп керде.

Жорадан бер адым да калмаска тырышып, палуба буенча киттем. Үзышлый өсләре ачып ташланган трюмнарга карап алдым. Тимер баскычлар... Тукта инде, безнең авыл кибетендә дә һәрвакыт шундый ис була түгелме соң? Кибет исе түгел бу, тозлы балык исе. Трюмнары тирән икән. Берсе-берсе ике-өч силос базы кадәр.

Озын мачтаны урап үттек тә, түгәрәк тәрәзәле тимер ишектән кердек тә, текә баскыч буенча даңгыр-доңгыр төштек тә бәләкәй рам эченә «Боцман» дип язылган ишек янына килеп туктадык.

Жора төрттеме әллә ишек үзе ачылып киттеме — икенче мәлне минем каршымда бөтен җиһазлары — драконнары белән каюта ялтырап тора иде инде. Ике түгәрәк тәрәзә, — нәрсә сөйлим, корабта тәрәзә буламыни,— ике иллюминатор арасында көнбагыш чәчәгедәй сап-сары чәчле, сап-сары сакаллы, кып-кызыл йөзле, баһадир гәүдәле агай үз алдына елмаеп гитара чиртә,-ап-ак тешләрен күрсәтеп, күзләрен сары керфекләр арасыннан елтыратып җырлый:

Бродяга к Байкалу подходит,
Рыбачью лодку он берет.
И грустную песню заводит,
Про Родину что-то поет...

«Про Родину что-то поет»,— дип кабатлый да балан капкан шикелле борынын җыера, чыраен сыта, күзләрен бөтенләй кысып бетерә, борыч кузагы кебек кызарган колагын гитара кылларына тиереп-тиереп ала. Аннары тагын елмая, шул ук җырны яңабаштан җырларга керешә.

Каюта диганнәренең җиһазлары поезд вагонынынкына охшаганрак икән лә. Стенага беркетеп куелган өстәл, агач диван. Түшәмдә пешәрпешмәс күкәй агы сыманрак төссез, яссы лампа. Ике якта ике ятак. Икесенең дә читләрендә тимер киртә. Давыл вакытында мәтәлеп төшмәскәдер, күрәсең.

Дракон диганнәре безне ишек төбенә бастырып, үзенең җырлаганын хәйран гына вакыт тамаша кылдырып торды. Гитарасын элеп куйгач та әле ул, бармакларын берничә мәртәбә һавада тибрәлдереп алды, аннары гына, олы гәүдәсен төз тотып, аяк өстенә басты. Ул кырык бишле үк булмаса да һич тә кырык дүртледән бәләкәй булмаган итеген чак кына кыймылдатып куюга, бөтен пароход чайкалып киткәндәй тоелды миңа.

Жора драконга кулын сузды. Сүзсез генә күрештеләр. Жора минем якка ымлады:

— Минем кореш Расин. Шахтер. Пароходта урнашырга исәбе.

— Я, Жора, ничек анда сезнекеләр? — диде дракон минем якка күз дә салмыйча, үзе койка астын ачып, буш шешәләр тутырылган чиләкне минем тарафка шудырып җибәрде.— Әйт әле Жора, корешыңа, буш шешәләрне илтеп тапшырсын. Сыра алып кайтсын.

Жора чиләкне тиз генә иелеп алды да мине ачык ишеккә сөйрәде, тышкы яктан ишекне япкач, ашыга-ашыга аңлатырга керешге.

— Ирләр җыелып калды бит әле юл буенда, шуннан ерак түгел, сопка итәгеннән генә сыпыртырсың.

Мин курка-курка гына палубага күтәрелдем. Жора тимер ишектән башын тыгып, Петяга кычкырды:

— Кертерсең корешны. Дракон ягулыкка җибәрде.

Табуын таптым пыяла савытлар кабул итә торган урынны да, сыраханәне дә. Әмма ләкин шешә саткан акчаң бер чиләк сырага җитмәде. Юлдан калган вак-төяк акчаларны кушарга туры килде.

Нишләсәм дә эшләдем, тик барыбер бер чиләк сыраны дракон каютасына алып кайтып утырттым.

Дракон беркавым мөлдерәмә тулы чиләк читеннән агып төшкән күбек юлларына гаҗәпләнебрәк карап торды. Берничә мәртәбә чиләк тирәли әйләнеп чыкты. Аннары гына миңа күз сирпеде. Бер сирпеде — һм, дип куйды. Ике сирпеде — вот даешь, диде. Өченче сирпеде — свихнулся парень, диде. Дүртенче мәртәбә күз сирпегәч кенә, сары сакалын биетеп, көләргә тотынды.

— Ха-ха, ха-ха, ха-ха-ха, уф, үләм! Жора, син кайда? Кер әле монда. Кемне алып килдең син пароходка?

Көтеп-көтеп тә Жора күренмәгәч, дракон керфекләреннән минем якка сары ялкын бөркеде.

— Шахтер түгел, шалопай син, белдеңме? Шахтерлар алар чешский сыра гына чөмерәләр. Ә син бурда күтәреп кайткансың. Әйт дөресен, авылдан килдеңме?

— Ие,— дидем мин драконга күтәрелеп карарга кыймыйча.

«Бетте баш, бер чиләк кенә җитми микәнни бу бирән зәхмәтенә?»

— То-то,— диде дракон бераз тынычлана төшеп.— Мин сине шешәле сырага җибәрдем.

Дракон, әй, бернәрсә дә аңламыйсың ла син барыбер дигәндәй, кулын селкеде дә чиләкне учлары арасына кыстырып югары күтәрде, сакалын чиләк читенә терәде һәм, сусаган сыердай озак итеп, тәмләп эчеп-эчте дә башын калкытты.

— Эчәсеңме?

— Эчмим,— дидем мин бер урында таптангалап.

— Утыр.

Дракон әйткәч утырмыйча ярамас. Әдәп саклап кына диван читенә терәлдем.

— Курыкма, авыл егете булгач, диңгездә эшли аласың син. Авыл егетләре нык була. Мин үзем дә авылныкы. Ишеткәнең юкмы, Байкал артында Степное дигән хутор бар.

— Юк, ишеткәнем юк. Татарстаннан мин, Уралның теге ягыннан.

Дракон сакал белән мыек арасына озаклап сыра койды да чиләген өстәлгә куйды һәм:

— Авыл егетләре нык була,— дип кабатлады.— Кадрлар бүлегенә баргач, әйтерсең, 346 нчының боцманы Грегус Георгиевич җибәрде мине диярсең. Инспекторга исеме белән эндәш. Фрол Никитич, менә мине шул пароходка алмакчы булалар, диген. Исеме белән эндәшкәнне ярата картлач.

Миннән дә бәхетле кеше бар микән бу дөньяда, билләһи. Барысы

да мин дигәнчә генә бара бит әле. Юкка гына куркытып маташкан мине Җора. Бик әйбәт, бик игелекле кеше ләбаса бу Грегус Георгиевич.

— Инспекторның күңеленә хуш килсән, ул сине бүген үк комиссиягә җибәрер. Мин монда чиф белән сөйләшеп куярмын.

— Нинди комиссия? — дип аяк өстенә сикереп тордым мин.

— Әллә дөньяга бүген генә тудыңмы? Нинди комиссия булсын. Медицина комиссиясе.

— Ме-дицина?

— Нәрсә булды сиңа?

— Ни бит әле минем... Теге ни... басым... кан басымы югары...

— Һи, булса соң, подумаешь,— диде Грегус Георгиевич гитарасына үрелеп.— Кичтән сыра эчкән идем, диярсең.

Беттем бугай мин. Нинди матур башланган көннең яме китте. Аяккуллар сау булгач, ике күзең, ике колагың урыннарында торгач, шул җитмәгән микәнни эшкә кергәндә. Армиягә алалар диярсең. Харап итте бу хәбәр мине, тирләп чыктым, тез буыннарым тотрыксызланды.

Кадрлар бүлеген Җора күрсәткән иде инде килешли. Халык алай ис китәрлек күп түгел. Безнең авыл кибетенә керосин кайткач моннан озынрак була чират.

Тирә-ягымда шау-шу. Диңгез турында, пароходлар турында, кайсы капитанның күпме балык тотуы турында сөйләшәләр. Ә минем бәгырьне «Комиссиядән үтмәсәм, нишләрмен?» дигән аяусыз сорау пәра-пәра телгәләп тора, кешеләрнең йөзләренә карарга, сөйләшкәннәрен аңларга ирек бирми. Юлга чыкканда берәрсеннән сорашмаганмын да, ичмасам. Галимулла абый да белмәде микәнни? Станциядә цемент бушатырга комиссиясез генә алган иде бит әле Нурулла. Монда нишл... ярамый икән?..

Төш җитәрәк мин дә бәләкәй тәрәзә каршына килеп бастым. Йөзе голландский этәчкә охшаган икән Фрол Никитичның. Борын очы аска кәкрәеп тора, яңаклары ябык, авызы зур. Колак яфраклары ирен читләренә кадәр шәлперәеп төшкән. Күзлек кысасы кызгылт, пыяласы карасу-көрән.

Ни генә яза икән бу кеше? «Эшкә керергә килгән идем», дип тә әйтеп карадым бит инде. Җитмәсә арттан төрткәләп торалар. Нәрсә терәлеп каттың анда, бич, йомышыңны йомышла да тизрәк сыпырт тәрәзә төбеннән, диләр.

— Фрол Никитич!

— Тыңлыйм!

Юан ручка минуты-секунды белән өстәл буенча тәгәрәп китте. Әтәч күзләре сыман күзлек пыялаларына кызыл ут кабынып сүнде.

— Мине Грегус Георгиевич җибәргән иде. Аларга бер матрос кирәк икән...

Фрол Никитич паспортымны сыңар кул белән генә актарып чыкты да өстәлгә ташлады.

— Пропискаң югын беләме соң Грегус Георгиевич хет?

— Белә.

— Без вакытлыча гына кертә алабыз пропискага.— Фрол Никитич тәрәзә төбенә эреле-ваклы берничә бит кәгазь алып ташлады. — Тутыр менә шуларны. Яр буе урамы, алтмыш сигезенче йорт, пропискага кергәч, шәһәр больницасында, комиссия үтәрсең. Ике-өч көннән пароходыгыз китә, йоклап йөрмә.

«Комиссия» сүзен ишетү белән янә коелып төштем. Кәгазьләрнең берсе кулымнан ычкынып, ачык тәрәзәдән очып китә язды. Ярый әле аны беләгенә кара тушь белән җилкәнле кораб рәсеме ясалган һәм «Газиз әниемне онытмам» дип язылган озын егет эләктереп өлгерде.

Кәгазьләрнең барысын бергә пинжәк кесәсенә бөтереп тыктым да, коридорда тәмәке пыскытучыларны ырып-ерып, саф һавага чыктым.

Комиссиясез бер җиргә дә эшкә алмыйлар микәнни монда? Рәхәт тә булган икән колхозда. Бернинди прописка кирәкми, бернинди комиссия.

Диңгез култыгы буйлап сузылган тар урам буенча бара торгач, итле сумса сатучыларга тап булдым. Үсемлек мае исе бөтен тамак юлларын, ашказаны стеналарын кытыклап узды. Көннәр буе болай ач йөри башласаң, билгеле, кан басымы тиз күтәрелер. Авыз суларын тыярга тырышып, бер кочак сумса сатып алдым да диңгез буена төшә торган тыкрыкка борылып кердем, телеграф баганасы төбенә чүгәләп «урырга» тотындым. Бер сумса өч мәртәбә кабарга җитми, икедән арта. Барысы ун сумса икән. Димәк егерме биш-егерме алты мәртәбә кабып чәйнім дигән сүз.

Соңгы сумсаны кабып йоткач, ашказаны бераз тынычланган сыман булды. Дөнья түп-түгәрәк. Хәйруллага бурыч түлисе юк, өй түбәсе ябылган, кышлык утын туралып өелгән, печән җитәрлек. Галимулла абый ачуланып калмады. Ни кирәк тагын миңа? Комиссия генә эчне пошыра, чәнчелгере. Юк, комиссия генә түгел, нишләп комиссия генә булсын... Үптем микән соң мин теге чакта Тәслимәне?.. Әллә татлы төш кенә булдымы ул?

Җебегән, җебеп торыр вакыт бит хәзер! Ач йөрү бик килешә сиңа. Ашказаныңны майлы сумса белән дыңгычлап куйгач, шулай була ул, кызлар турында уйлый башлыйсың.

Үз-үземне шулай тирги-тирги, шаулы урамга күтәрелдем, 68 нче йортны эзләп киттем.

Пропискага керүе кыен булмады. Поликлиникада «колак-тамак-борын», «күз» врачларына да җырлый-җырлый гына кереп чыктым.

Бал суыртасы көнне ачык умартага пош-пош төтен җибәртәләр бит әле. Терапевт кабинетында шундый тавыш ишетелгәч үк, баш очымнан ачулы безелдәп бал кортлары очып әйләнгәләндәй, куырылып кердем.

Яңакларын, маңгаен пәрәвез җепләре сыман вак кына җыерчыклар каплаган, карасу-көрән иреннәренең урта бер җире кишер-сарыга буялган олы яшьләрдәге хатын аппаратын берничә мәртәбә пош-пош китерде дә беләгемдәге тасманы чишеп кенә түгел, йолкып алды.

Бая ашаган сумсаларның кайсыдыр тамак төбенә менеп кысылды. Беттем икән, дигән уй бәп-бәләкәй чынаяк тәлинкәсе кадәрле генә калган өметем өстенә күтәрелде. Дөпелдәп төшәчәк тә тукмак менә, нәфис чынаяк челпәрәмә килеп тетеләчәк. Ул арада врач мин тотып кергән язуга нәрсәдер сырлап, ручкасын халат кесәсенә тыкты, кәгазьне өстәл читенә шудырып җибәрде.

— Ярабби, ходаем, шул балыкчыларның эчмичә йөргән көннәрен күрермен микән бер?! Диңгезгә кереп тозланалар да ярга чыгып спиртләнәләр. Башка бер эшләре дә юк. Хет комиссиягә эчеп килмәсен иде кеше.

Йөрәгем бер генә секундка тукталып torgандай булды да ярсыйярсый тибәргә кереште.

Өстәл читендә яткан кәгазьне эләктереп, ишеккә ташландым. Коридор тәрәзәсе янына барып, иҗекләп укыдым. Менә бит яшел кара аныкы. Здоров, дип язган. Здоров! Димәк, мин диңгездә йөзә алам. Су асты көймәсенә ярамасак та, су өсте көймәсенә ярыйбыз икән бит әле!

Нинди якты бина бу! Урамда нинди яктылык! Агачлары нинди күркәм, таулары нинди нурлы, диңгезе нинди серле! Адәм балалары яши торган җир кисәге түгелдер лә бу, җәннәтнең күркәм бер почмагыдыр.

Пароходка мин кичкырын гына кайтып кердем. Бу юлы трап янында погонсыз гимнастеркалы, йолдызсыз пилоткалы, шат чырайлы чибәр егет басып тора иде.

— Грегус Григорьевич сиңа язуларың белән өлкән ярдәмчегә ке-

рергә кушты,— дип каршы алды мине шат чырайлы егет.— Таныш булыйк, беренче класслы матрос Володя Шаляпин. Одессадан. Вова дип эндәшерсең.

— Казаннан. Расин.

Бу егеткә Рәсим, дип әйтсәң дә, аңлар иде, мөгаен. Хәер, Расин нигә ярамаган? Ун күгәрчен арасында бер карга булып йөргәнче Расин тек Расин... Жора, Вова, Петя, Расин... Нигә? Бик әйбәт компания ич?..

# Җәннәткә эләктем бугай

Әле кичә генә яр буенча чатырдай тезелгән сопкалар озата барган иде безне. Бүген инде алар да күмелде...

Сау бул, жир, киттем мин синнән. Миңа гелән-гелән елмаеп, ачык чырай күрсәтеп тормасаң да, ышанычлы идең әле син. Теләсәм, туган авылга җәяүләп тә кайтып китә ала идем әле мин синең баганалы юлларыңнан, якты сукмакларыңнан.

Еракта калдың, бик еракта калдың, жир. Кайсы якка гына күз салсам да зәңгәрле-яшелле су да су, су да су бүген.

Траулер артыннан күбекләнеп су чылбыры сузылган, кызыл флаг талпына-талпына җилферди, мачта очларына тияр-тимәс акчарлаклар уйный.

Траулерда гадәти эш көне, һәркем үз шөгыле белән мәшгуль. Тралмейстер белән неводчы — бертуган Семахиннар трал күзәнәкләрен тикшерәләр, чуен ядрәләргә охшаган чем кара калкавычларның җепләрен ныгыталар. Палубада чыгырлар әйләнә, трослар выжылдый. Миңа койрыктагы күперчеккә тезелгән мичкәләрнең кыршауларын ныгытырга кушканнар иде. Мичкәне әле тегеләй, әле болай әйләндерә-әйләндерә чүкеч белән даң-доң суккалыйсың шунда кыршауларга. Бер кыенлыгы да юк. Мондый эшләрне генә колхозда без...

Шулай уйлый-уйлый, акчарлакларны күзәтеп торганда, тавыш көчәйткеч аша:

— Боцман, матросларың күңелсезләнә,— дип кычкырдылар.

Озак та үтми ботдекта Грегус Георгиевичның сары сакалы җилфердәде.

— Трюмга төшик әле, Расин. Буш мичкәләрне чыгарып җиллätергә кирәк.

Мин берсүзсез генә боцманга иярдем. Җиңелчә генә чайкалган палуба буенча Жоралар, Петялар шикелле аягымны ерыбрак атларга тырыштым. Югыйсә, күперчектән штурманның күзәтеп торуы бар. «Бу нинди адәм имгәгеп алганнар безнең пароходка, тигез палубада да йөри алмый»,— дип көлмәсен әле.

Трюм авызына килеп, тимер баскыч буенча аска төшеп киттем. Борынга янә безнең авыл кибете исе килеп бәрелде, өстә «майна» дигән тавыш ишетелде. Минем арттан ук трюмга очына тимер ыргаклар беркетелгән нәзек трос төште.

Нишләргә икән соң бу ыргаклар белән? Ыргаклар белән нишләсеннәр, ыргакларны эләктерәләр инде. Менә бит, мичкә башларына эләктерәсең дә...

— Вирамы? — дип кычкырды өстән Грегус Георгиевич. Вирадыр инде мичкә эләккән ич.

— Вира, вира! — дип шәрран ярдым мин, аллага тапшырып.

Монысы да «батты».

Трюм төбенә ике кат мичкә тезелгән иде. — «вира-майна» дип кычкыра торгач, мичкәләрнең беткәнен сизми дә калганмын.

Мин якты палубага күтәрелгәндә, икенче трюм авызында «вира-майна» авазлары бик еш ишетелә иде әле.

— Тиз тоттың, молодец, — дип мактап куйды үземне Грегус Георгиевич.

Боцман койрыкка киткән арада, икенче трюмнан чыккан мичкәләрне ычкындырып торучы юантык матрос миңа пышылдап өлгерде:

— Сөйкемле сөягең бар, ахры, синең, дус кеше: дракон яратты үзеңне. Юкса, яңа матросларны бик коры тота торган иде.

— Бер каютада яшибез бит.

— Әһе! — дип бал кашыгы кадәрле көмеш тешен ялтыратып алды юантык матрос, — Җора да аның белән бер каютада яшәгән иде дә әнә... Тиргәлмәгән көне булмады Җораның.

— Ни өчен тирги иде соң ул аны?

— Тиргәсәң тиргәп кенә торырлык инде, хәер, аның Җорасын да... Тралмейстерлар трал төшергәндә бер тиешсезгә палубада буталып йөри. Ваерларны тарттырып, палубага балык өелә башлагач, гальюнга йомышын үтәргә кереп китә дә сәгатьләр буе чыкмый...

Куперчек тәрәзәсеннән вахтадагы матросның ерак офыкка төбәлгән житди йөзе күренә. Куперчектән штурманнар үтеп-сүтеп йөри. Радиорубка ишеге ачылганда «Мин—85, минем арттан барыгыз», «Мин—50, мин — 50, элемтәгә керәм» шикелле өзек-өзек авазлар колакны ярып үтә.

Бер заманны палубага яңа пешкән ипи исе таралды. Нәкъ өйдәге кебек, нәкъ өйдәге кебек. Тирә-юньдә агачлар да, өйләр дә күренмәгәч, әллә ничек, сәер тоела икән ипи исе. Менә кайсыдыр бер ишек ачылыр да палубага, бизәкле алъяпкычын бәйли-бәйли, әни килеп чыгар кебек.

Яңа ипи исе юкка гына кытыкламаган икән авыз-борыннарны. Кают-компаниягә кереп, тезелешеп утырырга да өлгермәдек, дневальный Марфа апа тәлинкә-тәлинкә өеп яңа ипи чыгара башлады. Һәр кисәге пар бөркеп, менә мине кап, дип тора инде җанкайларымның.

Аш пешерүчебез — аны монда кок дип йөртәләр икән — украин егете Довыденко үзе салган ипи кебек эшкә хәйран уңган. Тугызынчымы, унынчымы тапкыр ашыйм траулер салонында — әбәт саен яңа ризык. Авылда халык, кәбестә шулпасы, дип мыскыл итебрәк сөйли иде. Һе, булыр сиңа кәбестә шулпасы! Пешерә белсәң, кәбестә шулпасыннан да тәмлерәк аш юктыр дөньяда. Ә боткалары тагын! Кичә карабодай боткасы ашап рәхәтләнгән идек. Бүген төшке ашка, пожалсты, ит туралган тары боткасы. Җир йотсын, җәннәткә эләктем бугай мин. Әбәттән соң кояш төссезләнебрәк калды. Күк гөмбәзе дә иртәнге зәңгәрлеген жуйды. Мачта очлары акчарлак канатларыдай җемелдәми иде инде хәзер, бәс сарган агач кәүсәседәй агарып кына күренә иде.

Әкрен генә, сагындырып кына кич булды. Салкын кояш салкын су өстенә төшеп орынгач, китәргәме диңгез артына, әллә боларның килеп житкәннәрен көтәргәме дигәндәй, берничә минут бер урында уйланып торды да, сабырлыгын жуеп, диңгезнең без барасы ягын комачтай кызартып, үзе шул кызыл суга иңә башлады. Болытлар да кызыл, дулкын сыртлары да, мачта очы да, трюм капкачына менеп баскан Җораның ак береты да кызыл.

Безнең авыл күгендә дә шул ук кояш бит инде. Шулай кызарып бата микән анда да бүген кояш?..

Биек тауның башларында
Аю ята пакь җирдә.
Кызарып кояш баткан чакта
Сагындыра ят җирдә,—

дип җырлап үтәсе калган аны китәсе төнне авыл урамыннан...

Кич, салоннан кино карап чыкканда, диңгез өсте тәмам карангыланган иде инде. Җил дә көчәйгән, ахры — мачта очлары бик хәтәр сызгыра. Палуба юеш. Кичке якта берәү дә юдыртмады бугай ич аны. Димәк, дулкын кунак булып киткән.

Ярар, ни булса шул, дип каютага төшеп чишендем дә койкама кереп чумдым. Урын-жир чиста. Түшәмдә чүлмәк кадәрле лампа янып тора. Бәләкәй генә каютаны яктырта да шул, жылыта да.

Иртән дулкыннар иллюминаторларга кадәр менеп житә алмый иде бит әле. Ә хәзер калын пыялаларны бертуктаусыз су телләре ялый. Дулкын күмеп киткән мизгелләрдә иллюминаторлар түгәрәк күзләргә охшап кала. Әйтерсең лә, каюта эченә олы, яшел күзләре белән диңгез карый.

Мәрхәмәтле бул, диңгез! Рәхим-шәфкатеңнән ташлама, балыгыңны күпсенмә бездән. План дигәннәрен арттырып үтик...

Әһә, үтәрсең! Нигәдер кәефе кырылган әле моның. Тотып селкеде каютаны, гүя кемдер күзгә күренмәс кулларын сузып койкамны аска тартып алды. Мизгелнең күпмедер өлешен бушлыкта ятып үткәрдем. Аннары инде койка мине түшәмгә кысрыклады.

Кая китеп олакты икән соң боцманы да? Әһә, тимер трап дөберди. Кемдер төшә. Юк, ул булмады әле. Күрше каютага кереп китте. Шул каютада кайсыдыр кычкырып көлә түгелме соң? Көлә шул. Димәк, бернинди дә хәвеф-хәтәр юк.

Тагын берәү төшә. Монысы баягы кебек йөгерми инде. Нык, салмак адымнар. Монысы инде, һичшиксез, Грегус Георгиевич.

Каютага килеп керүгә, курткасын салып атты. Куртка астыннан ленолиумга боргаланып-сыргаланып су агып чыкты. Грегус Георгиевич, лампочка каршына килеп, юешләнгән сакалын борып сыкты да диванга утырды, итекләрен салды, чолгауларын сүткәч, ап-ак оекбашлы бәләкбәләк аяклары күренде. Аннары ул ленолиумга жыелган суны атлап үтте дә койкасы янына килде, лапылдап утырды, аякларын сузды. Кечкенә бала шикелле һаваланыбрак:

— Шәпме минем оекбашларым? — диде.

— Шәп.

— Шәптән бигрәк жылы. Әни карчык жибәргән. Онытмый. Күрешмәгәнебезгә ун ел инде.

Мин башымны күтәрдем, боцманның әйткәннәрен аермачык ишетсәм дә, кайтарып сорадым:

— Ун ел?!

— Ун ел.

— Кем белән яши соң ул?

— Үзе генә.

— Ә... нишләп кайтмыйсың?

— Тәк шунда. Бер чувиха өчен тилмереп йөргән идем яшь чагында. Ошатмады мине. Ничек жырлана әле бер жырда? «Йөрәгендә миңа урын тапмады, йөрәгенә кертте ятларны», — дипме? Паразитка! Күпме төн йокыларын калдырдым шуны уйлап, ничә пар итек туздырдым, ничә гитараның башына життем шуның артыннан йөри-йөри.

— Ә соң син аңа яратуың турында әйткән идеңме?

Боцман минем соравыма жавап бирмәде. Каюта чайкалган уңайга тибрәнгәләп утырды да одеал өстенә сузылды, сакалын учлап күзләрен йомды, ләкин шунда ук горт итеп йөзтүбән әйләнде.

— Паразитка! Кайтам әле шушы путинадан соң. Аны сагынып түгел, әнине күрергә кайтам. Каршыларыннан гитара чиртеп узам әле бер...

Әгәр мин дә ун ел кайтмасам авылга, нәрсә булыр иде икән? Күз алдына китерүе дә авыр хәтта. Юк, кайтам мин, калмыйм монда. Кайтам. Яшел күзле диңгезләре үзләренә булсын.

Инде мин төш күрәм. Хәбир белән өй түбәсе ябабыз, имеш тә, соңгы тактаны кадаклаганда аягым таеп китте. Очам бушлыкта, очам, һич кенә дә жиргә төшеп житә алмыйм. Үзем төшәм, үзем кычкырам. Әле дә ярый, бәрәңге буразнасына туры килгәнмен, кабыргаларым исән калмас иде, югыйсә.

Буразнада яткан килеш тә егылам түгелме соң тагын? Җирдән түбән төшәм түгелме соң?

Уяныл киттем. Әни әйтмешли, ходавәндәм — түшәмгә кадәр суырылып менәм дә тагын гөрселдәп урынга төшәм, тагын түшәмгә тартыла башлыйм. Өстәвенә, койка әле бер, әле икенче якка атылып-атылып китә. Койка киртәсенә ябышып Грегус Георгиевичка карадым. Йоклый, терсәкләрен ике якка аерып куйган да оча-оча йоклый. Әллә уятыйм микән? Яхшы тамаша түгелдер бу?

Траулерга астан йөзәр потлы чуен шарлар белән сугып торалар диярсең. Гөрс тә гөрс, дөпел дә дөпел. Төн микән соң бу, көн микән? Иллюминаторларда тоташ кара-кучкыл су гына ялтырый, бер генә ачык урын да юк. Ай-яй, кулыңны ычкындырдың исә, койкадан атылып төшкәнеңне көт тә тор. Каюта палубасында мәхшәр. Боцманның гитарасы минем итекләрем арасына килеп кергән. Юк икән әле, кереп җитмәгән, тагын шуып китте гитара. Рундук ишеге каерылып ачылды да гитара каршына минем чалбар төшеп ятты. Каютага коридордан шыбырдап су агып керде. Ай-яй үпкәләрне суырып ала бит бу. Ашказанын кабыргаларга кыса. Батабыз микән әллә?

Боцман һаман йоклый. Монысы нәрсә тагын? Теге якта кемдер көлә түгелме соң? Көлә шул. Кичтән дә шулай көлгәннәр иде. Жора, Жора бу. Куркуның ни икәнен белмәс егет булыр икән дөньяда. Вәт эт каешы. Болай булгач, сер бирергә ярамый инде миңа да.

Шушы буладыр инде шторм дигәннәре. Каютада ярый әле, түзәргә мөмкин. Тышта ниләр бар икән?

Юк, куркырга ярамый миңа. Дөресрәге, курыксам да курыкканымны күрсәтергә ярамый. Миннән көләләрдер әле теге яктагылар. Шыр җибәрәдер инде Расин, күзен ачып карарга да йөрәге җитмидер, дип сөйләнә торганнардыр.

Ә без койкадан менә болай төшәбез, арканы диванга терибез. Киенәбез.

Итеге дә тоттырмый бит аның син ашыккан чакта. Әле тегеләй, әле болай шуа да йөри. Егылмаска, егылмаска! Ишекне ачып, коридорга чыктым. Аяк астында бернәрсә дә юк сыман. Коридор белән бергә аска төшәм-төшәм — һич төшеп җитәр хәл юк. Яктырып килә икән инде. Коридор иллюминаторларыннан көн яктысы саркылып керә.

Нинди генә авазлар ишетелми палубада. Даң-доң тимергә тимер бәрелгән тавыш та, агач шыгырдавы да, калай шылтыравы да ишетелә. Вакыт-вакыт шул тавышларның барысын да диңгез шавы күмеп китә. Ул да түгел, палубага гөрселдәп дулкын килеп төшә, траулер калтыранып-калтыранып кыйшая, дерелдәп торая һәм искәрмәстән бушлыкка оча.

Текә трап буенча югарыга үрмәләдем.

Исән-имин менеп җиттем. Тимер ишекне акрын гына ача башладым. Башта, траулер янында ук түбә күренми торган соры чокыр күргәч, котым очты. Траулер кыйгачлап чокыр төбенә төшеп бара иде. Тик шул секундта ук чокыр урынында киртләчләрен тоныкъ кына ялтыратып мәчет биеклеге тау калкып чыкты да палуба бөтенләе белән су астында калды. Әмма траулерга андый-мондый хәл булмады, бераздан юеш такталар күренде. Фальшборт өстеннән диңгезгә шаулап су агуы ишетелде.

Ишекне киңрәк ачтым. Рубка тәрәзәсеннән өлкән ярдәмче Гуляев карап тора иде. Чәнчелгере икән — шул чагында әллә кайдан гына палубага буш мичкә дөпелдәп төште дә бер фальшборттан икенчесенә барып бәрелде. Инде котылдым, инде чираттагы дулкын юып төшерде дигәндә генә, тиктормас мичкә трал җәтмәсенә чорналып калды. Һәм, траулер икенче якка янтайгач, дөбер-шатыр килеп, трюм авызына таба тәгәри башлады.

Өлкән ярдәмче пыяла аша нәрсәдер ымлады. Әллә миңа гына шулай тоелдымы? Һәрхәлдә, башымнан: «Буш мичкә аркасында харап булам икән»,— дигән уй узып китте. Аннары башка икенче уй килде. «Теге вакыт цемент вагонында тончыгып үлә башлагач, Галимулла абыең ярдәм кулын сузган иде дә бит, монда Галимулла абыең юк инде. Монда үзең дә, үзеңнең намусың гына бар. Монда да чигенсәң, аннары. Аннары, аннары...» Аннары ни буласын уйлап бетермәдем, ишекне кинәт кенә ачып, кинәт кенә ябып, палубага чыктым.

Тотынырга урыны да юк бит әле аның, ичмасам. Беренче трюмны исән-сау үттем. Диңгезнең ярсулы сулышын бөтен җаным-тәнем белән тойган хәлдә, икенче трюм авызына ябыштым. Мичкә якын гына инде, миннән өч-дүрт адымда гына фальшбортка терәлеп ята. Траулер упкын төбенә төшеп җиткәнче эләктереп өлгерергә кирәк. Аннан олы чыгырлар артына бәйләп куелган тимер мичкәләр бар, шунда кадәр илтеп ташлый алсам, мин җиңдем, дигән сүз. Илтеп өлгерә алмасам инде... Әй, агач мичкәне юып китәргә дә көче житмәде ич әле. Минем аякларым, кулларым бар...

Палубаның мичкә яткан ягы күтәрелә... күтәрелә. Акрын кыймылдасам буш кул белән калачакмын. Чәчәккә кунган күбәләккә сикергән мәче баласы сыман, бөтен гәүдәмне җыерып, мичкә өстенә ташландым. Әһә, менә ул, җанкисәк, минем кулда. Юешләнгән, авырайган. Фальшборт янындагы кара тау да үсә барды, мин дә үзем терәлгән тимердән тиз генә кубып, мичкәне чыгыр артына ыргыттым.

Киемнәремнән шыбырдап су агып торган килеш, тышкы трап буенча сул канатка мендем дә рубка почмагына кереп чүгәләдем.

Штурвалда Вовка тора икән. Миңа борылып та карамый. Үз хәле хәл. Шабыр тиргә баткан. Әле тегеләй, әле болай зырылдатып әйләндерә штурвалны.

Өлкән ярдәмче дә палубага түгел, диңгезгә карый икән лә. Юкка тырышып йөргәнмен инде болай булгач. Кыскасы, берәүнең дә исе китмәгән икән минем батырлыкка.

Өлкән ярдәмченең тулы яңакларын төк баскан, бәләкәй күзләре кызарган. Менә ул эреле-ваклы приборларның әле тегесенә, әле бусына караштыргалап, Вовадан берничә мәртәбә:

— Румбада? — дип сорады.

Вовка төрлечә җавап бирде.

— 130, — диде беренчесендә.

— 135, — диде икенчесендә.

— 127,— диде өченчесендә.

Бер заманны траулер бик яман кыйшайды. Мин рубка ишегенә килеп сыландым. Гуляев та күперчекнең уртасына кадәр шуып төште дә «телеграф» дип язылган приборның рычагын тартты.

Траулерның чайкалуы кимегәндәй булды, ашказаны белән үпкә бавырлар үз урыннарына төшеп утырды.

Мин котырган диңгезгә тагын бер мәртәбә күз салып алдым да эчке трап ишегенә таба атладым. Гуляев бары тик шул чагында гына миңа игътибар итте:

— Боцман йоклыймы? — дип сорады.

— Йоклый.

— Ничек хис итәсең үзеңне?

— Ярыйсы.

— Күңелең болганса, укшыта башласа, аша син. Ашыйсың килмәсә дә, көчләп аша. Аңладыңмы?

— Аңладым.

Трап иңсәләренә тотына-тотына, комсостав каюталары тезелеп киткән тар коридорга төштем. Машина бүлегендә дизельләр дөпелдәве ишетелде. Камбуз ишеге ачылып-ябылып тора иде. Камбузга башны гына

тыгып карадым. Һе, ашарсың! Җиңел генә чифкә. Аша, имеш. Ә камбуз палубасында су шыпырдап йөри. Кок сүгенә-сүгенә плитәгә казан беркетеп маташа. Моннан ук күренеп тора: плитәләр дә, казан да салкын.

Кают-компаниягә кердем. Диванда куллары белән башын учлап, электрик утыра. Йөзе зәп-зәңгәр. Койрык югарыга атылып, иллюминаторлар су астында калган саен өстәл читенә ябыша, салон чайкалган көйгә, әллә ничек, кызганыч итеп ыңгыраша.

Электрикның газапланып утыруын озаграк карап тордым, ахры — кинәт үземнең дә күңелем уйный башлады. Әйтерсең лә, биек яр өстеннән түбәнгә мәтәлеп төшеп барам.

Аяк астында домино тартмасы чышт-пышт шуып йөри, буфетта тарелкалар, кашыклар шалтырый. Ичмасам, ипи ашыйсы иде. Ипиләре кайда икән соң боларның? Камбузга кереп, коктан ипи сорадым.

— Изгән килеш тора әнә, ничек пешерим, плитәне кабызыр хәл юк, мичкә су кергән, — диде кок.

Юеш итекләремнән су сыгып чыгара-чыгара, тагын трапка таба киттем. Саф һава сулыйм, ичмасам. Җиңелрәк булыр.

Шлюпкалар янында да коры урын калмаган. Брезентлардан тамчы тама. Шлюпка астында нинди мичкә әле ул? Балык тутырырга дигән мичкәләр зуррак, ә бу бәләкәй. Бармакларым авыртканчы каера торгач, капкачын ачтым мин моның. Мичкә тулы тозлы помидор. Үзләре чуерташ кебек каты, үзләре ямь-яшел. Менә кайда ул байлык, менә кайда татлы ризык! Бармак башы хәтлесен алып каптым да чәйнәмичә генә йотып җибәрдем. Икенчесен тәмләп ашадым. Тәнне җылытмаса да, күңел уйнавын басты тозлы помидор. Давыл әллә ничә көнгә сузылса да, тиз генә бетәсе юк әле җир күчтәнәченең. Шлюпка артында ышык. Траулерның имән яркасы кебек калын морҗасыннан быт-быт килеп төтен бөҗралары атылып чыга, койрыкта винт чих-чих итеп дулкын турый. Давылларга төкермибез дә, җырлап кына йөрибез әле болай булгач.

## Гомердә булмаган хәл

Безне өч тәүлек буе тагарактагы тары бөртекләре урынына сикерткәннән соң, диңгез тынычлана төште.

Ярдан кузгалганга унберенче тәүлек дигәндә, ниһаять, Бристоль култыгына килеп җиттек. Ни өчен култык дип атаганнардыр инде моны. Яры-фәләне бер дә күренми ләбаса. Монда ялгыз түгелбез икән әле, шөкер. Уң ягыбызда да, сулдарак та нәкъ безнеке шикелле траулерлар чайкала. Ерактан күзәткәндә бик харап икән, кешеләр яши аладыр шул тагараклар эчендә, дип һич кенә дә уйламассың. Әле мачталары белән суга ятып китәләр, әле төпләрен күрсәтеп, икенче якка авалар.

Төшке аштан соң күперчектә капитан күренде. Озын муенлы кечкенә башлы булгангамы, алтын краблы фуражкасы гадәттән тыш олы сыман иде аның. Капитан бинокль аша диңгез өстен күзәтеп торды да өлкән ярдәмчегә борылды. Шунда ук палубаны:

— Әзерләнергә! — дигән фәрман яңгыратты.

Күперчектә телеграф чылтырады. Траулер тизлеген киметте, җилгә ян беләнрәк борылды. Койрыкта да, борында да бер-бер артлы тимер ишекләр ачылып ябылганы ишетелде. Бер минуттан инде палуба кырмыска оясына охшап калды.

Тралмейстер белән неводчы һәм тагын берничә матрос тралны сүтеп, планширга китереп салдылар. Электрик щит янына басты. Капитан уң канатка чыгып кул селтәүгә, чыгыр барабаннары выжылдап әйләнергә тотынды. Трал, футбол тубы кадәрле тимер калкавычларын шалтыр-

шолтыр китереп, планшир өстеннән шуды-шуды да дулкыннар арасына кереп югалды. Беләк юанлыгы ваерлар сызгырышып күз иярмәс тизлек белән трал артыннан омтылдылар. Ай-яй озын дисәң дә озын икән бу ваер дигән тимер аркаңнар. Сүтеләләр, сүтеләләр чыгырлардан, һаман сүтелеп бетмиләр. Ниһаять, барабанда кызыл тамга җемелдәде.

— Стопорить!

— Есть, стопорить.

Электрик рубильник тәгәрмәчен кискен генә борды — ваерлар скрипка кылы кебек тартылдылар, траулер дерелдәп куйды...

Траулер ярымтүгәрәк ясап әйләнеп килгән арада без күн курткаларыбызны киеп, трюмнарны ачып, мичкәләрне, тоз капчыкларын әзерләп куйдык. Балыгы гына эләксен!

Әнә инде тралны чыгаралар да. Чыгырлар бар хәлгә үкерә. Ваерлар чытыр-чытыр килеп барабаннарга урала.

Палубадагы кешеләрнең йөзләре ачылганнан ачыла барды. Тавышлары ныгыды. Кайсыдыр шаян сүз әйтте, кайсыдыр шаркылдап көлде.

— Күрдеңме диңгез арсланнарын? — диде кай арададыр минем янга килеп баскан Жора диңгез уртасына ымлап.

— Кайда?

— Әнә ич кутец тирәсендә бутала. Эләккән балык, эләккән — балык эләкмәсә алай тыз-быз йөрмиләр алар.

— Нәрсә ул кутец?

— Трал койрыгы... Әнә, әнә, көмеш акча тутырылган капрон оек кебек елтырый. Трал канатларына карама син, арырак кара.

Шулай икән шул. Йөзеп килә икән ефәк тышлы ястыкка охшаган бер нәмәрсә. Текәлебрәк карагач, диңгез арсланнарын да күрдем. Тиреләре дуңгыз тиресе сыманрак аксыл, башлары мүкләк сыерныкы шикеллерәк икән. Үзләре дә сыер кадәр бардыр. Сикереп чумалар да дулкыннарга, бөтен тирә-якка су фонтаннары аттыралар.

Барабаннар туктый-туктый әйләнсә дә, ваерлар паман җыела. Әнә аеру такталары чыкты су астыннан. Фальшбортка килеп житүгә, аларны тиз генә тимер дугаларга чылбырлап куйдык. Озак та үтми траулер янына авызыннан ук көмеш сельдь балыгы белән тулган трал калкып чыкты.

— Гомердә булмаган хәл, аягың җиңел икән синең, — дип иңбашыма сугып узды Грегус Георгиевич.

Блоклар аша сузылган корыч бау ярдәмендә беренче кутецны күтәртеп, чишеп җибәрүгә, палуба тез тиңентен балык белән капланды.

Шул ук минутта аврал игълан иттеләр. Палубага берәм-берәм механиклар, штурманнар чыга торды. Барысы да эш киемнәреннән, барысы да резин перчаткалардан.

Мин Грегус Георгиевичка тоз капчыкларын бушатырга булышкан арада, балыкның бер өлешен тозлап, мичкәләргә тутырып, өстен ябып, кыршауларын ныгытып, беренче трюм янына китереп тә тезделәр.

Без Жора белән трюмга төштек.

— Майна!

— Вира!

— Майна!

— Вира!

Мичкәләрнең беренче рәтен уйный-көлә генә тәгәрәтеп йөрткән идек, икенче рәтен тезгәндә эшләр мөшкелләнде. Аяклар ике мичкә арасына туры килә янсә траулер чайкалып китә дә әле генә утыртып калдырылган мичкәң дөпелдәп ава һәм чак кына үзеңне бәреп екмый кала.

Өстә, трюм авызында, яулык кадәрле генә күк йөзе зәңгәрләнеп күренә, радио җырлаганы ишетелә:

Надо мной небо синее,
И облако лебединое
И плывет, и завет
В дальний путь за собой.

Тəслимəлəр янындагы кое авызына килеп кычкырсаң, шулай гөрелдəп ишетелə иде тавыш. Ул коеның суында күк шəүлəсе дə шулай дүртпочмаклы зəңгəр яулык булып күренə торган иде.

Ниһаять, икенче рəтне дə дыңгычлап куйдык. Соңгы мичкə сыймыйча интектерде, иблис. Бөтен рəтне яңабаштан тыгызлап чыгарга туры килде.

Мичкəлəрне өченче рəткə тəгəрəткəндə куртканы да, пинжəкне дə салып аттым. Һава житми иде монда, трюм мунча кебек эссе иде. Иңмасам, Жора, авызын ерып, мыскыл итеп маташа. Шахтер кешегə пүчтəк инде ул мондый тар урында эшлəү, ди. Боларга, ягъни, диңгезчелəргə читен, янəсе...

Кичке ашка кереп утырганда кашык күтəрерлек тə хəл калмаган иде инде. Ашап-эчкəч, трюмнарны ныгытып яптык, тралны мачтага урап куйдык, палубаны ике-өч мəртəбə юдырып төшердек.

Икенче көнне Грегус Георгиевич мине сəгать өчтəн уятты. Аяклар да, куллар да үземнеке түгел кебек. Киемнəрне тозлы су фанер кебек катырган.

— Киен, киен, əйдə, тралны күтəрер вакыт житə. Юынып, капкалап ал, — ди Грегус Георгиевич, ашыктыра.

Капкаларга тагын монда! Күзлəрне ачып, буыннарны язып булмый əле.

Трюмга бер дə төшəсе килми дə соң. Ə кем төшə, без төшмəсəк. Монда һəркемнең үз урыны бар. Монда беркем дə сине тегесен тегелəй ит, бусын болай ит, дип өйрəтеп тормый. Кулыңнан нинди эш килə — жиң сызганып шуңа тотынасың. Башкарып чыксаң, рəхмəт əйтмилəр, хəлеңнəн килмəсə, булышалар.

Əле кояш та чыгып житмəгəн, ə безнең палуба тагын балыкка күмелде. Иртəнге чəйгə кадəр икенче трюмны тутырып та куйдык.

Эш жиңелəйде. Палубага гына тезəбез хəзер мичкəлəрне. Башта брашпиль тирəсенə тыгызлап өйдек, аннары трюм араларына. Ə балык агыла да агыла. Тралмейстер белəн неводчы сосып кына алалар инде əллə балыкны траулер яныннан. Диңгез арсланнары бөтенлəй азынганнар — трал күзəнəклəреннəн йолкып алалар балыкны.

Акчарлаклар авызында да балык, фальшборт улакларында да, кок табасында да балык. Табада гынамы соң?! Иртəн кок балык кыздырган, төшкə балык шулпасы пешергəн, кичкə балык кəтлите ясаган.

Балык кəтлите ашап чыкканда бер генə буш мичкə дə калмаган иде инде безнең. Мичкə юк, дип, тоткан балыкны əрəм итмəбез бит инде. Чыгырлар артына эржə сыман əйбер əмəллəп, брезент жəеп, балыкны шунда тозладык.

Артык сикерəлми хəзер траулер. Планширга ятып, кулыңны сузсаң, бармакларың дулкыннарга тия. Иллюминаторлар барысы да су астында калды.

## Бар икəн кешелəр

Иматра култыгында якорь салып торган йөзмə базага трюмнарны шыгырым, палубаларны түбəлəмə тутырып əллə биш, əллə алты мəртəбə балык китердек инде, шайтан белсен.

Ничə мəртəбə килеп-китүебезне, тəүлеккə ничəшəр сəгать эшлəвебезне санап тормыйбыз. Кайчан таң атып, кайчан кич булганын да күрми калабыз.

Ләкин ал белми, ял белми, кара тиргә төшеп тырышуның да бер чиге була икән. Чираттагы килүебездә йөзмә база кабыргасына терәлеп ике көнгә якын черем итәргә туры килде безгә. Йөзмә базада буш мичкәләр юк, имеш. Экипажның бик тә кәефе кырылды монда. Кырылмый теге, квартал планын егерме көндә үтибез, дип тора идек ләбаса.

Бүген ревизорның кайтып та кергәне юк йөзмә базадан. Һаман да мичкә юллый. Әмма елга тамагында су кимегәнлектән, мичкәләр янына катер белән дә, көймә белән дә керерлек түгел икән.

— Ярда мичкәләре бармы соң аларның? — дип изүләрен чишеп җибәрде Грегус Георгиевич, ревизорның плавбазадан буш кул белән кайтуын ишеткәч.

Икенче штурман иреннәрен чәйнәүдән туктамыйча гына мыгырданып алды:

— Бар дип әйтеп торам лабаса. Су аяк битеннән генә елга тамагында, берничек тә кереп булмый.

— Аяк битеннән генә булгач бигрәк тә шәп, — диде Грегус Георгиевич кулларын уа-уа. — Ике мичкәне бау белән бәйлибез дә, иңебезгә асабыз да... Әллү!

— Яр читендә генә булса иде мичкәләр! Сопка итәгендә үк бит.

— Атна буе арка кыздырып ятыйк инде, алайса,— диде Грегус Георгиевич һәм сакалын тырпайтып палуба буенча әрле-бирле йөрде-йөрде дә йөзмә база бортына чертләтеп төкерде.

— Паразитлар! Балык эләкми торган вакыт булса, ачуың да килмәс иде, паразитлар!

Грегус Георгиевич фок-мачта төбендә яткан йомгактан шпагат кисеп алды да трапка юнәлде. Аның: «Сез ял итегез, алайса, мин акрынлап ташый торыйм әле», — дигән сүзләре һәммәбезне урыннарыбыздан кузгалырга мәҗбүр итте.

Бераздан траулерда капитаннан гайре нинди җан иясе бар — һәммәбез дә, пингвиннар кебек тезелешеп, боцман артыннан атлый идек инде.

Таулар текә, ташлы, биек икән монда. Карыйсың-карыйсың — бер генә җан иясе дә күренми. Шәрә тау битләренә томан сырышып йоклый. Таулар шул томанның тынычлыгын бозмыйм дигән сыман, чал башларын зәңгәр күккә терәп, оеп утыралар.

Менеп карыйсы иде тау башларына. Ниләр күренә икән өстән?.. Ике мичкә тагылган шпагат иңнәрне кисә, су эчендәге очлы ташлар аяк астына гына карап барырга куша. Менә кайда икән ул:

Магазинга балык кайткан,
Мичкәләр юк тозларга...

Грегус Георгиевич иң алдан атлый. Аның берәр потлы итекләре судан баш калкытып торган ташларны аудара, дуен юк жирдән дуен чыгара.

Әллә калак сөягенә кадәр кисеп керә инде, ләгънәт шпагат.

Җора әллә үзен тирги, әллә башка берәүне.

— Христофор токымнары, америкалары белән җиде диңгез артына олаккырлары...

Траулер белән мичкә күче арасында йөри-йөри күз алларында кызыл түгәрәкләр әйләнә башлагач, микрофонда капитан тавышы:

— Боцман, тоз алырга онытмагыз, тозны да сыртка салып ташырга туры килмәсен,— дип гөрелдәде.— Безнең чират анда, ике матросны плавбаза трюмына төшер.

Кемнәр төшәсе билгеле инде трюмга. Ике матрос дигәннәре Җора белән мин инде ул.

Һе, ансат кына. Төшер, имеш. Трюмга төшкәнче йөзмә базаның па-

лубасына менәсе бар бит әле. Йөзмә база сандык кадәрле булса, безнең траулер аның янында шырпы тартмасы хәтле генә.

Тырыша торгач, тәки менеп җиттек. Боларның палубалары ындыр табагы чаклы икән. Безнең мичкәләр уймак кадәр генә булып калган боларның палубасында.

Стрелаларын трюм авызына борып куйганнар, безне көтәләр. Якынрак килеп түбән карагач, башлар әйләнеп китте. Кайда соң моның төбе?

«Кисекбаш»тагы Карәхмәт нәкъ менә безнең кебек туктый-туктый, шомлана-шомлана төшкәндер инде кое төбендәге диюне үтерергә.

Шөкер, аяклар каты нәрсәгә орынды. Ә кайда соң тоз капчыклары? Капчыксыз тоз гына ич монда. Җора ап-ак тоз катламы эченнән тырпаеп торган чүпрәк кисәгенә барып ябышты, мине дә үзе янына чакырды:

— Әйдәле, кореш, корсак тиреләрен чыныктырып алыйк бераз, ашарга хут булсын.

Тартабыз, тартабыз икебез ике почмагыннан тотып капчыкны, чыкмый гына, иблис. Өстен таптап бетергәннәр шул. Әһә көрәк шунда гына ята икән. Алмаш-тилмәш казыйбыз да тагын тартабыз.

Чыкты, чыкмыйча кая барсын! Күргәнем юк иде, тозны да арыш капчыгына тутыралар икән, баксаң.

Унбиш капчыкны тоз арасыннан суырып чыгаргач, хәл җыярга утырдык. Әле генә финишка туктаган йөгерешчеләр кебек сулыйбыз. Җора, кулларын як-якка сузгалап, гимнастика ясаган була, мин, бармакларымны берәм-берәм авызыма кабып, тырнак асларына тулган тозны суырам.

Җора, гимнастика ясап бетерүгә, тельняшкасының җиңнәрен ипләбрәк сызганды да искәрмәстән генә минем бөергә китереп төртте. Авыртудан сыгылыплар төштем. Ачу катыш еламсырап кычкырып җибәрдем.

— Нишлисең, исәр?

— Сине чыныктырам,— диде Җора тешләрен ыржайтып,— юкса, тере мәет кебек селкенәсең, шәүлә кебек йөрисең, әллә сездә барысы да шундый мәлҗерек, растяпа христофорлармы?

Аскы иренемне авырткачы тешләп, аяк өстенә бастым. Алай канга батышып сугышканыбыз булмады авылда, мәгәр берничә мәртәбә Хәбирнең колак төбенә утырткалаганым исемдә. Шактый нык төшә иде — аяк чалып маташуларын, хәрәмләшүләрен, алдашуларын, бер-ике айга онытып, суфига әверелеп, песи кебек йөри иде Хәбирең. Аннан соң Тәслимә дә, кыюрак бул, дип акыл өйрәтеп маташкан иде ич әле миңа.

— Нәрсә, әллә җыларга да җыенасыңмы? — дип Җора мине тимер баганага кысрыклады.

Юк, чигенергә ярамый иде миңа хәзер, берничек тә чигенергә ярамый иде. Бөтен көчемне җыеп, кизәнми-нитми генә, әмма кискен һәм, үземчә, шактый нык итеп Җораның колак төбенә тамыздым. Җора әле генә үзебез казып чыгарган тоз капчыгы өстенә чалкан әйләнеп төште.

— Себердәге кебек кенә сукмыйлар безнең Татарстанда, менә шулайрак сугалар!

Сизми дә калдым — кай арада сикереп торгандыр Җора, кай арада нягемә китереп ямагандыр — күз алдымда Әхмәт абый пагоннарында Тәслимә күргән йолдызлардан да яктырак очкыннар уйнап алды. Мин чайкалып киттем, әмма егылмадым. Җора, мине ега алмаганына гарьләнепме, гаҗәпләнепме катып калган мизгелдә, азрак һушымны җыеп тордым да, муен тамырларымны, тез буыннарымны катырып, баш белән сөздем. Җора тагын егылды.

— Ә менә бусы сиңа Әхмәт абый пагоннарындагы йолдызлар өчен!

— Капитаныгыз ашыктыра, шаярмагыз, эшләгез, — дип кычкырдылар өстән.

Без бер-беребезне эт итеп сүгә-сүгә, бер-беребезне «күрсәтәм әле мин сиңа күрмәгәнеңне», «җиде бабаңа җитәм әле», «арт сабагыңны укытам әле мин синең» кебегрәк янау сүзләре белән коендыра-коендыра, янә тоз капчыкларына ябыштык.

Хикмәти хода! Ачулангач, эш тиз эшләнә икән, ардырмый да анна ры. Әллә шуны белеп, юри төртте инде Җора минем касыкка. Әллә мине сыныйсы итте... Ни генә булса да, Җораның борыны канаганга мин гаепле түгел, үзе башлады. Хәер, минем дә теш урты каный, ахры — авызда тоз тәме генә. Бәлки, канамыйдыр, тоз гына кергәндер. Тоз керсә дә, кан булса да төкереп карарга вакыт юк: Җора тоз базында җен кебек кайнаша. Мин дә аннан калышмаска тырышып, мыш-мыш килеп, әрле-бирле чабам, таш кебек авыр капчыкларны солы көлтәсен йөрткәндәй җилтерәтәм...

Бик йончыгач та йоклап китүләре авыр икән. Колак пәрдәләрендә берөзлексез «еще взяли, еще раз», «вира-майна» дигән авазлар янгырап тора. Беләкләргә тоз капчыклары асып куйган кебек.

Барыбер йоклаганмын икән.

Грегус Георгиевич төртеп уятты.

— Иртәдән дә тормадың, әллә әбәткә дә бармаскамы исәбең? — ди.

Күзләремне ачтым. Койка тирбәлә, каюта чайкала. Димәк, тагын ачык диңгездә инде без. Минекеме соң бу куллар, бу аяклар?..

Койка түгел икән әле бу, каюта палубасында ятам икән. Итекләремнең дә берсен салганмын, берсен — юк.

Торып утырдым.

Грегус Георгиевич йодрык кадәрле кабырчык өстенә иелгән. Лак белән ялтыратамы шунда, нәрсәдер язамы, ачык күреп булмый: керфекләрем йомылырга гына тора.

Ятам әле һаман. Грегус Георгиевич кабырчыкны лампочка шнурына элеп куйды да гитарасын кулына алды, кайсыдыр кылына чиертеп хатын-кыз үксегән аваз чыгарды, үзе күзләрен кысып шул авазны озак кына тыңлап утырды һәм тирән итеп көрсенде.

— Вот так они и жили.

Гитара тавышы мине йокымнан айнытып җибәрде. Буыннарым сулкылдавы онытылды, йөрәгемне әллә нинди тыелгысыз сагыш чеметтереп узды. Грегус Георгиевич икенче кылга чиртте. Гитара үксемәде бу юлы, киресенчә, кемнедер үртәп көлде генә.

— К черту, — диде боцман һәм гитарасын тагын үксетеп алды. — Быел да кайтмыйм авылга. Кайтсам, һичшиксез, теге паразитка очраячак.

— Әниең бар ич, — дидем мин үземә дә чак кына ишетелерлек тавыш белән.

Боцман озын бармакларын башта сакалына бәргәндәй итте, аннары кисәк кенә гитара кылларына чиртергә тотынды, борын астыннан гына җыр шыңшыды:

> Көтмә, әни, улыңны син,
> Көтмә тәрәздән карап.
> Аның сердәше — дулкыннар,
> Ә туган өе — кораб.

Инде бая ук керфекләремә килеп тәрәлгән яшь тамчысы күземне ачыттырып тибрәнде-тибрәнде дә тоз белән каткан җиңемә тып итеп тамды. Тиз генә урынымнан кузгалып, сыңар итегемне кия-кия ишекне ачтым.

Палубада диңгезне күзәтеп торырга ирек бирмәделәр. Тавыш көчәйткеч чыжылдап алды да мине вахтага чакыруларын игълан итте.

Бер мәлгә югалып калдым. Шулай да фәрманга буйсынмый мөмкин түгел. Рубка иллюминаторларына күтәрелеп карамыйча гына палуба буенча киттем, күперчеккә мендем.

— Володя, вахтаны Расинга тапшырырга! — диде өлкән ярдәмче күзләрен эхолот экранына төбәгән килеш.

— Есть, вахтаны тапшырырга! Румбада 230.

Атлар-атламас кына штурвал янына килдем.

— Курыкма, ашамый ул, — диде Гуляев, башын эхолоттан күтәрмичә генә.

— Күрәсеңме кызыл сызыкны? — диде Вовка штурвалны сыңар кул белән әле тегеләй, әле болай әйләндергәләп — 230 ның бу ягына да чыгарма, теге ягына да. Ә хәзер кабатла минем арттан. «Вахтаны кабул иттем, румбада 230» диген.

— Вахтаны кабул иттем, румбада 230, — дидем мин һәм ике куллап штурвал тәгәрмәченә ябыштым.

— Так держать! — диде өлкән ярдәмче.

«Так держать» икәнен аңладым ла анысы. Ничек итеп так держать? Вәт мәсьәлә кайда. Вовканың яшеле уңган гимнастеркасы ишек авызыннан югалуга, 240 турысына килде кызыл сызык. Штурвалны бар хәлгә кирегә әйләндереп җибәрдем. Һаман тыңламый, иблис, 241 булды... 245... 250... Әһә, туктады. Туктап кына калмады, саннар берәм-берәм, тизлекләрен арттыра барып кирегә шуыша башладылар. 230 ның кызыл сызык каршында туктар исәбе күренми иде. Биз аз гына дерт-мерт килеп маташты да кызыл сызыктан чаптырып узып китте. 225 кә төште, 220 гә, 217 гә. Маңгаема салкын тир бәреп чыкты, тез буыннарым сыекланды. Штурвалны ашыга-ашыга икенче якка әйләндерергә керештем.

— Румбада? — дип сорады шул чагында өлкән ярдәмче.

— Ике йөз... ике йөз... ике йөз ун...

— Курска сал.

Һе, ансат кына. Курска сал, имеш.

Өлкән ярдәмче, компаска күз дә төшермичә, уң канатка чыгып югалды.

Бар икән кешеләр. Кораб йөртүне башы-бөтен миңа тапшырдылар. Ирексездән диңгезгә күтәрелеп карадым. Горизонт чиста, траулер, борыны белән вак дулкыннар ерып, оча гына иде.

Гуляев тиз әйләнеп керде, хәер, рубкага. Керде дә штурвал янына килде. Кызыл сызык турысында 250 саны тирбәлүен күргәч, көлемсерәп башын чайкады, эхолот яныннан узышлый:

— Синеңчә ничек? Туры барамы судно? — диде.

Мин штурвалны әле сулга, әле уңга зырылдата-зырылдата:

— Диңгез уртасында ничек беләсең инде аның турымы, кыекмы барганын? — дип җавап бирдем.

— Чаңгы шуарга яратасыңмы?

— Яратам.

— Яңа яуган кар өстеннән шуганда, турымы, кыекмы баруыңны ничек беләсең?

— Чаңгы эзеннән, билгеле.

— Инде хәзер траулер эзен чыгып кара... Курыкма, курыкма, җибәр штурвалны, беркая да качмый ул алай кысып тотмасаң да.

Акрын гына ишекне ачтым, буш мичкәләр өстенә мендем. Траулер артыннан ап-ак буразна сызылып кына бара иде башка чакларда. Ә бүген хәйран тамаша — су өстеннән борыла-борыла ак тәңкәле елан шуышып килә, диярсең.

— Я ничек, — диде чиф, мин күперчекне әйләнеп кергәч.

— Туры тоталмыйм ла мин.

— Ә син алай кызу әйләндермә. Запас белән чамала, инерция көчен исеңнән чыгарма... Румбада?

— 230.

— Так держать!

— Есть так держать!

— Күр инде, әле генә әйттем. Арба тәгәрмәчен әйләндергәндәй пырылдатма син штурвалны. Аз гына борып куй да сабыр ит, көтеп тор. Кайсы якка көчлерәк каера, шуны тоярга, шул көчкә каршы торырга тырыш. Румбада?

— 230.

— Так держать!

— Есть, так держать!

Һәр нәрсәнең җае бар, бәрәңгесенең мае бар, диләр шул. Җаен белсәң, бәрәңгедән дә май чыгарып була, дигән сүз инде бу ягъни. Кызыл сызык нәкъ 230 турысында тирбәлә. Курс авыша башласа, чак кына каршы якка әйләндерәм дә штурвал тәгәрмәчен, тиз генә иске торышка кайтарам.

Тора-бара мин бөтенләй тынычландым. Алай гына да түгел, мускулларымда көч артуын, йөрәгемә шатлык тулып ташуын тойдым. Алай гына да түгел, үземне тирә-юньгә ак фонтаннар сибеп зәңгәр офыкларга омтылган шушы сөйкемле корабның аерылгысыз бер кисәге итеп хис иттем. Мин алып барам лабаса судноны, мин! Димәк, монда мина ышаналар. Димәк, инде мин монда үз кеше, кирәкле кеше!

## Яшәү шундый кызык

Ай-һай авыр әйләнә барабаннар, ай-һай ыңгырашып чорнала ваерлар. Траулер, янындагы йөкне селкеп атарга теләгәндәй, бөтен корпусы белән дерелди.

Капитан канатка чыгып баскан да, озын муенын сузып, трал койрыгы калкып чыгуын көтә.

Без эш арасында гына күз аткалыйбыз диңгезгә.

Мичкәләр рәт-рәт тезелгән, балык тозларга урын әзерләнгән, үзебезнең тамак тук, киемнәр коры. Рәхим ит, балык! Барысы да синең өчен!

Әмма капкан саен майлы калҗа булмый икән шул. Тралны судан чыгарырга тотынсак, ник бер балык эләксен. Ләм, суүсемнәр, диңгез кәбестәләре, йолдызчыклар, кальмарлар, диңгез керпеләре барысы бергә буталып, куе кисәлгә әверелгән. Ниндидер әкәмәт чиркангыч җанвар кебек кыймылдап ята трал койрыгы.

Һәркайсы үзенчә яшәргә тырышкан җан ияләренә беркавым җирәнебрәк карап торды да тралмейстер, трал койрыгы чайкалып, фальшборт өстеннән узгач, элмәкне тартып җибәрде — диңгезгә гөрселдәп лайлалы кара масса шуып төште.

Капитан күперчеккә кереп югалды. Матрослар, перчаткаларын салып, кесәләренә тыгылдылар, бер-берсенә карамыйча гына тәмәке кабыздылар.

— Киткән балык, безгә койрыгын күрсәткән дә киткән, — диде Грегус Георгиевич, палубага коелган лайлалы ыбыр-чыбырны сосма көрәк белән диңгезгә ыргыта-ыргыта.

Икенче салуда трал бөтенләй буш чыкты, өченче салуда трал канатлары чуалды.

— Сапожниклар,— дип тралмейстер белән неводчыны тиргәде капитан бу юлы.

— Әнә бит Сахалин тагарагы көри генә бит балыкны, — диде Җора капитан рубкага кереп югалгач, палубасында көмеш шарга охшаган куеш чайкалып торган траулерга ымлап.

— Кәп уңган бит безнең: эхолотка да күз салмый, тизрәк тралны су төбенә җибәрергә ашыга, — дип мыгырданды неводчы, трюм авызы чаклы кесәсеннән агач энәләрен, йомгакларын, пычакларын чыгара-чыгара.

— Кеше сүзенә колак салмый шул бер дә, гел үз белдеге белән генә йөри, — дип неводчының сүзләрен куәтләде тралмейстер.

Тралны төш житәрәк кенә рәтләп бетерделәр.

Эшләмәгәч, ашауның да рәте булмады. Беркем авыз ачып бер сүз әйтми, калай табакларына иелгәннәр дә кашыкларын хор белән шакылдаталар. Моторист кына:

Балык дип,
Каушама,
Ашыкма,
Колак сал:
Ни сөйли
кашыклар,

— дип шаяртырга теләгән иде, тралмейстер кашыгын күтәреп бәрде дә, мыекларын тырпайтып, шундый усал итеп карады, теге бичара дивангә инде, йөзен чәйнек артына яшерде.

Без ашап-эчеп палубага чыкканда жил көчәйгән иде. Кай арада дулкыннар сыртларына ак бөдрә туннарын ябынырга өлгергәннәр. Курсны үзгәрттек, ахры — траулар борыны белән дулкыннарны сөзәргә теләгәндәй, кыйгачлап, әле бер, әле икенче якка кыйшая-кыйшая бара.

Сахалин траулеры да каядыр китеп югалган, әйләнә-тирәдә бер генә карамчык та, бер генә жан иясе дә күренми.

Төштән соң шактый ерак китеп салдык тралны. Трал таккан килеш тә диңгезне байтак сөрде бу юлы траулер. Инде салонга кереп домино сугыйк, дип торганда гына күперчектән:

— Малый ход! — дигән тавыш ишетелде.

Йөрәкләр леп-леп килеп тибә инде, күзләр диңгездә. Нәрсә бүләк итәр бу юлы Нептун патша?..

— Диңгез арсланы, жәмәгать, диңгез арсланы эләккән тралга!— дип сөрән салды бер заманны югары күперчеккә менеп кунаклаган Петя.

— Шул гына кирәк иде, — дип читкә борылды Грегус Георгиевич.

Тралны күтәрә башладык. Диңгез арсланы судан аерылгач, авызын жигүле ат сыярлык итеп ачты да үкереп жибәрде. Фальшборт янында басып торган матрослар дәррәү артка чигенеп куйдылар.

Икенче мизгелдә диңгез арсланы бөтен гәүдәсен уйнатып югарыга томырылды һәм аунарга яткан ат кебек күңелле генә пошкыргалап алды да суга чумып юк булды. Диңгез арсланы урынында ярылган, мунчалаланган трал жепләре генә жилгә сибелеп жилфердәде.

— Паразит, — диде Грегус Георгиевич ачусыз-нисез генә.

Жора авызын ачып иснәде дә:

— Йокларга язгандыр инде бүген безнең христофорларга, барыбер балык эләкми, — диде.

Тралмейстер белән неводчы трюм читенә килеп утырдылар һәм, исәрләнгән кешеләрдәй, бер-берсенә карап, шырык-шырык көләргә тотындылар.

Өлкән ярдәмче вахтасына эләксәм ярар иде, дип теләгән идем, булмады — Петядан штурвалны кабул итүемә, күперчеккә капитан менде. Муены тагын да озынаеп киткән сыман, чырае караңгы, иреннәре кысылган.

«Румбада?» дип тә сорап маташмады бу миннән, бәйдән ычкынган диңгезгә дә күтәрелеп карамады, переборкаларга ышкылып ук радиорубкага узды.

Бераздан аның радистка нәрсәдер әйткәне, ә тагын бераздан юка ишек аша;

— Комета! Комета! Мин алты йөз кырык өченче, мине ишетәсеңме? Прием! — дип кычкырганы колагыма килеп керде.

Ул да түгел, эфирда коточкыч шау-шу купты. Кемдер «Марина»ны, кемдер «Юпитер»ны, «кемдер «Саратов»ны, чакыра. «Илле жиденче» «унсигезенче»дән дизель мае сорый, «йөз дә сикчәненче» флот капитанына мөрәҗәгать итә, тагын кайсыдыр кемнәндер Олютр култыгына барырга рөхсәт сорый. Бер мәлне бака туен хәтерләткән тавышлар еraклашып эфирдан:

— «Алты йөз кырык өч», «Алты йөз кырык өч», — мин «Комета».— дигән сүзләр йөзеп чыкты.

— Ишетәм, «Комета», ишетәм! Прием!

— Тыңлыйм, Фомич!

— Көне буе диңгез төбеннән чүп җыям бүген, ишетәсеңме, «Комета?» Балык юк, прием.

Радиорубкадан чыкканда капитанның яңак мускуллары тартыша, ирен читләре дерелди иде.

— Идиот, — дип кемнедер сүкте ул теш арасыннан гына. Аннары микрофонга кычкырды:

— Тралны әзерләргә!

Телеграф рычагы «малый ход» турысында чылтырады.

— Лево руля!

Мин штурвал тәгәрмәчен ашыга-ашыга сул якка әйләндердем. Палуба тагын су астында калды. Кайдандыр дулкын бәреп чыгарган мичкә капкачлары палубада айкалып йөрделәр-йөрделәр дә планшир аша диңгезгә томырылдылар.

Күперчеккә мыш-мыш килеп чиф йөгереп менде.

— Фомич, шторм биш баллга житте, аннары диңгез өсте дә караңгыланып килә, сабыр итикме әллә бүген?

— Кушканны эшләгез! Кайда боцман? Ни өчен палубада беркем дә юк? Бас штурвалга үзең!

Гуляев авыз ачып сүз әйтергә өлгерә алмый калды, күперчеккә Грегус Георгиевичның аяк тавышлары, шуның артыннан ук борчулы сүзләре ишетелде:

— Хәтерлисеңме, Фомич, узган ел колхоз сейнерлары неводларын шушы квадратта ярдырганнар иде.

Капитан капчыкланган күз кабакларын уып алды да эхолоттан башын күтәреп, Грегус Георгиевичка җикерде:

— Кайчаннан бирле штурманнар эшенә тыгыла башлады әле боцманнар? И вообще туктагыз миңа акыл өйрәтүдән! Сезме монда капитан, минме?

— Киттек, Расин, — диде Грегус Георгиевич аяк астыннан убылыпубылып төшкән күперчекне тигезләргә тырышкандай, әле бер, әле икенче якка кыйшаеп атлый-атлый. — Траулер астындагы балыклар без трал салганны көтеп зар-интизар булмышлар икән... Шул кадәр балыкны ничек тозлап бетерербез инде, белмим.

Диңгездә дулкыннарның кайсы яктан килеп сикергәннәрен дә чамаларлык түгел икән инде. Әллә диңгез ухылдый, әллә безнең траулер. Әллә җил дулкын ялларын өзеп йөзгә бәрә, әллә тозлы яңгыр ява, шайтан да аермас.

Стрелага асып куелган трал, калкавычларын шалдыр-шолдыр китереп, гигант сәгать теле кебек чайкала. Тралмейстер белән неводчы күн башлыкларын күзләренә үк төшереп кигәннәр, таган атынучы малайлар кебек, икесе ике яктан тралга ябышып йөриләр. Матрослар ярдәмгә килгәч кенә фальшбортның теге ягына шуып төште трал. Шул чагында кемдер ачы тавыш белән:

— Полундра! — дип шәрран ярды. Тилгәннән курыккан чебешләр сыман, палуба буенча сибелдек. Әле генә без басып торган урынга тавышсыз гына су тавы калкып менде, ухылдап урталай ярылды. Дулкын

чигенгәндә трал, ярга чыгарып ташланган спрутка охшап янә палубада җәйрәп ята иде.

— Что?! Кашу мало ели?! — дип кычкырды капитан күперчектән.— Тизрәк кыймылдагыз. Судноны сәгатьләр буе дулкынга ян белән тота алмыйм...

Нәүбәттәге дулкын ухылдап ярылуга, япан кыр уртасында киек күргән бүреләр кебек тагын тралга ташландык.

— Вира!

— Еще вира!

— Стоп.

— Майна, майна, майна!

Котылдык бугай. Ваерлар дулкын сыртларын яра башлагач, трал төпкә китте, дигән сүз инде.

Бу юлы кубрикларга кереп җылынырга да өлгермәдек, аврал уйнадылар. Йөгерешеп чыктык, тимер ишекне яптык. Әмма ул янә тупсасына кадәр каерылып ачылды да бомба шартлагандай шапылдап ябылды... Беттек, ахры... Вәсимәләр коймасыдай кыйшайган палуба буенча өскә үрмәләдем, күз ачып йомганчы трюм шинына тотындым... Нишләп турайммый соң әле бу палуба? Бик озак янтаеп торды түгелме соң инде. Арттан дулкын китереп бәрсә, харап эшләр. Курка-курка гына тирәягыма күз салдым. Берәү дә диңгезгә мәтәлмәгән бугай. Һәркем кулына нәрсә туры килсә, шуңа ябышкан, гаҗиз калып, әле диңгезгә, әле җансыз күперчеккә карыйлар. Мин генә түгел, алар да курка, димәк. Ә мин нәрсәдән куркам? Үлемнәнме? Үлгән чагында чын гашыйклар сөйгән ярлары турында уйлыйлар, имеш. Ә мин үзем турында уйлыйм. Юк, үзем турында түгел, синең хакта уйлыйм мин хәзер, Тәслимә. Менә шушы минутта траулер капланачак та салкын диңгез безне үз кочагына алачак. Туңып үләрмен микән, авызыма су тулыпмы? Соңгы уем җан бирүнең авырлыгы турында булыр микән? Юк, юк, Тәслимә, мин соңгы сулышымда да синең хакта уйлармын. Өй сала алмадым... Кичер, әни...

Әни әйтмешли, ходавәндәм икән — мачта очлары дулкын сыртларын кисеп кергән. Трал да күренми, ваерлар да. Ара-тирә молотилка барабанына салам тыгылгандагы шикелләрәк өзек-өзек гүләү ишетелеп китә. Анысы дизельләр бугай...

Нигә куркабыз соң әле шул кадәр? Нишләп агарынган бу кешеләр? Дөньяда бернәрсә дә мәңгелек түгел ич. Барыбер бер үләсе. Булсын иде көч, булсын иде... Турайтып куясы иде менә хәзер траулерны, коткарасы иде бу куркак кешеләрне...

Әллә чынлап та курыкмыйм инде мин үлемнән? Әчем җылынды, кулларым. Йөрәгем нииндидер билгесез көрәшкә әзер булып тибәргә тотынды... Туктасана, нишләп үлик ди әле без? Траулер нык. Кырын яткан икән — тураер. Мин бөтенләй тынычлана яздым. Хәтта әле генә уйлаган уйларымнан көләсем килеп китте. Теге чакта Жора көлгән иде ич әле давылда. Ә нигә миңа көлмәскә?! Һәм мин шаркылдап көлеп җибәрдем. Өй түбәсенә менеп утыргач, әтиләре кулында кычыткан күргән малайлардай, төрлесе-төрле рәвештә катып калган кешеләргә дәррәү җан керде. Кемдер тозлап-борычлап сүгенде, кайсыдыр усал итеп хихылдап куйды, кемдер капитанның унҗиденче бабасын телгә алды.

Шөкер, күперчектәгеләр дә исән икән, үлеп бетмәгәннәр икән әле. Капитан тавыш бирде, ниһаять:

— Боцман, нәрсә нәсел айгырлары кебек кешнисез?! Грунтка эләктек, чабып өз ваерларны! Живо!

— Балта! Балта китерегез, — дип гыжылдады Грегус Георгиевич һәм һаман да текәләнә барган палуба буенча түбәнгә тәгәрәде. Баш очымнан гына сабына капрон бау бәйләнгән балта шуып үтте. Мин икенче караганда, аякларын планшир кырына, аркасын палубага те-

рәгән Грегус Георгиевич, кулындагы балтасы белән кизәнә-кизәнә, нәрсәгәдер суга иде.

Полундра!

Әйтерсең лә, ваерлар ягыннан йөз потлы пружина этеп җибәрде траулерны — тонып кына киттек. Койрыкта нәрсәдер шартлап сынды, бөтен палуба буенча дөбер-дөбер килеп мичкәләр тәгәрәде.

Палуба турайгач, өскә шарламадай шаулап су агуына гына түзәбез инде. Без анысына күнеккән. Әһә, әйбәт үк кысып торганмын икән тимер шинны. Уч төбем суела башлаган хәтта.

Буш мичкәләр прожектор уты белән яктыртылган палубада тәгәрәшә калды, без сушилкага, өс-башларыбызны алыштырырга йөгердек.

Бераздан дөнья иске кыяфәтенә кайтты. Шырпы сызган тавышлар ишетелде, әле анда, әле монда утлар җемелдәде, тәмәке исе таралды. Тимер переборкалы, тәрәзәсез, эссе бүлмәдә тәмәке төтене куера барган саен, уй-фикерләр ачыкланды, сүз artында сүз чыкты.

— Кулым өзелә дип торам, валлаһи...

— Трос очы сыртыма китереп тондырды...

— Ну, үндык та соң быел кәптән.

— Бу кадәр дә үҗәт булыр икән кеше.

— Менә сезгә квартал планы, менә сезгә премия!

— Әрәм булды трал. Өр-яңа иде бит әле...

— Трал сиңа! Ваерларын әйт син...

— Башың сау булгач май кап инде. Илле икенче елны «Нерпа» SOS биреп тә өлгерәлмәгән энә. Экипажларыннан бер дневальный гына исән калган.

— Шундый штормда трал төшерәме соң акыллы капитан дингезгә!

— Һәй, таптыгыз инде чәйнәргә балык башы. Кәп та кәф һаман. Балык эләкмәгәч, нишләсен инде ул? План үтәлмәсә, иң башта аны утлы табага бастыралар лабаса.

— Менә хәзер рәхмәт әйтерләр инде бик.

— Хәленнән килмәгәч йөрмәсен, вакыты җиткән, пенсиягә китсен...

— Үзең китәрсең микән пенсиягә вакыт җиткәч, карап карарбыз.

Сүзләр өзелде, ишек авызында кемнеңдер куртка төймәләре ялтырады, нәзек сыйраклар шәйләнде. Өченче штурман инде, әрәктәй килбәтсез сынлы кем булсын тагын.

— Эдик, синме ул? Кер, әйдә, көйрәтеп җибәр.

— Вакыт юк братва, кәп болай да җенләнә.

— Кай тарафларга сәфәр кылабыз инде хәзер?

— Ремонтка, братва. Винтның бер канаты ярылган. Флот капитаныннан добро алдык. Так что ике-өч ай ярда сачковать итәргә туры килә. Судком члennары гафил булып калмасын, кичке аштан соң заседание... Анда боцман дөнья бетереп Җораны эзли. Күрмәдегезме сез?

Туктале, трал салганда Җора юк иде ич палубада. Трал салган арада черем итеп алам, дип кубрикка кереп киткән иде ич ул. Аврал игълан ителгәч тә күренмәде Җора. Траулер янтая башлагач, шапылдап ишек ябылды.

Шулай уйлый-уйлый сул канатка чыккан идем — караңгыда Грегус Георгиевич белән бәрелешә яздык.

— Җораны күрмәдеңме, Расип?

— Каютада йоклап ятадыр ул, Грегус Георгиевич.

— Бар әле, Расип, читенсенми генә карап кил. Мин машина бүлегенә төшәм. Шунда йоклап утырмый микән.

Иллюминаторлардан, мачта очындагы фонарьлардан палубага сүрән генә яктылык сирпелә. Җил, юеш. Менә шулай башны югары тотып киләбез тимер ишек янына. Тоткага ябышып этәбез — юк, ишек ачылмый.

Траулер борыны гөрс-гөрс килә, өскорма түбәсеннән чап-чоп су тама, якорь дөп-дөп бортны кыйный, ә ишек ачылмый да ачылмый.

Өскорма янындагы щиттан лом суырып алырга туры килде. Лом тыгып каера торгач, шылт ачылып китте ишек.

Тимер траптан дөбердәп түбән төштем — коридор дөм-караңгы. Капшана-капшана Жоралар каютасын эзләп таптым. Каюта коридордан да караңгырак иде. Кулымны переборка буенча шуыштырып йөртә-йөртә төймәгә бастым. Гөлт итеп йөзле лампа кабынгач, күзләрем әлже-мәлже килеп торса да, койка почмагында бөрешеп утырган кешенең сискәнеп китүен шәйләп өлгердем.

Ярты башы ак, чырае да акбур кебек. Ходаем, Жорамы соң бу? Жора ич. Тик нишләгән соң ул?

— Жора, син нишләдең?

Жора зур ачылган күзләрен миңа текәде, кулын койка иңсәсеннән ычкындырды да, каюта кыегайгач, яңадан иңсәгә ябышты.

— Жора, син нишләдең? — дип баягы сорауны кабатладым мин. — Чәчең агарган ич, Жора!

Жора койка иңсәсен ычкындырды, тырпайган чәчләренә бармакларын тидереп алды һәм капылт кына кычкырып елап җибәрде.

Мин аның койкасына барып утырдым.

— Ни булды, Жора, ник елыйсың?

Жора елый-елый сөйләргә тотынды:

— Хә, хә... инде мин, хә, инде мин сезне күрәлмим, дип уйлаган идем. Йокымнан хә... уянып киттем... хә... траулер авып маташа. Көч-хәл белән кубриктан чыктым... хә, үрмәләп өскә мендем. Хә, тышкы ишек ачылмый. Кычкырам, беркем дә җавап бирми... хә, беркем дә!.. Каютага төшсәм, хә, каютаның переборкасы палуба урынында, палубасы переборка... хә, переборка урынында... Траулер бата башлагандыр да мине калдырып киткәндер, дип уйладым аннары... хә син дөбердәп төшкәндә шундый курыктым... Берәр җанвар микән, мин әйтәм, хә, су анасы микән, хә...

— Я, тынычлан, тынычлан, Жора, әйдә ашарга барабыз. Нигә ут яндырмыйча утырасың соң?

— Хә, яндырырсың!..

Жора койкасыннан акрын гына төште, миңа иярде.

— Икенче мәңге үзем генә калмыйм каютада.

Тышкы ишекне ачкач, ярымкараңгы палубадан боцман тавышы бирде:

— Таптыңмы, Расим?

Таптым, дип әйтергә авызымны гына ачкан идем, артымда нәрсәдер дөпелдәде һәм боцманның ачыргаланып кычкыруы колак пәрдәләрен зыңгылдатты:

— Кач!

Куркуым беләнме, каушавым беләнме, Жораны нык кына итеп әле генә үзебез чыккан ишеккә таба этеп җибәрдем...

Бәхетем мичкәдәндер, күрәсең. Бу юлы минем өскә тимер мичкә ажгырып килә иде. Каһәр генә суксын, бәйдән ычкынган овчарка мыни! Жора артыннан ташлансам — өлгереп булмаячак, алга чапсам — куып житәчәк.

Буш түгел бит ул иблис. Дизель мае белән мөлдерәмә тулы. Житте, уйларга вакыт калмады, атылып планширга сикереп мендем. Дулкын шуны гына сагалап торган диярсең — авыр салкын кочагына кысып кына алды... Беттем!.. Йу-ук, диң-гез! Бетмәдем әле!.. Бер кулым белән планширның эчке ягыннан эләктереп өлгердем инде мин, гәүдәмне өзеп китсәң дә, кулымны ычкындырмаячакмын...

Нәүбәттәге дулкын килеп житә алмый калды. Грегус Георгиевичның көчле куллары мине палубага сөйрәп менгерде. Тезләремнең фальшьбортка бәрелүен, яңагымның ниндидер лайлалы салкын әйбергә ышкылып узуын соңыннан гына хәтерләдем.

— Бәхет йолдызы астында тугансың, Расин, — диде Грегус Георгиевич мине трюм капкачына илтеп утырткач. — Хәзер инде менә чын диңгезче булдың... Үзеннекеләр кипмәгәндер, бар, берәрсенең киемнәрен киеп тор. Мин теге паразит мичкәне ныгытып килим.

Киемнәремнән салкын су агып торса да, тәнем кызыша иде. Йөрәгемнең тибешен салмакландырырга теләп, башымны артка ташладым. Өстә, биектә-биектә, ертылган болытлар арасында, йолдызлар күргәч, сөенеп киттем. Әнә йолдызлар арасыннан җемелдәп, дугаланып, утлы эз сызылып төште...

Болай булгач, синең яныңа ал җилкәннәр корып кайтам да кайтам инде мин, Тәслимә. Без яшибез әле, яшибез! Яшәү шундый кызык!

## Ал җилкәннәр өчен

Тирә-як дөм-караңгы, диңгез ах-ух килеп көрсенә. Әллә үткәннәрен сагына шунда, әллә киләчәге турында уйлый, аңламассың.

Туган ярларга якынлашуыбызны җир исеннән, җылы җилдән, көзге урманнар исеннән сиздем. Сабан урагы беткәч басулардан, әрәмәлекләрдән нәкъ шундый ис килә торган иде. Камыл исе, каз үләне катыш эрем исе, яңгырларда юылган сары яфрак исе.

Әле яр буе утлары да, маяклар да күренми, аннары, иртүк вахтага басасы бар — ял итеп алмыйча булмас.

Грегус Георгиевич, кичтән, без кино караганда җырлап утырган, ахры — гитарасын кочаклап йоклап киткән.

Утны сүндереп урыныма менеп яттым. Баш уйлар белән шыгрым тулы. Нишләргә икән? Расчет алып, авылга кайтып китәргәме? Әллә ремонт беткәнне көтеп тагын диңгезгә чыгаргамы? Бәлки бүтән пароходка күчәргәдер, Жора расчет ала, Петя икенче пароходка күчә, Грегус Георгиевич отпуска алып «паразитка»сын күреп килергә ниятли. Ләкин, отпуска алам дигәч, нишләптер, һәммәсе дә көлә аннан.

Юк, ал җилкәннәр корып кайтып булмас бу юлы. Ничек икән, Әхмәт абыйның йолдызлы погоннарын онытмады микән әле Тәслимә? Туктале, чың сөю белән сөямме соң мин Тәслимәне, әллә хисләремне салкын диңгезләр суыта башлады микән инде? Тәслимә турындагы уй элеккегечә чеметтереп алмый сыман йөрәгемне. Төсе-бите, килеш-килбәте дә тоныкланды сыман. Юк, тоныкланмаган. Әнә ул елмаеп тора. Әнә уйнаклап торган толымнары, ягымлылык-садәлек белән мөлдерәмә тулы шамәхә-зәңгәр күзләре. Әнә ул кизләү сукмагыннан суга килә. Йомры ак беләге көянтә аша сыгылып төшкән. Чиләкләре аның матур атлавыннан көнләшеп чылтырый... .

Әгәр дә Тәслимә, яратам, дисә, киткән булыр идем микән мин авылдан? Мөгаен, юктыр. Аның мине яратмавы яхшырактыр да әле, бәлки. Шулай инде, йөзем җимешенә буе җитмәгәч, төлке дә: «Һәй, пешмәгән икән бу», — дип китеп барган, имеш.

Соңгы сулышымда синең хакта уйлармын, дигән идем, Тәслимә. Кичер, диңгезгә егылып төшә башлагач, синең хакта уйлый алмадым мин. Туктале, нәрсә хакында уйладым соң мин ул шомлы төндә, аяк очымда төпсез упкын сулышы белән үлем сулап торганда? Яшәү турында, әйе, бары тик яшәү турында гына уйладым. Барыбер бер үләсе булса да, мәгънәсез үлем белән китәсе килми икән дөньядан, Тәслимә. Җирдә яки кешеләр күңелендә бер эз дә калдырмыйча үлү бигрәк әллә ничек инде. Ул чагында дөньяга килүеңнән ни мәгънә, ни кызык? Дулкыннар да мәгънәсезгә тумыйлар бит әнә. Аларның да максатлары бар. Алар берберсенә кушылып үсәләр, зур көчкә әверелеп, куәтле давыл хасил итәләр...

Иртә белән мине йокымнан коточкыч тынлык сискәндереп уятты. Нәрсә булыр бу? Бөтен тирә-юнь катып калган кебек. Каюта буш. Иллюминатордан күз күнеккән зәңгәр киңлек күренми, нииндидер корылмалар, аркылы-торкылы тимерләр генә шәйләнә.

Аңлашылды. Причалга килеп туктаганбыз икән инде. Ашык-пошык киенеп палубага чыктым. Колагыма сагынылган шәһәр шау-шуы, машиналар тавышы, хатын-кыз сөйләшүе килеп керде. Палубада ыгы-зыгы. Исәнләшүчеләр дә, саубуллашучылар да байтак. Җора белән Петя чемоданнарын күтәреп чыкканнар, яр башындагы кер бавында җилфердәгән хатын-кыз киемнәренә төртеп күрсәтә-күрсәтә үзара нәрсә турындадыр күңелле генә сөйләшәләр, көлешәләр.

Ремонт вакытында траулерга яңа команда җыялар икән. Теләсәк, безгә дә калырга була, ди.

Калыргамы, юкмы, дип баш ватып торган арада, мине өлкән ярдәмче үз каютасына чакырып алды.

— Расин, — диде, — син безнең суднода иң яше, китәсең килмәсә, кал, китәргә теләсәң дә, бер-ике атна сабыр итеп тор, яр буе командасы җыелып беткәч китәрсең.

— Ә Грегус Георгиевич?

— Нәрсә Грегус Георгиевич?

— Ул каламы?

Гуляев мыек астыннан гына елмаеп куйды.

— Кала, дип тә әйтеп булмый әле аны, китә, дип тә...

Моторлары тынган, утлары сүнгән җансыз траулердан хәзер үк китәсем килсә дә, мин ризалашырга мәҗбүр булдым. Чөнки китү-калу хакында сүз барганда, «гипертония» искә төште. Китүен китәрсең, китүе ансат. Ә яңадан килергә туры килсә? Ярый да комиссиясез, яисә теге чактагы кебек ашык-пошык кына карап кабул итсәләр.

Төш җитәрәк причалда Грегус Георгиевич күренде. Энәдән-җептән генә чыккан күн тужурка, лавсан чалбар. Очлы башлы лакланган ботинкалары ялык-йолык килеп тора. Бер кулында кызыл бантиклы өр-яңа гитара, икенче кулында калын портфель.

— Ну, Расин! — дип трапка керми генә причал читеннән фальшбортка сикерде ул, — ну, Расин, миңа хәерле юл телә, кайтам, әни карчыкны сөендерәм.

Үзәкләрем өзелеп китте. Нишләп торам соң әле мин монда, чит авыл урамында адашып калган аңгыра көчек кебек нишләп йөрим? Кассага барып акча алырга да әллүр Элмәлегә. Төкерергә траулерына, гипертониясенә. Күпме булды соң әле авылны күрмәгәнемә? Өч ай гына бит әле. Көләр Тәслимә. Шул булдымы синең ал җилкәннәр корып кайтуың, дияр. Калтыранган иреннәремне тешләштергәләп, итәкләрендә ап-ак шәһәр җәйрәп яткан сары сопкаларга, аннары эреле-ваклы мачта шәүләләре тирбәлгән күксел суга карадым. Траулер янында ук минем үз шәүләм дә тирбәлә иде. Иңнәре салынып торган куртка, зәңгәр берет, елак чырай. Фу, кыяфәтсез! Егет дисәң, егет түгел, малай дисәң, тузганак йоннарыдай төссез мыеклар төртеп чыккан.

Грегус Георгиевич гитарасын фальшбортка сөяп куйды, портфелен саксыз гына палубага ташлады, зажигалкасын чыртлатып, кыйммәтле сигара кабызды.

— Нәрсә, Расин? Әллә авырыйсыңмы?

— Авырмыйм, — дидем мин карашымны янә сары сопкаларга юнәлтеп. — Авылга кайтып тормамдыр, ахры, мин быел, Грегус Георгиевич.

— Ихтыярың — мәйлең, — диде Грегус Георгиевич ягымлы тавыш белән. — Дөресен әйтим, ошадың син миңа, күп сөйләшмәвең беләнме шунда, эчкерсезлегең беләнме... Юл аягы тотыйк, дияр идем — эчмисең. Эчмәгәч, кыстамыйм. Эчмәгәч эчмә, кирәкми... Әни карчыкны күреп килә алсам, икенче пароходка күчәм. Өнәп бетермиләр мине монда. Гому-

мән, тату экипаж түгел бу. Диңгездә генә бергә. Ярга чыккач, бер-берсеннән бик тиз читләшәләр. Әле синең белән саубуллашырга гына килүем. Я, хуш.

— Хуш, Грегус Георгиевич.

Алла! Галимулла абыйдан да катырак кысты кулымны бу.

Көндез шәһәр карап йөргәндә, ашханәгә кергәч, кемдер аш өләшүчегә саф татар телендә «Рәхмәт» диде. Ялт итеп борылып карадым. Татарстаннан ун мең чакрым ераклыкта татар теле! Кашыгымны ташлап, «рәхмәт» хуҗасын эзләргә керештем. Әнә бит ул, әнә. Өстенә калын йон джемпер кигән, йөзе ябык булса да, ияге түгәрәк, җилкәсе калын. Уң яңагында кызыл эчле галош табанындагы сырлар шикеллерәк вак кына шадралары бар, күзләре уйнап тора. Хәбир күзләренә охшаган. «Исәнмесез, абый», дидем мин аңа күзләребез очрашкач татарчалап.

Чандыр егет:

— Ә нихәл, якташ,— дип ишекне ачты. Мин аның артыннан чыктым.

— Туктагыз әле, сез татармы? — дип сорадым.

— Татар, башыңны ватар, — дип елмайды егет. — Исемем — Минай, туган җирем Аксубай. Тормышым яхшы, һөнәрем — ташчы.

Мин исememне, туган җиремне әйтүем булды, Минай рифмалаштырып та өлгерде.

— Ә син... Кайда эшлисең, Рәсим?

— Пароходта.

— Пароходта булгач, эш хутта.

— Мин бу шәһәрдә якташымны очратырмын дип уйламаган идем.

— Уралның бу ягында безнең якташлар яшәми торган җир бармы? — дип сора син, Рәсим. Ишеткәнсеңдер, шәт, Колыма алтынын да Сафи Хәбибуллин дигән агай ачкан. Ләкин ул үлгән ачтан. Алтын тапкач беркемгә берни хәбәр итмәгән, иптәшләрен кайтып алып килмәгән, алтын тулы шурф өстендә утырган катып, тынсыз, булган диләр ул агайны бик тә комсыз.

— Куптәнме бирeдә, Минай абый?

— Бирeдә, энекәш, унҗиденче ел. Әнә күрәсеңме, нинди озын урам, аны буеннан-буена без төзедек туган. Таулар тиштек, ике йөз мең вагон гранит кистек.

— Хәзер дә йортлар саласызмы Минай абый?

— Әйе, теләсәң, кил безнең бригадага, эш житәрлек анда.

— Мин төзүче түгел шул. Йорт салырга гомерем буе хыялландым да соң...

— Йотр салуның ние бар, мүклисе дә цутлыйсы... Өйрәнерсең. Кил, безнең алтынчы СМУга, СМУыбыз булыр автобус паркын чыгуга...

Минай шаркылдап көлеп җибәрде, мине иңнәремнән тотып селкеде, күзләре тулы шуклык яшьләре иде аның.

— Рәхмәт, канәт, түзден, сабыр егет икәнсең, — диде ул кинәт кенә мишәр акцентына күчеп. — яшь цакта трагедияләр язып маташкан идем, көйләп сөйләшүем шуның шаукымы. Цыкмады миннән драматург, зато, строитель цыкты, цынлап сүлим мин сиңа, канәт, теләгең булса, кил безгә эшкә. Ике-өч атнада квалификация бирербез үзеңә. Дворец кебек йортлар салырбыз. Царьлар көнләшерлек йортлар. Диңгездә йөзәргә өлгерерсең, әүвәле җирдә городлар строить итеп калдырырга кирәк, диңгездән кайтып керергә урының булсын...

Мин дулкынлануымны, мена-мена тышка бәреп чыгарга торган шатлыгымны Минайга сиздермәскә тырыштым. Алдан кычкырган күкенең башы таз була, әллә чыга, әллә юк миннән төзүче. Аннары бит әле теге ни...

— Төзелешкә дә сәламәтлекне тикшереп алалармы, Минай абый?

Минай китә башлаган иде инде. Кинәт кенә борылды, күзләрен түгәрәкләндерде.

— Бәй, сырхау түгелсеңдер лә... Пароходта эшлим, дисең үзең. Инде сәламәтлегеңә шигең бар икән, болай ит син, канәт. Бак әнә иң биек сопканы. Тигр сопкасы ул. Шуның итәгеннән түбәсенә кадәр ташлы тропинка булыр. Шәһәр артына цык» Шул тропинка беткәнче, море күренгәнче тауга каршы цап. Сопка сукмагында сулышың кабып катмасаң, сәламәт булырсың, катсаң, мине аеплама...

Кайтсам, каютада Грегус Георгиевич иске гитарасын чиртеп утыра. Кызарган күзләрен сары керфекләре белән сыйпый-сыйпый, җырлый.

...Бродяга к Байкалу подходит...

Өс-башының карарлыгы калмаган. Галстугы юк, күлмәге юк, тельняшка өстеннән генә элеп җибәргән тужуркасының җиңнәре чирле күркә канатлары сыман салынып төшкән. .

— Грегус Георгиевич!

Мине күргәч, Грегус Георгиевичның йөзе майның унбишенче кичәсе кебек балкыды.

— Бу тагаракка тагын бер путина чыгарга язган, ахры, әле миңа, Расин, — диде ул гитара кылларына йодрыгы белән басып.

— Ни булды, Грегус Георгиевич, нигә кайтып китмәдегез?

Грегус Георгиевич гитарасын зыңгылдатып диванга ташлады. Аяк өстенә басып, чайкалгалап торды да койкасына ауды. .

— Әй, шайтаныма олаксын ла барысы да! Ел саен бер балык башы инде минем. Кайтырга җыенып чыккач, корешлар очрый. Ресторанга керәбез. Беренче рюмкаларны диңгездәгеләр саулыгына күтәрәбез, икенчесен диңгезчеләр өчен, өченчесен диңгезнең үзе өчен, дүртенчесен дуслар хөрмәтенә, бишенчесен так себя. Китә инде шуннан. Аннары таксилар алып гостиницадан гостиницага кунак булып йөрибез. Анда инде буфетлар-ниләре белән ярты гостиница безнеке. Тоташ бәйрәм, кыскасы. Бәйрәмнең ахыры һәр елны...

Грегус Георгиевич бәйрәмнең ахыры ни белән тәмамлануын әйтеп бетерә алмады, кулларын идәнгә кадәр салындырып, тирән йокыга талды. Мин аның чуаланган чәчләрен рәтләдем, баш астына мендәр кыстырдым.

Озак йокламады дракон. Палубада сварка уты чытырдый башлауга, дерт итеп уянып китте. Торып утырды, бирчәйгән бармакларын чигәләренә тидергәләп алды.

— Расин!

— Нәрсә, Грегус Георгиевич?

— Биреп торасыңмы миңа юллык акча.

— Биреп торам, Грегус Георгиевич, — дидем мин ике дә уйлап тормыйча.

— Мин сиңа рәхмәт әйтмим, Расин. Егет кешегә рәхмәт әйтмиләр, мескен кешеләр эше ул рәхмәт көтеп утыру. Болай итик без, , Расин. Озат син мине. Кибетләргә дә бергә керик, вокзалга да бергә төшик. Ә менә бу паразитны, — Грегус Георгиевич одеал астыннан бер шешә коньяк тартып чыгарды, — диңгезгә атабыз.

Ачык иллюминатор артында су чупылдавы ишетелде. Грегус Георгиевич иллюминаторны ныгытып япты, боргычлап куйды, аяк өстенә торды.

— Син миңа ышанасыңмы Расин?

— Ышанам, Грегус Георгиевич.

— Киттек, алайса, Расин.

— Киттек, Грегус Георгиевич.

Ишек төбенә килеп җитәрәк Грегус Георгиевич капылт кына кире

борылды, минем аягыма баса язып, яңадан каюта түренә узды, рундук тартмасыннан ниндидер кәгазьләр кыштырдатып алды, әнисе ж…рган оекбашларны күрсәткән чактагы сыманрак самими-эчкерсез елмаеп, кулындагы кәгазьләрен миңа сузды.

— Бие, Расин, сиңа хат. Хәер, биергә дә җырларга да була монда: хат янында повесткасы да бар.

Мин Грегус Георгиевич сузган конвертны шытырдатып ачып җибәрдем. Авылдан, Хәбирдән... Сызыклы, дәфтәр битеннән борыныма акация исе килеп бәрелгәндәй булды. Бер мәл күзләремә җылы элпә эленеп торды. Аннары гына кычыткан чәчәгедәй вак кына хәрефләр күрер...е.

«...Исәнме дустым, Рәсим. Үземнең яшь йөрәгемнән кайнап чыккан ялкынлы кайнар сәламнәремне иртән искән моңсу таң җилләре һәм тиз йөрешле ышанычлы совет почталары аша син яшәгән якларга очырып җибәреп, эшеңдә һәм яшьлек тормышыңда зур уңышларга ирешүеңне теләп калучы дустың Хәбир дип белерсең. Сәлам шулай ук әниеңнән, Фирдәүсәдән, Галимулла абыйдан, Мөнәвәрә ападан, Тәслимәдән...»

Хатны йөземә якынрак китердем. Керфекләремә тагын җылы элпә сарылды. Колакларын тырпайтып мышный-мышный хат язып утырган Хәбир күз алдыма килеп басты. Тәрәзә каршыннан үтеп баручы Тәслимәнең калын толымнарын күргән дә әнә сәлам яза хәзер. Хәбирләрнең тәрәзәләренә акация … ыклары бәрелә, өй алларында Нәфисәттәй белән әни сөйләшеп тора.

— Кайтмыймы әле малаең? — дип сорый Нәфисәттәй әнидән.

Әни Нәфисәттәйгә сиздерми генә көрсенеп куя, көттереп кенә җавап бирә:

— Хаты килеп тора, акчасын җибәрә, тәүфигы-шәфкате белән йөрсен, кайтыр әле...

«...Сәламемне тәмам итеп, азрак язылачак сүзләргә күчәм...»

Юк, болай ашыгып укырга ярамый бу хатны, тыныч вакытта төнлә, тәмен белеп укырга кирәк. Кесәгә тыгып чыксам, урамда укымыйча түзә алмам. Их яхшысы мендәр астына яшереп калдырыйм да, кич иркенләп укырмын.

Повесткасы кайдан тагын, әһе, военкоматтан. «...Сәгать өчкә комиссиягә килүегез сорала...» Иблис икән, тагын комиссия. Нәрсә дип бәйләнделәр әле болар миңа? Авылда үттем бит инде комиссияне, житми микәнни шул?

Грегус Георгиевичка ияреп кибетләргә керәм — уемда комиссия, Грегус Георгиевичка ияреп вокзалга төшәм — уемда комиссия, Грегус Георгиевич белән саубуллашам — уемда комиссия... Перронда Грегус Георгиевичка кул болгап калам — уемда комиссия...

Грегус Георгиевич поезды томанлы сопкалар арасына кереп күздән югалгач, сәгать өч тулганны да көтмичә, военкоматка киттем, өстемне салып, комиссия үтәргә килгән малай-шалайларны аралап, эчкә уздым, терапевтны эзләп таптым, ярсуымны тыя-тыя хәлне төшендереп бирдем.

Колак йомшагына өлгермәгән солы тәлгәше сыманрак яшел ташлар аскан тулы гәүдәле врач кыз мин сөйләгәннәрне суламыйча диярлек тыңлап утырды. Мин сөйләп бетергәч, ирен чите белән елмаеп, нәзек беләкле ябык сестрага карады, син нәрсә дә булса аңладыңмы, дип сорады.

Баксаң, берни дә аңламаганнар икән болар. Яңабаштан ачыграк, кыскарак итеп төшендерергә керештем:

— Ие, минем башым авыртмый, юк миндә гипертония, диңгездә үземне менә дигән хис итәм. Авыру түгел мин.

Врач кыз, кемнәндер ярдәм эзләгәндәй, як-ягына каранып алды. Аның Мөнәвәрә апаныкыдай матур күз алмалары, челт-челт килеп торган сөрмәле керфекләр арасыннан атылып чыгарга әзерләнгәндәй, зурайдылар. Кызның болай да нәзек тавышы өзелә язып нечкәрде:

— Кем янына килдең соң син, яшь иптәш, нинди йомыш белән, кем җибәрде сине?

— Сезнең янга килдем. Сезнең янга комиссия үтәргә, менә повесткам.

Сөрмәле керфекләр күз алмаларын кысып, түбән сирпелделәр, тик шул минутта ук җилпенеп өскә күтәрелделәр.

— Бүген түгел бит әле сезгә комиссиягә, тагын өч көннән, менә карагыз.

Чәнчелгере икән! «Карамыйча йөрсәң, авырмыйча үләрсең» шул буладыр инде ул менә.

Повесткамны учыма йомарлап, чыгар якка борылгач, артымда ягымлы сүзләр чылтырады:

— Теләсәгез, үлчим мин сезнең кан басымыгызны, пожалуйста...

Борылдым. Сөрмәле керфекләр еш-еш җилпенеп алалар да, тынып ял итәләр, җилпенәләр дә ял итәләр. Якынрак барып тыңласаң, күбәләк канат каккан чакта ишетелгән йомшак авазлар коеладыр, мөгаен, ул керфекләрдән.

— Килегез, пожалуйста! Утырыгыз...

Мин атлар-атламас кына өстәл янына килеп утырдым, күзләремне көзгедәй шома паркетка төбәдем. Беләгемә тасма уралды, тагын «пош-пыш» башланды.

Шөкер, беләгемнең берсе «пош-пыш»тан котылды. Нигә бу турыда уйлыйм соң әле мин. Әнә ничек йомшак кына тота сөрмәле керфекле кыз беләгемне. Йомшак тотмый, бармаклары йомшакка күрә шулай йомшак кебек тоела...

Тәмамланды бугай, ниһаять, «пош-пыш» операциясе. Бер кавым сулыш юлларымны дару исе кытыклап торды, аннары сузып тамак кыргын тавыш ишетелде.

Курка-курка гына башымны күтәрдем. Күз алмалары тагын зурайганнар, тагын сөрмәле керфекләр әсирлегеннән котылганнар.

— Шаяртасыз дисәм... шаян егеткә охшамагансыз, — дип тибрәлде буялмаган алсу иреннәр.

— Ничек?

— Берничек тә түгел. Кан басымыгыз нормаль сезнең. Альпинистлар көнләшерлек хәтта.

— Ничек? Күптән түгел генә югары иде бит әле...

— Дәвалангансыз, димәк... Физкультура белән шөгыльләнгәнсез...

— Сез, сез чынлап әйтәсезме?

— Уйнап әйтә торган урын түгел бу, яшь иптәш... сау булыгыз.

— Ие, ие, рәхмәт сезгә, сау булыгыз...

Урра! Кайларга гына йөгерим дә кайларга гына сикерим икән. Шатлыгымны уртаклашырга Грегус Георгиевич та юк, ичмасам. Әх, кеше төсле саубуллаша да алмадым Грегус Георгиевич белән. Әҗәткә биргән акчасын кызгана, шуңа йомылып сөйләшә дип үпкәләп китмәгән булса гына ярар иде инде.

Төкерәм мин әҗәткә, төкерәм гипертониягә! Урра!

Шәһәр урамы буенча тиле кеше сыман әле анда, әле монда сугылып йөрдем дә кичкырын Минай күрсәткән сопка итәгенә килеп туктадым.

Биек, рәхмәт яугыры. Сукмагы боргаланып менә икән. Курткамны корыган үләннәр арасына салып калдырдым. Үз мәшәкате белән кайнашкан шәһәр ягына күз төшереп алдым. Бухтадагы теплоходларның болытларга тераләгән мачталары гына күренә иде биредән. Тирән итеп суладым һәм чәнечкеле куаклар арасыннан югарыга таба йөгереп менеп киттем. Бер борылышны җиңел үттем, икенчесен... Өченчесен... Дүртенче борылышта сулышым капты. Юк инде, егылсам, егылам, туктамыйм, туктамыйм! Менә бу борылыш цемент вагоны өчен, монысы караңгы Иделгә кереп югалган бүрәнәләр өчен... Менә монысы башмак

өчен, монысы... гипертония өчен... Монысы иң текәсе, иң соңгысы — ал жилкәннәр өчен... Күкрәгемә гүяки эрегән кургаш тутырып куйганнар — авыр, кайнар... Аяк астыннан вак ташлар чәчрәп түбәнгә оча. Шәрә ботаклар күземә чәнечкеле тимер чыбыклар булып күренә. Мин — солдат. Мин һөҗүмгә барам. Миңа чигенергә дә, егылырга да ярамый. Мин жиңәргә тиеш!

Ниһаять, сукмак сөзәкләнде. Каршымда офыккача ялтырап гаҗәеп олы, кыргый диңгез ачылып китте. Сопка башындагы иң биек таш өстенә менеп бастым. Диңгездә дә, яр буенда да бер генә җан иясе дә юк иде. Бушлык, иксез-чиксез бушлык, су, таш таулар, болытлар. Бирегә диңгез шавы да менеп житә алмый иде хәтта. Җилләр дә тавышсыз исә иде бирегә. Бирегә минем йөрәгем генә ярсып-ярсып тибә иде.

Текә яр читенә үк килеп түбәнгә карадым: аста бәп-бәләкәй, тып-тын култык моңсуланып ялтырый иде. Тып-тын түгел икән. Кыялар арасыннан жил үтеп кергәндә, жыерчыклана икән су йөзе.

Диңгез үзе тиктормас малай булса, бу тын, уйчан култык — мөгаен аның әнисе. Борынгы тау тезмәләре белән уратып алынган иске йортта әнисен ялгыз гына калдырган да диңгез, ерак якларга чыгып киткәндер...

Кыялар артына төшеп барган якты кояштан оялгандай, йөзен күрсәтер-күрсәтмәс кенә ай урагы калыкты... Диңгез айны сөядер. Ләкин ай диңгезне яратмыйдыр. Кояшны юксынып, кояшны сагынып гомер кичерә торгандыр.

Сагынсын соң, сагынмагае! Бик аптырый диңгез! Дулкынлануы дулкынлану, офыкларны иңләп тирбәлүе тирбәлү әнә...

Әнисе кызганыч диңгезнең: шәрә таулар арасында берьялгызы сагышланып яши.

*1979—1980*

## Роберт Миңнуллин

# КИЛӘЧӘККӘ ТАБА

### Ашыгабыз

Ашыгабыз! Кая ашкынабыз?
Алга юллар, дөрес, ачык тора.
Заманабыз, кочакларын җәеп,
Капкаларын үзе ачып тора.

Киләчәккә таба төгәл генә
Көннәр, айлар, еллар узып тора.
Чал Тарихка китеп бара алар,
Кигән кием кебек тузып тора.

Чуар җанлы карт Кешелек әнә
Киләчәккә сукмак ярып бара.
Үз иңендә ниләр күтәргән ул?
Киләчәккә ниләр алып бара?

Чәчәкләрме, әллә бомбалармы
Киләчәккә дигән бүләгебез?
Ә Киләчәк баш тартмасмы бездән?
Сынатмасмы анда бирәребез?

Җавап эзлим шушы сорауларга,
Җавап көтәм сездән ачык кына:
Без заманны кая куалыйбыз?
[illegible] безне кая ашыктыра?

...Дөрли дөнья — кабынырга тора,
Түгелергә тора, ташып тора.
«Кешелекне нишләтергә?» — диеп
Яшь Киләчәк алда басып тора.

## Яланнарда йөри шагыйрь

*Сибгат ага Хәкимгә*

Яланнарда йөри шагыйрь...
Ул тын гына моңлана.
Әллә шагыйрь, әллә кошлар
Бер-берсеннән моң ала?!

Күпме моң туа җанында,
Ә күпмесе — бирердә.
Сибгат Хәким моңы белән
Сайрый кошлар биредә.

Тын гына җырлый үзе дә,
Тын моңы — күптән таныш.
Ул — тамак төбеннән түгел,
Җаныннан чыккан тавыш.

Көр тавыш белән дә җырлый
Белә ул. Ник белмәскә!
Аның тын гына җырлавы —
Кошлар җырын бүлмәскә.

Шагыйрьне бу яланнарга
Туачак Моң, Көй дәшә:
Гөлләргә шигырь укый ул,
Урман белән сөйләшә.

Агачларга, үләннәргә
Кагыла ул сак кына.
Ул бит шагыйрь генә түгел —
Тылсымчы да чак кына.

Яланнарда йөри шагыйрь...
Юкка гына йөрмидер:
Җанында Гамь, Моң, Җыр, Шигырь
Берөзлексез дөрлидер.

Ни булмас шагыйрь җанында —
Үзе белә ул аясын.
Яланнарда йөри шагыйрь...
Бүлдермәгез — уйлансын.
Бүлдермәгез — моңлансын!

## Юк, сайрамый...

Читлектә — кош. Җырның җаны...
Талантлы, моңлы, чибәр!
— Җырламый ничек түзәсең?
Булмаса, сайрап җибәр...

Җыр кайгысымы соң анда! —
Сунә генә тарлыктан.
Төшендә ул урман күрә,
Җыр ишетә таллыктан.

Читлеккә ничек сыйсын җыр —
Калган шул ул иректә...
Ә кошны и иркәлиләр,
Карыйлар җим биреп тә.

Юк, сайрамый, сайрый алмый,
Омтылса да еш кына.
Сандугач түгел инде ул —
Гап-гади бер кош кына.

## Энекәшләр

Берегез — Фән, берегез — Рим, берегез — Ким!
Горур булыйк, энекәшләр, без кемнән ким?!

Минем янда пәһлеван сез өчегез дә.
Әкияттәге шикелле көчегез дә:

Салсал Батыр, Камыр Батыр, Алып Батыр
Көрәшләрдә дошманнарны алып атыр!

Ватанымның солдатлары өчегез дә.
Солдатлар сез хәзер инде эшегездә.

Сабантуйда, мәйданнарда калыр батыр
Салсал Батыр, Алып Батыр, Камыр Батыр!

Әнкәемнең буе җитми кочакларга.
Сез — мәһабәт! Сыймыйсыз сез кочакларга.

Уртак җиңү — алышларда калса батыр
Камыр Батыр, Алып Батыр, Салсал Батыр!

Сез бар чакта Әнкәй тыныч, мин дә тыныч.
Сезнең кебек ирләр барда ил дә тыныч!

## Кызлар-җырлар

Яшәгәннәр гүзәл Зөлхиҗәләр,
Зиләйлүкләр, сылу Гөлҗамаллар.
Гөрләп торган алар авазыннан
Аулак өйләр, өмә, гөлъяланнар.

Җырлаганнар алар качып кына:
Җырларга да рөхсәт ителмәгән.
Елый-елый җырлаганнар алар,
Тик җырлары бәхет китермәгән.

Яратканнар кызлар Зөһрә кебек —
Яратырга ләкин ярамаган.
Яшь кызларның аккош җанын язмыш
Теләгәнчә телгән, яралаган.

Әмма якты, матур өметләрен
Югалтмаска кызлар тырышканнар.
Гүзәллек тә, хис тә, мәхәббәт тә
Бер моң булып җанда тулышканнар.

Алар гүзәл булган! Гүзәл була
Халык моңын җыйган күңел генә.
Җырга әверелеп, берәм-берәм
Очып киткән кызлар бүгенгегә...

Алар җыр-моң инде. Ул җырларны
Ир-егетләр җырлар, кызлар җырлар!
Халкыбызның җаны, бәгъре булып,
Күңелләрдә яши кызлар-җырлар.

Моңнар тула җанга, күңел тула —
Ал курайны, әйдә, ал кубызны!
Кызлар-җырлар ерак киләчәккә
Илтә бара туган халкыбызны.

## Ялгыз ләкләк

Сыгылдырып озын сыйракларын,
Бөтен буе белән сузылып,
Күтәрелде Сөннән ялгыз ләкләк,
Сыны гына калды сызылып.

Кем куркытты аны — Сөн сылуын!
Кагынды да бөтен көченә,
Кереп югалды ул офыктагы
Баеп барган кояш эченә.

Дулкынланды таллар. Җилләр генә
Исеп калды бер пар канаттан.
Каян килгән соң ул? Сөн буена
Кайтканмы соң-әллә кабаттан?!

Күз алдымда һаман ялгыз ләкләк,
Ләкләкнең иң сылу сынлысы!
Тик җанымда бер хис өзгәләнә
Һәм сулкылдый: соңгы... соңгысы...

●

Туйдым инде кыштан.
Арытты ла аклык.
Күзгә керә кояш.
Түзә алмам артык.

Сине кыштан эзләп
Таба алмаганга,
Шуңа күрә кышта
Кала алмаганга,

Кереп киттем язга,
Утка кергән кебек,
Утта янасымны
Алдан белгән кебек.

Яшисеңме әллә
Син тик язда гына?
Әйтәм аны, күңел
Тарта яз ягына.

Минем бәхеткә дә,
Ахры, язлар язган,
Мин тапканчы, зинһар,
Китә күрмә яздан!

...Синең күптән язда
Икәнеңне белеп,
Ташлап киттем кышны
Вакытыннан элек.

## Мәхәббәтем кошы

Син еракта миннән. Тәрәзәңә
Берәр кошчык килеп кунамы?
Әгәр кунса, кума син ул кошны —
Мәхәббәтеңнең ул кунагы.

Ул — бердәнбер генә. Ул кошчыкка
Кушылмаган әле исем дә.
Шул кош булып оча синең янга
Яратуым, моңым, хисем дә.

Сөюемнең җаны, рухы ул кош —
Сөй син аны, яме, иркәлә!
Куркытмасаң, синең тәрәзәңә
Ул киләчәк әле иртәгә.

Тик сайрамас ул кош. Гаҗәпләнмә.
Карап кына торыр күзеңә.
Ә аннары мәхәббәтем кошы
Очып кайтыр минем үземә.

Ул ташламас сине. Миннән соң да
Килеп йөрер синең янына.
Син тимәссең, яме, ул кошчыкка,
Кагылмассың, яме, җаныма!

●

Табигатьнең безне сынавымы,
Соры көннәр безне таныштырды.
Сокланырлык табигатебезне
Әйтерсең лә, пәри алыштырды.

Күкрәкләрдә тыпырчына йөрәк,
Күздә түгел инде, кышта күңел.
Әй табигать — язмыш кочагында,
Күз дә түгел җирдә, кыш та түгел.

Дөнья төссез, дөнья көчсез бүген,
Яшел түгел, сары, ак та түгел.
Шыксыз җилләр төссез җырлар җырлый,
Ярый әле безнең хакта түгел.

Кем хакында, ни хакындадыр ул,
Тетри күңел менә шушы җырдан.
Мәхәббәтне безгә исән килеш
Алып чыгу кирәк шушы чордан.

Табигатьне без үзгәртик мәллә? —
Үзгәртергә җитәр бер асыл сүз.
...Әй табигать (белмим, озаккамы?)
Бер фасылсыз калган, бер фасылсыз.

●

Чияләргә карыйм. Кызыктырып
Иреннәрең төсле янып тора.
Әй алмалар, бит очларың төсле,
Алсуланып һәм оялып тора.

Бал гынадыр кояш алмалары!
Алсу төсләр өсти таң аларга.
Җиңел булмасмы дип, битләремне
Куеп торам алсу алмаларга.

Йолдызларны үбәм. Күзләреңне
Үпкән кебек үбәм мин аларны.
Охшатканга синең тавышыңа,
Чишмә җырын тыңлыйм мин аннары.

Һәм талларның бөдрәләрен сыйпыйм,
Сыйпагандай кара чәчләреңне.
Син дә мине сагынасың икән —
Агинештән җыям яшьләреңне.

## Шигырь кичәсендә

Шигырь укыйм залга. Башыма да
Китермәдем болай буласын:
Залда — йөз кыз һәм син — якты йолдыз,
Ерактан ук балкып торасың.

Ап-ак кофтаң күзне чагылдыра,
Күзләремә хәтта яшь килә.
Син талпынып очып китәр төсле,
Сиңа карап бер сүз дәш кенә!

Беләм бит мин ул тылсымлы сүзне,
Синең өчен җитә бер сүзем.
Ләкин әйтмим әле. Очарсың да,
Мин калырмын монда берүзем.

Күзләреңә карап шигырь укыйм.
Мин алардан күпме моң оттым.
Сиңа карап, сиңа багышланган
Шигыремне кинәт онытгым.

Баш әйләнеп китте — җанымдагы
Шул гомерлек татлы ярадан.
Кычкырасым килде бөтен залга:
«Мин яратам сине, яратам!»

Тик әйтмәдем. Бер-беребезне без
Ул сүзсез дә, ахры, аңладык...
Шигырьләрем дәрли ялкынланып,
Бит очларың яна алланып.

Залдагылар исә ничә кабат
Алкышлары белән бүлделәр.
Алар белмәделәр. Шигырьләрне
Безгә укый диеп белделәр.

## Багышлау җыры

Синең белән узган минутларны
Айлар-елларга да алышмыйм.
Уем белән мин гел синең янда,
Өзгәләнсен әле синең җан да —
Бу җырымны сиңа багышлыйм!

Сагынулар, саргаюлар белән,
Югалтулар белән [illegible] мин.
Син дә мине искә төшерерсең,
Мине сөюеңне төшенерсең —
Бу җырымны сиңа багышлыйм!

Сине уйлап узган гомеремне
Сагышларым белән нәгышлыйм.

Син дә мине сагынырсың әле,
Узганнарга сарылырсың әле —
Бу җырымны сиңа багышлыйм!

Шатлыкларым күңел тулы иде,
Шатлык идем, инде сагыш мин.
Сиңа ләкин шатлык кына теләп,
Сиңа ләкин аклык кына теләп,
Бу җырымны сиңа багышлыйм!

## Оныт!

Оныт безнең мәхәббәтне,
Оныт җирдә мин барын!
Син теләсәң, бик теләсәң,
Кичерермен мин барын.

Булмады диеп исәплә
Бәхетле минутларны.
Теләсәң, мин сүндерермен
Җанымдагы утларны.

Оныт сиңа гына әйткән
Иң кадерле сүземне!
Тик борчылма, сөю үзе
Бирер миңа түземне.

Законнан тыш дип игълан ит
Мин сине яратуны.
Курыкма, минем болай да
Җанымда яра тулы.

Күңелеңнән чыгарып ат,
Оныт минем исемне!
Тик елама! Әллә инде
Миңа җиңел дисеңме?

Тик син минем бу сүзләргә
Йөри күрмә алданып:
Оңыта алмасыңны мин
Белеп торам алдан ук!

●

Сөюнең соңгы поезды
Җыенган кузгалырга.
Тәрәзләре кай арада
Өлгергән бозланырга?!

Кирәк миңа өлгерергә —
Ул мине көтеп тормас.
Сөюемнең поездлары
Моннан соң үтеп тормас...

Өлгерергә, өлгерергә
Булса да ничек кенә!
Икәүләшеп йөгерәбез
Ак карлар кичеп кенә.

Ә син сабыр. Син беләсең:
Синең кулда — киләчәк.
Сөюеңнең поездлары
Сиңа үзе киләчәк.

Туры килер әле сиңа
Бик күпне кичерергә.
Ә миңа һич тә ярамый,
Ярамый кичегергә!

Соңгы поезд... соңгы сөю...
Ул көтеп тормаячак.
Белеп торам, өлгермәсәм,
Башкасы булмаячак!

Равил Вәлиев

# ГӨЛМӘРҖӘН МӘКЛӘРЕ

хикәя

*Бөек Ватан сугышында һәлак булган этием истәлегенә*

## I



Гөлмәрҗән карчыкны авылда олысы да, кечесе дә Мәк әби дип йөртә.

Июль башлары җиттеме, Гөлмәрҗән карчыкның бәрәңге бакчасы ут капкандай кызарып чыга. Куе кызыл, алсу-көрән мәк чәчәкләре белән тула бакча. Кияүгә чыгарга җыенган кызларның туй күлмәгедәй ап-ак төстәгеләре дә күренгәли. Тик алары, ирләрен исән-сау килеш сугыштан каршылау бәхетенә ирешкән хатыннар кебек, сирәгрәк очрый. Күбрәге — кызыллар һәм алсулар..

Гөлмәрҗән карчык авыл читендәге искерәк кенә бер өйдә яши. Бәрәңге бакчасы кырыеннан, челтер-челтер килеп, соңгы елларда шактый саега төшкән Ашыт суы ага. Каршыдагы кечкенә генә агач күпер аша район үзәгенә озын юл үтә. Әлеге юлдан йөргән кешеләр, барган җирләреннән туктап, Гөлмәрҗән карчыкның кызыллы-яшелле бәрәңге бакчасына еш кына сокланып карап торалар.

Ерак җирләрдән туган-үскән якларын сагынып кайткан сабантуй кунакларын озатканда авыл хатыннары:

— Һи-и-и... Бигрәкләр дә тиз китәсез инде, ходаем! Очрашкан күк тә булмадык — ай күрде дә кояш алды үзегезне! Берәр атна сабыр итсәгез, Мәк әби бакчасындагы чәчәкләрне күреп китәрнегез. Хәрәпләр дә матур итеп яналар инде менәтерә! — дип саубуллашалар.

Июнь азаклары якынлашса, авыл механизаторлары:

— Мәк әбинең бәрәңге бакчасы кызара башлаганчы ничек тә печән эшләрен тәгәллисе иде. Аннары явымнарга китүчән була,— дип сөйләшәләр.

Гөлмәрҗән карчыкның ут күршесе — сугыш башланып берничә ай үтүгә, кулындагы бармакларын өздереп кайткан ире белән тигез генә гомер кичерүче Бәдыйгыл киленнең ат ятып аунарлык иркен түтәлләрендә дә матур-матур чәчәкләр үсә, югыйсә. Ул мамык кебек күперешкән түбәтәй-түбәтәй колмаклар, ул яшел рәшәткәләр буйлап үрмәләгән кыргый йөземнәр, ап-ак бадьяннар, зәйтүн һәм мигәүшәләр дисеңме — мәктән башка, дөньядагы бер генә чәчәк тә калмаган инде! Ләкин ни гаҗәп: Әҗем кешеләренең бу купшы түтәлләргә әллә ни исләре китми!

Бер елны шулай — күрше бакчадан очып төшкәннәр, күрәсең — Бәдыйгыл киленнәр бакчасында да язгы дым белән берничә төп мәк тишелеп чыккан иде. Ләкин Гөлмәрҗән карчыкның күз алдында:

— И-и, Мәрҗәнаттәй, ниләр генә дип утыртасың икән шул мәкләренне! Чәчәк атып ике-өч көн утырмыйлар — кырау суккандай, сулалар да төшәләр. Аннары, каккан казык шикелле, тик тырпаешып утыралар. Шайтан таягыннан бер дә артык җирләре юк инде менәтерә, билләһи! Ни матурлыгы, ни файдасы дигәндәй... Алар урынына мин лутчы керән утыртам! — дип такылдый-такылдый аларны ул чәчәкләре бөреләнгәнче үк йолкып атты.

Гөлмәрҗән карчык ул чакта:

— Әй... Ходайның язганыдыр инде, Бәдыйгыл килен! — дип сүзне озынга сузып тормаган иде.

Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә, ди шул!

Ә менә мәк шау чәчәк аткан июль башлары — Гөлмәрҗән карчык өчен дөньяда иң бәхетле көннәр! Аның өчен Яңа ел дигәннәре июльдә башлана! Ул, башкалар кебек, бер январьдан икенчесенә хәтле түгел, ә бер мәк чәчәк атудан икенчесенә кадәрле яши.

Ел саен бер генә килә һәм аккан сулар кебек бик тиз үтеп тә китә торган бу кадерле көннәрдә, бәрәңге бакчасы башындагы яшел чирәмлеккә утырып, Ашыт суы белән сөйләшә-сөйләшә, Гөлмәрҗән карчык кемнедер көтә, юксына, искә төшерә.

Юка ияген кәшимир яулыгының чите белән каплый да, кипшенгән, кан тамырлары бүртеп-беленеп торган икенче кулын кашы өстенә куеп, әледән-әле юлга күтәрелеп карый. Һәм, аяк-куллары сызлаусыз була күрсен, шулкадәр өзелеп көткән кешесе ел саен июнь азаклары — июль башларында бер кайтып китми калмый.

Тик быел гына әллә ничек килеп чыкты менә.

Бәрәңге бакчасында мәк чәчәк атар көннәр җиткәндә Гөлмәрҗән карчык кинәт сырхаулап китте. Ашаудан калды, кипте, саргайды. Тереләчәгенә өмете көннән-көн сүрелә барса да, шәһәрдәге бердәнбер күз нурын чакыртып телеграмма җибәртергә базмады. Берничә көн элек кенә килгән хатында улы Рамил уналты катлы йорттан яңа фатир бирүләре турында язган иде. Күченеп йөргән, мәшәкатьле чакларыдыр.

Бу хәбәргә Гөлмәрҗән карчык куанып бетә алмады. Ничек итеп сөенмәсен ди: ул «малосемейка» дип аталган уртак куышта (улы Рамил аны шаяртып «бала сыймыйка» дип йөртә иде) дүрт кешелек гаилә белән ничә ел буе яшәп кара әле! Сабыр төбе — сары алтын дигәндәй, инде менә сиңа өр-яңа өч бүлмәле фатир! Яңа йортта, тыныч кояш астында бәхет-тәүфыйклары белән генә яшәргә язсын иде инде. Гөлмәрҗән карчыкның улы-килененә һәм оныкларына бар теләгәне шул.

Ул яңа фатир дигәннәрен үлгәнче бер күреп каласы бик килә иде дә килүен. Улы-килене дә ике сүзләренең берсендә: «Әни, яңа фатир алу белән безгә килеп яши башларсың».— дип күңелне ымсындырып торганнар иде. Ул, әлбәттә, туган нигезен бөтенләйгә үк ташлап китә алмаячак. Тик шулай да салкын кышларны улы-оныклары янында үткәреп җибәрергә исәбе юк түгел иде. Нишләтәсең, насыйп түгелдер инде, ходайның бирмеш көне!

Гөлмәрҗән карчык бәлки шулай дөнья куйган да булыр иде. Әле ярый күрше Мөршидә бар! Хат-хәбәр булсын-булмасын, яңа килгән почтаны өйдән-өйгә өләшеп йөргәндә, ул көн саен Гөлмәрҗән карчыкның хәлен белеп чыкмыйча калмый иде. Менә шул пучты кыз бүген иртүк ашыгыч телеграмма тотып керде һәм шартлатып укып та бирде: «Күршеләрдән хат алдым. Көт, әнкәй, кайтам!»

Бу сүзләрне ишеткәч, Гөлмәрҗән карчыкның хәлсезләнеп калган гәүдәсенә көч кереп киткәндәй булды. Аз гына кузгалу белән шыгыр-шы-

гыр килә башлый торган агач караватыннан ничек торып утырганын сизми дә калды:

— Ә-ә?.. Менә сиңа кирәк булса!.. Кеше борчып йөрмәсәләр соң — күршеләрне дә әйтерием! Төнәген генә үзең укыдың ич! Яңа фатир бирделәр дип язганые түгелме соң?

— Борчылма, Мәк әби, борчылма!..— дип кабат урын өстенә яткырырга теләде хат ташучы кыз Гөлмәрҗән карчыкны.— Безнең Рамил абый энә күзеннән үтеп йөри торган егет ул. Раз кирәк икән, яңа фатирына да күченер, авылдагы авыру әнисе янына да кайтып килер.

— Рәхмәт инде, кызым, яхшы сүзенә!..

Гөлмәрҗән карчык урын өстенә бүтән ятып маташмады — улын каршы аласы бар ич аның! Бу турыда уйлауга, аның тән-буыннарына әбелхәят суы бөркелгәндәй булды, көч-сихәт йөгерде.

Хат ташучы кыз чыгып киткәч, эшне нидән башларга белмичә, Гөлмәрҗән карчык шактый вакыт эштер-өштер килеп йөрде. Анын хәл кереп киткән куллары әле бер нәрсәгә, әле икенчесенә килеп тотынды... Һиһаять, исенә төште: үлеп кабартма ярата ич аның Рамиле! Тиз генә камыр басты да кабара торсын өчен аны куәс чиләгенә салды. Аннары, бераз һава суларга дип, урамга чыгып китте.

Өйалды ишеген ачып җибәргән иде—Гөлмәрҗән карчык шатлыгыннан «дерт» итеп китте, бәрәңге бакчасы шау чәчәктә! Тотсаң бармакларны пешерерлек алсу-кызыл, кызларның күз сөрмәсе төсле күрәнкүгелҗем мәк чәчәкләре!

Куәс чиләгендәге кабарырга куеп калдырылган камыр онытылды. Шул уттай кызыл мәк чәчәкләре арасыннан, бәрәңге буразнасы буйлатып, Гөлмәрҗән карчык акрын гына Ашыт суы буена таба атлады. Мәк орлыклары сыман кара төрткеләр төшерелгән кешелеккә киеп тота торган ак ситсы күлмәгенең итәкләрен тез асларына җыеп куйды да җайлап кына яшел чирәмлеккә утырды. Күзләре янәшәдә, аяк очында гына челтерәшеп аккан көмеш дулкыннарга төште.

Ашыт суы соңгы елларда бик саекты. Ләм бөркәнгән яшкелт ташлар арасыннан, чулпы чыңыдай чупыр-чупыр килеп бераз агалар да, юшкынлы турыга житкәч, көмеш чәчле дулкыннар сүнеп-хәлсезләнеп калалар. Әйтерсең, елганың да сулар өчен тыны житми!

Ләкин Гөлмәрҗән карчыкның хәтер ярлары арасында Ашыт гел ташып, гел ургып ага...

## 2

Алар өйләнешеп берничә көн үтүгә, сугыш чыкты.

Әбүзәрнең бер дә кулыннан килмәгән эше юк иде. Сугыш алдыннан байтак вакыт Артышлы артилендә эшләп, ул бөтен районга танылган тегүче булып китте.

Сугыш купкан көннең иртәгесендә үк, фронтка җибәрүләрен сорап, Әбүзәр хәрби комиссариатка барды. Сабыр итәргә куштылар... «Тегү машинаңны майлый-карый тор: тиздән илгә бик күп хәрби кием кирәк булачак»,— дип борып кайтардылар.

Сабыр итә-итә сабыр канатлары сынып бетә язды Әбүзәрнең. Ул бер таңнан икенче таңгача, төрле үлчәүле солдат шинельләре, яшел гимнастеркалар, галифе чалбарлар, пилоткалар текте. Ләкин күңеле һаман фронтка омтылды. Бер көйгә кием теккән тегү машинасы тавышы аңа еш кына пулемет тыкылдавы булып ишетелә торган иде.

Вакыт белән исәпләшеп торырлык заман түгел иде — ял көннәрендә дә эшләделәр. Шулай да, жаен-әмәлен табып, ике атнага бер унике чакрымдагы Әҗемена — карт әнисе һәм сөекле Гөлмәрҗәне янына

кайтып китмичә калмый иде. Йокы аз эләккәнлектән, Әбүзәрнең ябыгып-тартылып киткән йөзе үзе теккән шинель тукымасы кебек сары төскә кергән, зәңгәр күзләренең агы яшен тамыры шикелле кәкре-бөкереле кызыл сызыклар белән челтәрләнеп беткән була иде. Хәер, ул чакта йокы дигәннәре кемгә генә туйганчы эләкте икән! Гөлмәрҗән үзе дә иртәдән кичкә чаклы колхоз эшеннән кайтып кермәде: атын да җикте, урагын да урды, көлтәсен дә бәйләде... Өйгә кайтуга, тизрәк урын өстенә аву ягын карый иде.

Шулай аеры-йомры яшәп, сугышның беренче язы да җитте. Апрель башларында — Ашыт елгасында боз кузгала башлаганчы — Әбүзәрнең Әҗемгә кайтып китәсе атнасы иде. Тик ул бу юлы, никтер, кайтмады. Гөлмәрҗән дә, Әбүбәкер карт та төне буе керфек какмадылар. Уйлары гел юлда булды. Мәгәр ике күзне дүрт итеп көткән кешеләре кайтмады да кайтмады.

Соңыннан, юллар төшкәч, Әбүзәр белән бергә эшләгән тегүче Гыйззәт, кайтып барысын да әнәсеннән җебенә хәтле сөйләп китте.

## 3

Әҗемгә кайтып килергә әзерләнеп беткән Әбүзәрне ашыгыч төстә авыл Советына чакыртып алдылар.

— Шинель тегә-тегә элекке һөнәреңне онытып бетермәдеңме соң әле? Аръяк тавындагы пыста йортта срочно яңа мич чыгарырга кирәк! Ул мич штубы өйне дә җылытырлык, иркенләп ашарга пешерерлек тә булсын! — диде авыл Советы председателе һәм бераздан, салпы якка салам кыстырып, өстәп куйды.— Бөтен ышаныч синдә, Әбүзәр! Юлыңны бүлгәнгә ачуланма инде. Шулай ашыгыч килеп чыкты...

Көнбатыштан эвакуацияләнеп, Арча вокзалына балалар йорты кайтып төшкән икән. Шунда тәрбияләнүчеләрнең зур бер группасын алып кайтыр өчен Артышлыдан бүген атлылар чыгып киткән. Иртәгә көндезге уникеләрдән дә калмыйча кайтып җитүләрен көтәләр. Шуңарчы хет дүрткә ярыл — яңа мич чыгарылып бетеп, кыш буе ягылмаган өй эче май кебек җылытылып куелган булырга тиеш. Хәзер көн кичкә авышып бара. Вакыт күп калмаган.

Нишләсен Әбүзәр — балалар дигәндә, аяк идәндә инде аның! Тиз генә фатирына кайтып, өстен-башын алыштырды. Ул килешкә, «балалар йорты»ның ишек алдына кемдер бер олау кызыл кирпеч аударган иде инде. Биленә зәңгәр алъяпкычын бәйләде дә, Әбүзәр эшкә керешт.

Тәрәзә төбенә куелган утызлы лампа яктысында мичнең яртысы чыгарылып бетеп килә иде инде. Төнге беренче яртылар тирәсендә, алҗып-әлсерәп, әртилдә бергә эшләүче дусты Гыйззәт килеп керде.

Кечкенә гәүдәле булганга, әртилдәгеләр аны Кәтүк Гыйззәт дип йөртәләр. Гыйззәтнең үзенең дә моңа әллә ни исе китми иде. Һәр кешенең нинди дә булса бер кушаматы булмый калмый лабаса!

Юаштан юан чыгар, ди. Кәтүк Гыйззәт үзе артыннан ишекне шундый каты итеп япты, якында гына бомба төшеп шартлагандай, тәрәзә пыялалары берьюлы зыңгылдап куйды. Һәм аңа ияреп кергән җил тәрәзә төбендәге лампаны өреп сүндерде. Кирпеч, ком-балчык исе сеңгән өй эче бер мәлгә дөм караңгы булып калды. Ялгыш кагылып куйды, ахрысы — җитмәсә каяндыр өстән Әбүзәрнең аягына зур гына кирпеч ватыгы килеп төште.

— Әбүзәр, сиңа повестка!

— Повестка?!..— дип кайтарып сорады Әбүзәр, шунда ук аяк авыртуын онытып.— Чынлапмы?

Тегү машинасы текелдәгәндәй, Кәтүк Гыйззәт бик тиз сөйләп китте:

— Ыһы... Иртәгә... Юк... хәзер төнге бер тулып килә — димәк, бүген үк икән инде, кичке алтыда ваянкаматта булырга тиешсең. Сине эзли башлаганга инде биш былтыр. Әҗемгә дә шалтыратып карадык.— «Күренгәне юк,— диделәр.— Алай булгач, тизрәк кайтып китү ягын карасын, Ашытта боз кузгала башлавы мөмкин. Иртәгедән калмас... Ә күпергә ышаныч юк: быел су бик мул буласы!» — диделәр.

Күзгә төртсәң күренмәслек караңгыда әйтелгән бу сүзләр шулкадәр көтелмәгәнчә килеп чыкты, Әбүзәр башта һәрчак сул кесәсендә йөргән шырпы кабын таба алмый, аннары лампа пилтәсенә ут кабыза алмыйча азапланды.

«Чыгып китәргә, димәк, ярты тәүлек кенә калган!»

Ниһаять, өй тагын яктырды. Ике тегүче, тирән итеп тәмәке суырасуыра, кинәт кенә муеннан буып алган вакыт элмәген ничек иркенәйтүозынайту турында уйлаштылар. Кием теккәндә әгәр ситсы җитми калса, яңасын ялгап була. Ә менә вакыт кайчысы, мәрхәмәтсез сугышның үзе кебек үк, кайчакта тормыш тукымасын бер дә ярамаган урыннан кисеп-тураклап ташлый икән шул!

Билгеле, Әбүзәр өчен бу уч төбенә сыярлык повестка кәгазе бер дә алай күктән төшкән хәл булып тоелмады. Ул аны ун айга якын көтеп яшәде. Тик менә, үч иткәндәй, шундый да тыгыз, шундый да ашыгыч вакытка туры килеп торуын кара син аның! (Энә күзеннән сынар, ди шул!) Ятим балалар кайтып җиткәнче, мичне ничек тә чыгарып өлгерергә кирәк! Ашытта боз кузгала башлаганчы, иртән аяк асты катырак чакта. Әҗемгә кайтып, әткәсе һәм Гөлмәрҗән белән саубуллашып килми дә ярамый иде. Бәлки, бу аларның соңгы күрешүләредер!

— Их, әгәр дә мәгәр мич чыгара белсәмме! — диде Гыйззәт, җеп кәтүге шикелле кечкенә һәм ябык йодрыкларын баш очында сәлки-селки.— Билләһи газим, сине Әҗемеңә кайтарып кына җибәрерием, Әбүзәр! Мич чыгарып ятар төнең мени синең?! Актык мәртәбә хатыныңны кочаклап ятар сәгатьләрең ич! И дөньялар, дөньялар — капчык-капчык җон җыялар, аны кая куялар, дип әйткән ди берәү, аптырагач...

— Әгәр дә мәгәр, тау асты Мәңгәр!..— дип үзенә-үзе әйтеп куйды Әбүзәр һәм күн итегенең үкчәсе белән тәмәке төпчеген изә-изә (шулай тиз тартылып беткәнгә, әйтерсең ул гаепле!) бераз уйланып утыргач, ниндидер карарга килгән сыман, кинәт кирпеч өстеннән сикереп торды.— Син теләсә ни әйт, Гыйззәт! Тик, бу мичне чыгарып бетерми торып, мин авылга кайтып китәлмим! Аннан күз күрер...

— Мәйлең, алайса... Бер закройщик әйтмешли, кышлык тунны тектергәнче бозлар китеп бармаса ярый ла!

Кәтүк Гыйззәтнең үзенә кирпеч биреп торырга җыенуын күреп, Әбүзәр мич чыгарган җиреннән туктап калды:

— Син нәрсә күләгәгә карап күлмәк кисәргә маташасың әле? Эштән яңа чыгып килешең! Таң тишегеннән тагын әртилгә чабасың бар.

— Бер төн йокламаганнан укам коелмас әле.

— Өс-башың да алыштырылмаган...

— Төкерсәнә, Әбүзәр!.. Исең киткән икән иске чикмән итәгенә!

— Мә алай булгач, һич югында биленә минем алъяпкычны бәйлә!

Төне буе ике тегүче, алны-ялны белми, мич чыгарды.

Ничек итсәләр-иттеләр, иртәнге алтылар якынлашып килгәндә алар түшәмгә җиткәннәр иде инде. Хәзер мичнең морҗа өлеше башланачак. Иң авыры артта калды.

Гыйззәт әртилгә китәр алдыннан Әбүзәр аның җеп кәтүгедәй кечкенә кулларын ныгытып кысты:

— Рәхмәт инде, дускай! Андый-мондый бүтән күрешергә туры килмәсә, сау булып тор!

— Ваянкаматка сине озатырга әбизәтелне киләм әле мин. Түлке, кара аны, Әбүзәр — Әҗемгә кайтып килми калма!
— Болай булгач, кайтам да кайтам инде!

## 4

Тиз генә тәмәке көйрәтеп алды да Әбүзәр, тагын кайнарланып эшкә тотынды. «Көндезге уникеләргә тикле эшне бетереп булса, минем карамакта тагын алты сәгать вакыт кала. Кайтырга, саубуллашырга, килергә — төп-төгәл икешәр сәгать! Түтелкәгә — түтелке...» — дип уйлады ул.

Ләкин бу фани дөнья мәшәкатьләрен алдан ук төп-төгәл планлаштырып булмый икән шул! Син болай үлчисең, ул еш кына тегеләй килеп чыга...

Дөрес, көндезге уникеләргә мич чыгарылып беткән иде инде. Әбүзәр мич авызы турысына кәгазь тасма китереп карады. Бераздан ул тасма, бауга эленгән кер кебек, дер-дер селкенеп тора башлады. Димәк, җиллек әйбәт суыра — тыныч күңел белән Әҗемгә кайтып китәргә дә була иде.

Ләкин бераздан, элеккерәк елларда күнегелгән гадәте буенча, үзе чыгарган мичкә үзе утын ягып карыйсы килде Әбүзәрнең. Тыштан бер кочак такта-токта кисәкләре күтәреп керде. Тагын бераздан юеш мич стенасыннан пар күтәрелә башлады, өй эченә әчкелтем-дымсу ис таралды. Балалар йортының булачак нянялары идәнне юып чыгарган арада, ул өйалдына кертеп өелгән тимер караватларны җыешты. Егермедән артык нәни караватны кертеп тезгәч, иркен йокы залы (бирдә элек район китапханәсе урнашкан иде) бөтенләй тараеп-кысанланып калды.

Ул арада Арча станциясенә җибәрелгән атлылар кәрваны да кайтып житте. Язгы җепшек көндә кырык километр юлны кайтулары җиңел булмаган, күрәсең, яңа чыгарылган мич кипкән шикелле, атларның юеш тәннәреннән бертуктаусыз пар күтәрелә иде. Ә печән-салам түшәлгән чаналарда, кәбестә кебек кат-кат төренеп, күзләре дә борыннары гына күренеп торган җанлы төенчекләр утыра иде. Кай арада бу тирәне сырып алган Артышлы хатыннары, берәм-берәм күтәреп, аларны өй эченә ташый башладылар. Берничәсен Әбүзәр дә күтәреп кертеште.

Өй эче май кебек җылынып өлгергән иде инде.

Йомшак матрацка салганчы, Әбүзәр уң беләгендә йокымсырап яткан сабыйга байтак кына томырылып карап торды. Кинәт туган Әҗеме, менә-менә бәбәй табарга җыенып йөргән Гөлмәрҗәне исенә төшеп, ул эсселе-суыклы булып китте. Куен сәгатен чыгарып караса — икенче киткән!

«Тышлыгы булды — инде эчлеге кирәк!»

Әбүзәр атылып ишек алдына чыкты һәм... чүт-чүт кенә әртил директорына килеп бәрелмәде.

— Син нәрсә, Кәбиров, дөньяңны оныттың? дип шаяртуандай итте башта директор. Аннары җитди төскә кереп өстәде:

— Әнәтерә җигүле Качыр! Чанасында ияре дә бар. Телисең икән — утырып, теләмисең икән — атланып чап! И штубы бер аягың монда икенчесе Әҗемеңдә булсын! Ашытта боз кузгала күрмәгәе...

Мондый ни чана эзе бетеп җитмәгән, ни арба эзе төшеп өлгермәгән көннәрдә Әбүзәрнең җигүле атны азаплап йөрисе килмәде, билгеле. Ул, әртил директоры җигеп йөри торган Качырны тугарып иярләде дә, турыдан — Печмәнтау болынлыгы аша туган авылына очты.

Ярты сәгать үтте микән, юк микән — акбүз атына атланган килеш

Әбүзәр Коллар тавы башында басып тора иде инде. Тик. Качырны күпме генә кумасын, ул сонга калган булып чыкты.

Ашытта боз кузгалган иде инде.

Идел шикелле җәелеп, мунча зурлыгындагы бозларны батыра-чумдыра, ике арада Ашыт елгасы ага. Ярсу дулкыннар, Әбүзәр басып торган тау итәгенә тәгәри-тәгәри килеп бәреләләр дә кире чигенәләр. Аннары, төргәк-төргәк булып, кабат ярга әйләнеп кайталар.

Әбүзәр, нишләргә белмичә, ярларыннан ташкан шул дулкыннарга байтак карап торды. Әҗемгә илтүче дамба язгы ташу астында калган иде. Озын күпер ерактан караганда шушы ташу-дәрья эчендәге утрау кебек кенә булып күренә. Язгы ташу вакытында аны бозлар бәреп ватмасын өчен, алгы якка берничә субай бәйләмнәре кагылган иде. Алар тирәсенә, яктылыкка килеп туктаган куй көтүе кебек, бозлар килеп бөялгән. Өй моржасы сыман тырпаеп бозлар арасыннан ул субайларның башлары гына күренеп тора.

Ә Ашыт арткannан-арта, агач утрау, күзгә күренеп, су астына күмелә бара иде. Тиздән, тиздән ярсу дулкыннар, төргәк-төргәк булып, күпер такталары өстеннән тәгәри башларлар...

«Эх! Өлгермәдем бит...— дип сыкранды Әбүзәрнең күңеле.— Ә өйдә... өйдә нихәлләр икән соң?»

Ияр өстендә утырган Әбүзәр кинәт сискәнеп китте: кулына озын колга тотып, бәрәңге бакчасы кырыендагы ызаннан әтисе — Әбүбәкер карт төшеп килә иде. Түр тәрәзәдән күреп алганнар димәк ки... Гөлмәрҗән кайда икән соң? Ул нишләп күренми икән?

Әбүзәр җәһәт кенә ияреннән җиргә сикерде һәм, Качырын җитәкләп, аска — елга буена төшеп китте. Су читенә җиткәч, авыр сулап куйды.

Әбүбәкер карт та теге як ярда, нишләргә белмичә, тыз-быз чабып йөри. Менә ул, ниндидер карарга килгән сыман, өстендәге бишмәтен салды да, ябык тезләре белән төя-төя, аны кысып төрде. Аннары, бик иплəп кенә күтәреп, ике кулында тирбәтеп тора башлады.

— Әти, тилердеңме әллә? Ки, зинһар бишмәтеңне! Салкын тиерәсең ич! — дип кычкырып җибәрүен сизми дә калды Әбүзәр.

Ләкин ара ерак иде. Улының ялварулы сүзләрен болай да колакка саграк булган Әбүбәкер карт түгел, ә актарылып аккан бозлар гына ишетте.

Ә шундый зәһәр җилдә бер кат ак күлмәктән генә калган Әбүбәкер карт походтагы солдат шинеле кебек кысып төрелгән бишмәтен ике куллап тирбәтепме-тирбәтә бирә.

Шатлыгыннан кинәт Әбүзәрнең йөрәге дөрселдәп куйды: «Балаң туды, балаң!.. Гөлмәрҗән килен шуңа синең белән хушлашырга төшә алмады»,— дип әйтергә теле түгелме соң аның әтисе?! Шулай ич!

Сөенеченнән нишләргә белмәгән Әбүзәр тиз генә атына менеп атланды һәм, кушаяклатып, су астында калган күпер турысындагы юл буйлап чапты. Качыр карышып маташмады: көчле күкрәге белән дулкыннарны ярып, Ашыт эченә кереп китте. Ун-унбиш адым атлауга, су атның тезенә җитте. Тагын бераздан язгы су Әбүзәрнең балтырын өтеп-көйдереп алды. Ә күпергә җитәр өчен, әле тагын йөз метрлар чамасы атларга кирәк. Тирәнгәрәк кергән саен, Качырга кыенлаша бара. Көчле агым аны һаман юлдан читкә — күбекләр кайнап торган төпсез упкынга өстери иде. Аяк астыннан басып торырлык каты җир югалдымы — беттем, диген... Бу — яңа туган беренче баласын тәүге һәм соңгы кат күреп калу хакына күрәләтә үлемгә бару белән бер иде. Ә кем белә, йөзеп булса да күпергә җитә алган булырлар иде әле, бәлки. Өметсез — шайтан, ди ич!

Шул чакны субай төбенә килеп бөялгән бозларның иң зурысы, ничектер ычкынып китте дә су астыннан араталары гына күренеп торган күпергә бар көченә китереп бәрде. Әйтерсең, якында гына снаряд төшеп

ярылды: күпер терәкләре шартлап сынды, шыгырдап сүтелгән бүрәнә-такталар, бөке кебек, берәм-берәм су өстенә калкып чыкты.

Ике яр арасы өзелде.

Шулай итеп, теләсә дә, теләмәсә дә Әбүзәр атны кирегә борырга мәҗбүр булды.

Күпер китте. Күпергә ияреп, соңгы тапкыр кавышу-күрешү өметләре дә агып китте.

Арада — ярсып-шашынып аккан бозлы дулкыннар гына! Хушлашу иделер инде бу, күрәсең...

Әбүзәр, бүреген болгый-болгый, әле аяк очыннан гына агып яткан бозлы дулкыннарга, әле теге як ярда һаман бишмәтен кимәгән килеш басып торучы әтисенә, әле кояш нурлары җемелдәшкән туган йорт тәрәзәләренә соңгы тапкыр күзләре талганчы карап торды.

Хуш, әти!

Хуш, Гөлмәрҗән!

Хуш, балам!

Хуш, Ашыт-су!..

Язгы нурлар җемелдәшкән туган йорт тәрәзәсеннән Әбүзәргә кемдер өзелеп-өзелеп карап калган кебек тоелды...

## 5

Сугышның соңгы айларында кинәт Әбүзәрдән хат килү туктады. Ләкин Гөлмәрҗән ул хәтле кара кайгыга батмады: «Хаттан элек, бәлки үзе кайтып җитәр әле»,— дип юанды.

Ниһаять, атылган кыр казлары төркеме шикелле, Әҗемгә берән-сәрән солдатлар кайта башлады.

Беркөнне ул иртүк торды да, зур мич казанын тутырып, су кайнатты. Аннары, җырлый-җырлый, озын ләгәндә кер юарга керешә:

> Сандыгындагы күлмәкне
> Ак булса да юа тор шул,
> Ак булса да юа тор!
> Үз-үземне юатмасам,
> Мине кемнәр юатыр?

Гөлмәрҗән, гадәттә, иң элек үзенең бер грамм кер кунмаган туй күлмәген юа. Юа да, киптереп үтүкләгәч, бер кимәгән килеш янә сандык төбенә салып куя. Атна үтә, ай үтә, туйдан сон бер мәртәбә дә кимәлмәгән күлмәк тагын әлеге сандыктан чыгарыла. Гөлмәрҗән аны моңсагыш тулы күзләренә каплый да ни турындадыр уйланып тора. Аннары ләгән тулы кайнар суга сала.

Туй күлмәге дигәннән, Гөлмәрҗәннең тагын бер сәер гадәте бар. Әбүзәр сугышка киткәч, Гөлмәрҗән аның бер бумази күлмәген юри юмый калдырган иде. Шул күлмәкне менә өч ел инде чиста керләре арасында саклады. Сандыкны ачкан саен Әбүзәрнең үзенә генә таныш исе килә дә җанына бераз җиңел булып китә торган иде...

Шул чакны, кош тоткандай балкып, ишек алдында уйнап йөргән улы Рамил килеп керде:

— Әни дим, әни!..— диде ул, аның күлмәк итәгеннән тышка өстерәп.— Әти кайта! Үзем күрдем...

— Ә?.. Ни сөйлисең, улым?!

Гөлмәрҗәннең тез буыннары йомшап киткәндәй булды. Аннары ул, терсәгенә чаклы сабын күбегенә баткан кулларын сөртергә дә онытып, улы артыннан урамга йөгереп чыкты.

Дүртенче яшь кенә киткән булса да, Рамил ялгышмаган иде. Күпер ягыннан чемодан тоткан бер солдат йөгерә-атлый менеп килә. Бераз катанлый төшеп атлавыннан Гөлмәрҗән аны ерактан ук танып алды:

— Күпер Зариф ич! И сөенер инде күрше Майҗамал, и сөенер!..

Улы Рамил, бөтен дөньясын онытып, солдат абыйсын каршы алырга йөгерде. Гөлмәрҗән, сөенче алырга дип, тиз генә күршеләренә кереп китте.

Майҗамал савыт-саба юып йөри иде.

— Ни булды, Гөлмәрҗән? Янасыз мәллә берүк?.. Кара әле ул беләкләреңне! Чат сабын күбеге ич!..

— Сөенче, Майҗамал җаным, сөенче-е!

— Ә?.. Әбүзәрең кайтты мәллә ходаем?

— Зарифың кайтып килә, җаным! Зарифы-ың!..

Тау кадәрле шатлыктан бер мәлгә каушап-югалып калган Майҗамал кинәт кулындагы чәйнеген идәнгә төшереп җибәрде. Ул йөгереп урамга чыкканда, Күпер Зариф Рамилне көчле кулларында үчтекли-үчтекли сикертеп тора иде. Җиргә аяклары тиюгә, Рамил кинәт сорап куйды:

— Син әтиме, абый?

— Һе-е...— диде Зариф салдат, тәмәке төтеннән саргаеп беткән мыек очларын боргалап.— Син үзең кем малае буласың соң?

— Әти малае...

— Менә ничек!.. Ә атаң кем исемле?

— Әбүзәл...

— Ә-ә... Кечкенә Әбдүш икәнсең, алайса. Әйтәм җирле охшашкансыз: күперенке иреннәр, курнос борын Әбүзәрнеке димме... Атаң кайтмадымыни соң әле?

— Ю-юк.

— Бер-бер хәбәре дә килмәдеме?

— Ю-юк...— дип, мышык-мышык килә башлаган борынын күлмәк җиңе белән сөртеп алды Рамил.

— Кайтыр-кайтыр... Син, энем, бер дә елама! Менә ул минем арттан сиңа нинди һәйбәт күчтәнәч биреп җибәрде,— дип юл капчыгына тыгылды Зариф солдат һәм улына тәгаенләп алып кайткан уенчык танкны, ике дә уйламыйча, күрше малайга сузды.

Елык-елык килеп торган кара буяулы танк кулга килеп кергәч, әти кайтмау кайгысы шунда ук онытылды, баш түбәсе күккә тия язды Рамилнең! Ул, үз чиратында, тез турысы ямаулы чалбар кесәсеннән шырпы кабы чыгарып, аны солдат абыйсына сузды:

— Мә, сиңа булсын!

— Нәрсә бу, энем?

— Ач!.. Аналы күлелсең...

— Уһы-у, песи борчагы!

— Әтигә дип җыйганыем мин аны! Ялал инде... Сиңа булсын. Танк өчен.

— Ә атаңа ни кала?

— Ул кайтканчы мин әле тагын җыялмын...

6

Көннәр бер-бер артлы үтә торды.

Рамилнең әтисе һаман кайтмады да кайтмады.

Бер авызың пешкәч, өреп кабарсың, ди. Инде Рамил хәрби киемле һәр кешенең әти була алмаганлыгына төшенде. Ул үзләренең бакча башындагы юлдан җил-җан атлап өйләренә кайтып барган фронтовикларга: «Син этиме, абый?» дип түгел, ә «Син минем әтине күрмәдеңме, абый?» дип эндәшә башлады.

Рамилнең бүләк уенчыклары арткаппан-арта торды. Тик менә әти кеше генә һаман кайтмады да кайтмады.

Тагын бераздан Рамил сугыштан кайтучы солдатларны каршы алырга бөтенләй чыкмас булды.

Беркөнне, табанына ут капкандай әсерәп, аларга авыл Советы дежурные килеп керде. Әле генә Арча станциясеннән капитан Кәбиров дигән кеше шалтыратуы, чорма бәбкәсендә эленеп торган каз түшкәсен пешерә торырга кирәклеге турында әйтте дә:

— Әбиткә генә кайтканыем, телефон ялгыз калды,— дип, ничек керсә шулай кабаланып чыгып та китте.

Кем кайткан, ник шалтыраткан — каушаудан йөрәге дөп-дөп тибә башлаган Гөлмәрҗән иркенләп сорашырга да өлгерми калды. Бераз хәл алгач, ашыга-ашыга чормага менеп китте.

Үткән язда аларның казы дүртесенә дүрт бәбкә чыгарган иде. Кышның корсагы киң, өчесе: үзенә, әтекәенә һәм улына дигәне, акрынлап ашалып бетте. Күпме ымсынган чаклары булса да, Әбүзәр өлешенә кагылырга куллары бармады. Ул каз, какланган килеш, чорма бәбкәсендә асылынган бауда гел шулай эленеп тора бирде. Газиз бала, газиз ир, газиз әти кеше кайтышка!

Чорма бәбкәсендәге калактан казны алганда, Гөлмәрҗәннең куллары калтырап азапланды.

«Бигрәк инде... Сугыш басылса дигән айларда гына суга төшкәндәй юкка чыкты ич! Тегүче инәсе түгел ул кеше — югалырга... Кайтулары хак микәнни соң, ходаем!»

Аннары какланган каз ботларын кискәндә, берничә мәртәбә кулыннан пычагы төшеп китте.

«Кайтулары хак микәнни соң, ходаем! Кулдан пычак төшеп китсә, кунак килүен көт тә тор, диләр ич! Менә сиңа кирәк булса...»

Ләкин Гөлмәрҗәннең сизгер күңеле моңа ышанып бетә алмады. Ник дигәндә, элек Әбүзәрнең, телефоннан шалтырата-шалтырата, бер дә алай шаулап йөри торган гадәте юк иде. Күпме аеры-йомры яшәп тә... Әллә сугыш кешене шулай тиз үзгәртә микән инде?...

Юраган юш килә дигәндәй, Гөлмәрҗәннең шикләнүләре юкка гына түгел икән! «Капитан Кәбиров» дигән кеше Әбүзәрнең бертуган абыйсы Әбекәрам булып чыкты.

Ул көнне алар өчәү генә утырып ашадылар. Ләкин Гөлмәрҗән, белеп-белмичәме, ашны беренче мәртәбә дүрт тәлинкәгә бүлгән иде.

Иртәгесен, сугыштан исән-сау кайткан якын туганнары хөрмәтенә, тагын итле аш пеште. Ничек инде Әбүзәр кайтышка дип шундый көндә казны җәлләп торасың?! Ит пешмәсә, бит пешә ич!

Түшенә тагылган орден-медальләре тезмәдәге балыклар төсле ялтйолт килеп торган Әбекәрам абыйсы капкаларыннан кереп киткәндә, Рамил урамда уйнап йөри иде.

Иптәшләре:

— Рамил, әнә әтиең кайтты!

— Сөенчегә бер кузна, малай!

— Ай-яй медальләре ку-уп! — дип карасалар да, Рамил өйләренә кайтырга бу юлы бик атлыгып тормады.

Аны бүген чакыртып кайтардылар.

Көннәр үтә торды.

Итле аш тагын, тагын пеште...

Бу — көтү, юксыну ашлары иде!

Ниһаять, көннәрдән беркөнне какланган каз «очып» юкка чыкты. Тик әти кеше генә һаман кайтмады да кайтмады.

Исән калган Әҗем солдатлары акрынлап сугыштан кайтып беттеләр.

Никадәр генә кыен минутлары булмасын, Гөлмәрҗән ул хәтле төшенкелеккә бирелмәде. Әбүзәрнең кайчан да булса бер кайтып килә-чәгенә өметен өзмәскә тырышты.

Рамил дә этисен өзелеп көтте. Инде алар бакчасы кырыендагы юлдан кайтып торучы солдатлар бөтән күренмәде. Ләкин ул барыбер көтте. Өй түрендәге үләннәр арасыннан буш шырпы тартмасына сәдәф хәтле генә аксыл-яшькелт песи борчаклары жыя-жыя көтте!

Беркөнне ишек алдында уйнап йөргәндә, ул үз капкаларыннан аркасына яшел биштәр аскан бер солдатның кереп килүен күреп алды. Күреп тә алды, чатыр чабып өйгә кереп тә китте:

— Әни дим, әни!..

Ләкин әнисе чормага олы мич юшкәсен ачарга менеп киткән иде. Ул төшеп житкәнче, бусагада солдат абыйсы үзе күренде һәм, керә-керешкә, Рамилне жилпучтай дәү куллары белән күтәреп тә алды:

— Я, таныш булаек... Һинең исемең ничек?

— Ламил... Ә синеке?

— Буранбай абзаң булырмын мин... Әсәең кайда һоң, энем?

— ?..

— Ә-ә... Әниең кайда дим, әниең...

— Очылмада.

Бераздан Рамил солдат абыйсына үзе сораулар яудыра башлады — түзеп кенә тор!

— Синең мидәлләлең юк мыни, абый?

— Бар, энем бар... Капчыкта алар...

— Ник такмыйсың?

— Үзең беләһең — һугыш беткәнгә бер ел инде, энем! Һәрчак медаль тагып йөремәйләр...

— Башкалар ник тага, алайса?

Солдат абыйсына бик жентекләп карап торды да Рамил тагын сорау бирде:

— Нигә синең башың тишек, абый?

— Нимес атты, энем!

— Нигә атты?

— Бәй-й... Нәмәгә булһын — үтерер өчен атты!

— Һе-е, пуле тигән ич... Үтелелгә аткач, ник үлмәдең?

— Жә, улым! Кунак' кешене шундый сораулар биреп йөдәтергә ярыймы соң инде?

Бусын — әнисе әйтте. Ул алъяпкыч читен юшкә ачканда буялган корымлы бармаклары белән ияге турысына күтәрә төшкән дә, елмаеп басып тора.

Буранбай Рамилне иплән кенә идәнгә төшерде һәм Гөлмәрҗән белән ике куллап, килеп күреште:

— Әбүзәр белән һугышта бергә булганыек...

Гөлмәрҗәннең зәңгәрсу күзләре, жил тигән утлы күмер шикелле, очкынланып китте:

— Пәрәмә-әч!.. Нигә болай ишек төбендә басып торабыз әле? Менә сиңа кирәк булса... Әйдәле, түргә үт, әйдәле! Утыр менә бу кәрпалы эскәмиягә! Менә шула-ай...

— Рәхмәт, Гөлмәрҗән!

— Әбәү!.. Син минем исемне дә беләсеңмени? Үзеңнеке ничек соң? Карале, тел очымда гына тора... бай, бай... Ә-э, исемә төште... Буранбай түгелсеңдер ич?

— Шулайрак.

— Әйтәм җирле Әбүзәр язганые аны бик әйбәт башкорт дустым бар дип...

— Һы... Руслар әйтмешли, һугышта от звонка до звонка берә булдык. Ул һине бик һагынып искә ала торганые.

— Торганые? — дип кайтарып сораганын сизми дә калды Гөлмәрҗән. Бу сүзләрне ишетүгә, аның кинәт күз аллары караңгыланып киткәндәй булды.— Мәнә сиңа кирәк булса... Башкаларның ирләре күптән кайтып бетте ич! Берәр хәл булды микәнни соң, ходаем! Ник тушы көнгә тикле бер хәбәр-хәтере дә юк икән?

— Әллә һезгә бер язу да килмәдеме?

— Килде-килүен... Тик күңелнең ышанасы киләмени? Бигрәк сугыш бетәр алдыннан гына суга төшкәндәй югалды ич!

Өй эчендә авыр тынлык урнашты.

Шактый икеләнеп торганнан соң, ниһаять, Буранбай Әбүзәрдән калган чигүле янчыкны алырга дип кесәсенә тыгылды. Ләкин, плюш тукымага орынуга, аның бармаклары пешеп киткәндәй булды. «Димәк, бу йортта Әбүзәрне әле һаман көтеп яшиләр!» — дип уйлап куйды ул һәм тиз генә буш кулын куен кесәсеннән тартып алды.

— Әбүзәрем кайда калды?.. Ник тел яшерәсең, Буранбай? — диде Гөлмәрҗән, ниһаять, күз яшьләренә тыгылып.

— Кайда калды дип... Яшерәм дип...

Буранбай ык-мык итте. Кинәт аның күзләре ишек төбендәге сәкедә торган солдат капчыгына төште. Ул тиз генә аны алып килде дә, «сүз булмаганда сүз булсын — ата казыгыз күкәй саламы» дигәндәй, өстәлгә берәм-берәм фронт күчтәнәчләре бушата башлады:

— Менә монысы — тушонка, ә монысы — сохари... Һолдат икмәге, ягъни мәсәлән...

Әнисе котыртып тора диярсең — күзләрен мөлдерәтеп, инде бу юлы Рамил сорап куйды:

— Әти кайчан кайта, абый?

— Менә монысы — консервы...— дип биштәрен бушатуда дәвам итте Буранбай. Рамилнең мөлдерәүле күз карашын тоеп. Кинәт ул дусты Әбүзәрнең батырларча һәлак булуы турындагы дөреслекне әйтә алмаячагы, һәрхәлдә бүген әйтергә тиеш түгеллекне аңлап алды. Өмет җебе өзелергә тиеш түгел! Кайчак дөреслек хакына ялганларга да кирәк була икән ул!— Әтиеңме? Кайтыр, энем, кайтыр... Яралары гына төзәлеп җитһен дә. Ә менә боларын һиңә әтиең госпитальдән биреп җибәрде...

Бияләй кадәрле берничә шоколад кулына килеп кергәч, Рамилнең авызы колагына җитте.

Ә Буранбай, тәмәке тартырга дигән булып, өйалдына чыгып китте. Тәмәкене ничек тартканнарын карыйсы килеп, Рамил дә аңа ияреп чыкты. Ләкин солдат абыйсының тәмәке турында исендә дә юк! Ул, өйалды баскычына утырган да, кызыл йолдызлы пилоткасын күзләренә каплаган...

## 8

...Бөек Ватан сугышының соңгы айлары иде инде.

Алар авылдан чыгып бераз китүгә, артта автоматтан чатор-чотыр аткан тавышлар ишетелде. «Сизделәр, каһәр төшкере!» дигән уй телгәләп үтте Буранбайның йөрәген. Разведчиклар адымнарын тагын да кызулата төштеләр. Пулялар колак турысыннан гына безелдәшә башлагач, алар бөтенләй җиргә ятарга мәҗбүр булдылар.

Ә бит барысы да әйбәт кенә башланып киткән иде.

Аларның урман читенә тупланган полкы иртәгә иртүк дошман өстенә ташланырга тиеш иде. Тиздән һөҗүмгә күчәбез дип торган әнә шундый дулкынландыргыч сәгатьләрдә аларның өчесен — старшина Кәбировны, сержант Трофимовны һәм ефрейтор Тансыккужинны штабка чакыртып алдылар. Разведка начальнигы куйган бурыч шуннан гыйбарәт иде: совет гаскәрләренең һөҗүм итү юнәлешеннән биш-ун чакрым читтәрәк урнашкан поляк авылына ниндидер дошман частьлары тупланa башлавы турында ашыгыч мәгълүматлар алынган. Һөҗүмгә керешкәч кенә дошман флангтан яки тылдан үтеп кермәсен дисәң, авиаразведканың бу шомлы хәбәрен игътибарсыз калдырырга ярамый иде. Кыскасы, кичекмәстән хәлне ачыклап кайтырга кирәк. «Тел» булса, тагын да яхшырак!

Юлның беренче яртысы хәвефсез үтте. Төн урталары житкәндә, әзмәвердәй гәүдәле ярым исерек обер-лейтенант масхалаттан әтмәләнгән капчык эчендә ята иде инде. «Тел»не авыл читендәге йорттан алдылар. Алар килеп кергәндә, вакыт бик соң булуга карамастан, кухня якта бер яшь хатын яшел буяулы бәби арбасында кечкенәсен тирбәтеп йоклатып утыра иде. Чакырылмаган кунаклар бик тынгысыз булып чыккан, күрәсең.

Мәлҗерәгән, китель изүләре чишүле обер-лейтенант, каршысында, күктән төшкәндәй, совет разведчиклары пәйда булгач, бик тиз айнып китте. Аның симез куллары үзеннән-үзе урындык аркасындагы кобуралы каешка үрелде. Тик сержант Трофимовның автомат прикладлы өлгеррәк булып чыкты.

Һаман йокыга китә алмаган сабый ул арада кинәт кычкырып елап җибәрде. Көтмәгәндә яңгыраган бу тансык тавыш старшина Кәбировка бөтен дөньясын оныттырды. Ул бәби арбасы янына аяк очларына гына басып килде дә, хуҗа хатыннан күз карашы белән рөхсәт сорап, ак биләүгә төрелгән баланы кулына алды. Ерак Ашыт буйларында калган гаилә-йортын, моңарчы бер мәртәбә дә күреп-сөеп караганы булмаган газиз улын искә төшерде, күрәсең — старшина Кәбиров беләгендәге биләүгә байтак томырылып карап торды...

Ул арада арттан ишетелгән ату тавышлары тагын да якыная төште. Хәерчегә җил каршы дигәндәй, күкнең бер читендә таң да беленеп килә. Әзәрлекле чыккан дошманнан авыр капчык күтәргән килеш качып котылып булмаячак: бу — көн кебек ачык! Кичекмәстән нидер эшләргә кирәк иде.

— Трофимыч! Син монда безне каплап торырга каласың, — диде старшина Кәбиров, ниһаять, ныклы карарга килеп.— Бераздан үзең дә урманга таба шуышырсың. Ул чакта инде фрицларга без баш күтәрергә ирек бирмәбез.

Буранбай белән Әбүзәр, «тел» салынган капчыкны икесе ике башыннан өстерәп, алга таба шуыштылар. Бик тиз арыттылар, тын житми башлады. Аз гына туктап тордылар да тагын, тагын шуыштылар.

Бераздан әлеге капчык Буранбайга авыраеп киткәндәй тоелды. Башын күтәреп караса — Әбүзәр берничә адым арттарак хәрәкәтсез ята иде. Дошман пулясыннан сакланырга кирәклек турында да онытып, Буранбай күз ачып йомганчы яткан җиреннән сикереп торды һәм икеәч атлауда командиры өстенә барып капланды.

— Әбүзәр! Әбүзәр дим... Нәмә булды һинә? Ач күзеңне!

Бил каешыннан тиз генә флягасын чишеп алып, яралы иптәшенә берничә йотым су каптырды Буранбай. Ниһаять, аңына килеп, Әбүзәр күзләрен ачты һәм авыр гына ыңгырашып куйды. Пуля тез капкачына тигән иде.

Ярасын бәйләгәч, Әбүзәргә бераз хәл кереп киткәндәй булды. Бер кулы белән Буранбайның муенына асылынган килеш, ул хәтта аягына

да басып карамакчы итте. Ләкин, яткан жиреннән аз гына күтәрелүгә, чалгы астында калган үләндәй, жиргә киселеп төште.

— Буранбай!.. Тыңла, дускай!..— диде Әбүзәр, бераз хәл кергәч.— Фрицларне тоткарлап тору хәзер минем өстә. Минем чират... Ә сез Трофимов белән алга, алга шуышыгыз! Анда «тел» көтәләр...

— Нәмә һөйләйһең, Әбүзәр! Ничек инде бу хәлеңдә берүзеңне ташлап китәек?

Көтелмәгән очрак килеп чыгуны аңлап, алар янына сержант Трофимов та килеп житте. Пулялар тагын колак төбеннән генә безелдәшә башлады. Һәр минут, һәр секунд исәптә — бәхәсләшеп торыр чак түгел иде.

— Сержант Трофимов! — Бу юлы Әбүзәрнең тавышы артык кырыс чыкты.— «Тел»не алып, кичекмәстән алга шуышыгыз!

— Ә син, старшина?..

Иптәшләренең нишләргә белмичә икеләнеп торуларын күргәч, Әбүзәр чалкан яткан жиреннән бераз калкына төште. Аннары янәшәдә, икеөч адымда гына үсеп утырган кушкаең төбенә тәгәрәп барды да, автоматын әйбәтләп урнаштыра — ут ачарга әзерләнә башлады.

— Биш-ун минуттан яныгызга тәгәри-тәгәри булса да барып житәрмен,— диде ул, гранаталарын кушкаен төбенә тезеп.— Тик карагыз аны — утны жәлләп торыштан булмасын! Ә хәзер — алга!

Буранбай бу приказга буйсынса да буйсынды, буйсынмаса да буйсынды. Аны һаман бер уй битәрләде: дошманны тоткарлыйм дигән булып, Әбүзәр юри артта калды. Болай да алжыган, хәлдән тайган иптәшләренә артык йөк булмас өчен калды!

Кинәт аның колагына:

— ...а-аай!.. — дигән тавыш ишетелгәндәй булды.

Буранбай артына борылып карады. Әйе, ул ялгышмаган иде. Әбүзәр дә аның туктаганын күрде һәм, саубуллашкан кешедәй, кулын болгап куйды. Буранбай ату тавышлары арасыннан баягы сүзләрне бу юлы ачыграк ишетте:

— Кушкаен төбендәү-ү-ү!.. Тап... Тапшыр...

Фронтта очрашкан беренче көннәрендә үк алар әгәр берсе үлеп, икенчесе сугыштан исән-сау кайта калса, һичшиксез, дустының гаиләсен эзләп табарга һәм аның ничек һәлак булуы турында сөйләп бирергә сүз куешканнар иде. Күрәсең, Әбүзәрнең шул вәгъдәне кабат искә төшерүе иде бу.

Старшина Кәбировның автомат утына ышыкланып, алар тагын, тагын шуыштылар.

Артта ату тавышлары кинәт тынып калды. «Әллә Әбүзәрнең патроннары беттеме?» дигән шикле уй Буранбайны тагын артка борылып карарга мәжбүр итте. Көтелмәгән хәлнең шаһиты булып, ул башта үз күзләренә үзе ышана алмыйча торды: Әбүзәр кушкаен төбеннән сикереп торды да, паникага бирелгән кеше сыман, титаклый-титаклый бирегә таба йөгерә башлады.

Юк, Әбүзәр куркак кеше түге-ел!.. Бу мәсьәләдә, әгәр кирәк икән, Буранбай кулын кисәргә бирә ала!

Немецлар бер мәлгә югалып калгандай булдылар. Менә аларның кайсыдыр түзмәде — борын төбеннән генә качып котылырга ниятләгән совет разведчигына автоматыннан чатырдатып атып та жибәрде. Ә Әбүзәргә шул гына кирәк тә! Артта ату тавышы ишетелүгә, пуля тигән кешедәй, ул кинәт йөзтүбән барып төште.

Куа килүче немецлар йөгерә үк башладылар. Табышына ташланган ерткычлар сыман, алар күз ачып йомганчы Әбүзәрнең «үле» гәүдәсен сырып алдылар.

Нәкъ шул мизгелдә галәмәт дәү ут йомгагы кушкаен турысыннан өскә сикерде.

## 9

Сугыш тынып торган арада, рөхсәт алып, Буранбай дошманнан яңа азат ителгән теге авылга китте. Кичәге вакыйгаларны күреп торган бер поляк карты аны урамда үзе танып алды. Бераздан алар икесе теге кушкаен төбендәге кабер каршына килеп туктадылар. Аның як-яклары тигезләп киселгән чирәм кәсләре белән капланган иде. Буранбай күптән аңлап алды: болар барысы да, мөгаен, әлеге карт эше!

Менә поляк карты куен кесәсеннән бик кадерләп төрелгән нәни төргәк чыгарды. Бу — дусты Әбүзәрнең исән калган әйберләре иде.

Әлеге карт кесәсеннән тагын бер фоторәсем алды һәм кулы белән әле көнчыгышка, әле фотога төртеп күрсәтә-күрсәтә, нидер аңлата-төшендерергә тырыша башлады. Фотодан Буранбай шикелле үк егерме яшьләр чамасындагы монсу йөзле егет карап тора иде. Картның кайгы-хәсрәтле карашыннан аңлашылды: әйе, аның улы яки оныгы да фронтта үлеп калган булырга охшый иде.

Комачау итмим дигәндер инде, Буранбайны авыр уйлары белән ялгыз калдырып, бераздан поляк карты китеп барды.

Дусты кабере янында озак утырды Буранбай. Шул кабердән истәлеккә бер уч балчык алыйм дип иелгән иде, сүтелә-сүтелә, кулыннан Әбүзәрнең әйберләре салынган нәни төргәк төшеп китте. Әнә ич теге таныш тәмәке янчыгы! Кара бәрхеттән тегелгән, кырыйлары чигүле бу янчыкка сары җеп белән «Әбүзәр, онытма мине! Онытмам сине — Гөлмәрҗән». дип язылган иде.

Буранбай җайлап кына тәмәке янчыгының бөрмәле бавын чиште. Ул ике бүлемле итеп тегелгән иде. Чигүле янчыкның беренче бүлеменнән Әбүзәр тартып бетерергә өлгермичә калган бер төрерлек эре бөртекле тәмәке (гармун күрегенә охшатып бөкләнгән газит кисәге һәм трофей зажигалкасы да шундый!), ә икенчесеннән дары сыман вак кына мәк бөртекләре һәм... бер саплам җеп килеп чыкты.

Таныш, бик таныш бу тегәрҗеп кисәге Буранбайга!

Узган көздә аларның дошманга тын алырга да ирек бирмичә һөҗүм итеп килгән полкы, бераз көч туплап һәм тамак ялгап алыр өчен яшелчә бакчасы кырыендагы болынлыкта кыска привалга туктаган иде. Мондый чакта билгеле инде: тәүлекләр буе керфек какмаган солдат халкы, җаен табып, аз гына булса да черем итеп калырга тырыша.

Поход кирәк-яраклары салынган биштәрен мендәр итеп баш очына салды да, Буранбай да чирәмлеккә сузылып ятты. Ә Әбүзәргә мендәрең ни дә, яшел чирәмең ни! Гел үзенең сәер гадәтен куар: якын-тирәдә тукталган берәр машина яки арба тәгәрмәченә башын салыр да, күккә карап, ни турындадыр уйланып ятуын белер. Дустын кызганудан, Буранбай берничә мәртәбә моның сәбәпләрен дә сораштырып караган иде.

Тик күп сөйләшергә яратмый торган Әбүзәр:

— И Буранбай, Буранба-ай!.. Йокы ястык телимени ул! — дия да, бетерә торган иде.

Бу юлы да шулай булган иде.

Солдат йокысы — сак йокы! Кемнеңдер акрын гына җырлап җибәрүен ишетеп, Буранбай кинәт уянып китте:

Сез генә истә, сез генә,
Кичен дә, көндезен дә.
Кораблар булып чайкалам
Сагыну диңгезендә.

Әллә машина көпчәкләре арасыннан ыжгырткан салкынча җилдән, әллә Әбүзәрнең күкрәк төбеннән бәреп чыккан үзәк өзгеч моңыннан тәненең кинәт бөрешеп китүен, беләкләренә «каз ите» чыгуын тойды Бу-

ранбай. Ул җирдә яткан йодрыкларын шулкадәрле каты итеп кысты, бер уч үлән, тамыры-ние белән йолкынып чыкты.

Бу юлы Әбүзәр эч серләрен яшереп маташмады:

— И Буранбай, Буранба-ай!..— диде ул янәшәсенә килеп чүгәләгән һәм иңбашына кулын куйган җан дустына.— Менә шушы машина көрчәкләренә башны терисе ие дә, кайтып киләсие келтер-келтер тәгәрәп Ашыт буйларына! Улым бигрәк сагындыра. Перәме, түзәр әмәл юк! Мин сугышка киткәч туды. Хет бер тапкыр күреп кенә дә калалмадым ич мин аны! Бар юанычым — менә шушы инде... Әбүзәр йомарланган йодрыгын ачып җибәрде. Дары-төтен исе сеңгән уч төбендә, туган як сукмагы кебек боргаланып-бормаланып, бер саплам тегәрҗеп ята иде.— Малайның буй озынлыгы, ягъни мәсәлән... Хатын үлчәп җибәргән. Хат белән. Сагынганда карарга...

Алар ял иткән урыннан ун-унбиш адым читтәрәк кенә ал чукларын инде күптән койган, озын саплы, уймак башлы берничә төп мәк үсеп утыра иде. Әбүзәр шуларны учына уып килгән арада, Буранбай дустының язмышы турында уйланып утырган иде.

Фронтовик солдат һәм мәк! Ничектер, аларның кырыс язмышлары арасында бик зур охшашлык бар кебек.

Кабер читендә утырган Буранбай, ирексездән, уч төбендәге тегәрҗепкә тагын бер карап куйды. Бу саргылт җеп кинәт дусты Әбүзәр яшәп калган кыска гомер булып тоелды.

Менә Буранбай, үзе дә сизмәстән, янчык төбендәге соңгы чеметем тәмәкене төрә башлады. Аннары шактый вакыт зажигалканы кабыза алмый азапланды... Тәмәке төтененнән кылкына-кылкына йөткерә башлагач кына ул үз-үзенә кырык кат бирелгән вәгъдәсендә тора алмавына төшенде. Госпиталь врачлары: «Яшисең килә икән — тәмәке дигәннәре төшеңә дә кермәсен!» — дип бик нык кисәткәч, ярты ел чамасы элек тартуны ташлаган иде Буранбай. «Чуртысним! Йөрәк янганчы, тәмәке янһын!» — дип куйды ул эчтән генә һәм әчкелтем төтенне суырунда дәвам итте.

Тәмәке төпчеге бармагын пешерә башлагач, Буранбай урыныннан торды һәм дустыннан соңгы ядкарь булып калган мәк бөртекләренең бер өлешен кабер өстендәге үләнле кәс кисәкләре арасына сипте. Аннары, тиз-тиз атлап, үз полкына кайтып китте...

## 10

Өйгә конюшняда ат караучы булып эшләүче Әбүбәкер карт та кайтып керде. Җыйнаулашып табынга утырдылар. Буранбайның япон сугышыннан саклап кайткан бер фляга аракысы бар иде. Башта сүз Буранбайга бирелде. Ул кушкаен төбендәге вакыйгаларга хәтлесен нәкъ булганча, дөрес итеп сөйләде. Аерма тик шунда гына иде: теге разведкадагы бәрелештән соң дусты Әбүзәр янына әйләнеп килгәндә, аны поляк карты күммәгән, ә госпитальгә алып киткәннәр булып чыкты.

Буранбай үзен энә өстендә утыргандай хис итте. Ышандылармы бу изге ялганга, юкмы — әмма ул бер саплам җеп һәм мәк бөртекләре салынган чигүле янчыкны бүген ияләренә тапшыра алмаячак — бу көн кебек ачык иде!

Иртән торуга, юлчы кешенең юлда булуы яхшы дип, Буранбай китәргә әзерләнә башлады. Аңа кичке поездга кайтып өлгерергә кирәк иде. Шунлыктан туган Карайделенә дә сугылмыйча, фронтовик дустының соңгы аманәтен үтәү өчен япон самурайларын җиңеп кайтышлый ерак Себердән башта Әҗемгә юл тоткан бу игелекле башкорт егетен тагын бер кич кунып китәргә кыстый алмадылар.

Әбүбәкер карт кадерле кунакны озата барыр өчен колхоз председа-

теле җигеп йөри торган Паташкыны җигеп кайтты. Хуш исле печән җәелгән арбага дүртәүләшеп менеп утырдылар. Башта озын күпергә хәтле генә озата барырга иде исәпләре. «Ат тикле ат җиктерә-җиктерә озаттырып йөрергә алланың кашка тәкәһе түгел лә мин!» — дип тә караган иде Буранбай.

Сөйләшә-сөйләшә барып, инде менә Ашыт тавына да менелде. Шулчак Буранбай хәрбиләрчә җитез хәрәкәт белән арбадан сикереп төште дә аркасына яшел биштәрен киде:

— Әле Арча поездына җитешәм. Лутчы җәяү атлай тораем. Озата килүегез өчен зур рәхмәт! Ягез, туганнар, һау булып торыгыз! Үзегез Карайделгә кунак булып килегез!— диде дә, җил-җил атлап, Артышлы юлыннан менеп китте.

Берникадәр баргач, ул кинәт артына борылып карады. Гаҗәп: озата баручылар һаман кире борылмаган — башын чайкый-чайкый Паташкы аның артыннан менеп килә иде. Бер-бер әйтәсе сүзләре калган микәнни соң? Алай дияр идең — бер дә ашыкмыйлар шикелле... Буранбайдан күрепме, менә ат та туктады.

Кинәт ниндидер карарга килеп, Буранбай үзен озата килүчеләргә каршы атлады.

— Әйтергә онытканмын икән, Гөлмәрҗән,— диде ул.— Өй артындагы бәрәңге бакчагызга бер уч мәк орлыклары сибеп киттем. Чәчәкләре ата башлаганчы, бәлки үзе дә кайтып җитәр әле.

— Рәхмәт, Буранбай! — диде Гөлмәрҗән, аның күзләренә туры карарга тырышып.

Ләкин Буранбайның керфекләре, кургаш эленгәндәй, аска иелгән иде. Ә Гөлмәрҗәннең йөзе, никтер, кинәт ак бәздәй агарып китте.

Җәяүләп атлаган солдат артыннан җигүле ат тагын байтак барды әле. Арбада утыручыларга Буранбай яңадан артына борылыр да, тагын нидер китереп бирер, тагын нидер сөйләр кебек тоелды.

Ләкин Буранбай бүтән борылып карамады.

Кунакны озатып кайткач, иң беренче эш итеп, Гөлмәрҗән кер юарга әзерләнә башлады. Башта, олы казанны тутырып, су кайнатырга куйды. Аннары чиста керләре саклана торган сандык каршына килеп чүгәләде, ак калай тасмалары белән каймаланган капкачны ачып җибәрде дә, бүтән вакыттагыча, борынына таныш ис килеп бәрелүен көтте. Ләкин, ни гаҗәп, дүрт елга беренче мәртәбә ул бүген Әбүзәрдән калган җанга газиз исне тоя алмады. Дүрт ел буе юылмаган бумази күлмәкне битенә каплап, үкси-үкси елады Гөлмәрҗән. Ничә айлар, ничә еллар буе җыелып килгән кайгы-сагыш, тулык ләгәндәге су кебек, күңел ярларыннан ташып чыгарга гына тора иде шул! Ләкин таныш ис, Әбүзәрнең үзе шикелле, суга төшкәндәй кинәт югалды да куйды.

Әбүзәрнең күлмәген ләгәндәге кайнар суга салды Гөлмәрҗән һәм бераздан кысып-кысып юарга керешге.

Иделкәйнең аръягында
Атлар килә адымлап шул,
Атлар килә адымлап.
Кайгым кара күлмәк булса —
Юарыем сабынлап...

## 11

Ашыт елгасы аша салынган күпер төбенә өр-яңа машина килеп туктады. Чабыш аты кебек ялык-йолык килеп тора!

Гөлмәрҗән карчыкның карап туймаслык мондый машинаны үз гомерендә беренче мәртәбә күрүе иде әле. Кабинасы өстендә, бәрәңге төбенә ия торган китмәнгә охшап тырпаеп чыккан нәмәстәкәе дә бар

Нәкъ беркөнне Купер Зарифлар телевизорында күргән машина шикелле... Әллә улы Рамил яшәгән шәһәрдә эшләнүче яңа әфтәмәбил шушы үзе була инде?!

Ерак юлдан килеше, күрәсең, кулына чәчәк тоткан шофер, су алырга дип, Ашыт буена төшеп китте. Муенына озын каешлы транзисторын да элгән. Бик җыр яратучы егет, ахрысы.

Казан радиосы да ял концерты тапшыра иде. Менә башкарылачак җырның исемен әйттеләр. Озак та үтмәде таллы-камышлы Ашыт буйлары бер тыңлауда күзләрдән яшь китерә торган моңлы көй авазларына күмелде:

Мәк чәчәген өзздем ялгыш кына...

Флера Сөләйманова башкаруында яңгыраган бу җырны Гөлмәрҗән карчык·элек тә бик яратып тыңлый иде. Ләкин табигать кочагында, мәк чәчәкләре уттай балкыган бакча каршындагы Ашыты белән серләшеп утырганда ишеткәнгә күрәме, бу җыр бүген Гөлмәрҗән карчыкка аеруча нык тәэсир итте.

Мәк чәчәген өзздем ялгыш кына,<br>Күзз яшьләрең түктең син шуңа...

Моңлы җырчының «өзздем» дип кабат өздереп алуы булды, Гөлмәрҗән карчык кинәт йөрәгенең хәлсезләнеп китүен тойды. Аның уңган яулык төсле агарган бит-маңгайларына бөрчек-бөрчек тир тамчылары бәреп чыкты. Гөлмәрҗән карчык хәлсез куллары белән янәшәдә үсеп утырган карт тал ботагына ябышты һәм, соңгы көчен җыеп, сердәш Ашытына дәште:

— Без икәү белгәннәрне улыма да сөйләрсең. Ул монда килми калмас... Хуш, Ашыт-су!..

— Чү, Гөлмәрҗән! Нишләвең бу? Куәс чиләгендә күптән куеп калдырган камырың ташый ич! Бердәнбер улың кайтасы барлыкны да оныттыңмыни? И дөньялар!..— дип җавап кайтарды Ашыт дулкыннары.

Гөлмәрҗән карчык таянган карт тал төбенә кайсыдыр кансызы балта чапкан булып чыкты. Әйтерсең, мылтыктан аттылар — яралы талның шартлап сынуы бөтен Ашыт буен яңгыратты. Тын гына агып яткан су өсте кинәт шадраланып китте. Ашыт буе таллыкларыннан өркетелгән бер көтү кош дәррәү очып һавага күтәрелде. Чулт-чулт итеп, камыш төпләреннән суга бакалар сикереште.

Ә бераздан Ашыт буе тагын тирән тынлыкка күмелде.

## 12

Әнисен җирләп кайткан көнне төне буе Рамил күзенә йокы кермәде. Күрше Зариф абыйсының чыгып киткәненә дә инде биш былтыр. Алар төнге икеләргә тикле сөйләшеп утырганнар иде. Зариф абыйсы аны үзләренә бик чакырып-кыстап карады: мәет чыккан өйдә ялгызыңа авыр булыр, диде. Ләкин Рамилнең бу соңгы төнне үз өйләрендә үткәрәсе килде. Аннары, иртүк торып, юлга да кузгаласы бар. Таң күзеннән кеше мәшәкатьләп йөргәнче!

Төнлә әнисенең моңарчы бер дә ватылу-фәләнне белмәгән борынгы стена сәгате туктап азаплатты. Ут яндырып караса, чылбыры өзелеп, җиз герләрнең берсе идәндә ята икән.

Сәгать белән янәшәдә генә әти-әнисенең портреты эленеп тора. Армиядән кайткан елны Рамил аны үзе зурайттырып алган иде. Әнисе башына ак шәл бөркәнеп төшкән. Әтисендә — аксыл каракүл бүрек,

шундый ук якалы пальто. Әнисе сөйләве буенча белә Рамил: бу фотога ул туарга берничә ай кала, әтисе сугышка китәсе язны төшкәннәр.

Рамил рамлы портретны ипләп кенә стенадан алды һәм бер туктап калган сәгатькә, бер тузанлы пыяла астыннан елмайган кадерле йөзләргә карый-карый, агач караватка килеп утырды.

Ниһаять, пәрдәләре корылмаган өй тәрәзәләреннән сыек якты сирпелеп керә башлады. Кичтән сүз берләшеп куйганнар диярсең — чиратлашып авыл әтәчләре кычкыра башлады.

Рамил, иске идән сайгакларын шыгырдатып, тәрәзә каршысына килеп басты. Кичә, энисен җирләп кайткан көнне, аларның бәрәңге бакчасы шау чәчәктә утыра иде әле. Бүген инде мәк чәчәкләренең кайберләре шиңә-сула да башлаган!

Әнкәсе, әлеге мәк чәчәкләре янынннан үткән сукмактан төшеп, Ашыт буенда нидер уйланып утырырга ярата иде инде. Рамилнең дә кинәт тын елга буйларыннан әйләнеп кайтасы килеп китте. Әмма китәргә вакыт житеп бара. Артышлыга беренче автобуска барып өлгерергә кирәк.

Рамил кулына кечкенә чемоданын алды да, сагыш-моңсулык белән тулы өй эченә соңгы кат күз ташлап, урамга чыкты. Иртәнге сукмак буйлап бераз баргач, туктап, чалбар балакларын өскәрәк күтәреп куйды. Чык төшкән иде. Аз гына тиеп киттең исә, әнкәйләрнең күз яше сыман коелырга гына торалар.

Ашыт буе сихри тынлыкка чумган. Бу тынлыкны таллардагы кошлар сайрашуы гына ара-тирә бүлеп куя.

Рамил күпер төбендәге таш өстенә килеп утырды. Хәзер, бер ярдан икенче ярга салынган бу бүрәнә тезмәсенең күпер дигән исеме генә бар! Ашыт аша чыкканда аяк суга чыланырлык булмагач ярый инде! Кем әйтмешли, күпер димәсәң хәтере калыр!

Ә менә сугышка хәтле биредә күпер бик озын, бик биек булган дилэр. Бөтен тирә-яктагы мари авыллары Арча станциясенә бүрәнә-утынны шушы юл, шушы күпер аша ташыган. Ашыт та ул елларда тирән булып, ярларын тутырып аккан.

Ике ярны тоташтырган элеккеге таш юл хәзер читтәрәк торып калган. Аның тирә-ягын әрем, алабута, тигәнәкләр басып киткән. Кызыл балчыклы яр читләренә керәшәләр оя корган.

Кинәт Рамилгә аргы ярда, кулын болгый-болгый, әтисе басып торадыр сыман тоелды. Шунда чыгып китәсе килеп китте. Арада — яндырылган авыл мичләрен хәтерләтеп утырган субай бәйләмнәре генә! Арада — сугыш! Арада — өзек!

Рамил бүген иртән үзенә күрә бер ачыш ясады. Элегрәк ул Ашыт аша чыгарга туры килгән вакытларда: «Шушы бүрәнә бәйләме өстеннән йөреп интекмәсәләр! Бабайлар, әтиләр йөргән олы юл турысыннан адәм рәтле күпер салып куярга кулларыннан килми микәнни соң?» — дип, эчтән генә авылдашларына рәнҗеп тә куйгалый иде. Моңарчы Рамил генә күрми йөргән икән. Ашыт ярындагы бу өзек үткән-барганнарга утыз елдан артык сугыш корбаннары турында сөйләгән, аларны искә төшереп торган икән!

Күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе күрми, ди шул!

Кинәт Рамил елга аръягындагы юлдан олы яшьләрдәге бер кешенең якынлашуын күреп алды. Бер кулына сумка, икенчесенә салам эшләпә тоткан. Ерак җирдән килеше, күрәсең. Таң тишегеннән юлга чыкмаса! Автобус көтеп торырга түземлеге җитмәгән микәнни соң?

Менә әлеге агай олы юлдан дамба читенә — бүрәнәләр бәйләменә таба төшеп китә торган җирне дә үтте. Ә алда — өзек юл. «Безнең як кешесе түгелдер, күрәсең,— дип уйлап куйды Рамил.— Югыйсә, бу турыда олы юлның күптән өзек булуын белер иде».

— Э-э-әй!..— дип кычкырды ул, куш учын авыз турысына китереп.— Юл читтән үтә, читтә-ә-ән... Юл әзе-е-ек!..

РАВИЛ ГАЛИЕВ ◆ ГӨЛМӘРҖӘН НӘЖЖЕМ МӘКЛӘРЕ

Тагын бер мизгелдән тавыш кайтаваз булып әйләнеп кайтты:

— ... эзе-е-ек!..

Елга аръягындагы кешедән җавап озак көттермәде:

— Рәхмәт, энекәш, һәйбәт һүзеңә-ә! Күптән кайталганым югые шул, бахыр...

«Һүзеңә?.. Бахыр?..»

Рамил, чалбар балакларына сырышкан чәнечкеле тигәнәкләрдән арынырга да онытып, аска — балачак еллардан бирле таныш башкорт агаен каршы алырга йөгерде.

## Укучының күңел дәфтәренә

### Осетин мәкальләре һәм әйтемнәре

*Очып чыкса тоталмыйсың — чөнки сүз чыпчык түгел.*
*Аяксызны аксарга өйрәтмә.*
*Чума белә, калкып чыга алмый.*
*Юләр — ботаклы бүкән: ничек борсаң да тырпая.*
*Казанга барам дип, Рязаньга килеп чыккан.*
*Нинди печән булсын ди бу — бары коры үлән ич.*
*Йөгәне атыннан кыйммәт.*
*Шайтан дуңгызны кырка: тавышы күп, йоны юк.*
*Кәкре җиккән, туры киткән.*
*Начар агач ботакка үсә.*
*«Яшәсен» дип башлап китеп, «үлде» белән бетерде.*
*Бәләкәй эт — картайганчы энчек.*
*Башын җуйгач чәчен җәлләп елый.*
*Балын биргәч кашыгын да бир.*
*Эткә арттан кил, әтка — алдан.*
*Тырнак бирсәң, бармак сорар.*
*Ялый-ялый тәлинкә ярган.*
*Сарык кына булып ал, бүреләре күптән бар.*
*Кызу канлы ат чаптырып кәләш алырга барма.*
*Җәяү атлаган юлаучы җайдакка юлдаш түгел.*
*Юкә белән каеш бәйләнми.*
*Беренче булып килә дә иң соңгы булып китә.*
*Өстәл — тәхет икмәк булган чакта,*
*Икмәк юкта өстәл — коры такта.*
*Оттырудан курыкмас өчен отып карарга кирәк.*
*Ничек кенә боргаланма, койрыгың барыбер артта.*
*Чүенны чүлмәк вата алмый.*
*Су үзәнсез акмый.*

## Ислам Беляев

### Тимер юлда уйлану

Ничә тапкыр яуның яшеннәре
Китереп кысты безне тупикка.
Ул әле тик алгы сызык иде,
Ерак иде соңгы сызыкка.
Баш өстеннән биеп үтте үлем,
Кырылып калды рота яртылаш,
Җиңү кояшыннан исәннәргә
Шатлык иңде әрнү аралаш...

Узды состав аваз салып ерак.
Моңсу миңа монда нишләптер.
Алга юл юк,
Бу соңгы чик, диеп,
Иске вагон, синме эндәштең?
Сукмаклар да өзелә бер көн, димсең,
Сүтелеп беткәч гомер йомгагы?
Маневренный саф-саф вагон тезә,
Бу почмакка күз дә салмады.
Пуля тишегеннән чебен керде —
Әллә кача кояш күзеннән.
Әллә бара стенага чәчрәп
Сеңеп калган каннар эзеннән.
Күңел дә бит сыя шул тишеккә.
Елларны ул белми ни дип тә...
Рельс беткән менә шушы чиктән
Алып кит син мине яшьлеккә.
Обелиск-маякларга карап
Чапсын әле бронза паровоз.
Алгы сызыкларда мәрмәрләрдән
Сафка бассын торып ротабыз.
Уянсыннар аяк тавышлары,
Куәт керсен арган тәннәргә.
Дип: яшәргә һәм үлгәннәр өчен,
Кушмадыкмы чорга без әллә!
Үлгәннәрне онытмаган өчен
Тиң булганбыз бәлкем полкка.
Без — исәннәр һәм үлгәннәр —
Бер көч,
Тоташкан күк бер ут бер утка.

## Солтан Шәмси

# СОҢГЫ ЮАНЫЧ

**хикәя**

Карт, электричкадан төшеп, төнлә генә явып киткән беренче кар өстеннән тимер юл буендагы моңсу дачаларга таба атлады. Аның иңендә шактый киелгән кара пальто, башында уңа башлаган эшләпә, кулында, үзе кебек үк, дөнья күргән хуҗалык сумкасы иде.

Ул, яңа карда эзләр калдырып, салмак кына атлап бара. Бераз баргач, тәбәнәк рәшәткә белән тотып алынган бакчаның кечкенә капкасын төртеп ача да эчкә уза.

Монда тынлык. Әле кайчан гына тормыш кайнап торган дачалар бушап калган, биредә хәзер эт-гадәм юк. Карт, тәмәкесен суыра-суыра, үткән җәй турында уйлый, сәерләнеп калган бакчасын, бакча уртасындагы печән чүмәләсен, күрше йортларның карлы түбәләрен күздән кичерә.

Аннан ул йозакны ача да өйгә керә. Эчтә бер мәлне арлы-бирле йөренгәч, кулына чүкеч һәм калай банка тотып, болдырга чыга, аларны ишек төбендәге озын эскәмиягә куя да өй артындагы сарайга юнәлә. Бер араны сарай ягыннан нәрсәдер ишелгән, дөбердәгән тавышлар ишетелеп тора, соңрак такталар күтәргән карт үзе дә күренә. Такталарны ул болдыр каршысына ыргыта да пальтосын кага, аннан, чүкечен һәм банкадан берничә кадак алып, такталар белән тәрәзәләрне аркылы-торкылы кадакларга керешә. Эшли торгач, тәрәзәләр, ниһаять, томаланып бетә, һәм ул, бераз читкәрәк китеп, хушлашуга охшаш моңсулык белән яшел төстәге гади генә өенә карап тора. Аннан баскычка килеп утыра, тәмәкесен кабызып, уйга чума...

*

* *

Узган ел җәй уртасында һич көтмәгәндә ялгыз калды карт. Алай, авырып-нитеп тә йөргәне булмады югыйсә карчыгының. Тик кайвакытларда гына, йөрәгем әллә нишләп куя, дигәли иде, әмма андый кәеф китеп торулар картларда түгел, яшьләрдә дә еш була бит.

Ул көнне карчыгы көн әйләнә кояш астында эшләп йөрде. Көн кичкә авышканда гына, башым шаулый, йөрәгем кыса, дип өйгә кереп ятты. Ләкин хәле аңа карап җиңеләймәде, торган саен авырая гына иде.

Болай булмас, ахры, өйгә алып кайтырга, врачлар чакыртырга кирәк дип, бакчага машинасы белән килгән танышыннан зинһарлап сорагач, тегесе атлыгып тормаса да, үтенечне кире кагарга яхшысынмады. Әмма шәһәргә кайткач, телефоннан чакырткан врачлар килеп җиткәнче, картын якты дөньяда калдырып, үзелде дә куйды җәмәгате. Картның үз кулында өзелде. Соңарып килгән врачлар: «Йөрәк!» — диделәр.

Әйе, көтмәгәндә ялгыз калды ул. Күңелсез, моңсу көннәр башланды карт өчен. Өйдә дә, дачада да үзенә урын таба алмый йөрде. Дөньясы кинәт бушап калды. Тормышның бар яме шул карчыгы булган икән. Әлек, карчыгы исән чакта, ничектер бу хакта уйланылмаган. Тигез, тату килеш яшәлгән дә яшәлгән...

Карт, бусагада утырган килеш, яшел түтәлләргә карап:

— И карчык, карчык... Үзең утырткан, үзең тәрбияләгән түтәлләрдән авыз да итә алмый киттең, — дип куя иде.

Ә бераздан аның уйлары кияүдәге бердәнбер кызына килеп тоташа һәм ул янәшәсендә карчыгы утыргандай:

— Әйттем мин сиңа, тырышма ул кадәр, бетермә үзеңне, дип... Безгә, карт белән карчыкка, күпме кирәк соң. Аларның хәзер үз тормышы... Үстердек, аякка бастырдык, гомер буе ата-ана җилкәсендә утырырга димәгән, үз көннәрен үзләре күрсеннәр... — дип сөйләнеп ала.

Җирләү, өчесен, җидесен уздыру мәшәкатьләре үткәч, кызы да әтисе янына килүен сирәкләтә төште. Хәер, әллә нигә бер генә, сумкаларын тотып, ире белән дачага килеп чыккалыйлар да тегесен-монысын алып китәләр. Ата белән кыз арасындагы салкынлык күптән килә иде. Хәзер, анасы китеп баргач, аралары тагын да суына төште.

Менә җәй дә үтте, көз җитте. Исән булса, карчыгы бу вакытларда тозласын тозлап, киптерәсен киптереп, кайнатасын кайнатып, мәш килеп кышка хәзерләнеп йөрер иде. Аш-суга оста, гаилә тәрбияләргә бик хирыс кеше иде шул, мәрхүмә, авыр туфрагы җиңел булсын. Ә хәзер кайда ул алай дәртләнеп йөрүләр... Янында якын кешең, эч-сереңне бушатырлык җан булмау авыр икән ул.

Кышка кергәч, карт бераз тынычлана, ялгызлыгына күнегә төште. Аяз көннәрне урамнарны урап кайта, үзе кебек ялгыз картлар белән танышып китеп, сөйләшеп йөри, вакытын шулай үткәрә иде.

Бер заман кояш югарырак күтәрелә башлады, кар да, пыяла сипкәндәй, җемелди, күзләрне камаштыра. Бу — яз галәмәте иде. Күп тә үтмәде, түбә кырыйларында сөңге очыдай бозлар хасил булды, карның төсе үзгәрде, чәрдәкләнеп эри башлады.

Борынына яз исе килеп кергәч, картның да күңеле кузгалды, ул хәзер табигатьнең тизрәк көч җыюын, гөрләвекләр шаулавын, сулар агуын, бозлар китүен һәм дачасында кабат җир ачылуын көтә иде. Ә көннәрдән бер көнне, дачасына барып кечкенә капканы төртеп ачса, каршысына карчыгы килеп басар төсле тоела башлады картка. Ул үзе моның хыялый бер уй гына икәнен дә аңлый, үз-үзен әрләп тә карый, әмма тегесе барыбер үзенекен итә, бимазалапмы бимазалый. Көн саен котыртып, ымсындырып торган өмет бик рәхимле, бик юмарт -кояшлы бер иртәне аерата көчәеп китте, һәм карт, түземен җуеп, электричкага утырды да бакчасына китеп барды. Ләкин анда карчыгы көтеп утырмый иде, әлбәттә, җир дә кардан ачылмаган иде әле. Ул өен бер әйләнеп чыкты да, эчкә кереп тормыйча гына бераз бусагада утыргач, кире кайтып китте. Шуның белән йөрәге азрак басылгандай булды.

Яңадан ул бирегә карлар эреп бетеп, җирләр тәмам ачылгач кына килде. Беренче көнне арлы-бирле йөренеп, эшкә керешкән күрше-күләннең хәл-әхвәлен сорашып, язның шифалы кояшында сөякләрен җылытып уздырды. Күңеле тулы уй иде картның һәм алар әллә ни куанычлы түгел иде.

Ничә уйласа да һаман саен бер нәтиҗәгә килә иде ул: шушы бакча ди-ди дөнья куйды түгелме соң карчыгы? Бик эшчән, тырыш хатын иде шул мәрхүмә. Эш дигәндә үзенә авырлык килер дип тормый, кул кушырып утыра белми иде. Нәкъ менә карчыгының тырышлыгы, булганлыгы аркасында бердәнбер кызлары ялкаулыкка, анасына салынырга өйрәнеп үсте дә. Ниемә кирәк иде аңа шушы тикле әйбер утырту, иртә таңнан кояш батканчыга хәтле түтәлләр арасында йөрү... Шулай эштән чыкты карчыгы, тыңламады картының сүзен, саклый белмәде үзен. Элегрәк, әле шәһәргә күчеп килгәнче, кичке ашка утыргач: «И-и, нигә житә икән шушы кичләр, күпме эшкә өлгерер идем», — ди торган иде. Әйе, яшерен-батырын түгел, уңды ул хатыннан. Гомер буе ир итеп, зурлап-хөрмәтләп тотты аны карчыгы. Кечкенә бала кебек карый иде ул аны. «Ирләр бит алар бала-чага төсле, бер генә дә үзләрен кайгырта белмиләр», — ди торган иде.

Күп уйланды карт ул көнне, төрле яклап уйлады һәм, төпле бер фикергә килеп, йокларга ятты. Иртәгесен шәһәргә китеп барды һәм бакчага кич житкәч кенә әйләнеп кайтты. Сумкасында азык-төлектән башка тагын ниндидер пакетлар да бар иде.

Беренче эш итеп ул менә ике ел инде корып, каерысына хәтле куба башлаган алмагачларны кисәргә булды. Пычкы белән берәм-берәм кисеп аударды да, утынга турады, өй артына алып барып өйде. Алмагачлары шактый иде, моңарчы ул аларны, күршеләр киңәше буенча, алынып китмәсләрме дип, кисмичә тотты. Юк. Теге суыклардан соң алынмадылар алмагачлар. Дөрес, бер-икесе төптән ботак җибәрде җибәрүен, ләкин кыргый алма бирәчәк ботаклар иде алары.

Берничә көне шулай алмагачлар белән маташып үтте, аннан ул бакчаны җыештырды, чүп-чарны, коры яфракларны яндырды, һәм үз җаена казырга тотынды. Кыймылдый торгач, атна-ун көн үткәнне сизми дә калды. Аның хәзер, көннәр җылынгач, шәһәрдәге буш һәм салкынча квартирына кайтасы килми иде. Азык-төлеккә дип бер әйләнә дә, бар вакытын бакчасында үткәрә. Дөресен генә әйткәндә, алмагачларны бетергәч, бакчаның хәзер бакча диярлеге дә бетте. Өй артында бер-ике төп чия белән рәшәткә кырыйлап утыртылган карлыганнар гына утырып калды. Уртада — еллар буе тиресли-тиресли карга канаты шикеллегә әйләнгән кап-кара җир.

Бер көнне карт, шәһәрдән алып кайткан теге пакетларны ачып, аннан килеп чыккан орлыкларны зуррак бер тартмага бушатты да, казыптырмалап күпертелгән җир өстенә айкана-селтәнә чәчеп йөрде.

Бу аяз көнне карт үзен ниндидер чикне үткәндәй хис итте. Борынгыча селтәнеп орлык чәчкән бу көнне ул гүяки таныш бер ил туфрагына аяк басты һәм аның юллары буенча китте. Эчкәрәк үткән саен ил аңа ачыла барды. Бу ил — аның үткәне иде. Хатирәләргә ул хәзер ешрак бирелә, узган гомеренә ешрак әйләнеп кайта, тирәнгәрәк үтеп керә иде. Шуннан җанына азык, күңеленә дәва таба иде карт. Гомерне яңадан кичереп утырулар аңа билгеле бер ләззәт бирә иде.

Бер көнне өйлә житәрәк — ял көн иде, ахрысы, чөнки карт хәзер, хаҗәте калмагач, нинди көн икәнне анык кына белеп тә бетерми иде, елмаеп, юантык-таза гәүдәсе белән уфылдап, бакчага кызы килеп керде. Карт баскан саен авышып йөдәткән бусага тактасына кадак сугып ята иде. Тавыш ишетеп борылып караса, кызы басып тора.

— Исәнме, әти, — диде кызы, кулындагы хуҗалык сумкасын җиргә куеп. — Ярый әле монда икәнсең. Мин сезгә кергән идем дә, бикле булгач, туры бакчага килдем.

— Менә шәп булган, — диде карт, инде байтактан күзгә күренмә-

гән кызы килеп чыгуга сөенеп, һәм эшен бер читкә куйды да казылган бакчага карап торган кызын өйгә чакырды.

Верандага керделәр. Кызы, сөйләнә-сөйләнә, алып килгән күчтәнәчләрен бушатты, карт исә, күңеле булып, плитәгә чәйнек куеп җибәрде, табын хәзерләргә кереште.

Бераздан чәй дә өлгереп җитте. Өстәл янына утырдылар. Кызы өй хәлләрен сөйләде, иреннән зарланып алды, аннан бакча турында сүз чыгып, сорап куйды:

— Алмагачларны кискәнсең икән, әти.

— Ие шул, кызым, кистем. Алынып китмәделәр бит.

— Яхшы иткәнсең. Барыбер файдасы юк. Урын алып кына торалар.

Кызы тәрәзә аша бер мәл бакчага карап торды.

— Бакча хәзер ничектер киңәеп калган шикелле, — диде.

— Ие-ие, — диде карт, кинәт җанланып, — алмагачлар булмагач, ачылып, зураеп китте бакча.

— Ярар, әти, кайгырма. Җир тик ятмас. Нишләргә икәнен белербез, — диде кызы һәм шул чакны нидер искәреп, кабат бакчага карап алды, аннан әтисенә борылды: — Карале, әти, күрми дә торам, викторияләрне бетергәнсең ич! — Аптырап әтисенә төбәлде. Җавап көтте. Карт дәшмәгәч, чыдары бетеп, үзе сорады: — Яңаларын утыртырга уйладың мәллә?

— Юк, кызым, моннан соң утыртмабыз, ахры, викторияне, — диде.

— Ничек? — Кызы, нидер сизенгәндәй, әтисенә төбәлде.

Карт уңайсызланып алдындагы чынаягына иелде, күзләрен яшерде.

— Хәзер әниең дә юк, авырга килер, дим.

— Килмәс, әти, килмәс, үзебез булышырбыз.

— Юк, кызым, көчләмә инде син...

Кызы тагын да аптырый төште һәм, кыза башлап, һөҗүмгә күчте.

— Ә нишләп ятмакчы буласың ул бакчада? Әллә суган белән кишердән кайнатырбызмы вареньеларны?

Яшь хатын җәелгән түшендә ачу кабаруын сиздерерлек итеп әйтте сүзен. Ул әтисенең әйткәненнән кайтучы түгеллеген белә иде.

— И-и, әти, үзең дә уйлап чыгарасың. Их, әни исән булса, кайнатыр иде хәзер эшне! Синең шикелле тик ятмас иде.

Хәтере калды картның бу сүзләргә. Атна-ун көн эчендә күпме эш әйләндереп ташлады, берүзе бакчаны казыды, нинди юан алмагачларны кисте. Ә кызы ни дип тора? Карт кызының ачулы күзләренә, турсайган иреннәренә, ят булып тоелган йөзенә карап алды да, авыр сулап, өстәл яныннан торып ук китте. Нәкъ менә сезнең өчен тырышып китеп барды да бит анаң, димәкче иде ул, әмма тыелып калды. Әйтәсе сүзе тышка авыр көрсенү булып кына чыкты.

Карт ишек яңагына килеп сөялде, бер мәлне кояшлы бакчага карап торгач:

— Моннан соң мине, тегене чәчик, моны утыртыйк дип, аптыратасы булма. Эшләргә барыбер киләсегез юк. Барысы да минем өстә калачак. Мин үземә кирәген чәчтем, — диде.

— Ни чәчтең тагын?

— Печән! — диде ул, үзе өчен күптән хәл ителгән, күптән уйланылганын ярып салып, һәм бусагадан тышка атлады.

Өй эченнән байтак вакыт кызының ярсып кычкыруы, әллә ниләр әйтеп әтисен әрләве ишетелеп торды. Ә бераздан карт аның кызарынып-бүртенеп бакчадан чыгып баруын күреп калды.

Күк күкрәп, җылы яңгырлар явып үтте. Җир яңарып сулыш алды. Картның бакчасында, уҗым тишелгәндәй, бихисап яшел энәләр күренде. Алар әле шул кадәр кечкенәләр, зәгыйфьләр, үсеп китүләренә дә ыша-

насы килми иде. Әмма көн үткән саен алар зурая, куера, ныгый бардылар, буй җибәрделәр. Менә өсләреннән инде аксыл-яшел дулкыннар йөгереп уза, җил бергәләнып юнәлешен үзгәртсә, үлән тирбәлә, төрле бизәкләр хасил була. Тәсе, төсе бик тә матур иде тишелеп чыккан яшел үләннең. Үзе әйтеп бетергесез чиста, ниндидер күзләрне иркәли торган назлы иде ул. Шушы үләннәр тирбәлүе бусагада утырган картның җанына әллә нинди ял, сихәт бирә иде. Уйлары белән ул әллә кайларда йөри, томанлар эчендә калган ерак елларны урап кайта. Шунысы гаҗәп: болай утырганда исенә һаман якты хатирәләр генә килә иде аның. Тормыш булгач, төрле хәлләр башыннан кичте югыйсә. Ә күңелендә менә яктылары гына калган... Димәк, берәүгә дә ачу сакламаган ул, көнләшеп, үчләшеп яшәмәгән. Кулыннан ни килсә, шуны эшләгән, эшенә күрә ашын ашаган, кеше өлешенә кул сузмаган. Шуңа күрә карт көнендә күңелен берни дә тырнамый, вөҗданы тыныч.

Эх, менә кызы гына ул дигәнчә булып чыкмады...

Дулкынланып утырган үләннәр буын чыгарды, ныгыды, айканып чабарлык печәнгә әверелделәр. Гаҗәп хәл: баштарак кайсы ачыктан-ачык көлеп, кайсы җирне әрәм итмәскә үгетләп йөргән күршеләр, үз бакчаларында эшне бетереп ял иткән сәгатьләрендә, карт янына килеп утыра, хәл-әхвәл сораша торган булып киттеләр. Үзләренең казык кагарлык та буш җир калдырмый файдаланылган бакчаларына карaганда куперөп үскән ямь-яшел печән белән хозурланып утыру аларга да рәхәтрәк иде булса кирәк. Карт моны бик хуп күрде, сөенде, шулай булыр дип көткән иде. Янына берәрсе килеп утырганда, нилектән икәнен үзе генә белеп, мыек астыннан сизелер-сизелмәс кенә елмая иде. Кызы соңгы сөйләшүдән соң бөтенләй күренмәс булды. Әтисеннән тагын да суынуы, ерагаюыдыр, мөгаен. Ә болай кеше белән утырганда үзен ялгыз тоймый иде карт.

Кайвакыт эскәмиягә җыелганнар арасында кызык кына сүзләр дә чыгып куя иде.

Бер көнне, үзе шикелле куна-төнә бакчада яшәп яткан күршесе Шәйхи белән картларча мыдыр-мыдыр сөйләшеп утырганда, яннарына Рафаэль килеп утырды. Ул да күрше. Җәйләрен бакчада яшәргә тырыша, эшенә электричка белән йөри. Менә бүген дә, эшеннән туры бакчага кайтып ашап-эчкәч, һава алыштырырга дип өеннән чыкты һәм, эскәмиядә картларны күреп, яннарына килеп утырды.

Хәл-әхвәл сорашып, мондый очракта әйтелә торган сүзләр әйтелгәч, алар беравык тынып калдылар. Өчесе дә куперөп үскән печәнгә күз салгалап, кичке тынлыкны бизәп яңгыраган чикерткә тавышын, ара-тирә тимер юлдан ишетелгән рельслар гүләвен тыңлап, поезд юлының теге ягындагы картайган кояшка карап утырдылар. Шул вакыт әле генә килеп туктаган Рафаэль, көндезге шәһәрдән, аның ыгы-зыгысыннан, бөркү урамнарыннан котылуына шатланып булса кирәк:

— Рәхәт монда, — дип куйды һәм ачык изүеннән күренеп торган йонлач күкрәген уып алды.

— Әйтмә, энекәш, — дип алып китте Шәйхи карт, — шәһәр кешесе җәйләрен хәзер бакчада ятып үткәрә инде. Башка чарасы калмады.

— Чыннан да, җәен шәһәрдә яшәүләре бигрәк авырайды соңгы елларны, — диде Хуҗа да, сүзгә кушылып. — Бәлки шуңа күрәдер һәрбер кеше бакча алырга, алачык төзеп, җәен шунда үткәрергә тырыша.

— Дөрес. Соңгы ун-унбиш елны бакчалар бигрәк ишәеп китте, — диде Шәйхи карт. — Элегрәк, без яшьрәк чакта, кирәге юк шикелле иде.

— Элегрәк аның шәһәре дә бүтәнчә иде шул. Урамнары, йортлары хәзергедәй кайтышрак булса да, тынычлыгын зур иде. — Хуҗа күкрәк кесәсеннән портсигарын чыгарды да сигарет алды. — Ә хәзер өйгә кай-

тып тәрәзәне ачарлык түгел. Ул тавыш, ул тузан... — Һәм ул, сөйләп торуның кирәге юк дигәнне аңлатып, кулын гына селтәде.

— Ә һавасы, һавасы, — дип элеп алды Шәйхи карт. Машина исен инде әйткән дә юк. Аның заводлары да үтә хитриләнеп китте... Ял көн җиттеме, атна буе җыйган газларын чыгара башлыйлар. Ярый ла көне җилле туры килсә, һавада тик асылынып тора.

— Газ дигәннән... кайбер урамнарда хәзер завод чыгарган истән агачлар ук корый дип сөйлиләр. Әле дә ничек чыдый бу кеше дигәнең, ә?

Карт сигарет киертелгән мундштугын авызына капты да үт кабызды.

— Табигатьнең тәмам көе китте. Нинди афәт бу? Болай барса, белмим... ничек кенә булып бетәр.

Шәйхи карт хуҗаның сүзен җөпләп башын чайкады һәм сүзгә кушылмый гына тыңлап утырган Рафаэльгә борылып:

— Син, энекәш, мена укымышлы кеше. Студентлар укытасың. Бәлки син әйтерсең, кая бара бу дөнья?

Рафаэль дигәннәре кырык яшьләр тирәсендәге чәче коела башлаган күзлекле адәм иде. Ул тыйнак кына елмайды да, күзлеген баш бармагы белән кашына шудыртып:

— Моның ише сүзләрне хәзер еш ишетергә туры килә, — дип куйды. — Мена әле дә сезне тыңлап уйланып утырдым. Нигә соңгы елларны бу хакта бик еш ишетергә туры килә? Нигә бу мәсьәлә көн тәртибенә калкып чыкты? Чыннан да, бу турыда хәзер бик күпләр уйлана, фән дөньясында да бу хакта күп язалар хәзер.

Рафаэль тукталып бер мәлне тимер юл буенда тезелешкән топольләр челтәре аша чәрдәкләнеп күренгән шәфәкъ кызыллыгына, күктәге каурыйсыман алсу болытларга карап торды һәм сүзен дәвам итте:

— Ярар, еракка китмичә генә башта мена үзегез телгә алган дачалар, бакчалар мәсьәләсенә тукталыйк... Нигә соңгы елларда бакчалар күбәйде? Нигә һәрбер кеше, җәен инде әйткән дә юк, хәтта кыш көннәрендә дә шәһәрдән качарга, берничә сәгать кенә булса да табигать кочагында булырга тырыша... Тирәнрәк уйласаң, дача дигәнең ул заман китереп чыгарган нәрсә, икенче төрле итеп әйткәндә: мин табигатьтән көчле, мин аның хуҗасы, мин аны буйсындырам, дип шапырынган кешенең җиңелә баруын күрсәтә торган бер фактор. Үзегез уйлап карагыз: кеше гасырлар буе тырыша-тырыша прогресска омтылды, яңадан-яңа җирләр ачты, ул җирләргә зур-зур шәһәрләр корды, шәһәрләрдә заводлар төзеде, табигатьнең бихисап серләрен ачты. Аның хыялы — җир йөзен гөлбакча итү иде, үзенә матур, уңайлы, рәхәт тормыш төзү иде. Ә нәтиҗәдә нәрсә килеп чыкты соң? Кеше үзе сулый торган һаваны бозды, елга-суларны пычратты, бик күбесен корытты, бик күп урманнарны кырды, тереклек ияләрен юк итте. Кеше гасырлар һәм гасырлар дәвамында бүгенге көн ихтыяҗлары белән яшәп килде, алга карый белмәде, кылган эшләренең нәрсәгә китерәсен уйламады. Һәм мена бүгенге көнне кешегә үзе төзегән зур шәһәрләрдә һава җитми, анда тузан, урамга чыкса, колагын ярып, янәшәсеннән зур-зур машиналар уза. Үзе төзегән шәһәрдә яшәү авыр аңа хәзер, елдан-ел йөрәк һәм нерв авырулары белән җәфаланучылар саны ишәя, һәм бу авыруларны хәзер «гасыр китереп чыгарган авырулар» дип атыйлар. Анасы табигатьтән бик тә ераклашты кеше. Шәһәр кешесенең дачада качып ятуы ул аның буйсындырырга тырышып караган табигать-ана каршысына килеп тезләнүе, аның кочагында аз гына булса да ял итеп, көч җыеп, какшаган нервларын, сәламәтлеген ныгытырга омтылуы түгелме?

Рафаэль артык мавыгып китүен, үзенең студентлар алдында түгел, ә сезгә генә булса кирәк, туктап калды. Кабат борын очына шуыша башлаган күзлеген төзәтеп куйды. Картлар да, яшь галимнең сүзләре

тээсирендә ахрысы, тың гына утыра бирделәр. Берәү дә сүз катарга ашыкмады. Тынлыкта чикерткә черелдәде, колак төбендә озынборын безелдәде. Күп тә үтмәде, тимер юлдан электричка сызгырып узды һәм бер мәлне ераклаша барган рельслар гүләве ишетелеп торды. Шул вакыт хуҗа кеше, онытылып мундштугында сүнгән сигаретын капшап карады да, телгә килде:

— Сине тыңлаганда, әнекәш, мин яшьлегем узган авылымны күздән кичереп утырдым әле, — диде ул. — Безнең авылда Күл буе дигән җир бар. Мин балачакта анда чыннан да җикән камышлы шактый тирән күл бар иде. Шунда әтиләрнең ат коендырып, балык сөзеп, чиләкчиләк кәрәкә тотканнары хәтердә калган. Әтинең сөйләве буенча, әлеге күлдә аның әтисе дә (минем бабай) ат коендырган, балык сөзгән. Димәк, элегрәк табигать ул кадәр үк тиз үзгәрмәгән. Ә менә хәзер, минем күз алдында диярлек, әлеге күл буйлары бөтенләй бетте. Исеме генә күл буе аның хәзер. Күл үзе күптән юк. Ләм басты, кипте, тигезләнде ул турлар... Тирә-юньдәге тугайларны сөреп, бер-ике ел файдаландылар да ташладылар. Хәзер анда алабута котыра...

Әйләнә-тирәдәге бөтен нәрсәнең җиргә иңгән караңгылыкта эри барып, шәфәкъ баткан офык читенең'дә шәмәхә төскә авышкан шушы мизгелендә картның тавышы аерата ачынулы яңгырады. Ул, сүнгән сигаретын аяк астына ташлап, мундштугын кулына кысты да, үзен борчыган бөтен нәрсәләргә берьюлы җавап алырга өметләнгәндәй, сорау бирде:

— Әйт әле, энекәш, нигә бу кадәр кадерсезлиләр бу җирне? Нигә болай тиз үзгәрә бу табигать дигәнең? Нигә сакламыйлар аны?

— Мин генә хәл итә торган мәсьәлә булса, — диде Рафаэль, көрсенеп, — ул көн тәртибендә дә тормас иде... Бу бит хәзер кешелек алдында торган мәсьәләләрнең дә мәсьәләсе. Галимнәр дә, дәүләт кешеләре дә бу хакта нык уйлыйлар. Кыска гына итеп әйткәндә шул: кеше заманнар үтү белән биологик яктан әллә ни үзгәреш кичерми, әмма актив рәвештә үзе яшәгән тирәлекнә, мохитны үзгәртә. Элек бит ул ничек булган: әйләнә-тирә кичергән бу үзгәрешләр ничәшәр буын гомеренә туры килгән, шуңа күрә артык сизелмәгән дә. Ә хәзер исә, техниканың үсүе сәбәпле, бу процесс бик тә көчәйде, бер кеше гомерендә дә күпме яңалык, үзгәреш була. Кешенең психикасына көч килә. Кеше барысын да аңлап, үзләштереп бетерә алмый.

— Ярамый бит болай. Чиге булырмы соң моның? — диде карт.

— Булыр. Булырга тиеш. Моңа кадәр дә, алдына берәр проблема килеп басканда, кешелек әмәлен таба килде. Бу юлы да табар дип ышанырга кирәк. Галимнәр инде моның киләчәк өчен никадәр куркыныч икәнен аңладылар. Биосфераны саклауның төрле юлларын эзлиләр. Ә менә производство өлкәсендә әлегә эшләр элеккечә бара. Алар һаман да бүгенге көн хаҗәтләре белән яши. Һаман план куалар.

— Соң булмасмы соң?

Рафаэль җавап бирмәде. Аягына торып басты да, утырып оеган буыннарын язгандай, хәрәкәтләнеп алды, аннан, биленә таянып күккә карады. Күктә исә һаман үзгәреп, һаман яралып торган тормыш мисалында дәһшәтле бушлыкка сибелгән йолдызлар кабынган иде. Рафаэль, бер мәл җемелдәгән шул нокталарны күзәтте һәм, сәер елмаеп:

— Кеше дигәнең ахыр чиктә акылга утырыр, андый акылсызлыкны эшләмәс дип уйлыйм, — диде. Аннан борылып, үз бакчасына таба китте.

Картлар исә, эскәмиягә кадаклангандай, утырып калдылар.

Яшь чагында ярты гомере шәһәрдә үтәр дип уена да килми иде картның. Әмма язмышның кая борыласын алдан күреп булмый икән.

Аннары шунысы да бар: авыл җиреннән тәмен татыган, анда күпмедер тир түккән кеше гомер буе шәһәргә ияләшә алмый икән ул, күңеленең кайсыдыр чите өзелеп авылда калган була, һаман аны сагына, аңа тартыла икән...

Карт та менә, шәһәргә күчкәч, яңабаштан тормыш та төзеде, тату да яшәделәр, ләкин барыбер вакыты-вакыты белән яшьлеген, егет чакларын, өйләнеп кеше арасына кергән авылын юксына иде. Ә карчыгы менә шәһәргә бик тиз ияләшеп китте, барысын да юнәтергә, кешедән калышмаска тырышты. Әлеге бакча дигәнең дә ул үгетли торгач кына булдырылган нәрсә. Дөрес, бакчада карчыгы арттырыбрак җибәрә иде, монда да күрше-күләннән калышмаска, кешедә ни булса, үзендә дә барысын булдырырга тырышты. Картның сүзен тыңламады, үзенә авырлык килсә килде, ләкин йөзенә кызыллык китермәде карчыгы. Андый зат түгел иде шул, мәрхүмә, урыны йомшак булсын.

Ә печән чәчеп яхшы итте әле ул. Җитәр җирнең җелеген суырырга. Бирәсен бирде инде ул, карт үзе исәнендә бераз ял итеп, тын алсын җиркәй, күкрәгендә үскән печәннең салмак кына тибрәнүеннән иркәләнсен әле бер... Аннан соң кемнәр кулына калыр бит...

Әнә, күрше бакчаларны гына күр син. Их, гомере буе сөймәде шул һәр нәрсәдән файда эзләүчеләрне! Бәлки аларга үч итеп чәчкәндер дә әле бу печәнне. Көлсеннәр, көлә бирсеннәр... Килеп утыралар бит аның эскәмиясенә, помидор казыкларына төбәлеп утыру түгел бит ул. Картка шунысы да җиткән...

Ничек кенә тартып-сузып йөрмәсен печән чабуны карт, ул көн барыбер килеп җитте, печән каерып чабарлык булып өлгереп житеште. Җилдә дулкынланып уйнаган печәнгә сокланып утыру кебек үк бу эшнең дә карт өчен үз мәгънәсе, үз ләззәте бар иде.

Чабарга тәгаенләгәч, ул каравылчыдан чалгы сорап алды, аны үзенә яраклаштырып көйләде, чөйләрен какты, тимер-томыр әрҗәсеннән өч кырлы игәү табып кыргыч ясады һәм, ашыкмыйча гына чалгысын кырып, чөен суга батырды да, эшне иртәгедән башларга ниятләп, чалгыга ул көнне кагылмады.

Иртәгесен карт, кояшның беренче нурлары агач башларына, юеш түбәләргә кагылып узганда ук, уянып китте. Һава тып-тын, аяз иде. Чыклы печән тагын да куерып, калынаеп күренә, парланган пыяладай аксылланып утыра.

Карт, йокыга талган дачаларның тынычлыгын бозып, беренче тапкыр чалгысын янаганда, кояш инде бераз күтәрелгән, бакчаның тегe башындагы печән, өстендә асылташлар сибелгәндәй, җемелдәп-җемелдәп куя иде.

Чалгысын янап бетергәч, бер мәлне карт, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, чабасы печәненә, аяз күккә, тын иртәгә карап торды, аннан учына төкерде дә, үзенә генә билгеле борынгы сүзләр пышылдап, күкрәк киереп селтәп җибәрде. Җанга рәхәт чалгы тавышы ишетелде, сөрлегеп печән ауды, икенче селтәнүдә, яшкелт сызык булып, чалгы астында чиста җир ачылды... Картның байтак еллар инде кулына чалгы тотканы юк иде, әмма онытылмаган икән әле печән чабулары! Аның хәрәкәтләре элеккегечә төгәл, салмак, һәр мускулы чалгыны тоеп бара. Күңелен иркәләүче көйгә бирелеп, селтәнде дә селтәнде карт. Селтәнгән саен чалгы тавышы аның йөрәгенә сихәт өсти, тәне кызганнан-кыза, торган саен җиңеләя, бүртенгән тамырларында көч-куәт арта, күлмәккә бәреп чыккан тир еллар авырлыгыннан арындыра бара һәм күңелендә дә нидер үсә, яңара, җанланганнан-җанлана иде. Хәзер аның уйлары, бу печәнне чәчкән язгы көндәге шикелле әллә кайларда йөри, еллар томаныннан онытылган күренешләр, төрле йөзләр калкып чыга, һәм алар, бүген генә булгандай, күз алдына килеп баса. Менә алтын йөгертелгән кырлар буенча лобоггрейкалар тартып атлар йөри, лобогрейка-

ларның берсендә, кулына агач сәнәк тотып, карт үзе (ул вакытта әле яңа өйләнгән егет) утыра, ә ак яулыгын артка бәйләгән карчыгы (ул чакта әле яшь килен) хатыннар белән бөгелә-сыгыла көлтә бәйли... Ул кырларны икенче күренешләр алыштыра. Менә алар болында, аркан белән урап, чүмәлә тарттыралар. Кипкән печән исе борыннарны кытыклый, талгын җил исә, хуш исне болынга тарата. Күренешләр алышына тора, үткән гомер әле бер тәрәзәсен, әле икенчесен ачып юата картны. Картның күз тирәләрендә елмаю туа һәм йөзенә тарала.

Тукталып хәл алган чакта бакчасы кырыеннан үтеп баручы, кепка кигән ирне күреп алды карт. Теге ир дә, картның ни белән шөгыльләнүенә гаҗәпсенеп булса кирәк, башта адымнарын акрынайтты, аннан бөтенләй туктап, әле чабылган печәнгә, әле чалгы сабына таянган картка карап торды да дәшми-нитми китеп барды. Бераз киткәч, тагын борылып карады. Ирнең йөзе картка таныш кебек тоелды. Кайдадыр күргәне бар иде, ахрысы.

Ул көн шулай печән чабу белән узды. Иртәгесен дә карт күтәренке күңел белән торды. Кичәге эштән тәне генә азрак сызлагандай итә иде. Кояш бераз күтәрелеп, төнге чык кипшенгәч, бакча тутырып кичә чапкан печәнен таратып салды ул, аннан эскәмиясенә килеп ял итәргә утырды. Үзенең кечкенә печәнлегендә барысын да яңадан татып карыйсы, тирләп эшлисе, кибеп яткан печәнне кузгатканда башны әйләндерә торган хуш исне, шифалы һаваны күкрәк тулганчы эчкә аласы, шушы эшләр белән мавыгып, үзенең картлыгын онытып торасы һәм картлык алып килгән ялгызлыгыннан, сагышлы уйларыннан бер кадәргә арынып яшисе килә иде аның.

Кичләрен эскәмиягә тагын күршеләр килеп утыргалый иде. Печән исе тарта иде аларны. Картның сәер гамәлләренә инде күнеккән булсалар да, дачада печән чабып киптерү алар өчен үзенә күрә бер тамаша иде, ахрысы.

Бер көнне өйлә җитәрәк, калдык-постык такталардан, чыбык-чабыктан бакча уртасында куыш оештырып, өстен шытырдап торган печән белән ябып ятканда, кечкенә капканы төртеп ачып, карт янына бер ир килеп керде. Текәлебрәк караса, бу теге узып барышлый тукталып, картның печән чабуын карап торган кепкалы кеше икән. Сәлам бирештеләр. Ир кеше яртылаш ябылган шалашка күз ташлап:

— Кызыксынып керүем иде, — диде. — Бер көнне сезнең печән чабып ятканны күреп узгач, моңа мәйтәм, печәннең кирәге барыбер шул кадәр генә, сатмас микән, кереп белешим әле, мәйтәм. — Ир сынап картка төбәлде.

— Юк шул, — диде карт. — Печән сатлык түгел. Үземә кирәк.

— Әллә берәрсенә ышандырып куйган идегезме? — диде ир, үзенеке итеп. Картка ул ышанмый иде. — Алай булса, мин кыйбатрак та бирә алам.

— Юк, туган, ышандырган кешем юк. Сатмыйм. Ачуланма.

Ир үзенә печән әләкмәсен сизенде, әмма сатмауның сәбәбен белеп китәсе килде аның һәм читләтеп ачыкларга кереште.

— Бу дачаларда шәһәрнекеләр торадыр бит? — диде ул сак кына.

Карт «әйе» дип баш какты һәм, сүзне беткәнгә санап, кулына сәнәген алды. Ә ир кеше, атка каныккан кигәвендәй, аның саен төпченүен дәвам итте.

— Димәк, сезнең дә асрар терлегегез юктыр, шәһәрдә кайда асрыйсың аны. Соң нигә кирәк сезгә печән? Бәлки сатарсыз? — Аның тавышы кинәт бер-ике баскычка түбән төште.

— Юк, туган, үземә кирәк печән. Күңеленә авыр алма.

Ирнең кәефе кырылды, ул картның куыш өстен ябуын өнәмичә күзәтеп торды да нигәдер кепкасын салып кабат башына киде. Ир кеше

картка бу юлы да ничектер таныш шикелле күренде. Кайдадыр күргәне дә бар кебек, кайда икәнен әйтә генә алмый.

— Килешеп булмады инде алайса, — диде ир, кулын селтәп. — Печән шәп, болай әрәм-шәрәм генә булып бетәчәк... Юкка сатмыйсыз...— һәм ул, теләр-теләмәс атлап, кечкенә капкага таба китте. Капканы ябарга дип артына борылганда, картның зиһене кинәт ачылып китте һәм кылт итеп исенә төште: бу кешенең ул дачалар артындагы авыл кибетенә ипигә барганда бер ишегалдына мотоциклын кертеп ятканын күреп калган икән.

Сизелми дә үтеп китте картның бу җәе. Җылы һәм аяз төннәрне ул, астына коры печән түшәп, шалашында куна иде. Кайчакларда төн урталарында уянып китә дә, куышыннан чыгып, күктәге эре йолдызларга карап тора, аннан тәмәкесен кабыза. Мондый чакларны картның күңелендә төнге тынлык кебек талгын хисләр тирбәлә, гүя ул инде дөньяда башкарасы бөтен эшен тәмамлаган да, ниндидер икенче сыйфатка күчкән һәм бу сыйфатында аяк астындагы ташларга, үсеп утырган үләннәргә, агачларга, хәтта күктәге йолдызларга да якынрак тора. Кеше гомере, дип уйлый иде ул үзенчә, йолдызлар гомере белән чагыштырып карасаң, бер мизгел генә бит, югыйсә. Ә шул мизгел эчендә дә кешегә күпме күрергә, күпме татырга язган. Кеше дигәнең табигатьнең бәхетле затларыннандыр, ахры...

Ә бер төнне, гадәтенчә уянып китеп шалаш янында басып торганда, кайчандыр колагына кереп калган: «Озак һәм тату гомер иткән кешеләрнең берсе дөньядан китсә, икенчесе дә күп тормый, имеш», — дигән сүзләр хәтеренә килде. Ләкин карт моны бик тыныч кабул итте. Аның өчен ул сулыш алу кебек табигый иде.

*
* *

Карт, урыныннан торып, сумкасын кулына алды да капкага юнәлде. Аны шыгырдатып япкач, такта өенә, бакча уртасындагы ак түбәтәй кигән печән чүмәләсенә тагын бер күз салды. «Исән-сау кышларны чыгып, кабат монда киләсе, бакчаны күрәсе иде», дип уйлады ул, һәм борылып, әйләнгеч юлдан, дачалар артында торган авыл аша станциягә китте. Аның үтешли теге кепкалы ир янына керәсе, алып кит печәнне, миңа барыбер кирәге юк, диясе бар иде.

## Нияз Акмалов

### Таң

Җан тартмаган чит якларда булсын,
тау артыннан чыксын, үзәннән,
иң бәхетсез көннәремдә булсын —
сокланмыйча барыбер түзәлмәм:
Күтәрелә... Офыкларда кояш!
Җиргә таңнар иңеп килә бит!
Борчуларым бер чигенеп куяр,
сулышларым китәр киңәеп.
Күрер күзгә шәфәкъ кына түгел,
җанга шәфкать таңның буй-сыны.
Шушы таңда бер буйсыну булса,
гүзәллеккә бары буйсыну.
Көннәреңне вак-төяккә димләп,
бутый калса әгәр бүтәннәр, —
уйламаган уйларыңны йолкып
төшләреңә керер бу таңнар.
Таң — яңару,
таңда — яңа дәвам,
таңда — җанның кабат балкышы.
Шуңа, ахры, шушы ал таңнарга
гел таң калып карыйдыр кеше...

### Кадер

Кадерлем, дип әйтә алсак иде
кадерләрлек һәрбер кешегә.
Кешеләрдән күңел җылынып китә,
кешеләрдән күңел күшегә.
Дан югалса болай үртәлмәмен,
мал югалса болай үкенмәм, —
җуелып калган һәрбер өмет белән
көн җылысы китә бу көннән.
Кадерсезнең изге җаны булып
әрәм-шәрәм йөри куп байлык.
Кешеләргә кадер кимегәндә
туа торган иде сукбайлык...
Мин бик беләм: кеше булганнарның
һәр кешедә диләр эше бар, —
эзәрлекләп түгел,
эзләп кенә
яши белсен иде кешеләр.

Кадер барда күңел җылынып китә,
кадер юкта күңел күшегә.
Кадерлем, дип әйтә алсак иде
кадерләрлек һәрбер кешегә...

## Мәхәббәт

Алдыгызга алсу гөлләр җәям,
Юлыгызга — яшел аланнар:
Мең мәртәбә бәхетледер җирдә
Мәхәббәтен таба алганнар.
Мәхәббәтнең күге — гел кояшлы,
Тугайлары — һәрчак тургайлы.
Мәхәббәтнең таңы — гел былбыллы,
Мәхәббәтнең төне — гел айлы.
Әгәр күңелең мохтаҗлыкка чыкса,
Һәм теләсә синнән бер аклык, —
Бу гөнаһлы җирдә яши алган
Мәхәббәттә генә гөнаһ юк.
Мәхәббәтнең яралавы — дәва:
Язмыш җиле үтсә яралап,
Тик мәхәббәт саклап кала безне,
Тик мәхәббәт кала аралап.
Мәхәббәтнең күге — гел кояшлы,
Тугайлары — һәрчак тургайлы.
Мәхәббәтнең таңы — гел былбыллы,
Мәхәббәтнең төне — гел айлы.
Алдыгызга алсу гөлләр җәям,
Юлыгызга — яшел үләннәр, —
Мең мәртәбә бәхетледер җирдә
Мәхәббәтен таба белгәннәр...

●

Көн җитми кала — төн керә...
Йоклап китәргә күндерә
төн.
Үзем генә белеп калам,
мин бу төннең кодрәтен.
Төн җитми кала — таң керә...
Уйлардан йолкып бүлдерә
таң.
Әле ярый җирдә таң бар,
туар өчен кабаттан.
Таң җитми кала — көн керә....
Мәшәкатьләрен иңдерә
көн.
Кеше үзе белеп торсын,
бу көнгә ни кергәген.
Көн җитми кала — төн керә...
Керфек очларын көйдерә
төн.
Таңга кадәр ничек саклыйм
бу йөрәкнең кодрәтен?!

# СЫНАУЛАР АША

КамАЗның унъеллык шанлы һәм данлы эпопеясе тәгәлләнде. Бу бер дистә ел бик күп экономик, техник, шәһәр төзү һәм социаль-әхлак проблемаларын берләштерде, ул проблемаларның һәрберсе, аерым-аерым караганда да, бергә җыеп алганда да халыкара яңгырашка ия булган политик мәсьәләгә әверелде. Ул еллар чынлап та, үзенең халык хуҗалыгындагы чагылышы һәм комплекслы нәтиҗәләре белән кайбер егерме еллыкларга тиңләрлек ара.

Соңгы вакытта Чаллыдагы икенче чират объектларындагы зур җанлылык тагын да артып китте, әмма беренче чиратны сафка бастыргандагы кебек ыгы-зыгы, шау-шу күзәтелмәде. Монтаж һәм җибәрү-көйләү эшләре күләме биш ел элек булгандагыдан һич тә ким түгел иде, югыйсә. Өстәвенә, бүгенге КамАЗга игътибар да башка чаклардагыдан кимрәк төсле булды, кадрлар җитенкерәмәде; материаль-техник кыенлыклар булды. Әмма, шуңа да карамастан, икенче чират куәтләре сафка басты инде. Һөҗүмчән үсеш диалектикасы шуннан гыйбарәт тә шул инде: еллар үткән саен вакыйгалар сыйфат ягыннан тагын да камилрәк, югарырак дәрәҗәдә кабатланалар, ә көндәлек мәсьәләләр яки алда торган проблемалар акыллырак һәм эшне белебрәк хәл ителә.

Без «һөҗүмчән үсеш диалектикасы» дигән сүзне очраклы төстә генә кулланмадык, чөнки КамАЗ үзенә илебез һәм дөнья автомобиль төзелеше туплаган барлык яхшы, алдынгы ысулларны җыйнады, ЗИЛ, ГАЗ, ВАЗларның законлы дәвамы рәвешен алды. Ул гына да түгел, практика һәм фәннең барлык яңалыкларын үзләштереп, КамАЗ бүгенге автомобиль төзелешенең табигатен тирәнәйтеп һәм киңәйтеп җибәрде, зур масштаблы техник, шәһәр төзү, конструкторлык, оештыру-идарә итү мәсьәләләрен хәл итүнең үз ысулын һәм стилен булдыруга иреште.

* * *

Алтмышынчы еллар уртасында ВАЗ төзелә башлаган иде. Моңарчы күрелмәгән масштаблар, әлбәттә, баштарак һәрвакыт өркетүчән, ләкин ВАЗны төзи башлау КамАЗны төзергә керешүгә караганда җиңелрәк иде бугай. Ул вакытта халыкара хәл үзара файдалы хезмәттәшлекне тормышка ашыруга уңай йогынты ясады, шуның өстенә, ил эчендә ВАЗның материаль, кеше һәм башка ресурсларны җәлеп итәрдәй зур масштабтагы «көндәшләре» дә юк иде, ә автомобиль промышленносте министрлыгы Тольяттига тармакның иң яхшы белгечләрен җибәрде. Әмма ВАЗ бернинди каршылыксыз гына төзелде, дип арттырып та җибәрергә ярамас. ВАЗ бүгенге көн биеклегеннән, КамАЗ белән чагыштырып караганда, Кама ярлары буенда күп санлы, алдан күрелмәгән кыенлыкларны җиңгәннән соң гына чагыштырмача җиңел ватыла торган «чикләвек» булып тоела.

ВАЗны төзүчеләргә дә сокланырлык. Алар хезмәтне оештыру, производствоны планлаштыру, вакыт исәбеннән түләү — төзәтү-ремонт һәм ярдәмче хезмәт тармакларын үзәкләштерүнең күпләгән мәсьәләләрендә вакытны узып эшләделәр, элекке какшамас кебек күренгән карашларны челпәрәмә китереп таратып салдылар, барлык арадашчыларны һәм тәэминатчыларны яшәп килгән чараларга башкача карарга мәҗбүр иттеләр. ВАЗ әлегәчә бүгенге производствоның эталоны булып тора һәм, алгарак китеп булса да, ВАЗ булмаса, КамАЗ булмас иде дип әйтүгә җирлек бирә. Һәр ике заводта да эшләгән һәм аларны яхшы күзаллаган белгечләрнең күмәк фикере әнә шундый.

Җитмешенче еллар башында КамАЗга нигез салынды. Аның колачы да, мас-

штаблары да, шартлары һәм төзелешендәге хәлләр дә ВАЗ белән генә чагыштырырлык түгел иде инде.

Госпланда һәм проект-конструкторлык бюроларында инде БАМ һәм Атоммаш, Чабаксар трактор заводы, трансмагистраль «Оренбург — Көнбатыш чик» газүткәргече проектлары өлгереп килгән чак иде. Илдә эшче куллар җитмәү мәсьәләсе күтәрелеп чыкты, ерак офыкта энергетика һәм чимал кризисы янавы шәйләнә башлады. Бу хәлләрнең барысы да, һичшиксез, КамАЗ төзелешенең һәм куәтләрне үзләштерүнең төрле чорларына тәэсир итмичә калмады..

Совет автомобиль флагманнарын булдыру тарихында КамАЗ ВАЗдан ераграк китәргә тиеш иде.

* * *

КамАЗны тормышка ашыру барышында торак һәм производство корпуслары төзү, заводлар салуның техник һәм технологик аспектлары, социаль-әхлак, КамАЗ бүген һәм иртәгә дигән проблемалар җитдирәк калкып чыкты.

Аларның һәрберсе гаять киң, колач җитмәслек булганлыктан, табигый ки, сүз бары тик Чаллыда барлыкка килгән һәм элегрәк илебез тормышында күрелмәгән яңалык һәм казанышларның иң күзгә ташланганнары турында гына барачак.

Йөздән артык проект оешмасы һәм институт, бөтен проект әзер булуын көтеп тормыйча, төзүчеләргә эш сызымнарын өлешләп биреп, торак һәм производство корпусларын бер үк вакытта кору, производство объектларын кору темпларын бер елдан артыкка кыскарткан субайларны бораулап сугу, технологик җиһазларны җирдә эреләндерелгән секцияләр һәм блоклар белән кору кебек кыю ысуллар барлыкка килде.

Безнең автозаводларда машинаның яңа моделен эшләү һәм ясап чыгару өчен уртача 7 — 8 һәм хәтта 10 ел вакыт кирәк. Ә Чаллыда исә уртача алганда елына бер модель эшләнә. Мондый искиткеч йөгерек нәтиҗәләргә ни исәбенә ирешелде соң? Нигездә, принципиаль ике яңалык исәбенә. Болар — исәпләү техникасын киң куллану, проект эшләрен исәпләү һәм автоматлаштыру системасының бүгенге ысулларын булдыру; әле беркайда да, шул исәптән Көнбатыш илләрендә дә булмаганны эшләү. Алга үзеннән-үзе бер сорау килеп баса: ә ЗИЛда, ВАЗда исәпләү машиналары юкмыни? Бар, әлбәттә, тик аларда машиналар... конструкторлар түгел. КамАЗда детальләрне электрон исәпләү машиналары — ЭВМ исәпли, ә ВАЗда моның белән кеше шөгыльләнә. КамАЗның конструкторлык бюросында 200 кеше эшли, ә ЗИЛда —500. КамАЗда тарту-динамик исәпләүләрне ЭВМ 10 минутта башкарса, кеше-конструкторга исә моның өчен баш күтәрмичә өч ай буена эшләргә кирәк булыр иде...

Ул гына да түгел, КамАЗда конструктор ЭВМ белән диалог системасында эшлиләр, машинага: «Әгәр дә...» дигән яңадан-яңа мәсьәләләр куела. ЭВМ алдан күрелгән һәм күрелмәгән вариантларны чишә. Чагыштыру өчен тагын бер сан китерик: КамАЗдагы проект эшләрен автоматлаштыру системасы белән шөгыльләнүче төркемдә 10 кеше эшләсә, ВАЗда —150. Чаллыда ничек «түбән тәгәрәүләрен» белгәч, ВАЗда башта аптырашта калганнар, аннары, акыллы кешеләр буларак, бик тиз арада камазлылар белән иҗади хезмәттәшлек турында килешү төзегәннәр. Бәлкем мондый очракларда ВАЗда эшләүчеләрнең профессиональ горурлыкларына бераз хилафлык та килгәндер, әмма мондый хезмәттәшлектән совет автомобиль төзелеше отканлыгы бәхәссез.

Чагыштыруларны дәвам иттерик. Башка конструкторлык бюроларында конструкторның бурычы барысын да төгәл исәпләүдән, яңа машина эшләүдән һәм узелларны, частьларны, детальләрне эшкәртүнең иң отышлы вариантлары эшләнсен өчен документацияне производствода эшләүчеләргә һәм технологларга тапшырудан гыйбарәт. КамАЗда исә технологларны бетерү ягында торалар, чөнки ЭВМ, детальләрне исәпләү һәм эшләү белән бергә, аны программалы идарә итүле станокта җитештерүнең чыгым иң аз тотыла торган һәм нәтиҗәле вариантын күрсәтә. Өстәвенә бу яңалыклар каяндыр күктән төшмәде, ә КамАЗның яшь конструкторлары тарафыннан эшләнде.

«КамАЗ стиле» белән конструкцияләүнең икенче принцибы — булмаганны эшләү. Кызганычка каршы, әле бүгенгәчә кайбер конструкторлар арасында тамырлары еракка барып тоташа торган бер гадәт яши: теге яки бу нәрсә кемдә дә булса бар икән, димәк, үзеңнекен эшләргә, ягъни, яңадан, «велосипед уйлап табарга» кирәк, әгәр берәүдә дә юк икән, димәк, тотынырга да ярамый. КамАЗда детальләрнең, узел, эшләнмәнең шундый ук төре бармы-юкмы икәнен тиз арада ачыкларга мөмкинлек бирә торган патент һәм документларны эшкәртүнең илебездә бердәнбер саналган системасы булдырылды. Табылганны, булганны, эшләнгәнне кабатлау — үз-үзеңне техник прогресстан артта калуга дучар итү дигән сүз ул. Менә шуның өчен дә КамАЗның инженерлык үзәгендә 90 нчы еллар моделе инде әзер килеш тора, ә унберенче бишьеллык машинасы КамАЗ — 4310 әле биш ел

8*

элек үк ведомство сынавын үтте һәм икенче чират конвейерында үзенең урынын котә.

КамАЗның ВАЗдан да алгарак китәргә тиеш булуына гаҗәпләнергә кирәкмәс. Моны башка шартлар, вакытның башка таләпләре һәм продукциянең башкача дәрәҗәсе таләп итә. Тольяттилылар, илебездә беренчеләрдән булып, фирма автоүзәкләре челтәре булдыра башладылар. КамАЗ да алар үрнәгенә иярде. Бүген төрле өлкә һәм республикаларда КамАЗның 100дән артык автоүзәге бар инде. Ләкин, тольяттилылардан аермалы буларак, КамАЗ пунктларында машиналарга хезмәт күрсәтү һәм ремонттан кала тагын шоферларны яңадан өйрәтү эшләре дә алып барыла әле. Чөнки КамАЗ өчен ГАЗ, ЗИЛ, ВАЗларга караганда квалификациялерәк шоферлар кирәк. Шуңа туры китереп, автомәктәпләр дә үз программаларын киләчәк үзенчәлекләрен исәпкә алып үзгәртеп коралар. 90 нчы елларда КамАЗларның даими паркы 1,5 миллион машинадан торачак. Төрле юнәлешләрдә файдаланылачак бу йөк машиналарын нәтиҗәле файдалану инде бүген үк гомумдәүләт күләмендәге әһәмият ала.

*
* *

Өченче проблеманы социаль-әхлак, шәхес проблемасы дип атарга мөмкин.

КамАЗ кеше язмышлары һәм характерларын сынауның гаять зур мәйданы булды. Биредә гадәти, тыныч эшләү белән, җимерү, «шартлату» яклылар, тәвәккәллеккә баручылар, үтә дә хәтәр хәлләрдә үзләренә җаваплылык алудан курыкмаучылар арасында котылгысыз бәрелешләр барды. Монысы һәркемгә мәгълүм. Ә менә ахыр нәтиҗәләр бар кешегә дә мәгълүм үк түгел.

Гомумиләштереп караганда, КамАЗ эшчесе кем ул? Нинди? ЗИЛ, ВАЗ эшчесеннән ул нәрсәсе белән аерылып тора? Автопромның элекке министры Тарасов моны гади генә итеп болай аңлатып биргән иде: «КамАЗда кешеләр башка заводларга караганда күп өлешкә дәртлерәк»

Чаллыда үз гаебеңне, булдыксызлыгыңны башкаларга сылтау чарасы калмады. Күп миллион акча тотып эшләнгән проектның язмышы, аның уңышы сиңа, миңа, аңа — безнең барыбызга да бәйле иде. Чаллыга эчкерсез булмаган Көнбатыш көнләп тә, юрап та карап торды; янәсе, руслар булдырып чыга алырлармы? Шуңа күрә дә аңы һәм сәләте төрле дәрәҗәдә булган эшче һәм җитәкче, курыкмыйча әйтергә мөмкин, үзендә дөньякүләм җаваплылык тоеп эшләде һәм эшли. Җаваплылык хисе һәркайда өстенлек итте. Элекке рекордларны, срокларны, кеше мөмкинлеге чикләрен челпәрәмә китерүче яңа норма, кагыйдәләр барлыкка килә. Мондый шартлар ирексездән барлык урында массовый иҗат тудыра. Филимонов һәм Ганиев, Новолодский һәм Мәүликов, Павлов һәм Баштанюков, Каменский һәм Мишин кебек талантлы эшлеклеләр җиң сызганып эшләделәр һәм эшлиләр. Хезмәт каһарманнарын күпләп санарга мөмкин.

ВАЗда да, КамАЗда да чит илдән китерелгән стандарт булмаган җиһазлар күп. Аларны кору һәм көйләү вакытында һәр предприятиедә «эшче аристократлар» барлыкка килә. Алар искиткеч осталыклары һәм катлаулы техник бурычларны хәл итә алулары белән хәтта зур тәҗрибәле инженер-техник белгечләрне дә сокландыралар. Тик үзләштерү, көйләп җибәрү чоры беткәч, халыктан чыккан бу осталар каядыр китеп югалалар. Алар турында якты истәлекләр генә кала. ВАЗда шулай булды. КамАЗ исә башка юлдан китте. Зур квалификацияле слесарьлар, көйләүчеләр, монтажчылар, электрончылар эзсез югалмасыннар, вак-төяк эшкә кереп чуммасыннар өчен махсус «Промавтоматика» тресты төзеделәр, алар ремонт-инструментлары заводының стандарт булмаган җиһазлар цехында башка подразделениеләрдә эшлиләр.

КамАЗның тагын менә мондый сабагы да бар: Чаллыга бөтен ил буенча югары квалификацияле эшчеләр эзләделәр һәм чакырып алдылар, тик аларның байтагы КамАЗда тәпләнеп кала алмадыр. Кагыйдә буларак, болар штурмовщинага яраклашкан, айның беренче яртысын тик тору аркасында тәмәке тартып, ә аннары планны эш вакытыннан соң калып 7 —10 көндә «куарга» күнеккән эшчеләр иде. КамАЗда исә һәр көн, һәр сәгать эшләргә кирәк, монда бөтенесе дә минутлап бүленгән, ә бу исә башка психология, эшче дисциплинасының башкача аңга корылганлыгын таләп итә иде.

Ямсә менә сиксәненче елның өр-яңа мисалы. Кою заводы — КамАЗның иң четерекле баласы. Сүз дә юк, ул уникаль, колач җитмәстәй, бөтен яктан карагандa да «иң-иң». Әмма шунысы хәтәр: завод беренче көннән үк аксый башлады, планнарны үтәмәде. Кою заводының көнлек, айлык планы үтәлми кала икән, димәк, тулаем, КамАЗның планы челпәрәмә килә. Нәрсәләр генә эшләмәделәр, нинди чаралар гына күрмәделәр... Кайберәүләр хәтта бу завод белән тиешенчә идарә итү мөмкин түгел, завод масштаблары кеше мөмкинлекләре чигеннән ташып чыга дип тә сөйләнгәли башладылар.

Заводка әле кырык яшен дә тутырмаган яңа директор җибәрделәр. ВАЗдан

килде. Заводта ике ай йөрде: каранды, сорашты, өйрәнде. Һәм беренче тапкыр кою заводы планны үтәп чыкты. Директор әле заводта дүрт кенә ай эшли, апрельдә генә килде, ә июль-августта инде завод күзгә күренеп югарыга үрли башлады. Шунысын да әйтик, яңа директор бераүгә дә җикеренмәде, бераүгә дә аяк тибеп кычкырмады, бераүне дә эштән кумады. Бех фамилияле ул. Николай Иванович. Үзен юньләп хәтердә калдырырга да өлгермәделәр, 56 нчы үлчәмле костюм киюенә карамастан, башка җитди директорлар арасында үтә дә яшь булып күренә, әйтерсең лә, эшлекле кешеләр киңәшмәсенә ул ялгыш кына килеп эләккән. Бу юлларның авторы аңа икеләтә зуррак эш хакы һәм оҗмах шартлары бәрабәренә кире ВАЗга кайтыр идегезме дип сорагач, директор катгый төстә: «Юк!» дип баш кына чайкады.

* * *

Унберенче бишьеллык зур йөк автомобильләренең Кама берләшмәсенең стабильләшү, проекттагы тулы куәтне үзләштерү, оештыру, идарә итү принципларын ныгыту һәм тотрыклыландыру бишьеллыгы булырга тиеш. Моның өчен нәрсә эшләнә, нәрсә эшләргә кирәк соң? Киләчәктә КамАЗ нинди каршылыкларга очраячак? Бу хакта бүген уйлыйлармы?

ВАЗның промышленностебызга булган күтәренке һәм күп яктан вакытны узып киткән таләпләрен еш кына санга сукмаган булсалар, инде куәтле ВАЗ — КамАЗ чылбыры безнең барлык индустриябезне яңабаштан коруны таләп итә. Акрын булсын, һәрвакытта да кирәгенчә үк булмаска да мөмкин, әмма барыбер яңа материаллар, аппаратура, яңа технология, эш кораллары, тәэминатчылар белән арадашчылар арасындагы элемтәләрнең яңа принципларын булдыруны таләп итә. Һәм промышленностьның барлык тармакларына прогрессив йогынты,— хәтта «басым» дип тә әйтергә мөмкин,— һаман саен тирәнәя бара.

Шуның белән бергә, КамАЗның киләчәктә дә киңәячәге көн кебек ачык. Компетентлы белгечләр фикеренчә, автогиганттан күбрәк файда алу һәм аның тәэминатчы-арадашчыларга бәйлелегең бетерү өчен КамАЗның үз металлургия базасын, шарикллы подшипниклар һәм электр техникасы заводларын салу кирәк. Һәркайсының күләме хәзерге заводлар белән тиңләшерлек булырга тиеш.

...Чаллы әлегә ирләр шәһәре буларак үсә. Анда күпчелек хатын-кызлар хезмәте кулланыла торган җиңел промышленностьның махсус предприятиеләре юк. Бәлки шуңа күрәдер дә 100 мең кешелек КамАЗ коллективының яртысыннан артыграгын хатын-кызлар тәшкил итә. Төп производстволарда хатын-кызларны кем алыштырыр һәм моннан бушаган хатын-кызлар кайда эшли башлар соң? Мондый сораулар көн саен арта бара. Минемчә, «2000 нче елда КамАЗ белән Чаллыны сез ничек күз алдыгызга китерәсез?» дигән темага зур социологик тикшерү үткерелсә, зыянга булмас иде.

* * *

КамАЗ тәҗрибәсе һәм аның сабаклары — барлык мәсьәләләрдә бик күп чыгым таләп иткән һәм кыйммәт түләнгән иҗтимагый байлыгыбыз ул. Әлеге көнгә кадәр информация чараларының да, әдәбиятның да, кинематографиянең дә КамАЗ сабакларын гомумиләштерү белән шөгыльләнгәннәре юк. Бу тәҗрибә югалып калмаска тиеш. Унберенче һәм алдагы бишьеллыкларда зур масштабтагы төзелешләр аз булмас. КамАЗның уңай һәм кайбер тискәре яклары әйбәт сабак булып, оештыру-техник чараларның нәтиҗәлелеген арттырырга ярдәм итәр, материаль һәм мораль югалтулардан саклап калыр иде.

Шунысын да онытмаска кирәк: кайбер геройлар, күренекле төзүчеләр, производствочылар, җитәкчеләр лаеклы ялга да китеп бара. Ветераннарга алмашка башка буын, КамАЗ сынаулары аша узмаган яшь буын килә...

Вахит ШӘРИПОВ.

# ГАП-ГАДИ ХАЛИКОВ

ОЧЕРК

Ул минем күңелемне күптән, әйтергә кирәк, беренче очрашуларда ук яулап алды. Киң җилкәле, ягымлы карашлы кеше ул. Кулны нык кысып күрешә.

Минем игътибарымны яулавына аның тәэсирле итеп сөйләү сыйфаты, тиктормас холкы сәбәп булгандыр.

Бервакыт миңа КамГЭСэнергострой производство берләшмәсенең яңа техника бүлегендә булырга туры килде. Ул чакта үзем төзелештә эшли идем әле.

— Әгәр дә сез,— диделәр анда,— уңган, белемле инженер, производство рационализаторы белән танышырга уйласагыз, металл конструкцияләренең тәҗрибә заводына барыгыз. Автобус белән ярты сәгать. Анда заводның баш конструкторы ярдәмчесе Халиков Венерны табыгыз.

Заводка килдем. Аның производство цехы мине күңелгә дәрт бирә торган хезмәт гөрелтесе белән каршылады.

Заводта биш цех. Һәр цехның үз көне, үз җыры, һәр цех аерым эшли, үз тормышы белән яши. Әмма алар барысы да бер максатка юнәлдерелгән эш белән кайныйлар.

— Сезгә Венер Мөнирович кирәкме? Андый кеше бар, әлбәттә. Ул хәзер, тагаен, үзендә. Әнә анда машинасы тора,— диде миңа беренче очраган кеше. Аның күзләре тиз генә алтын сыман төскә буялган «Жигули» автомобиленә айкап алдылар. Һәм ул сүзен дәвам итте:— Өченче катка күтәрелегез, аны шунда табарсыз.

Ул кем беләндер сөйләшә иде. Шулай да миңа игътибар итеп алды. Әлеге әңгәмәдәше белән хушлашкач, минем яныма килеп туктады. Ярый әле, бик вакытлы килгәнмен дип уйлап алдым.

— Юк, хәзер мөмкин түгел,— диде ул, бераз уңайсызлана төшеп.— Эш вакыты лабаса, сөйләшеп утыру килешми.

— Ә эштән соң?

— Анысы башка нәрсә. Монда кат-кат килеп интекмәгез. Өебезгә рәхим итегез.

Ул миңа бер кәгазь кисәге сузды.

Ниһаять, мин алар квартирында. Эш өстәле китаплар белән тулы. Төрлесе бар: техник, фәнни, нәфис китаплар. Чынаякларга чәй ясый-ясый ул миңа зур кызыксыну белән сөйли башлады:

— Заводның тәрәзә рамнары ясау планы елга ике мең тонна. Рамнарны торба конструкцияләр цехы хәзерли. Нигездә цех планны зур көч түгеп үти. Авырлык белән. Кәефне кыра. Эретеп ябыштыру һәм продукциянең сыйфаты да... канәгатьләндерми. Рамнар начар, туп-туры әйтәм. Эретеп ябыштыру тиешенчә түгел. Ачыграк әйтимме? Тәрәзә рамнары хәзерләгәндә торба белән лентаны бер-берсенә ябыштырганда өелмә күп була. Проектта шулай каралган. Эретмә өелмәсе суынганда төп металл кыскара. Аннан соң металл янганда, кирәгеннән артык эри дә...— Ул чәй эчеп алды.— Күп уйландым, эзләндем. Эретеп ябыштырганда чыккан өелмә минем шәхси дошманыма әйләнде. Кеше итәм мин сине, мәйтәм. Билгеле, эчтән генә инде... Проектны тикшерүдән башладым. Ревизия? Әйе, ревизия. Эшләнмәнең ныклыгы җилгә каршы торуда кирәгеннән артык итеп билгеләнгән.

— Проектны тикшереп чыгу бик күп вакыт алгандыр ич?

— Төннәр буе утыргаланды. Шунсыз мөмкин түгел иде. Әмма тикшереп чыктым. Әнәсеннән җебенә тикле.

— Шуннан соң?

— Эретмә өелмәсенең бер өлешен киметтем дә лабораториядә тикшердем. Әйбәт чыкты. Тик...

Венер Мөнировичның уйлап тапканын заводтагы Техника советы белгечләре якламый. Торба белән лента тоташкан урыннарның үзгәрүен хуп күрмиләр. Эшләнмәнең ныклыгы кимиячәк, ә бу хәл бер-ике елдан соң күңелсезлекләр китереп чыгарыр, җилгә чыдамыйча таралачак диләр. Монда нәрсәдер бар дип, уйга калганнары да була. Тәкъдимне заводның баш инженеры Михаил Константинович Белов белән баш механик Валерий Дмитриевич Пустынцев яклап чыгалар.

Техника советы Венерга Мәскәүгә барырга тәкъдим итә. Ул анда Промышленность төзелеше проекты институтында үз тәкъдимен кабул иттереп, производствога кертү хокукы алырга тиеш була. Четерекле эш, әйтүе генә җиңел. Шуның белән тынычланып калалар.

Ул туктамый. КамГЭСэнергострой белгечләренә бара. Берләшмәнең яңа техника бүлеге башлыгы Анатолий Сергеевич Романенко икенче көнне үк заводка килеп җитә. Җентекләп тикшерә дә идеяне яклап чыга.

— Яхшы фикер!— дип шатлана КамГЭСэнергостройның баш эретеп ябыштыручысы Виктор Яковлевич Шипин да.— Мин ябыштыру өчен күпме ярымавтоматлар бирәм. Исәпләсәң, елына тау хәтле өелер.

Тәҗрибәле белгечләрнең яклавы авторга көч өстәп җибәрә. Ул тәкъдиме белән Чаллыдагы Промышленность төзелеше проекты институтына килә. Анда сынау өчен бер үрнәк әзерләргә кушалар. Мәскәүдән белгечләр чакыртырга булалар.

...Көтелмәгәндә телефон шалтырый. Промышленность төзелеше проекты институты филиалының бүлек начальнигы икән.

— Венер Мөнирович кирәк.

— Тыңлыйм.

— Хәерле көн! Сезнең эшне карарга Мәскәүдән проектның баш инженеры килде. Сез әзерме?

— Әзер.

Ул каушап калды. Тәҗрибә үрнәге! Аны кайдан алырга? Эшләргә өлгермәде ич әле. Ничек өлгертергә? Бер тәүлек вакыт бар.

— Егетләр,— диде ул бригадага килеп.— Үрнәк кирәк. Иртәгә тикшерергә киләләр.

Эшчеләр барысын да белә иде. Алар эшкә керештe.

Комиссия Венер Мөнировичның тәкъдимен яраклы дип тапты. Аның кабул ителүенә беркетмә язылды.

Баш инженер, әлеге беркетмәне тотып, директор бүлмәсенә атылып барып керде.

— Николай Иванович!— диде ул, кабалана-кабалана.— Менә нинди беркетмә. Халиков тәкъдиме!

— Халиков тәкъдиме? Аңа кем кушкан?— диде директор.

— Үзе.

Завод директоры тыныч холык-фигыльле, әмма гаярь кеше. Беркетмә белән танышкач, ул андагы фикерне хуплап бәяләде. Бәяләрлек тә. Рамнарның бар периметрында баш архитектор ризалыгы белән ябыштыру ялгаулары чистартыла. Өелмә күренмәс булып кала, стена белән каплана. Эретеп ябыштырганда була торган эчке җөйләрне дә чистарту күпкә кими. Элек ул 60 миллиметрлык иде, хәзер нибарысы ун-унбиш миллиметр. Шулай итеп, завод рамнарны яңача эшли башлый.

— Моңа күпме вакыт китте соң?— дип сорадым мин.

Венер Мөнирович уйга калды. Күрәсең, ул нәрсәнедер әйтмәскә чамалый, нәрсәнедер әйтергә кирәклеген исәпләп тора. Ниһаять, ул миңа бер график сузды:

— Шушыннан аңларсыз.

Документ яңалыкның нибарысы бер ай эчендә тормышка ашуын сөйли иде.

Инде чәй суынган иде. Беркавым тып-тын утырдык, һәркайсыбыз үз уена чумган иде. Тынлыкны мин боздым:

— Бу тәкъдимегез заводка күпме файда китерде соң?

— Эффект яхшы,— диде ул.— Хәзер рам ясауга электр энергиясе һәм кислород ике мәртәбә ким тотыла.

Заводның баш экономистында моның төгәл саннары да бар. Ул цехта җитештерелгән продукциянең үзкыйммәте нык кимүе, хезмәт җитештерүчәнлегенең бер ярым тапкыр артуы хакында сөйли.

— Кыскасы,— ди ул,— завод яңача эшләү нәтиҗәсендә елга йөз дә ундүрт мең сумлык файда ала. Венер Мөнирович — ул Венер Мөнирович инде! Шушы ачышы өчен ул ел дәвамында 1662 сум акчалата бүләк алды. Цехта һава да чистара төште, эретү утыннан элек күп төтен чыга иде, хәзер нык кимеде.

— Инде нишлисез?— дип сорадым мин Венердан.

— Шул ук эшнең технологиясен камилләштерәсе бар. Ябыштырганнан соң калган җөйләрне беленмәслек итәргә кирәк. Килеп чыкса, хезмәт җитештерүчәнлеге тагын да артачак, сыйфат та яхшыра.

Икенче бер вакытта ул шушы ук хакта:

— Рамнарның өлешләрен ясауны автоматлаштырырга кирәк әле. Эшкә керештем. Киләсе елда җыелма ябыштыру цехындагы кайбер нәрсәләрне исәплисем килә. Ул цех металл эшкәртү цехы белән бәйле. Бер цехта эш алга китсә, аның өчен икенче цехның материал хәзерләп җитештерә алмавы ихтимал. Хезмәт җитештерүчәнлеген үзара бәйле цехларда тигез күтәрү сорала. Кечкенә нәрсә түгел бу, четерекле мәсьәлә.

Ул озак сөйләде. Эштәге кимчелекләрне дә искә алды. Ул аларны бетерү юлларын эзли. Ә юл — маяксыз, тик ул ялгыз түгел. Компасы да бар — аек акылы һәм ихтыяр көче.

Чаллы заводлары шушындый — Халиков кебек гап-гади кешеләре белән көчле, әнә шундый новаторлары белән алга бара, үсә, ныгый. Күтәрелештә коммунист инженер Венер Халиковның да шәхси өлеше һәм халәл көче бар, һәм ул кечкенә түгел.

Рубин ФӘТХУЛЛИН,
инженер
Чаллы

## Нияз Хәкимуллин

# АРКТИКА КИҢЛЕКЛӘРЕНДӘ

ЮЛ ЯЗМАЛАРЫ



Архангельск диңгез портында 150 дән артык причал бар. Барысы да илебездә иң зурлардан санала. Хәзерге заманның иң эре диңгез корабларын йөзәрләп кабул итә алалар. Мондыйлар дөньяда бик аз. Чакрымнарга сузылган ул причалларга Куба, Германия Федератив Республикасы, АКШ, Англия, Һиндстан, Вьетнам... флаглары астында океан суднолары килеп туктый һәм кире китә. Бирегә урман һәм агач материаллары алырга киләләр.

Һәр җәйне аннан озак һәм мавыктыргыч сәяхәткә комфортабельле пассажир теплоходы Арктика киңлекләренә юлга чыга.

Мин шушында килдем, боз белән капланган диңгез-океаннар аша кызыклы бер сәфәргә чыгарга булдым.

Төньяк Двина елгасы буйлап барганда Ак диңгез бик якын. Нибары 30 чакрым! Шунлыктан Архангельскины «Арктика капкасы» дип атыйлар. Шәһәр уртасындагы диңгез вокзалында «Татарстан» дип язылган теплоход та бар. Башка кораблар янында ул аеруча мәһабәт күренә — аккошны хәтерләтә. Күләме дә таңга калырлык. Озынлыгы 100 метрдан артык! Биеклеге — 16 метр, биш катлы йортка тиң!..

Шул теплоходта без Арктикага сәяхәткә чыгабыз. Юлыбыз бик үк гадәти түгел: туган илебезнең төньяк ярлары буйлап үтәсе.

Иң әүвәл шушы катлаулы диңгез юлыннан алып баручы капитан белән танышабыз. Анатолий Анатольевич Окороков ул. Идел егете, Куйбышевта туып үскән. Иллене дә тутырмаган ир уртасы. Капитанның чәчен көмеш сызыклар чуарлый. Моңа бер дә гаҗәпләнерлек түгел. Иң кыен шартларда утыз еллап инде ул диңгез-океан киңлекләрендә йөзә. Идарә пульты каршысына ул утырган теплоходлар Һинд һәм Тын океаннарының җылы суларында да, Ак, Баренц, Карск, Чукот диңгезләренең, Төньяк Боз океанының салкын суларында да булган.

Капитан — дөньяны күп күргән кеше. Туристларны Финляндиягә, Норвегиягә, Даниягә алып барган. Польша һәм Германия портларын да яхшы белә. Берничә тапкыр экваторны үтеп чыга, аның теплоходлары акулалар арасында йөзә, Африка һәм Австралия портларына туктый, Антарктиданың бозлы ярларыннан үтә.

— Безнең теплоход — Төньяк диңгезе пассажир флотының флагманы, — дип сөйли ул кораб турында. — 1963 елда А. А. Жданов исемендәге Ленинград судно төзү заводында эшләнгән. Егәрлеге дүрт мең ат көченә тиң. Сәгатенә 30 километрга кадәр юл үтә. Аның каюталарына 250 кеше урнаша ала. Уңайлы бүлмәләрдә һава алышынып тора.

Пассажирларның туган-тумачалары, күргән-белгәннәре белән сөйләшәселәре килсә, радиотелефон бар. Безнең радист Советлар Союзының теләсә кайсы шәһәре белән элемтәгә керә ала. Туган якларыбыздан никадәр ерак булсак та, шәһәр телефоныннан сөйләшкән кебек ачык ишетелә. Сәяхәтчеләр, газеталар укып, дөньядагы иң соңгы вакыйгалар белән хәбәрдар торалар. Газета материалларын телетайп аша алабыз.

Теплоходның тагын бер уңайлыгы — мунча. Кнопкага гына басасы. 15 — 20 минуттан мунча 120 — 130 градуска кадәр җылына. Теләгән кадәр чабын!

Анатолий Анатольевичның мавыктыргыч әңгәмәсен һәм акчарлаклар җырын тыңлап, Төньяк Двина буйлап Ак диңгезгә килеп чыкканыбызны сизми дә калганбыз.

Уң якта биек-биек дулкыннар арасыннан ком утравы Мудьюг күренгәләп китә. Җәфа чигү һәм үлем атавы ул. Үзе әллә ни зур да түгел. Ак диңгездә йөзгән һәр кеше аны яхшы белә. Ерак юлларга чыгучы, чит илләрдән туган ярларыбызга кайтучы кораблар, аңа сәлам биреп, гудок кычкыртып узалар.

Мин дә без дә беренче мәртәбә «Татарстан»ның кычкыртуын ишетәбез.

... Теплоходыбыз Мудьюг ярында туктала. Мондагы һәр карыш җирне кан сугарган. Чәнечкеле тимер чыбыклар белән әйләндереп алынган урыннар, каравыл каланчалары, җиргә күмелә язган бараклар — безнең көнгә кадәр утрауның авыр үткәнен саклаучы телсез шаһитлар.

1918 ел башында Совет властен танырга теләмәгән Антанта җитәкчеләре Европаның бөтен төньяк өлешен яулап алу өчен көч туплыйлар. Мартта Англия крейсеры Мурманскига десант ташлый. Аның артыннан Франция һәм Америка крейсерлары килә. Июльдә интервентлар Архангельскига таба якынлашалар. Шәһәрнең оборона куәтен ныгыту өчен күп кенә чаралар күрелә. Коммунистларны һәм эшчеләрне хәрби эшкә өйрәтү башлана. Архангельскины диңгез ягыннан саклауда бердәнбер терәк булган Мудьюг оборонасына аерым игътибар бирелә.

Ләкин көчләр тигез булмый. Атауда туп тавышлары тынгач, Архангельскига юл ачыла. 2 нче августта кичке алтыда шатлыгыннан ни эшләргә белмәгән шәһәр буржуазиясе интервентлар десантын каршылый.

Архангельскига басып керүгә өч атна дигәндә, губерна төрмәсе кулга алынучыларның барысын да сыйдыра алмый башлый. Дошман аларны күпләп шәһәрдә калдырудан да курка. Шунлыктан 1918 елның август ахырында Мудьюгта хәрби әсирләрне тоту өчен беренче концентрация лагере ачалар. Утрауга эләккән кеше тере мәет була, яшәү сәләтен югалта. 23 нче августта бирегә 134 хәрби әсирне китерәләр. «Хәрби әсирләр өчен кагыйдә»не аз гына бозган өчен дә үлем җәзасы бирелә. Эш көне 12 сәгать. Азык-төлекне җан асрарлык кына биреп, мөмкин кадәр күбрәк эшләтү илбасарларның катгый таләбенә әверелә. Әсирләрне күпләп атып үтерүләр башлана.

Без бер агач баракны карап йөрибез. Ул 100 — 150 кешегә исәпләп төзелгән булса да, анда 300—350 ләп хәрби әсир тотканнар.

Әсирләргә кул-битләр юу урыны да эшләнми. Пычракка, тиргә, канга баткан киемнәре түзми, чери.

Барак янында лазарет төзелә. Авырулар анда әләгүдән куркалар, баракта үлүне кулайрак саныйлар. Лазаретта үлми калган әсирләр аннан аяк-куллары өшегән хәлдә чыгалар. Монда тәүлек саен унарлап кеше үлә. Концентрация лагерыннан өч матрос качкач шартлар тагын да катгыйлана. Карцер куллана башлыйлар. Тирәнлеге өч метрлы шул чокыр тереләр өчен бозлы кабер була. Мудьюг утравында совет кешеләре 13 ай буена җәфа чигә. Интервентлар бөтенләй гаепсез меңнәрчә кешеләрне аталар, газаплап үтерәләр.

Большевиклар монда көрәшне туктатмыйлар. Алар әсирләрнең качуын оештыралар. Алар 1919 елның 15 нче сентябрендә атауда баш күтәрәләр, илле әсир качып китә.

1958 елда утрауда интервенция корбаннары истәлегенә һәйкәл ачыла. Аның итәгендә һәрвакыт чәчәкләр.

... Безнең сәяхәт дәвам итә. Ак диңгездә — ак төннәр! Гаҗәеп матур күренеш. Бөтен тирә-як көмеш сыман ялтырый. Әфлисун төсле кояшны баш турысына элеп куйганнар диярсең. Йолдызлар һәм ай күренми.

«Татарстан» теплоходы, Ак диңгезнең салкын суларын ярып һәм үзе артыннан көчле дулкыннар калдырып, безне XV гасырга — Соловки монастырена алып килә. Иртәнге томан пәрдәләре аша крепость, экияттәге кебек, диңгез төбеннән калкып чыккан зиннәтле сарай шикелле күренә.

Соловки — дулкынландыргыч, мәһабәт һәм шул ук вакытта моң-зарлы урын ул. «Соло» карель телендә — «куе урман», саамча «урманлы утрау» дигән мәгънәне аңлата. Исеме җисеменә туры килә. Утраулар урман белән капланган.

1590 — 1593 елларда, рус-швед сугышы барган көннәрдә, диңгездә дошманның җилкәнле көймәләре күренгәли башлый. Монастырьдагы ир-ат хәрби эшкә өйрәтелә. Диңгездән кинәт һөҗүм итү куркынычы монастырьны хәрби гарнизонга әверелдерә. Аның тарихында чиркәүнең бүленүе чоры мөһим вакыйга булып кала. Бу XVII гасыр уртасына туры килә. Һавалырак холык-фигыльле һәм фанатик патриарх Никон гыйбадәт кылу китапларына һәм чиркәү йолаларына үзгәрешләр кертә. Руханиларның күбесе Никонга каршы төшә. Моңа кайбер монастырьлар, шул исәптән Соловки монастыре да кушыла. Раскольникларны эзәрлеклиләр. Соловки монастырена яңа китаплар китерәләр. Тик монахлар алардагыча гыйбадәт кылудан баш тарталар. Патша Соловкига гаскәрләр җибәрә. Монахлар буйсынмый. Алар таш стеналар эченә кереп бикләнәләр, бирелү турындагы таләпкә җавап итеп, туксан туптан ут ачалар. Монастырьны камап алалар. Шул хәлендә ул сигез елга якын тора. Монастырьны саклауда Степан Разинның бирегә сөрелгән казаклары зур роль уйный. Алар, оборона оештыруны үз кулларына алып, монастырьны саклыйлар. Хәрби кирәк-яраклар һәм азык-төзек кимегәннән-кими бара. Шулай да крепость бирелми. Феоктист атлы бер монахның хыянәте нәтиҗәсендә генә монастырьны патша гаскәрләре яулап ала. Бу вакытта да әле анда 7 — 10 елга җитәрлек иген-икмәк, ике еллык май запасы һ. б. була. Әлеге сатлык җан патша гаскәрләренә таштан эшләнгән яшерен юлны күрсәтә. 1676 елны 22 нче январьда укчылар отряды, шул яшерен юлдан монастырьга кереп, капкаларны ача. Искәрмәстән һөҗүм итүче гаскәрләр баш күтәрүчеләрне кулга алалар. Бәреп керүчеләр ярым йокы хәлендәге арыган каравылны үтереп бетерә. Монастырьны саклаучыларның барысы да диярлек кыска һәм каты сугышта үлә. Исән калган алтмыш кешенең егерме сигезе шул чакта ук, калганнары бераз соңрак җәзалап үтерелә.

1668—1676 елллардагы Соловки восстаниесе, Степан Разинның крестьяннар сугышыннан соң, иң куәтлесе була. Восстание ул елларда Соловки монастыренең зур көчен күрсәтә. Әмма крепость шушы вакыйгадан соң шактый озак аякка баса алмый. Аның куәте һәм көче, байлыгы акрын арта. Моның белән хөкүмәт үзе дә кызыксынып тора. Петр I патша монда үзе ике тапкыр килә.

Ак диңгез аша Европа илләренә юл ачылгач, монастырь берничә мәртәбә хәрби куркыныч астында кала һәм Россиянең төньяк дошманы, Швециядән саклануында куәтле крепостька әйләнә. Шушы вакытта рус патшалары монастырьга тәреләр һәм кыңгыраулар түгел, туплар һәм дары ташыта торган булалар. Крепость буларак, ул авыр сынаулар үтә.

1854 елгы Кырым сугышы чорында инглизләр һөҗүм иткәч, монастырь күп кенә авыр көннәр кичерә, үз диварларының ныклыгын сыный. Монастырьга берничә шәһәрне җимереп ташларлык снаряд ыргыталар. Ул нибары сигез пушка белән коралланган була. Дошман кораблары 70 орудиедән аталар. Монастырьга әллә ни зыян килми, инглизләрнең суднолары берни эшли алмый, хурлыклы рәвештә кире кайтып китә.

Соловки монастырена күп гасырлар дәвамында каторжниклар сөреп торалар. Ләкин андагы төрмәләр турында Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр бик аз кеше генә белә. Моны руханилар һәм власть сер итеп саклый. Иң коточкычы — бер кешелек яшерен камералар. Аларга башлыча патша строе дошманнарын, декабристларны ябалар. Toткыннар төрмәдә 20 — 30 ел һәм аннан да озаграк утыра.

Утрауларның табигате күңелдә зур соклану уята. Бозлар монда Скандинавия ярымутравы ягыннан ике тапкыр һөҗүм итәләр. Бозлар утрауларда зур-зур йомры ташлар калдырып чигенәләр. Алар ташлар тезмәсе булып та, баскыч-баскыч булып та яталар. Атауларда биш йөздән артык күл бар. Күбесе бер-берләре белән тоташкан. Борынгы заманда яшәгән монахлар шул каналлар аша күлдән-күлгә күчеп йөргәннәр, утрауларга йөк ташыганнар.

Култыклар һәм бухталар илебезнең бу почмагын матурлап һәм бизәп торалар.

Соловкиның яр буе суларында, Ак диңгездә, плантацияләр сыман, су үсемлекләре үсә. Аларны җыеп киптерәләр дә порошок хәленә китереп уалар. Эшкәртелгән су үсемлекләре азык промышленносте һәм медицинада, тукымаларны маңу өчен буяулар эшләүдә кулланыла.

Утрауларын үсемлекләр дөньясы бик бай: биш йөз төрле! 40 — 50 метрга кадәр үскән чыршылар аеруча сылу. Иң матурлары ап-ак каеннар, әлбәттә. Атауларда алма агачы, чикләвек куагы, әрәңге дә үсә, чия, гөлҗимеш, балан һәм миләш чәчәк ата. Укучылар кыяр һәм помидор, хәтта карбыз һәм кавын да үстерәләр!

Секир тавына килеп җиткәнче үк, аның түбәсендәге ак бина күзгә ташлана, Тау башына Ак диңгездәге иң зур маяк куелган икән. Янәшәсендә, бик биектә, диңгезне күзәтү мәйданы. Гадәттә бирегә Соловки белән саубуллашырга киләләр. Без дә утраулар яныннан кул изәп үтәбез. 1974 елда бу атаулар тарих-архитектура һәм табигать музей-заповедингы дип игълан ителә.

«Татарстан» алга бара. Без Ненец милли округының башкаласы Нарьян-Мар шәһәренә килеп җиттек. Диңгез порты причалыннан яшь калага күз салабыз. Предприятие, мәктәп, кинотеатрлар, магазин, башка культура-көнкүреш биналары, торак йортлар моннан ях-

шы күренә. Мәңге туң җир тундрада нинди шәһәр калкып чыккан! Моннан өч дистә ел элек бүрәнәләрдән салынган берничә йорт булган урында Нарьян-Мар кебек индустрия һәм культура үзәге төзелү тәэсирләрне тагын да баета төшә.

Патша Россиясенең тундрадагы почмакларында, В. И. Ленин билгеләп үткәнчә, патриархальлек, ярым кыргыйлык һәм чын мәгънәсендә кыргыйлык хөкем сөргән. Төньякта яшәүче төп халык — ненецларны рус купецлары һәм гаскәр башлыклары изгән, аларга авыр ясаклар салган. 18 яшьтән 50 яшькә кадәрле эшкә яраклы бөтен халыкны талыйлар, башка сыймаслык налоглар түләргә мәҗбүр итәләр. Ясак өчен җәнлекләрнең затлы һәм кыйммәтле тиреләрен генә алалар. Әлбәттә, бу хәл җирле халыкта ризасызлык хисләре уята. XIX йөзнең беренче яртысында Вавле Ненянга җитәкчелегендә восстание күтәрелә. Ненецларның Робин Гуды, байларның болыннарын, мал-мөлкәтен алып, ярлыларга бирә. Вавле халыкны рус патшасына ясак түләүдән баш тартырга чакыра. Властьлар аны кулга алалар, ул төрмәдән кача һәм 1841 елда 400 кешедән торган отряды белән Обдорск шәһәренә — хәзерге Салехардка килеп җитә. Баш күтәрүчеләрнең җитәкчесен алдап, властьлар Вавле һәм аның көрәштәшләреннән үч алалар. 1831 елда Себердә ирекле сәүдә рөхсәт ителә. Тире сәүдәгәрләре, балга ябышкан чебеннәр кебек, ненец җиренә ябырыла. Байлар аучы, болан караучы һәм балыкчы ненецлар тормышына цивилизация төсмере кертүне максат итеп куймыйлар, аларны бөлдерәләр. Җирле халык төрле авырулардан күпләп үлүгә дучар ителә, укый-яза белми.

Бөек Октябрь социалистик революциясе дулкыны Петроградтан ерак төньякка да килеп җитә. Яшь Совет республикасы боланчылыкны һәм кооперацияне үстерүдә зур эшләр башкара башлый. Халык санын алу үткәрелә, 1929 елның 15 июлендә Ненец милли округы төзелә, җирле идарә итү органнары оештырыла.

Ул вакыттан бирле күп нәрсәләр үзгәрде. Хәзер Нарьян-Мар илебезнең урта полосалары шәһәрләренә хас сыйфатлар белән яши. «Арктика» кинотеатрында атна-ун көн чамасы гына башкала игъланнарында күренгән фильмнар бара. Киоскларда — бүген иртән Мәскәүдә чыккан газета-журналлар.

Ненец җире көмешсыман төлке, чәшке үрчетүче җәнлек совхозлары белән дан тота. Округка СССРның Европа төньягындагы боланнарның яртысына якыны туры килә. Шуңа күрә ветеринария белгечләренә ихтыяҗ зур. Алар Нарьян-Мар зооветеринария техникумнарында укыйлар.

Бу якның табигый байлыкларын үзләштерү көннән-көн яңа офыклар ача. Бораулаучы-эзләүчеләр ненецлар җирендә нефть һәм газ тапты. Тундрадагы вышкалар — иҗат итү нәтиҗәләрен, кешенең табигать көчләреннән өстен булуын күрсәтеп тора.

Биредән Диксон да ерак түгел инде — аның ярларын күрәбез.

Диксонның тарихы гаять бай һәм шактый кызыклы.

Үткән йөзнең алтмышынчы елларында Төньяк диңгез юлларын үзләштерү энтузиасты — Себердәге алтын промышленносте хуҗаларының берсе М. К. Сидоров була. Ул Европадан Себер елгаларына йөзү проектын эшли, матросларны бүләкләү өчен шәхси мөлкәтеннән 14 мең сум акча бирә, диңгездән Енисей елгасы тамагына беренче булып килә. Ул патша хөкүмәтенә Төньяк диңгез юлларын ачу өчен экспедиция оештырырга үз акчасын тәкъдим итә. Хөкүмәт моннан баш тарткач, Сидоров, Англиягә, Финляндиягә, Норвегиягә һәм Швециягә барып, үз фикеренә ирешү йөзеннән лекцияләр укый. 1868 елның көзендә Швециядә танылган галим һәм Төньяк котыпны өйрәнүче А. Э. Норденшельд белән таныша. Галимнең Шпицберген-

нан кайткан чагы. Алар дуслашалар. Норденшельд Енисей тамагына баручы экспедициягә җитәкчелек итәргә ризалык бирә. Себер сәүдәгәре һәм швед капиталисты Оскар Диксон акчасына экспедиция оештырыла. 1875 елда «Превен» дигән җәнлек аулый торган кечкенә генә җилкәнле көймә юлга чыга. Норденшельд белән ике ботаник, ике зоолог һәм команданың 17 кешесе бара.

Маточкин шары районында сәяхәтчеләр көчле давылга һәм калын-калын бозларга очрыйлар. Норденшельд, Югор шары аша үтеп, Карск диңгезенә килеп чыга, Ямал ярымутравын әйләнеп үткәч, Енисей дугасына барып җитә. Енисей култыгына кергәндә уңайлы бер гаваньга игътибар итә һәм аны үзенең бай ватандашы Диксон исеме белән атый. Соңга таба утрауны да Диксон утравы дип йөртә башлыйлар.

Диксонда тормыш кырыс һәм романтикага бай. Кышын бередә өч айга якын котып төннәре булып ала. Поселокка чыршы бәйрәменә ак төлкеләр генә түгел, ак аюлар да рәхим итә.

Түгәрәк ташлар белән капланган Диксон урамнарына такта тротуарлар җәелгән. Бер адым читкә атладың исә, кыска җәйнең эссе көннәрендә өсте бераз эрегән мәңге туң җир пычрагына батасың. Тротуарлар белән торак йортлар арасына рәшәткәләр тотылган. Җәйләрен аларның кирәге юк. Диксонда буран купкан котып төннәрендә алар кешеләрне поселокта адашып йөрүдән саклый.

Диксон — Таймыр милли округының административ үзәге. Поселоктагы йортларга су кертелгән, алар үзәктән пар белән җылытыла. Анда яшәүчеләр җәен-кышын яшелчә, җиләк-җимеш белән тәэмин ителә. Аларны зур җирдән китерү белән бергә, теплицаларда да үстерәләр. Ярдәмче хуҗалыкларда ит һәм сөт җитештерелә, помидор һәм кыяр үстерәләр Диксонда моряклар, очучы, метеоролог, сейсмолог, радист, врач, укытучы, техниклар — ике меңнән артык кеше яши. Төньяк диңгез юлларында судноларның йөрешен тәэмин итү белән бергә, алар Арктиканы өйрәнүдә зур фәнни эш алып баралар.

Диксон үзе зур түгел. Әмма тарихи урыннар һәм һәйкәлләр биредә бик күп. Кыялардан күтәрелгәндә, зур бер ташка уеп ясалган тәрегә күз саласың. Вакыт үтү белән ул кара-коңгырт төскә кергән. Менә аның тарихы: 1918 елның 18 июлендә ике мачталы «Мод» корабле Норвегиядән Төньяк Боз океанына юлга чыга. Экспедиция җитәкчесе, Норвегиянең танылган тикшеренүчесе Руаль Амундсен, бер кыш кышлап, Азиянең төньяк ярлары буйлап үтәргә уйлый. Бер ай дигәндә ул Карск диңгезен кичә. 31 нче августта «Мод» Азиянең төньяктагы иң ерак ноктасы булган Челюскин борынын әйләнеп үтә. Таймыр ярымутравының көнчыгыш ярларында судно йөзеп үтә алмаслык бозлар арасына килеп эләгә. Амундсен, утраулар янына килеп, судноны кечерәк кенә бухтага кышлатуга куя. Соңыннан бу урын Мод гаване дип атала. Кышлау бер ел дәвам итә. Ике матрос — Тессем һәм Кнудсен — туган илләренә кайтырга телиләр. Амундсен алар белән хат-хәбәрләр җибәрә. Енисей култыгына кадәр Тессем гына барып җитә, әмма ул Диксонга аяк баса алмый. Туңган матрос, радиомачталар буенча юнәлеш тотып, боздан түше белән шуыша-шуыша тәмам талчыга. Кышлаучыларның өйләренә берничә чакрым гына калгач үлә. Аның гәүдәсен рус тикшеренүчесе Никофор Бегичев табып ала. Аның кесәсендә алтын сәгать, компас һәм Амундсенның хат-хәбәрләре була.

Бөек Ватан сугышы елларында Төньяк диңгез юлларының әһәмияте тагын да арта төшә. Арктика магистральләре буйлап фронт өчен хәрби йөкләр төягән суднолар йөзә. Фашистлар командованиесе Төньяк диңгез юлының нинди роль уйнаганын яхшы аңлый һәм

Арктикада совет корабларының йөрешен туктату өчен «Вундерланд» операциясе кора. Фашистлар безнең ил өчен шушы авыр вакытта, төньяктагы су юлын өзеп, Карелия фронтын икмәк һәм корал белән тәэмин итүне туктатырга, Карск диңгезендәге бозваткыч флотны юкка чыгарырга уйлый. Бу эш «Адмирал Шеер» линкорына йөкләтелә. 1942 елның августында линкор Карск диңгезендә «Сибиряков» бозваткычы белән очраша. Гитлерчылар безнең судно экипажына әсирлеккә төшәргә кушалар. Җавап итеп, совет моряклары дошман корабына ут ача. Көчләр тигез булмый, әлбәттә — «Сибиряков» батырларча һәлак була.

27 август төнендә фашистлар линкоры Диксон бухтасына үтеп керә. Анда илебезнең транспорт суднолары тора. Диксонның барлык халкы кулына корал ала, сугышка хәзерләнә. Лейтенант Николай Корняков командалыгындагы яр буе батареясы дошман кораблена ут ача. Фашист снарядлары тигән «Революционер» пароходына ут каба. Моряклар ут белән кыю көрәшә һәм янгынны сүндерә. Судно дошман снарядлары эләгә алмаслык урынга күчерелә. Фашистлар линкор утын «Семен Дежнев» пароходына юнәлтәләр. Ул портны һәм анда торучы судноларны каплап тора, койрыктагы тупларыннан ата. Безнең снарядлар линкорга туп-туры килеп эләгә дә янгын чыга. Төтен белән капланган «Адмирал Шеер» үз позициясеннән китә. Ләкин берничә сәгатьтән ул Диксонның икенче ягыннан килеп чыга. Яр буе батареясы һәм судноларо тагын дошман белән бәрелешкә керә. «Адмирал Шеер» бу юлы инде су төбенә китә. Лейтенант Корняков оста командалык итүе өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. Карск диңгезенә фашистларның су асты көймәләре килә, алары да базаларына кире әйләнеп кайта алмый. Шулай итеп, гитлерчыларның Диксонны юкка чыгару уе чәлпәрәмә килә. Порт сугыш барышында фронтка берөзлексез ярдәм итеп тора.

Бу җиңү күп корбан бәрабәренә яулана. «Семен Дежнев» корабындагы күп кенә кешеләр, зур батырлык күрсәтеп, яу кырында мәңгегә ятып кала. Диксон утравында аларның якты истәлегенә һәйкәл куелган. Туганнар каберлегендәге мемориаль тактада менә нинди язу: «Монда дошман белән тигезсез бәрелештә каһарманнарча һәлак булган Ульянов И. Н., Давыдов В. И., Карачев А. М., Мойсюк Г. И., Хәйруллин Г., Суслов В. И., Борисихин А. П. күмелгән». Мәңгелек дан аларга, туфраклары җиңел булсын...

«Татарстан» Енисей култыгыннан Себернең иң зур елгасы тамагына таба йөзә. Диңгезнең якынлыгы үзен нык сиздерә. Култыкның табигате Карск диңгезендәге кебек кырыс. Елга буйлап югары күтәрелү белән, ул йомшара бара, яр буенда балыкчы бригадалары, торак урыннары күренгәли.

Енисей — илебезнең иң куәтле елгасы. Җирле халык телендә аның исеме «күп су» дигән мәгънәне аңлата. Исеме җисеменә туры килә. Ул — озынлыгы һәм куәте белән җир шарында — алтынчы, Советлар Союзында иң күп сулы елга. Урыны-урыны белән аның киңлеге 50 чакрымга җитә. Ул бик тирән. Эре диңгез суднолары аның буйлап Игаркага кадәр күтәрелә ала.

Мин Енисейда беренче тапкыр гына түгел. Саяно-Шушенское ГЭСы төзелешендә булдым, Красноярск су электр станциясе корылышын һәм бирегә Енисейны йөгәнләүне күрдем, тиз йөрешле «Метеор»ларда йөздем, аның салкын суында коендым. Әмма диңгезгә килеп тоташа торган урында аның куәте аеруча нык сизелә. Енисейны тикмәгә генә «Океан энесе» дип атамыйлар икән. Заманында А. П. Чехов та елганы түбәнге өлешендә «аның көчен һәм яшьлеген кая куярга белмәвен» үзе күргән бит.

Без шактый озак йөзәбез. Энә елганың уңъягындагы комлы ярда ике юрта — киездән ясалган йортлар күзгә чалына. Җирле балыкчылар тора, күрәсең. Үтенечебезне тыңлап, капитан судноны рейдка куя. Резин итекләр киеп, ярга чыгабыз. Киез йортларның хуҗалары ненецлар безне икмәк-тоз белән каршы алдылар. Без — аларның кадерле кунаклары. Балыкчылар ерак, җир читендә диярлек яши, алар янына сирәк киләләр. Якын-тирәдә шәһәр-авыллар да юк. Шулай да тормышлары тулы канлы. Дөньяның бар вакыйгаларыннан хәбәрдарлар. Үзәк газета-журналлар килә, радио сөйли. Уку елы башлангач, балалары елганың теге ягындагы Усть-Енисей районына күчә. Анда мәктәп һәм интернат, Усть-Порт поселогында «Октябрьский» совхозы урнашкан.

Балыкчылар бригадиры Константин Романович Ямкин сүзгә җор кеше булып чыкты. Тормышларын, эшләрен мавыктыргыч итеп сөйли. Иртән тоткан балыкларын күрсәтә. Ниндиләре генә юк аларның!

— Кышын нишлисез? — дип кызыксынабыз.

— Ауга йөрибез. Безнең якта көмешсыман төлке, тиен, куян һәм кыр тавыклары бик күп.

Кунакчыл хуҗа безне чумга — киез ябулы торагына әйди. Идәне такта, уртада — тимер мич. Җылы юрганнарны пөхтәләп төреп куйганнар. Төньяк салкыннары алар өчен берни түгел! Торак тирәсендә Константин Романовичның балалары кайнаша. Олы кызы Клава унынчыга күчкән. Ул — хуҗалыкта әтисенең иң якын ярдәмчесе. Никита, Валера, Оксана, Женя, Таня, Руфана өйдә кулдан килгән кадәр эш эшли икән. Саубуллашыр вакыт җиткәч, Константин Романович безне складка охшаш бер бинага чакырды. Ул биредә балык киптерә икән. Үзе тозлаган искиткеч тәмле балык белән сыйлап озатты.

Теплоходыбыз яңадан кузгалып китте. Алда — Таймыр милли округының үзәге булган Дудинка. Төньяктагы иң өлкән шәһәрләрнең берсе, нигез ташлары XVII йөз башында салынган.

Дудинка порты — күп тармаклы хуҗалык, Таймырның диңгез капкасы: җирле радио рус, долган, ненец, нганан телләрендә тапшырулар алып бара. Туган якны өйрәнү музее — шәһәрнең горурлыгы. Биредә гаҗәп кызыклы экспонат — «кар сарыгының» башы һәм тиресен күрдек. Бозлар һөҗүме чорында бу якларның җәнлек-җанварлары көньякка күчә. Таймырның таулар арасындагы оазисларында төньяк сарыклары сакланып кала. Аларны безнең көннәрдә дә очратырга була әле. Ул — гаять эре мал, зур мөгезләре — тармаклы. Хәзер аларны аулау тыела. «Кар сарыгын» илнең көньягында иткә һәм йон алу өчен үрчетә торган сарыклар белән кушып, кырыс табигать шартларына чыдам токым алырга уйлыйлар.

Таймырның хайваннар дөньясы яңа җәнлекләр белән баетыла. 1974 — 1975 елларда ярымутрауга Канададан һәм Аляскадан сарык-үгезләр кайтарыла. Аларны мондагы табигатькә яраклаштыру тәҗрибәләре алып барыла. Кайчандыр сарык-үгезләр, мамонтлар белән бергә, Таймыр киңлекләрендә йөргән. Арктиканың бу эре хайваннары мамыклы, җиңел һәм җылы тиреләре белән аеруча кыйммәтле. Алар салкыннардан да, бураннардан да курыкмый, тундрадагы вак үсемлекләр белән туклана.

Таймырда сирәк очрый торган кошлар оя кора. Кызыл бүксәле казарка — шундыйларның берсе: ул оясын текә ярларга ясый, һәм анда кечерәк төркемнәре белән килеп урнашалар. Янәшәдә генә ерткыч кош Сапсон оялый. Ул үз оясын да, казаркаларны да дошман-

нардан саклый. Таймырда казаркалар күп түгел, аларны аулау тыела.

Ярымутрауның икенче бер гүзәл кошы — алсу акчарлак. Танылган сәяхәтче Фритьоф Нансен Арктиканы өйрәнгәндә серле кошларны күрергә хыяллана. Бу аңа насыйп була, хәтта ул акчарлакны кулына да тотып карый. Алсу акчарлакларның торган урыны дип төньяк Якутия тундрасының бер төбәген саныйлар, 1973 елда аларның оялары Таймырда табыла.

Таймырның тундра кошлары арасында, җәнлекләр дөньясындагы кебек үк, зур һәм бик кечкенәләре бар. Тундра аккошының авырлыгы ун килограмман да артып китә, иң кечкенә пеночкалар исә ун грамм да тартмый!

Дудинкадан җир шарының иң төньягындагы тимер юл — Дудинка — Норильск тимер юлы башлана. Ул гаять катлаулы табигать шартларында 30 нчы елларда төзелә. 1937 елның 18 маенда Дудинкадан Норильскига беренче поезд кузгалып китә. 1953 елда тимер юл киңәйтелә, ул, мәңгелек туңлыкта салынган юл буларак, бик уникаль корылмалардан санала.

Шушы тимер юлдан без Норильскига китәбез. Тирә-якны вагон тәрәзәсеннән күзәтеп барган юлдашыбызның берсе:

— Боланнар, боланнар! — дип кычкыра.

Юл кырыенда тундраның мөгезле хуҗалары — боланнар йөри. Таймырда алар бик күп, 450 мең баш! Бу — безнең илебездәге боланнарның иң зур көтүе. Табигатьнең гаҗәеп байлыгы булган кыргый боланнар тундрага кабатланмас ямь бирә.

Сазлыклар... Иге-чиге юк кебек. Явым-төшем дә аз инде, югыйсә. Сазлыклар каян килә соң? Җәй көннәрендә мәңгелек туңлык бераз эри, ә су җиргә сеңми, өстә җыелып тора, салкын җәйдә парга да әйләнми. Сазлык хасил булуның төп сәбәбе менә шунда.

Норильскига якынлашкан саен, совет кешеләренең фидакарь хезмәте таңга калдыра. Монда — шахталар, тау казылмаларын баету комбинатлары, дүрт-биш, сигез-тугыз катлы торак йортлар, монда — куәтле җылылык электр станцияләре... Юан торбалар буйлап газ килә һәм кайнар су ага.

Совет кешеләре тудырган Норильск шәһәре — үзе бер фантастика могҗизасы. Аны тикмәгә генә Заполярье йолдызы дип атамыйлар. Ул тундра чәчәге кебек күзгә күренеп үсә. Исеме ерак тундра серләрен ачуның үзенчәлекле ачкычы сыйфатында яңгырый. Батыр хезмәткә һәйкәл булып калыккан бу шәһәр Мәскәүдән 6 мең чакрым ераклыкта. Үткән йөздә Россия үзәгеннән бу җирләргә айлар буена барганнар. Хәзер Мәскәү аэропортындагы «һава кошлары» берничә сәгатьтә Норильскига очып килеп җитә.

1935 елның 23 июлендә СССР Халык Комиссарлары Советы Норильск бакыр-никель комбинаты төзү турында карар чыгара. Шәһәр шушы көннән башлана. Ул — хәзер эре промышленносте булган шәһәр, дөньядагы төньякка урнашкан иң зур тау-руда һәм металлургия үзәге. Монда иң югары сыйфатлы никель, кобальт, бакыр һәм башка кыйммәтле металлар алалар. Бүгенге Норильскиның колачы менә нинди!

Норильскида кышын тәүлек буена төн, кояш Арктика күгенә китеп югала, тундра поляр төн караңгылыгына кереп чума. Җәен исә бөтен тәүлек дәвамында — көн. Шәһәр җитмешенче параллельдә. Төньяк Боз океаны да кул сузымында гына. Климаты Арктиканыкы. Салкыннар бирәдә 50 градуска кадәр, эсселек исә 30 градуска хәтле була. Һава еш үзгәреп тора. Кыш көне күз ачкысыз буран куба, тирә-як тирән кар белән каплана. Ачы җилләр тундрадан шәһәргә кышын 80 миллион кубометрга кадәр кар китереп ташлыйлар.

Сәгать саен чистартмасалар, шәһәр кешеләре квартирларыннан урамга да чыга алмый.

Төзүче — шәһәрдә иң хөрмәтле һөнәр иясе. Шәһәр еллап түгел, айлап үсә. 1939 елда Норильскида 14 мең кеше булса, хәзер 200 мең кеше тора. Норильскида агач йортлар юк. Тау урамында төзелгән беренче агач өйне тарих истәлеге итеп кенә калдырганнар. Аны 1920 елда Николай Урванцев җитәкләгән геология экспедициясе төзегән булган. Таш биналарның һәммәсе дә субай нигезләргә утыртылган. Шуның нәтиҗәсендә мәңгелек туңлыкта җир асты коммуникацияләре челтәрен салу хәл ителгән. Йортларның беренче катлары биектә. Биналар астыннан җылы сулы торбалар уза. Алар җир астына күмелми, ә җир өстенә салына.

Шәһәрдә 20 культура сарае һәм клуб, киң экранлы кинотеатрлар, 20 елдан артык инде музей эшли. Музейга бөтен Норильскиның тарихы тупланган.

... Без яңадан «Татарстан» теплоходында Енисей буенча югарыга йөзәбез, Себернең диңгез капкасы булган Игаркага килеп җитәбез. Бу портның төзелүе илебезгә Ерак Төньякны үзләштерүдәге мөһим мәсьәләләрне чишүгә ярдәм итә. Игаркада СССР Фәннәр академиясенең туңлыкны өйрәнү станциясе урнашкан.

Игарканы урман башкаласы яисә дөньяда иң күп агачлы шәһәр дип йөртәләр. Навигация башлану белән, саллар ага башлый. Урман эшкәртү заводлары уннарча чакрымга сузылган. Соңгы елларда шәһәр, күзгә күренеп, Заполярьеның мөһим бер хуҗалык үзәге булып үскән. Озакламый ул халыкара күләмдәге урман базары дәрәҗәсенә күтәреләчәк.

Илебезнең төньяк җирләре күңелләрне куандырып әнә шулай яңара. Үзәктән ерак булган бу якларны яңа тормыш төзүче совет кешеләре үзгәртә.

Төньяк хәзер аны беренче ачучылар күргән буп-буш җир түгел инде. Ул аэропортлар һәм тимер юл вокзаллары, театрлар һәм концерт заллары, мәктәпләр һәм больницалар, техникумнар һәм институтлар белән тулы. Анда иң кыйммәтле җир асты байлыклары чыгарыла, зур төзелешләр бара, урман һәм җәнлек тиресе эшкәртелә. Халык дастаннары, сынлы сәнгать һәм архитектура һәйкәлләре, кырыс гадилек һәм искиткеч матур табигать, иксез-чиксез киңлекләр, кешеләрнең күңелен биләп, Төньякка чакырып тора.

Нури Арсланов

# БЕЗНЕҢ МУСА

Муса Җәлилне хәтерләү белән минем күз алдыма уртадан түбән буйлы, нык гәүдәле, һәрвакыт бик пөхтә киенгән, әлбәттә, галстук һәм шләпәдән, уйчан, шул ук вакытта үткен-шаян карашлы, коңгырт күзле татар зыялысы килеп баса.

Хәтерлим: бөек рус шагыйре М. Ю. Лермонтовның 125 еллыгына багышланган кичәгә хәзерлек бара. Кичәне оештыручылардан берсе — шагыйрь Фәтхи Бурнаш. Мин аннан «Мцыри» поэмасыннан үзем тәрҗемә иткән бер өзекне — монастырьдан качкан яшь монахның барс белән көрәшен сурәтләгән өлешен кичәдә укырга рөхсәт сорадым.

Фәтхи Бурнаш карап чыкты да, тирәсендәге язучыларга күз төшереп алды, аннан миңа борылды. Ул арада бүлмәгә Муса Җәлил килеп керде. Фәтхи Бурнаш аңа: «Менә теге син әйткән эквиритмик тәрҗемә», диде.

— Ә шигъри эшләнеше? — диде Муса.

— Укып кара.

Муса күз йөртеп чыкты да:

— Укысын, мин каршы түгел,— диде, үзе миңа әлеге коңгырт күзләре белән серле генә итеп карап алды. Шуны да әйтергә кирәк, без Муса белән баш изәп кенә исәнләшә торган танышлар идек. Чөнки ул вакытларда мин редакцияләрдә художник вазифасын үтәүче хезмәткәр, ә ул танылган шагыйрь иде. Фәтхи Бурнаш исә, ике күзен дә кысып, башкаларга күрсәтмичә генә миңа ымлап куйды. Икесенең дә миңа карата мондый мөнәсәбәтләреннән мин эчтән бик шатландым. Шулай да бу тәрҗемәмне кичәдә миңа укырга туры килмәде. Монысына мин үзем гаепле. Әлеге кирәкмәгән артык тыйнаклык сәхнәгә үк чыгудан тыйды...

Бөек Ватан сугышы башлангач, фронтларга таралыштык. Күп еллар үтте. Ул елларда күп сәнгатьтәшләребезнең гомере киселде... Без, исәннәр, Казанга әйләнеп кайттык. Муса турында күп төрле хәбәрләр ишетелде... Ниһаять хакыйкать өстенлек алды — Муса Җәлил мәшһүр «Моабит дәфтәрләре» белән күтәрелеп чыкты. «Нур өстенә нур» дигәндәй, шагыйрьнең фашистлар тылында совет иле ватандары буларак кылган зур батырлыклары аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелүгә сәбәп булды. Бу хәлләр күңелләребездә сүрелмәс горурлык уяткан, тарихыбызга алтын белән язылган иң кадерле сәхифәләрдән иде.

Бер елны мин «Победа» корабында Кара диңгез буйлап сәяхәткә чыктым. Язмышның көлүен кара син! — минем каютам кайчандыр Гитлер сайлаган люкс булган икән. Корабта кеше күп. Халык бик төрле. Бер вакыт, палубада, арадан берсе, иңенә кино һәм фотоаппаратлар асканы, минем яныма килеп рәшәткәгә таянды:

— Гафу итегез, күптән сорашырга теләсәм дә батырчылыгым җитми килде. Сезне кем дип кабул итик?

— Турист.

Тегенең бераз кәефе кырылды:

— Юк, ул турыда сорамыйм, без монда барыбыз да туристлар.

— Пенсионер.

Теге тәмам үпкәләгән тавыш белән:

— Мин сезне язучы дип ишеткән идем. Ә язучылар пенсиягә чыкмыйлар бугай.

— Кем икәнемне белгәч, нигә сорашасыз соң?

— Аныклар өчен.

— Әйе, мин татар шагыйре.

— Таныш булыйк,— ул үзенең һәм атасының исемен әйтте,— Көнчыгыш илләрендәге дипломатлар корпусы хезмәткәрләреннән берсе.

Бу үзенең дипломатларга мөнәсәбәтле икәнлеген белдерү өчен мине сайлаган икән, дип уйлап алдым.

— Үз телегездә язасызмы?

— Әлбәттә.

— Ә бит сезнең шагыйрегез Муса Җәлил турында без яхшы беләбез. Без генә түгел, аны бөтен дөнья белә. Шигырьләре нинди көчле, дәртле! Көрәш шигырьләре!

— Әгәр дә Сез, Көнчыгыш дипломатларыннан буларак, мәсәлән, төрек я уйгур телен белеп, шагыйрьне оригиналыннан укый алсагыз, шигырьләреннән тагы да күбрәк ләззәтләнгән булыр идегез.

— Гафу итегез, Муса Җәлил шигырьләре русчасына караганда татарчасында сәнгатьчәрәк, төгәлрәк дип әйтергә теләмисездер бит?!

— Һич шиксез, шуны әйтергә телим.

Мин бу урында, ни кадәр яхшы булса да, тәрҗемәнең оригиналга караганда тәгәлсезлеге: мәгънә, фикерләү, хис-моңнарның тулысынча бирелеп җиткерелә алмавы турында сөйләдем. Үрнәккә гаптәшем кулындагы русча җыентыктан, Ширази, Навои, Хәйям әсәрләреннән, хәтеремдә сакланган хәтлесеннән үрнәкләр дә китердем. Шулай ук Шекспир, Гете, Байрон әсәрләренең дә русчага тәрҗемәләрендә, гаҗәп яхшы булуга карамастан, барыбер оригиналдагы барлык нечкәлекләр-нәфисләкләрен тулысынча саклый алу мөмкин түгеллеген әйттем. Гаптәшем бер кадәр тынып калды.

Соңыннан сүз турыдан-туры Мусага күчте. Ул миңа Муса Җәлил томын укып чыгуын, шигырьләренең көчле тәэсирен, үзендә Муса Җәлилнең туган халкына карата яңача бер кызыксыну, ихтирам тууын чын күңелдән сөйләде.

Шагыйрь Муса Җәлил Ватан сугышына кадәр үк татар әдәбиятында безнең танылган әдипләребезнең берсе иде. Әйе, күпләрдән берсе иде. Ләкин яраланып дошман кулына төшү, Абдулла Алиш кебек ватандар дуслары белән яшерен көрәш алып бару, аннан кулга эләгеп, төрмәгә ябылу елларында аның шәхси көрәше — шигърияте, кинәт бәреп чыккан янар тау кебек кайнар сулышы, ялкыннары белән күккә үрләде. Ул янгын, илләр, еллар аша үтеп, бөтен дөньяга балкыды, күкрәү тавышы континентларга ишетелде. Монда инде шагыйрь Муса Җәлил күпләрдән берсе булып түгел, ә бердәнберебез булып күтәрелде! Аның шигырьләре көрәш программасы сыман, азатлык өчен көрәшүчеләргә мәңгелек өндәү — васыять булып калды. Яшь буынга — нәге көрәш романтикасы белән хыялланучыларга һөҗүм быргысы булып яңгырады. Ниһаять, моңлы Тукайлы, гыйсъянчы Такташлы, дулкынлы Туфанлы сугышчан татар шигъриятен Муса Җәлил үзенең тез чүкмәс, җиңүчән шигъри әсәрләре белән тагы да бер баскычка күтәрде. Планетабызда хәзер Муса Җәлил исемле данлы татар шагыйре барлыгын белмәгән бер ил дә, бер халык та юк!

## Ренат Харис

# ВАТАНДАРЛЫК ТАМЫРЫНДА

Батырлык — кешенең иң матур сыйфаты. Совет власте өчен, социализм өчен, коммунистик идеяләр тантанасы өчен көрәш чорлар-гасырлар таң калырлык тиңдәшсез каһарманнар тудырды. Гражданнар сугышы чоры батырлары Лазо, Щорс, Азин, Амангельды, Котовский, Чапаев, Бөек Ватан сугышы геройлары Матросов, Гастелло, Карбышев, Җәлил һәм меңләгән башка каһарманнар совет халкының хәтерендә генә түгел, аңында, күңелендә. Безнең патриотик хисләребезнең тамыры Ленин эше өчен, коммунистик идеология өчен, Ватан өчен гомерләрен аямаган әнә шул батырларның мәңге тере хатирәсенә дә тоташкан. Алар, урам, колхоз, шәһәр исемнәренә генә әверелеп калмыйча, намус, ныклык, халыкка тугрылык төшенчәләренең синонимына әйләнделәр. Бу төшенчәләр кешенең иң олы сыйфатларын билгелиләр. Кешенең шушы сыйфатларына дан җырлау әдәбиятны һәм сәнгатьне иҗтимагый көч итә.

Муса Җәлилнең һәм аның унбер көрәштәшенең кылган каһарманлыгы язучыларны, композиторларны, рәссамнарны, театр һәм кино сәнгате осталарын илһамландырып тора икән, димәк,— аларның батырлыгы халкыбыз күңелендә мәңге яшәячәк рухи көчкә әверелгән дигән сүз.

Муса Җәлил шигырьләренә язылган җырлар, романслар, вокаль циклларны һәм шагыйрьнең үзенә багышлап иҗат ителгән музыка әсәрләрен бер концертка тупласаң, ул концерт берничә көнгә сузылыр иде. Анда Нәҗип Җиһановның мәшһүр «Җәлил», «Алтынчәч» опералары, Алмаз Монасыйповның «Үлемсез җыр», Анатолий Лупповның «Сандугач һәм чишмә» балетлары, Рөстәм Яхинның «Моабит дәфтәре» дигән вокаль циклы кебек күләмле әсәрләр яңгырар иде.

Муса Җәлилнең скульптор Владимир Цигаль иҗат иткән бронза һәйкәле Казанның художество символларының берсенә әверелде. Рәссамнарның Муса Җәлилгә булган олы ихтирамнары әледән-әле оештырылган «Сынлы сәнгатьтә Җәлил образы» дигән күргәзмәләрдә дә күренә. Анда без Харис Якуповның совет сынлы сәнгатенең алтын фондына кергән «Хөкем алдыннан» дигән картинасы, Бакый Урманче эшләгән скульптур портретлар белән очрашабыз.

Нәкый Исәнбәтнең «Муса Җәлил» трагедиясе, Риза Ишморатның «Үлемсез җыр» драмасы буенча эшләнгән спектакльләр Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең образларын театр сәхнәсенә алып менде.

Гази Кашшафның, Рафаэль Мостафинның, Роберт Бикмөхәммәтовның шагыйрьгә, аның иҗат һәм тормыш юлына багышланган фәнни хезмәтләре, Шәйхи Маннурның «Муса» романы, Илдар Юзеевның «Соңгы сынау» поэмасы, Бәхтияр Ваһабзаденең әзербайҗан әдәбияты дәреслекләренә кергән «Очыгыз, толпарларым!» поэмасы, күп санлы шигырьләр, хикәяләр, җырлар, «Моабит дәфтәре» дигән нәфис фильм, документаль киноленталар — болар барысы да Муса Җәлилнең тормышы, иҗаты, көрәше илһам чыганагына әйләнүе хакында сөйли торган дәлилләр. Бу әсәрләрнең авторлары арасында сиксән яшьтән узганнары да, утызга җитмәгәннәре дә бар — совет шагыйренең, совет солдатының батырлыгы төрле буын вәкилләренә бер дәрәҗәдә иҗат ялкыны бирә ала торган көчкә ия!

Җәлилнең, җәлилчеләрнең каһарманлыклары нигезе нәрсәдә соң?

Аларның батырлыгы кайсы ягы белән безнең күңелләрне тартып тора? Билгеле, дошман оясында кылычка-кылыч килгән яшерен көрәш романтикасы белән генә түгел. Ул көчнең асылы — иң беренче нәүбәттә җәлилчеләр каһарманлыгының идеологик каһарманлык булуында. Коммунистик идеалга, Ватанга тугрылык Муса һәм аның көрәштәшләренең кеше буларак, солдат буларак, ныклыкларының нигезендә ята!

Җәлилнең һәм җәлилчеләрнең батырлыгы аерым бер төркем кешеләрнең генә гомерләрен саклап калуга юнәлтелмәгән. Аларның батырлыгы эгоист максатлардан азат,— шуның өчен дә җәлилчеләр, кулларына үлем карары китереп тоттыргач та, фашизмга каршы көрәшләрен дәвам иттерә алганнар.

Рухи каһарманлык һәрвакыт илһам чаткылары сибеп торган мәңге сүнмәс йолдыз булып кабына, йөрәкләргә юл күрсәтүче маяк булып балкый. Рухи каһарманлык кешенең яшәү рәвешенә принципиаль тәзлек, эшенә максатчанлык кертә, гомерләрне бәяләүче бизмәнгә әверелә. Әгәр дә син аңа табынасың икән, ул синең фикерләү рәвешеңә дә үзенең пакь эзен сала. Иҗади батырлык, ихтыяр көче, идеологик ныклык турында сүз чыкканда без әле дә, сугыш беткәнгә утыз биш ел үткәч тә, «Җәлил кебек», «җәлилчеләрдәй» дип сөйлибез, аларны үзебезгә дә балаларыбызга да үрнәк итеп куябыз, аларның туган көннәре безнең йөрәк бәйрәмнәренә әйләнә.

Мин 13—14 еллар элек «Мулланур» дигән поэма яздым. Аның сюжеты бик гади: Мулланурны аталар — ул үлми, Мулланурны суга батыралар,— ул үлми, Мулланурны асалар — ә ул һаман исән. Иҗат аңым формалашкан чорда Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең тормыш үрнәкләре булмаган булса, үлемсезлекнең мондый образын мин таба алган булыр идем микән?!

«Мулланур»ның рухи дәвамы буларак «Яралар» циклы язылды. Безнең социалистик тормышыбызга ил дошманнары, идеологиябез дошманнары үтергеч яралар салалар, ә социализм исән, социалистик Ватан исән. Бу шигырьләрнең дә аркау җебе— Җәлил һәм җәлилчеләр батырлыгыннан күтәрелгән рух.

Ахыр килеп, мин «Җәлилчеләр» дигән шигырьләр циклы яздым. (Ул «Социалистик Татарстан» газетасының 1980 елның 28 сентябрь санында басылып чыкты). «Кеше» ораториясенең шагыйрьгә багышланган бүлеген санамаганда, әлегә кадәр язганнарымда Җәлил һәм җәлилчеләрнең рухы гына булган булса, яңа циклымда алар үзләре минем әсәремнең персонажларына әверелделәр. «Җәлилчеләр циклы Муса Җәлил, Гайнан Курмаш, Абдулла Алиш, Фуат Булатов, Әхмәт Симай, Фуат Сәйфелмөлеков, Гариф Шабаев, Зиннәт Хәсәнов, Рәхим Саттар, Абдулла Баттал, Әхәт Атнашев, Сәлим Бохаров монологларыннан гыйбарәт. Алар исеменнән сүз әйтер өчен мин үзем алар мохитына керергә тырыштым. Бу юлда миңа Гази ага Кашшаф, Рафаэль Мостафин, Юрий Корольковның хезмәтләре ярдәм итте. Җәлилчеләр батырлыгын сәнгатьчә өйрәнү процессында мин тагын бер мәртәбә коммунистик идеология тәрбиясе алган кешенең рухи бөеклегенә инандым. Үзеңдә каһарманнар рухы тою — тиңдәшсез шатлык!

Җәлил һәм аның батыр көрәштәшләре турындагы әсәрләр СССР халыклары әдәбиятларының һәрберсендә диярлек бар. Аларның саны елдан-ел арта бара. Җәлилчеләрнең батырлыгы яңа легендалар тудыра. Әгәр дә Җәлил, җәлилчеләр турындагы барлык әсәрләрне бергә тупласаң, совет кешесенең үлемсез рухына дан җырлаучы гаҗәеп антология килеп чыгар иде.

## Равил Фәйзуллин

# ЕЛЛАР ҮТКӘН САЕН БИЕГӘЯ

Хәтердә: моннан берничә ел элек, Җәлил көрәштәшләренең берсе белән, Кремль калкулыгыннан — хәзерге 1 Май мәйданыннан Казан елгасына, Елан таулары ягына, Идел киңлекләре тарафына, сүзсез генә озак итеп бер карап торган идек. Вакыт — кич чак, шәфәкъ чагы. Тын вакыт, моңсу вакыт. Кабаланмаган кеше өчен уйландыра торган вакыт. Офыкта кызгылт төсләр вакханалиясе. Һәм шул алсу кызыллык, Казан суында үзгә бер киң коридор ясап сузылган да, ак Кремль диварларына кадәр күтәрелгән. Бөтен тирә-юньдә әлеге шул алсу кызыллык чагылышы. Җәлилнең бронза сынында да, агач ябалдашларында да, ак манарадагы сәгать телләрендә дә, сөзәк дамбаның шомарып беткән ташларында да. Скверлардагы гөлләр, үзләренең кызыллыкларына яңа кызыллык өстәлгәч, бөтенләй яңа кайнарлык белән дөрлиләр шикелле. Һәммә җирдә кызыллык. Без басып торган һәм шул мәгърур һәйкәлне күтәреп торган туфрак, җир үзе дә кызыл төстәдер, кан төсендәдер кебек...

Ветеран агайның йөзенә күз сирпеп алам. Минем башта менә шушы кызыл төсләр һәм шул төсләр аша ассоциатив чагыштырулар, параллельләр... ә менә гомерендә күпне күргән, күпне кичергән бу агай ниләр уйлый икән? Теләгемне күңеле белән сиздеме, әллә үз уеның табигый агышы шулай идеме, ветеран агай, борылмыйча, үз турына караган килеш салмак һәм нык тавыш белән әйтеп куйды: «Муса турында менә шулай биектән торып уйларга кирәк шул!..»

Чыннан да, Җәлил язмышы һәм иҗаты, аның кылган гамәле һәм батырлыгы хәзер дөньяның иң биек мөнәбәрләреннән торып, кешелек акылы ирешкән иң югары фәлсәфи категорияләр белән анализланырга, бәһаләнергә тиеш. Еллар үтә. Төрле социаль үзгәрешләр һәм яңа рухи төсмерләр белән кешелекнең янә бер гасырын очлау ягына барабыз. Шунысы характерлы: еллар үткән саен халыклар күз алдында Җәлил күтәрелә генә бара. Исем түгел, эш күтәрә аны, Матурлык һәм Батырлык елъязмасына керткән өлеше күтәрә. Әйе, еллар үтә. Җәлилнең һәм аның көрәштәшләренең үтерелүләренә дә инде кырык елга якын. Аның үзен күргән, аралашкан, якыннан белгән кешеләр дә берәм-сәрәм генә калып бара. Хәзерге яңа буыннар — яшьләр өчен, гәрчә алар шагыйрьнең тормыш юлын китаплар һәм башка чыганаклар аша шактый ук яхшы белсәләр дә, Җәлил, беренче чиратта, рухи яктан тарихи каһарманлык эшләгән кеше буларак якын һәм кадерле. Еллар үтү белән шәхеснең бәндәлеге онытыла; рухы кала, игелеклелеге, кешелеклелеге кала; батырлыгы, фидакарьлеге, тугрылыгы кешеләр хәтерендә яңа яхшы төсмерләрдә яңара. Җәлилнең тормышы һәм үлеме хәзер инде яшәеш факты булып кына түгел, ә тарихи вакыйга булып танылды.

Муса Җәлил бөеклек баскычына шагыйрь фидакарьлеге һәм солдат батырлыгы күрсәтеп күтәрелде. Шагыйрь батырлыгы. Солдат батырлыгы. Үлемсезлек өчен аларның берсе генә дә җитә кебек. Ике төр батырлык. Ә Җәлил мисалында бу батырлыклар — органик бер бөтен, алар, гүя, аның асылын ача торган ихтыяҗи чаралар. Җәлил гомумән, күпкырлы шәхес, күпьяклы шәхес. Ә кирәк чакта, хәлиткеч сынау вакытында ул үзенең иң асыл ягы белән ачыла: бөтен көчен һәм рухын бер максатка — Илгә һәм Поэзиягә тугрылыклы булып калуга юнәлтә.

Муса Җәлилгә табигать күпне биргән. Шуңа өстәп Җәлил үзе дә, табигать бүләкләренең ни бәһа икәнен яхшы аңлаган: саулыкның, вакытның, хезмәтнең кадерен һәм ләззәтен бик яхшы белгән. Сез аның моннан 4—5 ел элек чыккан дүрт томлык китапларын ешрак алып укып карагыз: Дөньялыкта шактый аз яшәп киткән шагыйрьнең безгә калдырган шактый биек рухи һәйкәле бит алар! Шигырен укыйсыңмы, мәкаләсен яки публицистик чыгышынмы,— Җәлилнең кабатланмас шәхесе килеп баса. Ул — тынгысыз, ул — эш кешесе, ул — һәрвакыт динамик хәрәкәттә, ул — оптимист, ул — үз эшенә нык инанган... Ул томнарда Муса Җәлилнең татар әдәбияты һәм сәнгате өлкәсендәге титаник хезмәте һәм, гомумән, культурабыз тарихындагы урыны бик ачык күренә.

**Күп эшләгән шагыйрь!**
**Нык янган!**

**Ташка басып чыгарганы —**
**йөзләп табак...**

Дүрт томлыгы тора киштәмдә
күзне иркәләп,
җанга рух биреп.

Ә калган томнары —
төрмә, вәхшәт йотканнары —
күңелемдә йөри әрнешеп...

Муса Җәлилнең әдип буларак зурлыгы, олылыгы бәхәссез нәрсә. Очраклы хәл мени: илебезнең иң зур бүләге булган Ленин премиясен совет шагыйрьләре арасында беренче булып Җәлил шигырьләре алды бит! Бу — аның поэтик батырлыгын ил һәм дөнья күләмендә тану һәм билгеләү булды.

Әйе, Муса Җәлил батырлыгының мәгънәсе вакытлар үтү белән һаман зурая бара. Аның батырлыгы — үткән өчен генә түгел, хәзер дә, киләчәк өчен дә бик кирәк батырлык, ихтыяҗи батырлык булып чыкты. Җәлилчеләр көрәше — кешелекнең фашизм кебек афәтне җиңә алу мөмкинлегенең бер дәлиле, җиңә алу тантанасының бер чагылышы иде. Тик әле, Кешелекнең оятына каршы, фашизмның Җир йөзеннән себерелеп түгелеп бетә алганы юк. Кешелекнең киләчәк язмышы хәвефсез булсын өчен төрле социаль системалар, кыйтгалар, илләр-дәүләтләр арасында аяусыз көрәш бара. Көрәш кискенлегенең, рухи киеренкелекнең кимегәне юк. Димәк, көрәшчеләр кирәклеге, Җәлил кебек гуман сәнгатен һәм гомерен салып көрәшә алырлык шәхесләрнең һаман күбрәк кирәклеге торган саен ныграк сизелә. Кешелекне кешелеклегенә чакыру, аның вөҗданын уяту, җир йөзендәге җаннарның мөмкин кадәр күбрәген бөек идеалларга хезмәт иттерү... Тере материянең йөрәген саклау, җанын пакьләү... Менә хәзер безнең Яшәеш килеп терәлгән глобаль проблемалар. Мондый проблемаларны Кешелек файдасына чишәр өчен Җәлил кебек интернациональ күңелле, көчле рухлы чын көрәшчеләр кирәк. Миңа калса, менә шуның өчен дә төрле милләтнең акыл ияләре — дәүләт эшлеклеләре, философлары, шагыйрьләре Җәлил турында үзгә бер патетик тойгы белән фикер йөртәләр. Үзебездә бер хәл, инде шушы соңгы дистә еллар эчендә тугандаш халыклар телендә Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында күпме җырлар, шигырьләр, пьесалар, поэмалар, повестьлар туды, күпме сынлы сәнгать һәм сәхнә әсәрләре иҗат ителде! Хикмәт — Җәлилчеләрнең батырлыгына дан җырлау гына түгел, төп максат — киләчәк буыннарда Җәлил кебек тормышсөяр, илсөяр тойгылар тәрбияләү, аларны чын кешеләр итеп үстерү.

Безнең өчен, бүгенге татар совет әдәбиятын үстерү эшенә күңелләребез белән алынган кешеләр — язучылар өчен, Җәлил шагыйрь һәм әдип буларак аеруча кадерле. Җәлил — зур тарихи поэтик мирасны нык үзләштергән, яңа шартларда үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән кеше. Әгәр без аның шагыйрьлек һәм гражданлык батырлыгы турында олы сүзләр сөйләп, аның традицияләре турында бик еш яза килеп тә, бүген аның юлын, политик һәм эстетик идеалларын конкрет эшебездә, конкрет хезмәтләребездә дәвам итмәсәк, без бер яклы һәм шактый дәрәҗәдә фәкыйрь кешеләр булыр идек. Шөкер, бүгенге татар поэзиясе туктаусыз үсештә. Җәлилләр эстафетасын яңа буыннар ышанычлы адымнар белән яңа сыйфатларда дәвам итә. Без бүген, имannарыбызга хилаф китермичә, хәзерге заман совет поэзиясенә үзләреннән лаеклы өлеш кертә алырлык байтак исемнәр саный алабыз. Димәк, Җәлил шагыйрь буларак та һаман безнең белән, ул — күңелләрдә, йөрәкләрдә, рухы һаман исән, сау-сәламәт!

## Әхәт Гаффар

# ДАСТАНЧЫЛАР

Плетцензее төрмәсендәге гильотина белән башлары киселгән биш мең политик тоткын арасында унбер татар егете булганлыгын тарих мәңге исендә тотачак.

Биш мең тоткын. Аларның күбесе — үз фюрерларына һөҗүм ясаган һәм империягә каршы заговорда гаепләнгән немецлар. Зур хәрби чиннар, дәрәҗәләр. Яки фашизмның җан дошманнары — немец антифашистлары.

Һәм менә шулар арасында татар халкының унбер улы да килеп керә. Елмаеп... Юлиус Фучикны шушы ук төрмә тирында атканнар...

Иң авыр җәзага тартыр өчен җәлилчеләрне III рейх газраилләре ни дәрәҗәдә күрәлмаска тиеш булган соң?!

Фашизмга сатылмау кеше өчен иң кадерле нәрсә — җан белән түләнгән. Хәер, җәлилчеләргә иң кадерле нәрсә җан булмаган, ә халык пакьлеге, хәрби антка тугрылык, Ватанга бирелгәнлек, илдәге туганнарны ярату.

«Безнең бик күп язган һәм язарга уйлаган нәрсәләребез үзебез белән бергә китә». Абдулла Алишның тоткынлыктан туганнарына юлланган соңгы хаты җәлилчеләрнең иң зур фаҗигасен чагылдыра. Алар үз көрәшләренең нәтиҗәсен күреп һәм

аңлап, инде үзләренең җиңүче икәнлекләрен белеп үлгәннәр. Мин аларның гомерләре киселүгә караганда да зуррак бер фаҗигаләрен күрәм: «...кая языйм? — Үзем белән бергә үләләр. М. Җәлил».

Шагыйрь өчен язганының үзе белән бергә югалуын күрүдән һәм сизүдән дә авыррак, хәтәррәк фаҗига бар микән? «Мин үзем өчен берни теләмим, Сездән бер генә нәрсә сорыйм: Мусаны коткарыгыз. Ул бөтен татар халкына кирәк»,— дип язган Абдулла Алиш. Шагыйрь үзенә дә, Мусага да берни теләми, ул халыкка шагыйрь Мусаны кире кайтарып бирүне таләп итә. Ә Җәлил үзе бөтен немецлар өчен кирәк булган бер шагыйрьне халыкныкы итәсе килә: «...Гейне кайтсын иленә».

Аяныч һәм сокландыргыч түгелмени: сүзләрен һәм көрәшләрен фашизм бары тик җәзалау белән генә тоткарлый алган унбер тоткынның бишесе — шагыйрь! Хәер, аларның һәркайсының гомере — өзелгән җыр, әмма ул унбер гомернең һәркайсы — ахырынача җырланып беткән илаһи бер җыр. Көрәш һәм рух гүзәллеге дастанчыларының дастанга тиң җырлары.

Ә биш шагыйрь... Гайнан Курмаш, Абдулла Алиш, Әхмәт Симаев, Муса Җәлил, Рәхим Саттар. Бер халыкның бер вакыт арасында биш шагыйре җәзалану — җир йөзендәге сирәк һәм коточкыч вәхши хәл.

Нәрсә соң бу? Инде борыннарына үз үлемнәре исе керә башлаган җәлладларның әлек Сүзне, язылган һәм язылачак шаһитларны юк итәргә ашыгумы? Әллә бу гади очраклылык кына микән?

Юк, җәлилчеләрнең тоткынлыктагы беренче көннәреннән башлап, соңгы сулышларынача бер генә очраклык та күрәсем килми. Алар арасында бер генә дә очраклы кеше, алар көрәшендә бер генә дә очраклы гамәл, алар иҗатында бер генә дә очраклы сүз юк. Чөнки җитмәсенә илле миллион корбан эләктергән фашизм үрмәкүче очраклылык түгел. Шагыйрьләрнең алмадай матур гомерләренә төшкән кортлар гына очраклы. Ул хаиннәр халкыбыз нәфрәтенең мәңгелек туңлыгында күмелеп калды. Хыянәт мамонтлары...

Җәлладлар башта шагыйрьләрне кискән. Аларның шагыйрь икәнлекләрен фашистларның белмәве дә ихтимал. Иң алдан яшерен оешманың җитәкчеләрен юк итәргә ашыкканнар. Ә биш шагыйрь — оешманың төп җитәкчеләре. Сугыш чоры татар поэзиясенең фашизм белән көрәш үзәгендә торуы очраклылык мыни? Очраклылык икән, татар әдәбияты әһелләре арасыннан кулына корал тотардай кайсы ир-егет тылда шигырь «генә» язарга калган?! Сугышка кадәрге тормышта бер-берсен белгән әлеге биш шагыйрьне язмыш бу зур планетада фашистлар өненең үзе — Берлинда ничек очраштырган икән? Табышмак, ләкин җавабы гап-гади — ипи кебек: зур планета, кан саркып торган бөтен яралары белән бергә, анасына сыенган яшь баладай, бу биш шагыйрьгә дә сыенган һәм аларның уртак йөрәгенә әйләнгән. Һәммә кешеләрнең дә йөрәгендәге теләге, уе, хыялы уртак икән, аларның кайда, ничек очрашуы әһәмиятле мени?

Әгәр Җәлил дәфтәрләре немец фашистлары империясенең сакчы этләре кулына килеп эләксәләр, аларны, төгаен, аерым хөкем карары чыгарып, иң зур, иң дәһшәтле крематорийларның берсендә яндырган булырлар иде. «Моабит дәфтәрләре»ндәге шигырьләр — әдәбиятыбызның алмаз ташлары. Аларның һәркайсы, һәркайсының һәр сүзе килешмәс ике идеология — фашизм белән коммунизм идеологияләренең кискен көрәше үзәгендә иҗат ителгән. Гомумән, Муса Җәлил иҗаты ике чакма ташы бәрелешеннән мәңге сүнмәскә чәчрәп чыккан очкыннар көлтәсен хәтерләтә. Ялкынлатыр өчен ул очкыннарны йомшак мамыкка тидерү хаҗәт түгел — кеше йөрәгенә якынайту җитә. Җәлил иҗатының бөтен дөнья кешеләре арасында теләктәшлек уятуы, мәхәббәт казануы сере — шунда. Күрәсең шагыйрьнең рухы шул кадәр кысылган, йөрәге нәфрәттән шул кадәрургыган, каны ачудан шул кадәр кайнаган, җаны сагынудан шул кадәр өзгәләнгән,— аның һәр шигыре алмазга әверелгән. Гади генә сүзләр белән язылганнар, югыйсә. Тик җир астындагы янартаулар кайнарлыгына һәм басымына килеп эләккәнче, алмазлар да бары тик кара таш — графит кына була лабаса.

Алар — ач, хокуксыз әсирләр — үзләрен дошманнан көчлерәк сизгәннәр. Нык алмаз — көл, көчле әсир кол булмас. Көчен сизгән әсир көрәшчегә әйләнә. Моны тарихка бер мәртәбә Спартак исбатлап күрсәткән. Кешелекнең язмышы шундыйдыр, күрәсең: моны тагын бер мәртәбә җәлилчеләргә дә исбатлап күрсәтергә туры килде. Фашизм төрле халыкларны, төрле милләтләрне үзенең колларына әверелдереп, аларны үзара сугыштырырга, талаштырырга — аларны XX гасыр гладиаторлары итәргә исәп тоткан иде.

Җәлилчеләр үлеме — җәлилчеләр үлемсезлеге. Бу — Җәлил шигыре һәм аның дүрт шагыйрь дустының тантанасы. Бу — татар һәм бөтен совет халкының горурлыгы.

Кешелекнең язмышы шундыйдыр, күрәсең: аңа һәр нәрсәне кабат-кабат исбатлап торырга кирәк. Тагын кемнәргә туры килер икән?

1. Виктор Хара.
2. Пабло Неруда.
3. ?..

...Ә барысына караганда да элегрәк чәчәннәрнең телен кискәннәр. Тик алардан тормышны тормыш иткән үлемсез дастаннар калган.

Григорий Бровман,

рус совет тәнкыйтьчесе

# МУСА ҖӘЛИЛ БЕЛӘН ФРОНТТА ОЧРАШУ[1]

1942 елның март азакларында «В бой за Родину» исемле армия газетасы йомышлары белән мин 4 нче армиядән Малая Вишера шәһәренә, Волхов фронты политидарәсенә килдем. Бәләкәйрәк бу шәһәр инде фашистлар кулында булган, алар аннан 1941 елның ноябрендә ук куып чыгарылсалар да, гитлерчылар эшләгән башбаштаклык һәр адымда сизелә иде әле.

Политидарә урнашкан йорттан ерак түгел генә бер урында, капка төбендәге бүрәнәләр өстендә берничә хәрби утырып тора. Бу якларда сирәк була торган кояшка йөзләрен куйганнар. Күрәсең, аларны тоташ соры болытлар каплаган күңелсез күк йөзе туйдырган, йөзләрендә яктылык, ачыклык сизелә. Арадан берсе, тәбәнәк базык гәүдәле, кара тут йөзле, чаткыланып торган шомырт кара күзлесе, никтер миңа таныш кебек тоелды. Өстендә аның яңа шинель, петлицасында бер шпал иде. Мин алар янына туктап, әлеге таныш сыман тоелган хәрбигә төбәлдем.

— Тыңлыйм сезне, иптәш батальон комиссары! — диде ул, аяк өсте басып һәм честь биреп.

— Әгәр хәтерем ялгыштырмаса, без сезнең белән...

— Так точно, Беренче МГУда укыган идек. — Каты итеп кул кысышканнан соң: — Җәлиловны онытмадыгызмы?! — диде.

— Исемдә, исемдә, — дидем мин ашыгып, — без бит әле сезнең белән этнофакта бергә укыган иптәшләр генә түгел, студентлар газетасына языша торган каләмдәшләр дә идек.

Бүрәнә өстендә утыручылар фронт юлында бер-берсен тапкан сабакташларга кызыксынып карый башладылар... Чыннан да без аның белән бергә Беренче МГУ да (Пироговкада ул чагында Икенче МГУ да бар иде) әдәбият бүлегендә укыдык, ул бүлек никтер «этнология бүлеге» дигән серле исем йөртә иде. Аннан соң безнең факультет үзгәртелде, аңардан Редакция-нәшрият институты аерылып чыкты һәм ул хәзерге Киров урамының кайсыдыр бер тыкрыгындагы йортта урнашты.

Һәртөрле үзгәртеп-корулар, яңалыклар заманы иде ул. Дөресен әйткәндә, егерменче елларның азагында, утызынчы елларның башында укыган студентлар—без дә үзгәртеп коруларга үз өлешебезне керттек. Университетның күп тиражлы газетасына без революция дәверендә лекцияләр һәм имтиханнарның һич тә кирәге юклыгын яздык, без бары тик консультацияләргә, коллоквиумнарга гына риза булабыз дидек, университет белеменә каршы чыккан чаклар да булды безнең! А. В. Луначарский 1929 елның ноябрендә «Революция һәм культура» дигән журналда минем Евгений Поповкин белән бергә язган «Университет үзенең революциясен көтә» дигән кискен мәкаләбезне фикер алышу тәртибендә бастырып чыгарды. Анда без университетны махсус институтлар итеп бүлү кирәклеген кузгаттык. Аларның берсе РИИН булды, ягъни Редакция-нәшрият институты. Безнең факультетка икенче исем бирделәр, төрле цикллар оештырдылар. Студентларның байтагысы, администрация таләбе белән педагогик циклга керде, ә Муса Җәлилов, мәсәлән, редакцион-публицистик бүлектә тәнкыйть циклында укыды... Поэтик цикл юк иде ул чагында. Ничек кенә булмасын, без укуыбызны университет дипломы белән тәмамладык.

Шулай итеп безнең чыгарылыш әдәбият һәм сәнгать факультетын тәмамлаучылар булып саналды. Әдәби-редакцион эш алып баруына һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетында эшләвенә карамастан, Муса укудан артта калмаска тырыша иде. Дөрес, ул озак вакытлы академик ял да алып торды, әмма курсны барлык студентлар белән бергә үз вакытында тәмамлады. 1931 елның 19 июнендә без кулга диплом алдык.

...Менә хәзер без Муса белән кар күмгән урам буйлап икәүдән-икәү генә атлыйбыз, шәһәрнең җимерек йортлары яныннан узган чакта, еракта калган студент елларын төрлесе төрле якка таралган сабакташларыбызны, сугыш өермәсе чәчеп ташлаган дусларыбызны искә төшерәбез. Анатолий Тарасенков Ленинградны дошманнан саклый, Евгений Поповкин кайдадыр шул тирәдә генә — Төньяк-Көнбатыш фронтында

[1] Бровман Г. Человек для людей. Очерклар, уйланулар, истәлекләр. М., 1978.

армия газетасында эшли, бергә университет тәмамлаган байтак иптәшләребез сугышта йөри, без аларның кайсы тарафта икәнен аермачык кына белмибез әле...

— Без аудиторияләрдән зур тормышка чыккан июнь көннәреннән соң ун елдан артык вакыт узып та киткән,— дип үз алдына сөйләнеп бара Муса Мостафович,— эшләгән эш тә юк диярлек әле, инде менә... — Ул кояшны каплый башлаган болытка һәм бер уңайдан улап очкан «юнкерс»ка күрсәтте.

— Сезгә ул хакта сөйләү гөнаһ,— дип бик катгый рәвештә каршы төштем мин,— без бит сезне университетта чакта ук инде, бик хаклы рәвештә, татарның классигы дип атый идек, ә аннан соң сез никадәр әсәр иҗат иттегез!

Җәлилов минем белән килешмәде. Аның шигырьләрен яшьләрнең чиксез дулкынланып тыңлауларын, яратып укуларын исенә төшерергә туры килде. Шулай бер мәлне кышын, утыз беренче елның башларында, без аны кышкы салкын кичтә Нескучная яр буе урамындагы тулай торакка алып килдек. Муса үзе башка урында, Зур Черкасский тыкрыгында яши иде, йорт саны 7, бүлмәсенең саны да 7 икәне хәтеремдә калган. Тулай торакка без 34 нче номерлы трамвай белән Моховаядан башлап Хамовническая яр буе урамына тикле бик озак бардык. Баскыч култыксасына ябышып, ачы җилдә дә селкенергә туры килде. Без, бу якта яшәүчеләр, университетка алай баруларга күнеккән идек инде: кичләрен трамвай һәр вакыт шыгрым тулы була, өстәвенә әле суык та була иде. Трамвайдан төшкәченнән дә әле Мәскәү елгасы аша салынган тимер юл күпере аша чыгарга кирәк иде. Зур Черкасский тыкрыгында яшәүчеләргә, әлбәттә, университетка йөрү, безгә караганда күп өлеш җиңелрәк. Әмма Җәлилов әлеге ерак һәм уңайсыз сәяхәттән зарланмады. Аны безнең студентлар торагында бик җылы каршы алдылар. Яшьләрне Поповкин белән мин, тагын ике студент яшәгән бәләкәй генә бүлмәгә сыйдырырлык түгел иде—шуңа күрә без коридорга чыктык. Бирегә икенче катта яшәгән филологлар һәм беренче катта яшәгән методик кызлар килеп тулды. Муса шигырьләрен татарча укыды. Без татар телен белми идек, әмма Җәлил поэзиясенең аһәңе, аның тыенкы, тыгыз, шул ук вакытта күңелне кузгата торган ритмы авторның ялкынланып янган күзләре, аның саен, әмма хәтердә кала торган мимикасы — болар барысы тыңлаучыларга нык тәэсир итте. Берничә шигырен ул азактан русча да укыды. Талантлы иптәшебезне бик озак үзебездән җибәрмәдек...

Муса менә хәзер сүзне үзеннән читкә алырга тырыша.

— Ә мин бригада ысулы белән укуыбызны искә төшердем,— ди ул,— әкәмәт роман иде! Беребез бер предметтан имтихан бирә, барыбызга берьюлы билге куялар. Безнең бригадада бишәү иде укып баручылар... Ярый әле, ул ахмаклыкны үз вакытында туктатып өлгерделәр.

Профессорларыбызны искә алдык.

— Мине Петр Семенович Коган бик ярата иде. Сорамый да диярлек билге куя иде, — диде Муса.

— Ул барыбызы да ярата иде. Сезгә, әлбәттә, аеруча игътибар итә, поэзия аның җан сөйгәне иде.

Искиткеч лектор, рус һәм дөнья әдәбиятының зур белгече Петр Семенович Октябрьдан соң университет аудиторияләрен тутырган яңа студентларны чыннан да ихтирам итә иде. Үзен тыңлаган студентларның кем икәнен, рухи дөньясы ниндирәк икәнен белү өчен ул аларга төбәлеп карый, җентекләп күзәтә. Студент халкы да аның коры академизмын бер якка куеп, совет әдәбиятының язмышын кайгыртканы, давыллы заман белән бергә атлап барганы өчен ярата иде. Табигыйдыр ки, Муса Җәлилов кебек түбәннән күтәрелгән, патша заманасында кыерсытылган, артта калган милләт балаларын, инде хәзер иҗат биеклекләренә омтылган яшьләрне ул бик үз итә иде. Петр Семенович Мусаның ярлы гаиләдә үсүен, рабфак бетергән булуын, халкы аның шигырьләрен ратуын белә, шуңа күрә имтиханнарда артык бәйләнүләр белән аның күңеленә тиярга теләми иде.

Хәер, Петр Семенович башка студентларга да әллә ни артык таләпләр куймый иде. Ф. В. Гладков иҗатына багышланган коллоквиум исемдә калган.

— Ягез әле, әйтеп карагыз: «Цемент» романындагы әхлакый конфликтта кем хаклырак: Глебмы, әллә Дашамы? — ди профессор.

Студентлардан кемдер кыюсыз гына кул күтәрә.

— Миңа калса, Глебның позициясе дөресрәктер шикелле...

— Яхшы. Бирегез имтихан кенәгәгезне,— ди профессор канәгать тавыш белән.

— Ә минемчә,— ди икенче бер студент урыныннан торып,— Дашаның гамәлен тулысынча аклап була.

— Сез дә имтихан кенәгәгезне китерегез, — ди Петр Семенович йомшак тавыш белән.

Гаҗәп тоелуы мөмкин, таләпчәнлеге ким булуга карамастан, П. С. Коган алып барган курсларны без бик яхшы белә идек, университетны тәмамлаганнан соң да ул алып барган лекцияләрне һәм коллоквиумнарны рәхмәт тойгысы белән искә төшерә торган булдык.

Муса минем белән килеште.

— Моховойдагы йорттан без белемне күп алып чыктык. Миңа, мәсәлән, ул белемнең файдасы бик тиде. Фәнгә сусаганнарга юл ачык иде, тик шуны әйтим,

фәнгә сусау бетми, елдан-ел арта бара икән ул. Тормыш безнең алга елдан-ел зуррак таләпләр куя...

Җитдилек хас бу сүзләргә. Студент чагында да шундый иде Җәлилов. Без аның ул заманда ук татар халкының танылган шагыйре икәнен белә идек. Иҗаты белән Мусаның үзебездән өстен икәнен дә аңлый идек, әмма ул үзе беркайда да, беркайчан да үзенең өстенлеген алга куймады. Татар телендә чыга торган берничә журналның редакторы һәм талантлы әсәрләрнең авторы булганы хәлдә, ул үз халкының социалистик культурасын үстерүдә актив катнаша, дәресрәге ул чагында әле безнең хыялда да булмаган эшне эшли иде. Тыйнак табигатьле, пөхтә-җыйнак, эшлекле, уйланучан һәм моңланучан булуына карамастан, ул башкалар белән тиз аралаша ала, шат холыклы иде.

...һәм менә хәзер, политидарәдә кабул итүләрен көткән һәм командирлар ашханәсен эзләгән чакта без Малая Вишера урамнары буйлап атлыйбыз. Азык аттестатларыбызга күз төшереп алган арада без Георгиевский тыкрыгындагы студентлар ашханәсен күз алдына китерәбез. Ул ашханә кулинарлык осталыгы ягыннан югарыгы баскычта тормый иде, әмма ул кызыклы вакыйгалары, шатлык-мәзәкләре белән безнең күңелебездә калды.

— Исегездәме, ашханәгә керер өчен чират торган чакта, без өй кыегыннан сузылган су торбасы янынннан уза идек. Торбада инде әллә кайчан ук бер белдерү ябыштырылган, анда кемнеңдер эте югалу хакында әйтелгән, шул белдерү кәгазе өстенә кайсыдыр шаяны кызыл карандаш белән эре итеп: «Сезнең фокстерьер бик тәмле булып чыкты!» дип язып куйган иде.

— Анысы исемдә калмаган,— диде Муса.— Минем хәтеремдә икенче бер нәрсә торып калган: без сезнең тулай торактан Нескучный бакчасы ягыннан Үзәк культура һәм ял паркына ашарга йөри идек, ә анда ресторанда кашыклар, чәнечкеләр һәм пычаклар чылбыр белән өстәлгә беркетеп куелган иде...

— Аны нарпит дирекциясе безнең аркада өстәлгә беркетеп куйган булгандыр,— дидем мин.— Кичке аш белән иртәнге ашны ашарга без коммуна булып бара идек. Савыт-сабаны дежурныйлар юып өлгертә алмыйлар иде. Шуңа күрә коммуна кашыкчәнечкене иләп кенә рестораннан ала да, ашагач, юмаган-нитмәгән килеш шыпырт кына урынына кайтарып куя иде... Димәк, безнең эшне сизгәннәр!

Без көлке нәрсәләрне, мәзәк хәлләрне искә төшердек. Ә күңелдәге уйлар безнең ул көнне мәзәк түгел, уйлар авыр иде. Ихтимал, шуңа күрә без яшьлектәге гамьсез чакларыбызны искә төшергәнбездер дә. Волхов фронтындагы хәлләр драматик. Фронт штабы урнашкан Папоротно авылыннан килүчеләр: январьда ук әле дошман оборонасын өзгән 2 нче удар армиянең хәле хәзер бик тә катлауланган булуын әйттеләр. Өзеп чыккан урынның бугазында ук, Новгород белән Чудово арасындагы юлда, Волховның көнбатыш ярында аяусыз сугышлар бара. Мясной бор белән Спасская Полисть дигән авылларның исеме телләрдән төшми. Нәкъ менә шунда немецлар алга таба киткән армия белән безнең арадагы коммуникацияне өзәргә, безне элемтәсез һәм азыксыз калдырырга тырышалар иде... 2 нче удар армиянең камалышта калу куркынычы килеп туды. Любан ягына таба берничә дистә километр читкә керсә дә, ул уңышка ирешмәде. Ленинградны камап торган фашист гаскәрләренә куркыныч тудыра алмады. Кириши-Погостье районыннан каршыга килгән 54 нче армия дә бик әкрен хәрәкәт итә иде.

Үзеннән-үзе мәгълүм, барлык волховлыларны борчуга салган бу хәлләр Мусаны да борчымый кала алмыйлар иде. Фронтның политидарәсе резервында булган хәлдә, ул хәрәкәттәге частьлар янына барып кайта. Ул инде куркыныч-хәвефле бәрелешләрдә булган, биредә сугыш алып баруның никадәр кыен икәнен аңлаган: кышын — утыз биш градуслы суык, кар көртләре, бозлы күлләр; язын, җәен һәм көзен — батках-сазламык белән тулы урманнар, билдән су ерып барасы, юл-мазар юк...

Хәзер инде мин ничегрәк аерылышканыбызны аермачык кына хәтерләмим. Тик Җәлилнең яшь чибәр чырае, бераз моңсу үткен карашы, каты итеп кул кысышуы әле дә күз алдымда тора. Без дошманнарга каршы мылтык һәм каләм белән сугышырга дип бер-беребезгә уңыш теләдек...

Атна-ун көн узгач, мин үзебезнең редакция урнашкан Будогощька кайтканнан соң, Мусаның 2 нче удар армия газетасы «Отвага»га эшкә җибәрелгән булуын белдем. Аңарчы ул урында Всеволод Багрицкий эшләде, ул 1942 елның февралендә Новая Керсть авылы янында һәлак булды. Ул урынның хәвефле икәне барыбызга да мәгълүм: барып җитәр өчен генә дә артиллерия утына тотыла торган гына түгел, пулеметтан да өзлексез атып торган тар коридордан узарга кирәк. Әмма мин икенче бер хәлгә сөендем. Муса китәр алдыннан 4 нче армиянең Хәрби Совет члены, дивизион комиссары Иван Васильевич Зуев 2 нче удар армиягә күчерелде. Армия политработниклары аның китүенә үкенделәр, әлбәттә. Без, газетачылар да, аның китүенә үкендек. Иван Васильевич хәрби журналистларны бик ярата, катлаулы фронт шартларында аларга һәр яклап ярдәм итәргә тырыша иде.

Исемдә әле, 1941 елның декабрь урталарында һич көтмәгәндә ул безнең редакциягә килеп чыкты. Без ул чакта Тихвиннан ерак түгел генә Великий Двор авылында яши идек. Безнең редактор Оскар Елин яшәгән ярым җимерек йортта газета работникларының киңәшмәсе бара иде. Вакыт кичке эңгерләр. Иске-мосКы тутырылган чоланда нәрсәнеңдер дөбердәп ауганы ишетелде. Кемдер караңгыда ишек-

кә таба килергә азапланә иде. Елин урыныннан торды да, ишекне ача төшеп, аваз салды:

— Кем ул анда Гамлет әтисенең әрвахы кебек йөри?

Шаяртып дәшү бөтенләй урынсыз булып чыкты. Адъютант һәм ике автоматчы озатуында, өйгә дивизион комиссары килеп керде. Ул яшь күренә, һәм аның безнең Хәрби Советның яңа члены булуына ышанасы килми иде. Аяк өсте бастык. Ашыга-ашыга гимнастеркасын төймәләп, каешын каптыра-каптыра, Елин рапорт бирә башлады. И. В. Зуев аны бүлдерде:

— Чоланны яктырта алмыйсызмыни сез? Тәртип урнаштыра алмыйсызмыни анда?!

— Иптәш дивизион комиссары, движогыбыз начар, хәтта хәреф басу машинасын әйләндерергә дә көче җитми. Еш кына кулдан әйләндерәбез. Шуңа күрә караңгыда утырырга мәҗбүрбез! — диде кызарып чыккан редактор.

— Талабегез җитди,— дип елмайды Иван Васильевич.— Алай булгач, әйдәгез, танышыйк, бер уңайдан редакция ихтыяҗлары хакында да сөйләшеп алырбыз.

Шуннан соң озак та үтмәде, редакция нормаль эшләр өчен кирәкле барлык нәрсәне алды. Аннан ары да И. В. Зуев газетаның игътибарлы ярдәмчесе һәм дусты булып калды. Кешеләргә карата ягымлы һәм таләпчән булуы аның югары культурасыннан, хәрби һәм политик тәҗрибәсеннән килә иде. Дөресрәге, аның әнә шул тәҗрибәсе, тормышны белүе кешеләргә булган мөнәсәбәтен билгели иде. Ул чагында аңар әле 35 яшьтән артык түгел иде. Әмма ул узган героик юл, шул исәптән Испания республикасы өчен көрәш юлы аны олы, дәрәҗәле кеше итә иде.

Егетлек белән батырлык — аның төп сыйфаты. И. В. Зуев полклар белән батальоннарның командный пунктларын гына йөреп калмый, еш кына алгы сызыктагы землянкаларга да килеп чыга иде. Волховның көнбатыш ярындагы дошманнан сугышып алынган бер кишәрлек җиргә комиссарның килүе хакында миңа 1942 елның гыйнварында «Известия» газетасына да язып чыгарга туры килде.

— Юкка сез минем исемне телгә алгансыз,— диде ул миңа, газетаны карагач.— Көне-төне сугышкан кешеләр турында язарга кирәк. Без бит анда узып барышлый гына булдык.

Солдатны җаны-тәне белән ярата иде Зуев, ул моны матур күренер өчен эшләми иде. Дошманны тар-мар итәр өчен көчен кызганмаган һәркем аның якын дусты иде.

Муса Җәлиловның комиссар Иван Васильевич Зуев кул астында эшләячәген белгәч, мин чынлап торып сөендем. Ләкин бу хезмәттәшлек озакка сузылмады. Муса да, аның комиссары да үлемсезлек бусагасы алдына басканнар иде инде...

Иван Зуевның героик үлемен без башта «Известия» газетасыннан, ә аннары Б. Гусев белән Д. Мамлеевның әйбәт китабыннан укып белдек. Хыянәтче тарафыннан дошманга күрсәтелгән Иван Васильевичны фашистлар чолгап ала, әмма ул тере килеш дошманга бирелми, соңгы пулясын үзенә ата.

Комиссарның полкташы Муса Җәлил дә үлем белән шулай очрашуга әзер була.

**Волхов шаһит, изге сугыш антын**
**Соң чиккәчә керсез сакладым.**
. . . . . . . . . . . . . . . .

**Язмыш көлде, үлем, кагылмыйча,**
**Үтте яннан, минем тирәләп.**
**Нишлим, нишлим, соңгы минутымда**
**Пистолетым итте хыянәт!**

**Чаян чага үзен соңгы чиктә,**
**Бөркет ярдан түбән ташлана.**
**Мин соң бөкрет түгел идеммени,**
**Баш ияргә шуннан башкага!**

**Ышан, илем, шундый бөркет идем,**
**Мин дә соңгы минут килгәндә,**
**Әзер идем, мәгърур канат җәеп**
**Ташланырга ярдан түбәнгә.**

**Нишлим, сугыш дустым-пистолетым**
**Соңгы сүздән кинәт баш тартты.**
**Богау салды дошман кулларыма**
**һәм хурлыклы юлдан атлатты.**
. . . . . . . . . . . . . . . .

**Тик бер өмет, дуслар, сезнең сафта**
**Табар соңгы көрәш теләген,**
**Яралангач, ләкин тар коллыкка**
**Баш имәгән керсез йөрәгем.**

А. И. Герцен дөрес әйткән: «Хак эш үлемсез». Шагыйрь Муса Җәлил дә, аның комиссары Иван Зуев та тарихта үлемсез булып калдылар.

**Гариф АХУНОВ** тәрҗемәсе.

Рафаэль Мостафин

# СЕРЛЕ ЙОМГАК ЭЗЕННӘН

Шигырьләренең иҗат ителү вакытын күп очракта шагыйрь үзе күрсәтеп барган. Ләкин алар Моабит дәфтәрләренә кайчан, нинди шартларда теркәлде икән?

Беренче карашка гына бик гади тоелырга мөмкин бу мәсьәлә. Ә бит аңа җавап табу, каһарман шагыйрь биографиясендәге мөһим моментларны ачыкларга, Муса Җәлилнең фашист тоткынлыгында иҗат иткән шигырьләрен теркәүче бүтән дәфтәрләрнең булу-булмавы хакындагы бәхәсләрне хәл итәргә булышыр иде. Әйе, беренче карашка гына җиңел күренергә мөмкин әлеге мәсьәлә. Моабит циклына кергән үлемсез шигырьләрнең юеш һәм тар казаматта үлем белән күзгә-күз калган чакларда язылганлыгын онытырга ярамый.

Төрле кәгазь кисәкләреннән бик пөхтә итеп тегелгән дәфтәр-блокнотларны кулыма алам. Сабый кулы яссуыннан гына булган бу кечкенә дәфтәрләр хәзер Татарстан Дәүләт музеенда саклана. Аларның кадерле сәхифәләрен ачам, укыйм, җуела башлаган карандаш эзләренә, вак-төяк төзәтүләргә игътибар белән карыйм. Акрынлап вакыт томаны тарала, серләр пәрдәсе ачыла башлый кебек...

1942 елның 26 июненнән — авыр яраланган политрук Җәлиловның гитлерчылар тырнагына эләккән көненнән башлап, 1944 елның 25 августына — шагыйрь башы өстендә фашист балтасы күтәрелгән сәгатькә кадәр 791 көн үтә. Киң мәгънәсендә алганда, Моабит дәфтәрләренә шагыйрьнең фашизм белән, үлем белән кылычка-кылыч килеп яшәгән шушы ике ел да ике айлык гомере сыйган. Түбәнсетергә маташулар, хәлдән тайдыргыч сорау алулар, ачлык һәм салкын белән җәзалаулардан торган, бер генә сәгатькә дә тынмаган көрәш белән тулы 791 көн. Шул вакытны ачыграк, төгәлрәк итеп күз алдына китерергә мөмкин түгел микән?

Ике дәфтәрнең дә тышына Җәлил үзе «1943—1944» дип язып куйган. Димәк, алар шагыйрь кулында 1943 елның икенче яртысыннан (М. Җәлил 1943 елның 12 августында кулга алына) 1944 елның башына кадәр булган, дип фараз кылу дөрес булыр (1944 елның февралендә инде М. Җәлилне Дрезденга хөкемгә алып китәләр). «Моабит дәфтәрләре»нең беренчесендә 1944 елны иҗат ителгән бер шигырь дә юк, ә икенчесендә нибары бер шигырь — 1944 елның тәүге көнендә язылган «Яңа ел теләкләре». Шулай булгач, дәфтәрләрнең икесе дә 1943 елның икенче яртысында тегелгән булырга тиеш. Андре Тиммерманс та, әлеге дәфтәрләрне Мусса минем күз алдымда, кырык өченче елның соңгы айларында тутырды, дип искә алган иде. Билгеле, сәгатенә-көненә кадәр хәтерендә калдыра алмаган инде ул. Ләкин Моабит дәфтәрләрен җентекләп өйрәнү тагын кайбер нәрсәләрне ачыкларга ярдәм итте.

Дәфтәрләр хәрби почта өчен махсус эшләнгән хат кәгазеннән тегелгән (аларда «Фельдпост» — «кыр почтасы» дигән рәсми мөһерләр ярылып ята). Бу кәгазьләрне шагыйрьгә А. Тиммерманс биргән. Тиммерманска ике атнага бер мәртәбә туганнары белән хат алышырга рөхсәт иткәннәр һәм ул төрмә кибетеннән ике-өч куш биткә кадәр кәгазь сатып ала алган.

Кулымда — гарәп хәрефләре белән язылган беренче дәфтәр. Ул 1943 елның 2 ноябрендә иҗат ителгән «Буран» шигыре белән ачыла. Бу дәфтәрнең шул көннән дә иртәрәк башлануы мөмкин түгел. Күңел үк сизенә: Беренче дәфтәргә үзенең шигырьләрен нәкъ менә шул көнне — 2 ноябрьда терки башлагандыр Җәлил. Безнең кулда әлеге фаразны раслый алырлык дәлилләр бармы соң?

Дәфтәрдә икенче булып килгән шигырь «Тау елгасы» дип атала. Ул 1943 елның 28 октябрендә язылган. Шул ук әсәрне Икенче дәфтәрдә дә очратабыз, ләкин анда аның иҗат ителү вакыты анык күрсәтелмәгән: 1943 елның октябре дип кенә куелган. Моның сере бик тиз аңлашыла. Әлеге шигырьне Беренче дәфтәргә теркәп куйганчы әле берничә көн генә үтәргә өлгергәндер, шунлыктан Җәлил аның язылу вакытын яхшы хәтерләгән. «Тау елгасы»н Икенче дәфтәргә күчереп язганчы исә шактый гомер үткән.

Беренче дәфтәргә барысы 61 шигырь һәм өч фрагмент тупланган. Аларның ноябрь аенда язылганнары бик эзлекле тәртипкә теркәлеп калган. Яңа әсәрләр элегрәк иҗат ителгәннәре белән аралашып килә. Мәсәлән, «Буран»нан соң өч «иске» шигырь теркәлгән: «Тау елгасы» (1943 ел, 28 октябрь), «Бөрлегән» (1943 ел, 8 октябрь) һәм «Тозлы балык» (шулай ук 8 октябрьда язылган). Моннан соң «Буран» белән бер үк көндә иҗат ителгән «Авырудан соң» дигән шигырь урын ала (1943 ел, 2 ноябрь). Әлбәттә, 2 ноябрь — шигырьнең тәмам эшләнеп беткән көне дә

булырга мөмкин. Шул ук Тиммерманс сөйләгәннәрдән мәгълүм: Муса Җәлил әсирләргә «килә торган» немец газетасының язусыз кырыйларын каралама урынына файдаланган. Шулай булгач, 2 ноябрь көнне элеккерәк шигырьләрен дә тагын бер кат карап, мөкәммәл хәлгә китереп, әле яңа гына тегелгән дәфтәренә күчереп куюы бик ихтимал. Һәрхәлдә, Беренче дәфтәргә шигырьләрнең теркәлә башлау көне миңа ачык тоела.

Дәфтәрнең алдагы сәхифәләрен дә ачып карыйк. «Авырудан соң» шигыре артыннан «Корыч» (1943 ел, 30 сентябрь) һәм «Сөеклемә» (1943 ел, сентябрь), аннан соң «Күршеләр» исемле яңа шигырь (4 ноябрь) килә. Аннары тагын элгәрәк иҗат ителгән әсәрләргә урын бирелә: «Гашыйк һәм сыер» (1943 ел, август), «Юллар» (1943 ел, октябрь)... һәм яңа шигырь — «Чәчәкләр» (1943 ел, 9 ноябрь). Мондый эзлеклелек алга таба да саклана. Шуның өстенә, Җәлил яңа әсәрләренең язылу вакытын бик төгәл билгеләп бара, ә искерәк шигырьләрнең бары ае-елы гына күрсәтелгән.

Беренче дәфтәр исеме һәм төгәл датасы булмаган бер шигъри фрагмент белән тәгәлләнә. Әлеге фрагмент дигәнебез Икенче дәфтәргә дә кергән. Биредә аңа исем дә табылган («Егет көче») һәм язылу көне дә ачык күрсәтелгән (1943 ел, 19 ноябрь). Беренче дәфтәр ноябрьның 2 сеннән 19 ына кадәр тутырылган булып чыга! Без ачыклаган бу даталарның төгәллегенә янә бер шаһит бар: 20 ноябрьда язылган «Ышанма» дигән шигырь Беренче дәфтәргә кереп өлгермәгән.

Шушы унҗиде көн эчендә Муса Җәлил алты яңа шигырь һәм бер фрагмент иҗат иткән. Калган шигырьләр исә, элгәрәк иҗат ителеп, бу дәфтәргә кайдандыр күчереп кенә алынган.

Инде Икенче дәфтәргә күз салыйк. Ул латин хәрефләре белән язылган.

Дәфтәр 1943 елның 26 ноябрендә иҗат ителгән «Җырларым» исемле мәгълүм шигырь белән башлана. Минем уемча, бу Җәлилнең кайбер әсәрләрен шушы төпкә теркәргә керешкән көне. Әлеге фараз дәфтәрдәге язмаларның урнашу тәртибе белән дә раслана: «Кыз теләге» (29 ноябрь), «Ике йөзле дуска» (28 ноябрь), «Кар кызы» (4 декабрь)...

Биредә дә яңа шигырьләр искерәкләре белән аралашып килә. Датасы билгеле булган шигырьләрдән иң соңгысы — «Серле йомгак» — 1943 елның 12 декабрендә язылган. Димәк, Икенче дәфтәр дә унҗиде көн эчендә тутырылган булып чыга (26 ноябрьдан 12 декабрьга кадәр). Бу дәфтәр беренчесенә караганда шактый юка. Аның соры катыргы тышлыгында шагыйрь үзе язып калдырган шундый юллар бар:

«Бу төптә — 33 шигырь.

Әсирлектә һәм төткынлыкта — 1942. IX — 1943. XI — арасында язганнарым — 125 шигырь һәм поэма. Ләкин кая языйм? — Үзем белән бергә үләләр».

Бу язу төрмәдә кәгазь юнәтүнең никадәр читен булуы турында сөйли. Иҗатының Туган илгә кайтып җитә алмасын сизенеп, ничек өзгәләнгән шагыйрь күңеле! Ләкин азмы-күпме вакыттан соң Җәлил кайдандыр берничә бит шундый ук кәгазь табыштыра алган һәм, аларга унҗиде шигырен язып, Икенче дәфтәргә өстәгән. Әлеге битләр тегелмәгән, дәфтәргә пөхтә итеп кыстырып кына куелган. Шулай итеп, бу төптә барлыгы 50 шигырь җыелып калган. Инде әйтелгәнчә, дәфтәргә теркәлгән иң соңгы шигырьнең язылу вакыты — 1944 елның 1 январе. Димәк, кәгазь юклыктан туктап торган араны да исәпкә алсак, Икенче дәфтәрнең 1943 елның 26 ноябреннан 1944 елның 1 январена кадәр тутырылган булуы аңлашыла. Шул ук вакытта, язу рәвешенә карап, соңыннан өстәп куелган шигырьләрнең унҗидесе дә бер тын белән, бәлки, бер үк көнне язылуын чамаларга мөмкин. «Яңа ел теләкләре»ннән кала, аларның барысы да элгәрәк иҗат ителгән. Ә тулаем алганда, Икенче дәфтәрнең яртысы диярлек яңа шигырьләрдән тора.

Сүз уңаенда күңелгә килгән тагын бер сорау: ни өчен Беренче дәфтәр — гарәп, икенчесе латин хәрефләре белән язылган соң? Хәер, бу йомгакның очы бик ерак түгел. Беренче дәфтәрне төрмәдән Габбас Шәрипов алып чыкканлыгын искә төшерик. Җәлил моны алдан белгән һәм дәфтәр тышлыгына Габбас Шәриповның исемен үзе язып куйган. Күрәсең, бу — тенту-фәлән була калса, фашистларның дәфтәрне кулга төшерүе ихтималын күздә тотып эшләнгәндер. Төрмәдән бүтән кешеләрнең әйберләрен, язуларын алып чыгу катгый тыелган, шушы таләпне үтәмәгән тоткын бик аяныч хәлләргә дучар ителгән. Дәфтәр «үзеңнеке» булгач, тотылган тәкъдирдә дә аны алып калырга гына мөмкиннәр. Г. Шәрипов белән төрмә подвалында берничә мәртәбә очрашканлыктан, М. Җәлил, әлбәттә, аның гарәп язуын таныганлыгын белгән.

Икенче дәфтәрне төрмәдән Андре Тиммерманс алып чыккан (дөресрәге, ул аны үзенең көндәлеге дигән булып почта аша өенә салган). Бу очракта инде шигырьләрне латин хәрефе белән язуның мәгъкульрәк булуы көн кебек ачык.

Хәзер иң катлаулы сорауларның берсенә җавап бирергә тырышып карыйк: Муса Җәлилнең илгә кайтып җитмәгән бүтән дәфтәрләре булганмы?

Г. Шәрипов, бер очрашуда Муса Җәлил миңа тар гына кәгазьләрдән төпләнгән шигырь дәфтәре күрсәтте, ул урталай бөкләнгән укучылар дәфтәрен хәтерләтә иде,

дип сөйләде. Әлеге дәфтәр (һич югы, тышкы кыяфәте белән) безгә мәгълүм Беренче һәм Икенче дәфтәрләргә охшамаган.

Моабит дәфтәрләрен җентекләп өйрәнү, чыннан да, әченче блокнотның да булу ихтималына ышандыра.

Безгә кайтып җиткән шигырьләрнең уңдүрте 1943 елның сентябрь аенда, егерме икесе — октябрь аенда язылган. Баштарак мин бу хәлне Җәлилнең гадәттән тыш нык хәтерле булуыннан гына килә дип уйлаган идем. Ул бит шигырьләрнең язылу вакытларына кадәр исендә тота алган. Ләкин хикмәт бөтенләй башка нәрсәдә. Октябрь аенда шагыйрь каләменә илһам кошы ешрак кунган (764 шигырь юлы). Һәр айда язылган шигырьләрнең күләмен күрсәтүче диаграмма төзесәң, продуктивлык ягыннан октябрьдан соң сентябрь ае (450 юл), аннары декабрь (421) һәм ноябрь (416) айлары килер иде. Бу — 1943 елның сентябрь-октябрь айларында Җәлилнең махсус блокноты булуын ышандырырлык итеп күрсәтүче дәлил (андый блокнот әле сыңар гына булмаска да мөмкин). Шагыйрьгә төрмәдә җыештыручы булып эшләүче немецларның да кәгазь биргәләве мәгълүм. (Тора-бара Җәлил алар белән элемтәне югалткан ахрысы; юкса ул немецларны бүтән җиргә күчергәннәрдер). Карандаш кисәген исә кухняда эшләүче Гәрәев фамилияле тоткын биргән.

Моабит дәфтәрләре. Нәни кош баласын тоткан кебек, мин аларны сак кына кулыма алам. Бу кадерле сәхифәләр шагыйрь кулының җылысын саклый, шагыйрь җанының горур сафлыгы турында сөйли. Ил бөркетенең тормышы һәм иҗаты белән бәйле бүтән табышмакларны да чишәргә, серле йомгакның очын табарга да булышыр әле ул дәфтәрләр.

# БЕР ШИГЫРЬНЕҢ ТАРИХЫ

Мәгълүм булганча, 1941—1942 еллардагы канкойгыч сугышлар вакытында «Отвага» дигән армия газетасы корреспонденты Муса Җәлилгә алгы сызыкта еш булырга туры килә. Газета хәбәрләрен, очерклар-зарисовкаларны ул русча яза, ә шигырьләрен татарча язып, соңыннан газета өчен үзе үк русчага тәрҗемә итә.

Муса Җәлилнең фронтташ дусты — Волхов фронтының икенче удар армиясенә кергән 59 нчы аерым укчы бригада политбүлеге әлкән инструкторы Иван Павлович Паньков (бүгенге көндә ул Приморьеда яши, авыл хуҗалыгы институты доценты) шагыйрьнең нинди куркусыз һәм батыр йөрәкле булуы, кыенлыкларны зур сабырлык белән кичерүе хакында хөрмәт белән искә ала.

— Хәтеремдә, безнең армиянең азык-төлек белән тәэмин ителүе тукталып алган көннәр иде. Бер бәрелештән чыккач Муса миңа өч көн буе авызына бернәрсә дә капмаганлыгын әйтте,— дип сөйли И. П. Паньков.— Шунда без урманнан үзебез ашарга яраклы дип тапкан үләннәрне җыеп котелокта пешереп ашадык...

1942 елның апрелендә Муса Җәлил 59 нчы бригадага тагын килә. Иван Паньков белән бергә, ул беренче укчы батальонга бара. Батальон ул вакытта Мало Еглино авылы янындагы урманда оборона тотып тора. Үткән көнне генә фашистлар белән каты сугыш булган икән. Бәрелеш вакытында кыю кыз, батыр йөрәкле фельдшер Аня Аверина һәлак була. Ул сугыш кырыннан яралы солдатларны алып чыкканда минага эләгеп шартлый. Кызның үлеме шагыйрьгә бик нык тәэсир итә.

— Мин аның турында шигырь язачакмын,— ди ул шунда фронтташ дусты Иван Паньковка.

Кичен Дубовик белән Малое Еглино авыллары арасында урнашкан блиндажда бригада политработниклары җыйнала. Муса Җәлил дә килә. Фельдшер Аня Авериналың һәлак булуы турында сүз чыккач, барысы да тынып калалар. Бригадада аны һәркем яхшы белгән һәм якын күргән. Үлеме алдыннан гына Аня партия членлыгына кандидат итеп алынган булган.

Шушы тынлыкта Муса Җәлил Аня Аверинага багышланган «Кыз үлеме» дигән шигырен укырга рөхсәт сорый. Башта ул әлеге шигырен татарча, аннары үз тәрҗемәсендә русча укый.

Хәзер бу әсәрне шагыйрьнең бик күп җыентыкларында очратырга була. Менә ул.

## КЫЗ ҮЛЕМЕ

Йөз яралы кызылармеецны  
Алып чыкты сугыш кырыннан.  
Яраларын бәйләп, һәркайсына  
Су эчерде ул үз кулыннан.  
Яңгыр төсле җиргә пуля яуды,

Мина очты күктән котырып.
Ә ул кырда йөзнең берсенең дә
Ташлап калдырмады мылтыгын.
Тик... йөзенче кабат барышында
Екты аны мина аяктан.
Чагылдырып аның йөрәк канын
Иелделәр данлы байраклар.

Менә ята ул кыз носилкада,
Җил иркәләп үбә чәченнән.
Болыт төсле куе керфекләре
Зәңгәр күзен аның яшергән.
Ярым ачык юка ал ирендә
Катып калган тыныч елмаю.
Әйтерсең лә, иидер сөйли-сөйли
Көлемсерәп аңын җуйган ул.
Йөз тормышны кабызып, кинәт кенә
Үзе сүнгән бу яшь гомернең
Даны яшәр,
чиксез батырлыкка
Рухландырып йөз яшь күңелне.
Бу йөрәктә яшьли тынган яшьлек —
Көн тудырган ал таң шикелле.
Дошманнарга үлем,
Ә үзенә
Мәңге үлмәс яшәү китерде.

— Бу шигырь юллары минем күңелемә мәңгегә уелып калды,— дип искә ала И. П. Паньков.— Әйе, Аня Аверина йөзләрчә сугышчыларны коткарып калган оныtылмас батыр кыз иде... Шулай ук фронтташ дустым Муса Җәлилне дә мәңге онытасым юк.

Равил ЕНАКАЕВ.

Фатих Урманчеев

# ДАСТАННАРГА ЛАЕК ЗАМАНА

Татар поэзиясенең ерак гасырлардан килгән күркәм традицияләре бар. Шулар арасында халык иҗаты белән бәйләнеш иң җитди урыннарның берсен алып тора.

Халык иҗаты белән тыгыз бәйләнеш традициясен яңа гасырда бөек Тукай күтәреп ала. Шул нигездә ул үзенең «Туган тел», «Әллүки», «Су анасы», «Шүрәле»ләрен иҗат итә. Язма поэзиянең классик үрнәкләре булу белән бергә, әлеге әсәрләр халык иҗатының үсешенә дә зур йогынты ясадылар. Бу традицияләрнең Такташ, Җәлилләр иҗатына да йогынтысы көчле. Утызынчы елларда Һ. Такташның «Урман кызы», Ә. Фәйзинең «Умырзая» һ. б. җырлар иҗат ителә. Соңыннан алар халыклашып, халык җырларына әвереләләр һәм бүген дә заманча яңгырыйлар.

Татар опера һәм балет театрына нигез салынгач, репертуар булдыру өчен яңа жанр әсәрләре — опера либреттолары иҗат итәргә кирәк була. Шул уңайдан язучы-шагыйрьләрнең игътибары халык эпосына — әкият-дастаннарга, тарихи бәетләргә, риваять-легендаларга юнәлә. 1940 елның 7 декабрендә Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе М. Җәлил язучылар алдында «Югары сыйфат өчен көрәшкәндә» дигән доклад белән чыга. «Хәзерге татар әдәбиятында тематик яктан күзгә бәрелгән тагын бер әһәмиятле момент — язучыларда фольклор темасына омтылыш артудан гыйбарәт,— ди ул.— Бервакытларны бездә фольклор шактый читләтелгән иде һәм фольклордан йөз чөерү, качу урын алган иде. Хәзер, бигрәк тә соңгы бер-ике елда, шагыйрьләр һәм драматурглар арасында халык эпосларын, халык әкиятләрен, дастаннарын, җырларын өйрәнү, шулардан иҗат өчен азык алу, аларның мотивлары буенча әсәр тудыру фактлары ешая бара»[1]. Әнә шул нигездә туган әсәрләр рәтеннән М. Җәлил түбәндәгеләрне күрсәтеп үтә: Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин», Т. Гыйззәтнең «Кыю кызлар»ы, Ш. Маннурның «Котан батыр»ы, М. Җәлилнең «Алтынчәч»е, Ә. Фәйзинең «Зөлхәбирә»се, А. Алишның балалар өчен әкиятләре, Ә. Ерикәйнең «Асылгөл»е һ. б. Әлеге әсәрләрнең иң зур күпчелеге татар әдәбиятының, гомумән, милли сәнгатебезнең алтын хәзинәсендә урын алдылар.

Кырыгынчы елларда һәм илленче еллар башында фольклорга, бигрәк тә халык эпосына, игътибар бераз кими. Ләкин бу елларда да Н. Исәнбәт, Х. Туфан, С. Хәким, кебек фольkларга якын торган шагыйрьләрнең иҗаты уңышлы дәвам итә. Н. Исәнбәтнең фольклор белән тыгыз бәйләнештә туган гүзәл җырлары һәм драматик әсәрләре халык ихтирамын казана.

Х. Туфан поэзиясендә халыкның рухи дөньясына якын, халык моңнарына аваздаш әсәрләр үзенчәлекле яңгырыйлар. С. Хәким иҗатына да фольклор традицияләре зур йогынты ясый. Аның 70 ләп җыры халык арасында зур популярлык казана. Шагыйрьнең халык иҗатына мөнәсәбәтендә тагын бер үзенчәлек бар. С. Хәким шигъриятенә фольклор йогынтысы Г. Тукай иҗаты аша килә. Безнең бүгенге поэзиядә Тукайга С. Хәкимнән дә якын торган шагыйрь юк кебек. Аның шигырь-поэмаларында без халыктан, аннан соң Тукайдан килгән су анасы, шүрәле, пар ат, Казан арты образлары белән еш очрашабыз. Заман әдәбиятында барган үзгәрешләр белән бергә, бүгенге көндә поэзиянең халык иҗаты белән бәйләнеше дә тирәнгәрәк китә. Бәлки шуңа күрәдер, бу бәйләнешнең үзенчәлекләрен ачыклавы да җиңел түгел. Хәзерге поэзиядә фольклор сюжетларына, халык иҗаты әсәрләренә турыдан-туры мөрәҗәгать итү сирәк очрый. Әдипләр халык иҗатының эчке мәгънәсенә, фәлсәфи тирәнлегенә шигъри гүзәллегенә игътибар итәргә тырышалар. Бүгенге поэзия халык иҗатының төп һәм фундаменталь жанрлары белән тыгыз бәйләнештә үсә. Әлеге багланышның нисбәтләре дә үзгәреп тора. Борынгы йола поэзиясе, туй җырлары белән бәйле әсәрләр, мәсәлән, юк дәрәҗәсендә аз. Аның каравы, халыкның гореф-гадәтләре, изге традицияләренә бәйле шигырьләр бик матур тәэсир калдыра. Ш. Маннурның «Олы чишмә» исемле шигырен хәтергә төшерик...

[1] Муса Җәлил. Әсәрләр, дүрт томда. IV том, Казан, 1976, 253—254 битләр.

**Бик борынгы**
**Тулбай бабам юлеп**
**Бу чишмәне күргәч**
**Таң калган:**
**— Гөбердәп лә җырлап ага! — диеп,**
**Тирәсеннән китми таптанган.**

Билгеле булганча, безнең авыллар борын-борыннан елга ярларына, чишмә тирәләренә салынган. Бәлки шуңа күрәдер салкын чишмә образы халык иҗатына һәм язма поэзиягә гүзәл бер сурәт, сафлык, пакьлек символы булып кереп калган.

**Борыннан ук килгән шундый йола:**
**Таңышканнар чишмә буенда.**
**Йөрешкәннәр...**
**һәм алдагы елда**
**Кавышканнар сабан туенда.**

Мондый тыйнак, күркәм йолаларны җырлау күңелдә тирән хисләр уята. Ул якты моң әнә шул чишмә образы белән бәйле.

Шагыйрь зур булмаган бер әсәрендә халыкның үткәнен һәм бүгенгесен гәүдәләндерүгә ирешә, үз язмышының халык язмышыннан аерылгысыз булуы хакында сөйли.

Шагыйрьләребез иҗатында борынгы әкият — легендаларга таянып язылган әсәрләр дә матур яңгырыйлар. Халык күңелендә мең еллар буе яшәп килгән сюжетларга заман аһәңе, чор темасы килеп кушыла. И. Юзеевның «Көянтәңне куй да...» шигыренә игътибар итик. Ул су алырга килгән Зөһрә исемле кызга мөрәҗәгать итү рәвешендә язылган.

**Әбиләрдән калган әкият бар:**
**Көянтәле бер кыз — адашың**
**Ятимлектән качып Җирдән киткән,**
**Салкын Айда калган адашып.**

Бу легенда бик күпләргә мәгълүм. Әгәр шигырьдә сүз шул турыда гына барса, аның әллә ни яңалыгы да булмас иде. Шагыйрь борынгы легендага безнең көннәр темасын куша, яңача яңгыраш бирә. Сүз беренче хатын-кыз космонавт Валентина Терешкова батырлыгына күчә:

**...Караңгы дип торма, йөгер әле,**
**Чәчәк җыйыйк бергә болында.**
**Мин көйләрмен сиңа матур бер җыр**
**Канатлы кыз Валя турында.**

Бик борынгы бер легенда бүгенге көннең әһәмиятле вакыйгалары турында шигъри тел белән сөйләргә ярдәм итә.

Татар поэзиясе үсешендә хикмәтле сүз традицияләре элек-электән зур роль уйнап килде. Бу хакта Н. Юзиевның тәфсилле тикшеренүләре дә мәгълүм. Поэзиянең иҗтимагый әһәмияте киңәю һәм фәлсәфи мәгънәсе тирәнәю белән бергә, бүгенге шигърияттә хикмәтле сүз традицияләре тагын да җитдирәк роль уйный башлады.

Билгеле булганча, хикмәтле сүзнең башы — фольклорда. Ул борынгы халык шагыйрьләре — чәчән-импровизаторлар иҗатына барып тоташа. Н. Исәнбәт сүзләре белән әйтсәк, «чәчән — халык шагыйре һәм хәким кеше». Шагыйрь буларак, ул җыр, эпос-дастан тудырса, хәким буларак, ул тирән мәгънәле шигырь, хикмәтле сүз әйтә». Әнә шуңа якын хикмәтле сүз булып яңгыраган шигырь соңгы елларда аеруча зур абруй казанды. Билгеле бер дәрәҗәдә поэзия үзенең борынгы асылына — хикмәт иясе булган чәчәннәр иҗатына якыная кебек. Бүгенге поэзиядә хикмәтле сүз традицияләренә нигезләнгән шигырьләр төрле формаларда иҗат ителәләр. Бу яктан Р. Харис әсәрләре игътибарга лаек. «Беләзек» исемле шигыренә, мәсәлән, ул мондый эпиграф китерә: «Берникди дә бизәк булмас богау беләзегендә...» Шул ук формадагы эпиграф «Кояш тыныч кына чыга...» шигырендә дә бар: «Дөньяны җил, суны дулкын, кешене сүз болгата...» Халык җырларыннан алынган бу өзекләр безгә күптән таныш. Шигырьгә эпиграф итеп алынгач аларның мәгънәсе тирәнәеп китә кебек. Тулаем алганда Р. Харис халык иҗаты мотивларын сирәк куллана, ешрак үзе хикмәтле сүз әйтергә тырыша. Халык мәкальләре белән бер дәрәҗәдә торган тирән фәлсәфи мәгънәгә ия булган сүзләр-җөмләләр Р. Харис иҗатында шактый: «Еллар буе меңнәр таптаган эз — сукмак. Юллар буе кемнәр таптаган сүз — мәкаль?!»; «Еллар узган саен үкенечләр арта».

Бүгенге поэзиянең күркәм сыйфатларыннан берсе буларак, хикмәтле сүз традицияләре башка шагыйрьләр иҗатында да билгеле бер урын алып тора.

Хикмәтле сүзләрдән файдалануда Ш. Галиев тә үзенчәлекле һәм нәтиҗәле алым куллана. Шигырьнең соңгы юллары, йомгагы аның кайбер әсәрләрендә хикмәтле сүз дәрәҗәсенә күтәрелә:

**Үлгәннәрнең**
**Каберен бел,**
**Исәннәрнең**
**Кадерен бел!**

Р. Фәйзуллин поэзиясендә турыдан-туры фольклордан килүче сюжетлар, мотивлар, хәтта шигъри образлар да аз. Дөрес, аның шигырьләре арасында халык җыры үлчәмендә язылганнары да очрый:

**Язгы дәрт белән өздерә**
**Ай яктысында тургай.**
**Кайтып җитү шатлыгыннан**
**Айнып беталмый бугай.**

Биредә шигъри үлчәм генә түгел, рифма (тургай-бугай) һәм лексика да халык җырларына якын. Ләкин Р. Фәйзуллин поэзиясенең халык иҗатына якынлыгы мондый тышкы охшашлыкларда түгел. Биредә мәсьәләгә, күрәсең, тирәннәнрәк килергә кирәк. Шагыйрьне кешенең мораль сафлыгы, туган иленә, үз халкына бирелгәнлеге, югары идеаллар белән яшәү ныклыгы, кешенең чын мәгънәсендә кеше, шагыйрьнең шагыйрь була белүе дулкынландыра. Аның әсәрләрендәге җитди, тирән һәм киң категорияләр — заман, чор, рух — конкрет шигъри образлар төсен алган. Р. Фәйзуллин халык иҗатына әнә шул яктан якын килә. Аның шигърияте халык иҗатының шундый ук тирән мәгънәгә ия булган хикмәтле сүз, мәкаль кебек жанрларына авазда.

**Үлемнәре белән үлемсезлек**
**Яулап ала безнең шагыйрьләр.**

Шигырьнең дәвамыннан күренгәнчә, биредә сүз Тукай, Кәрим, Кутуй, Җәлилләр турында бара. Хикмәтле сүздән башланган шигырь шундый ук мәгънәле юллар белән тәмамлана:

**Ә бит үлеп үлемсезлек яулау —**
**Бердәнбер юл түгел тормышта.**

Гомумән, Р. Фәйзуллин поэзиясендә, борынгы чәчәннәр иҗатына, мәкальләргә һәм дастаннарга үрелеп килгән шигырьләр әһәмиятле урын алып тора. Моның конкрет мисалларын аның иҗатыннан күпләп табарга мөмкин.

Бүгенге поэзиядә, гомумән борынгы чәчәннәр традициясе яңа бер баскычка күтәрелә, хәзерге профессиональ шагыйрьләр тарафыннан заман рухында дәвам иттерелә.

Соңгы елларда халкыбыз тарихын, бигрәк тә борынгы чор тормышын өйрәнү җитди нәтиҗәләргә китерде. Бу мәсьәлә буенча әһәмиятле хезмәтләр язылды. Биредә А. Х. Халиковның «Татар халкының килеп чыгышы», М. З. Зәкиевнең «Татар халкы теленең барлыкка килүе», С. Х. Алишевның «Урта Идел татарлары Пугачев күтәрелешендә», Р. Г. Фәхретдиновның «Ташлар моңы» һ. б. китапларны атап китәргә мөмкин. Тарих фәненең борынгы катламнарны күтәрүе бүгенге әдәбиятка да билгеле бер йогынты ясады. Соңгы елларда борынгы Болгар турында шактый әсәрләр язылды.

Халкыбызның борынгы тормышына багышланган әсәрләрнең иң зур күпчелеге халык иҗаты нигезендә барлыкка килә. Чөнки халык иҗаты халык тарихы белән тыгыз бәйләнештә үсә. Заман рухын чагылдыручы поэзия дә халык иҗатының катлаулы, бай тәҗрибә туплаган төрләренә мөрәҗәгать итә. Р. Харис үзенең бер шигырендә болай дип язган иде:

**Урамнарда афәт эзләре юк.**
**Кешеләрнең тыныч йөзләре...**
**Бер уйласаң, дастаннарга лаек**
**Ил-көндәге шушы үзгәреш.**

Бүгенге шагыйрьләр халык иҗатының эпик жанрларына, халык эпосына еш таяналар. Татар халкына гына хас бәет традицияләренә билгеле бер урын бирелә. Аерым шагыйрьләр бездә элек тә бәет иҗат итәләр иде: Н. Исәнбәт, Х. Туфан, һ. б. Бу традиция бүген дә дәвам итә. Н. Арслановның «Устиния бәете»ндә сүз 18 яшьлек Устиниянең ире Е. Пугачев белән нибары ике атна торганнан соң Әби-патша тарафыннан гомерлек төрмәгә утыртылуы турында бара:

**Бары ике атна торган**
**Ир белән бергә,**

**Соңра урыны тәрмә булган**
**Гомер-гомергә...**

Әсәрнең эчтәлегенә, гомум яңгырашына хас көчле трагизм аның халык бәетләре белән бәйләнештә иҗат ителүен раслап тора.

Г. Афзалның «Тарих мең дә...» шигырендә дә бәет традицияләре уңышлы дәвам иттерелә. Анда сүз татар халкының культура тарихында китапның роле турында бара. Ара-тирә шагыйрь аерым бәетләр эчтәлегенә туктала. Халык иҗаты мотивлары шагыйрьнең иҗади максатларына буйсындырыла. Нәтиҗәдә бәет стиле белән үрелеп килгән шигырь барлыкка килә:

**Тарих мең дә...**
**Алпавытның йорты янды.**
**Пристав килде, Хәтмулладан допрос алды...**
**Урманнарда качкыннар күп.**
**Карья белде...**
**Галләм кызы чибәр Гайшә батып үлде...**

Күрүебезчә, тарихка игътибар арту белән бергә язучы-шагыйрьләрнең уй-фикерләре тарихи фольклорга юнәлтелә. Төрле тарихи шәхесләргә багышланган әсәрләр дә шул рухта иҗат ителә. Бер әсәренең жанрын И. Юзеев «Пугачев полковнигы Мәсәгут Гомәров бәете» дип билгели. Әсәрдә сүз, халык бәетләрендәгечә, М. Гомәровның лашманчы булып йөрүе, Пугачау патша турында хәбәр ишеткәч, алпавыт — боярларга каршы баш күтәрүе турында бара:

**Өздем мин коллыкның**
**Мәңгелек чылбырын,**
**Иректә яшәдем**
**Гомеремнең бер елын.**

Халык бәетләре кебек үк, әсәр трагик рәвештә тәмамлана. Пугачев полковнигы мәңгелек каторгага җибәрелә. Әсәр безнең көннәр шагыйре тарафыннан язылган. Димәк, ул бәет традицияләре белән генә чикләнә алмый, аның шигъри образлар системасы, поэтик алымнары шактый катлаулы. Халык бәетләре стиленә шагыйрь заманча яңгыраш бирә:

**Еракта-еракта**
**Торналар чылбыры,**
**Бәхил бул гомеремнең**
**Бәхетле бер елы...**

Мәсәгут батырның иреклектә, комсыз изүчеләргә каршы канлы көрәштә уздырган бер елы әсәрнең үзәк темасына әверелә һәм аның башыннан ахырына кадәр дәвам итә, аңа нур өсти.

Шул ук тема — Пугачев күтәрелеше — Н. Арсланов иҗатына да килеп керә. Ул Пугачев полковнигы Канкаевка багышлап «Канкай углы Бәхтияр» шигырен иҗат итә. Билгеле булганча, бу тарихи шәхес турында халык арасында да тарихи җырлар йөри. Бу хакта С. Алишев та язып чыккан иде[1]. Узган гасыр урталарында шул ук батырга багышланган «Бәхтияр турында җыр»ның эчтәлеге русча тәрҗемәдә дә басылып чыга[2].

Ләкин Н. Арсланов шигырен тарихи җырларга нигезләнгән дип әйтүе кыен. Шигырь бәет һәм тарихи җыр традицияләрен берләштерә кебек. Аның беренче юллары бәет башламнарын хәтерләтә:

**Тарих мең дә җиде йөз дә**
**Җитмеш өчтә — данлы елда**
**Чыктың, батыр Канкай углы,**
**Пугач белән канлы юлга.**

Бәхтиярнең батырлыгы хакында шагыйрь бәет рухында тәфсилләп сөйли. Шигырьнең кушымталары исә тарихи җыр, хәтта дастан стилендәрәк яңгырый:

**Бәхтияр, Бәхтияр!**
**Азатлыкка идең яр,**
**Искә алыр илең бар,**
**Горурланыр затың бар,**
**Канкай батыр дигән атың бар!**

---

[1] «Казан утлары», 1968, 1 сан, 109—115 битләр.
[2] Вестник Императорского Русского Географического Общества, 1858, часть XXIV, 226—227 битләр.

Фольклорның борынгы төрләре арасында дастаннар аеруча әһәмиятле урын алып торалар. Дөрес, соңгы елларда халык теленнән язып алынган дастаннарның күпчелеге әлегә басылып чыкмаган. Шулай да дастаннарга игътибар торган саен арта бара. Поэзиядә бу төрлечә чагыла. Әйтик, бүгенге шигырьләрдә безгә күптән билгеле Алып, Таһир-Зөһрә, Ләйлә-Мәҗнүн, Йосыф-Зөләйха исемнәре ярыйсы ук еш очрый. Гадәттә бу геройлар турында киң мәгълүматлар бирелми, ул исемнәр укучыларга яхшы таныш булганга күрә генә кулланылалар кебек. Тик аерым очракларда гына дастан геройларына багышланган махсус шигырьләр иҗат ителә. Бу яктан Арслановның «Баян-Сылу» шигыре аеруча игътибарга лаек. Билгеле булганча, Баян-Сылу — төрки халыкларда, шул исәптән Себер татарлары арасында да киң таралган «Кузы-Көрпәч белән Баян-Сылу» дастанының героинясы. Казакъ халкында Баян-Сылу турында бүгенге көнгә кадәр гүзәл легендалар йөри. Н. Арсланов әсәре нәкъ шул легендаларның берсенә нигезләнә.

Бөтен җирдә Баян-Сылу —
Әкиятләрдә хәйран сылу,
Яши һаман күңелләрдә,
Күчеп илләр, гомерләргә.

Бүгенге поэзиядә чагылыш тапкан дастан төсмерләрен ачыклау авыр түгел.

Төрки эпос рухын беркадәр күз алдына китерү өчен халык иҗатыннан бер мисалга тукталып үтик. Н. Исәнбәтнең табышмакларга багышланган җыентыгында болгар чорына караган «Сәрвиназ» исемле табышмак-әкият китерелгән[1]. Әкиятнең шигъри өлешендә шундый бер табышмак бар:

Ике бүре бер куй җийде, кан чыгармай,
Яхшы түрә дау бетерә, җан чыгармай,
Уң кулымда алтын йөзек, ал чыгармай,
Табучыга мин тиярмен, мал чыгармай.

Бу өзекнең шигъри үлчәме, ритмикасы һәм рифмалары бер төркем төрки дастаннарның поэтик үзенчәлекләрен шактый тулы чагылдыра. Гомумән алганда, бүгенге поэзиядә төрки дастан стиле сирәк очрый. Күрәсең шунлыктан, яңа күренеш булырак кабул ителә. Поэзия халык эпосының рухын, шигъри асылын, гомуми яңгырашын үзләштерә. Һәм бу хакта аерым шигырьләр нигезендә сөйләргә мөмкин. Мисал өчен Зөлфәтнең «Елтыр гына елтыр» шигыренә тукталыйк. Әсәр укучыда матур тәэсир калдыргандыр. Моның төп сәрләреннән берсе — аның халык эпосы традицияләренә якын торуында булса кирәк. Шигырьнең интонациясе, шигъри яңгырашы башкорт халык җырыннан алынган эпиграфка нигезләнә:

Елтыр гына елтыр утлар яна,
Юлаучыдан калган бер кумер...

Кечкенә генә бер шигъри деталь — юлаучыдан калган бер күмер — безне ерак заманнарга алып китә кебек. Бу хис әсәрне укыган саен тирәнәя бара. Шигъри үлчәме, ритмикасы һәм рифмалары аны халыкның дастан-җырларына якынайта:

И җыр гынам, җырым! Сөйгән җырлар!
Бирсен сезгә язмыш мең гомер...
Җыр бар — димәк, җан бар! Һәр моңлы җыр —
Юлаучыдан калган бер күмер.

Әсәрнең гомуми яңгырашы гына түгел, кайбер конкрет детальләре дә халык дастаннарына авазаш: иле өчен яуга чыккан ирнең акбүз аты; кыргый атны йөгәнләгән ил батыры һ. б. Әсәрдә дастан сюжеты да, эпос геройлары да юк. Ләкин борынгы дастан рухы, дастан аһәңе үзеннән-үзе күңелгә бөркеп тора.

Н. Арслановның «Ал син шәфәкъ болытларын» әсәре дә поэтик стиле ягыннан тулысынча борынгы дастан рухында яңгырый:

Күзең — диңгез, керфегең — бозь, кашың — кыйгач!
Матурлыгың белән күңел күгемне ач,—
Күзләремнән ал син шәфәкъ болытларын,
Ялтыра гел сокландырып, алтын кояш!

Н. Арсланов әсәрләре арасында борынгы дастан рухында язылган шигырьләр аз түгел: «Батырлык турында», «Төшенкелек», «Кырмыскадай көчле» һ. б. Бирәдә иң элек татар халык эпосы йогынтысы төсмерләнсә, икенчедән Урта Азия, бигрәк тә казакъ халкы дастаннарының тәэсире ачык күренә. Соңгысы Н. Арсланов шигырьләренең теле, лексикасы белән дә раслана. Анда казакъ теленнән алынган сүзләр һәм

[1] Исәнбәт Н. Татар халык табышмаклары. Казан, 1970, 438—444 битләр.

сүз әйләнмәләре шактый еш очрый: «Илем-йортым өчен бөтен җан-арманым» (арман — теләк, омтылыш); «Керәшчеләр белән мин дә катардамын» (катар — янәшә); «асау ат» (асау — ярсу, чыгымлы) һ. б.

Гомумән, Н. Арслановның соңгы биш-ун елда язылган шигъри әсәрләре арасында тарихи темага, халкыбызның данлы үткәненә, аның батыр улларына багышланган шигырьләр зур гына урын биләп торалар. Бу үзе бүгенге поэзиянең әһәмиятле бер тенденциясен чагылдыра. Шундый ук үзенчәлекләр, әйтелгәнчә, башка кайбер шагыйрьләр иҗатында да сизелә. Тик Н. Арслановта алар күрәсең, аеруча ачык чагыла.

Халык иҗатында **җыр** сүзе ярыйсы ук киң мәгънәдә йөри: эпик, лиро-эпик һәм лирик шигъри әсәрләр гомуми планда барысы да җыр дип аталалар: җыру-дастан, тарихи җыр, лирик җыр. Шагыйрьләр дә поэзияне җыр дип атаганда халык иҗаты традицияләренә таяналар. Ләкин бүгенге көндә халык иҗатының һәм профессиональ сәнгатьнең конкрет һәм жанр үзенчәлекләре шактый төгәл ачыкланган бер төре генә җыр дип атала. Бу сүзнең мәгънәсе шактый ачык һәм мәгълүм.

Әгәр бәет, тарихи җыр, дастан халык иҗатының борынгы һәм фундаменталь төрләренә керсә, халык җырлары бүген дә киң таралган актив һәм хәрәкәтчән жанрлардан санала. Шуңа күрә алар бүгенге поэзиянең үсешендә дә житди роль уйныйлар. Үз чиратында профессиональ поэзия бүгенге җыр репертуарын баетуда катнаша. Безнең көннәрдә киң таралган җырларның авторлары — халыкның ихтирамын казанган шагыйрьләр: Н. Исәнбәт, Х. Туфан, С. Хәким, Ш. Галиев, И. Юзеев, Г. Рәхим, Г. Зәйнашева һ. б. Аларның җырлары гына түгел, бик күп шигырьләре дә халык лирикасы традицияләренә нигезләнә. Халык җырларына, халык лирикасына иң якын торган һәм аны яңа җәүһәрләр белән баеткан шагыйрьләрнең берсе — Сибгат Хәким. Аның мәшһүр «Юксыну»ы М. Исаковскийның «Катюша»сы белән бер үк вакытта 1938 елда язылган иде. Соңрак халыклашып киткән бу җырлар ярыйсы ук катлаулы иҗади юл үттеләр, аларның дистәләрчә вариантлары туды. Халык аларны үз иҗади җимеше итеп кабул итте.

1947 елда язылган «Фазыл чишмәсе» дә шундый ук популярлык казанды һәм яшьләрнең иң яраткан җырларыннан берсенә әверелде.

С. Хәким лирикасы иң элек проблематикасы, төп мәсьәләләре белән халык җырларына аваздаш. Туган халкының уй-фикерләрен, хис-кичерешләрен, рухи дөньясын йөрәгенә якын кабул итә шагыйрь. Халык бәхете өчен фидакарь хезмәт, борынгы гореф-гадәтләргә һәм изге йолаларга тирән ихтирам, туган илгә, туган җиргә мәхәббәт, саф һәм тирән кичерешләр — С. Хәким поэзиясенең төп проблемалары әнә шулар. Икенчедән, С. Хәким әсәрләренә халык җырларындагы кебек тулы һәм матур яңгырашлы рифма, җиңел һәм җырлап торган ритмика, халыкчан лексика хас.

Ш. Галиев лирикасында да халык җырларына аваздаш мотивлар аз түгел. Ул язган җырлардан соңгы елларда аеруча киң таралып яшьләрнең мәхәббәтен казанганнары — «Утыр әле яннарыма», «Тамчылар тамар чаклар», «Шомырт чәчәкләре ак кына» булса кирәк. Бу әсәрләр халык җырлары рухында язылган. Чын күңелдән чыккан якты юмор аркылы Ш. Галиевның «Шалт Мөхәммәтҗан», «Бар икән күрәселәр» кебек җырлары популярлык казандылар. Аның җырларында балалар фольклоры, такмак-такмаваллар, уен-бию, лирик озын җырлар, дүрт юллыклар, халык мәзәкләре белән бәйләнгән мотивлар еш очрый. Бирегә исә Ш. Галиевның бер үзенчәлекле әсәренә генә тукталып үтик. Сүз «Бер директорның яраткан җырлары» шигыре турында бара:

**Әй, дусларым да гынай, Закир абый,**
**Сезнең белән, Җамалый кода,**
**Шат минем күңелләрем,**
**Сәйфетдин җизни, Якуп агай-эне.**
**Сезнең белән бергә, бер конторда,**
**Җамалый кода, Закир абый, Якуп агай,**
**Үтсә иде лә гомерләрем.**

Шагыйрь бик үзенчәлекле форма кулланган. Әсәрнең яңгырашы керәшен татарларының туй җырларыннан килә кебек.

Утызынчы елларның икенче яртысында язылган җырларында һәм «Хат ташучы» поэмасында М. Җәлил халык җырларыннан әерым әзекләр куллануны үзенчәлекле һәм нәтиҗәле шигъри алым дәрәҗәсенә күтәргән иде. Әнә шул ук алым төсмерләре бүгенге поэзиядә дә, шул исәптән И. Юзеев шигырьләрендә дә очрый. И. Юзеев халык җырларыннан тулы юллар, әзекләр алмый. Ул халык лирикасының кайбер детальләрен, сүзләрен, сүз әйләнмәләрен генә куллана. Әнә шундый детальләр конкрет әсәрнең халык лирикасы белән бәйләнешен раслап торалар. Мәсәлән, «Әтнә истәлеге» шигыре.

**Талир таңкәләрен чылтыратып,**
**Су китерә Әсма апалар.**

**Бураннарда, Әтнә көен җырлап,**
**Уңган кызлар эштән кайталар.**

Әсәрнең ритмикасы һәм рифмалары гына түгел, талир тәңкә чылтыратып су ташучы Әсма апалар, Әтнә көен җырлап эштән кайтучы кызлар да шигырьнең халык җырлары белән аваздаш булуын раслап торалар.

Халык җыры мотивлары И. Юзеев әсәрләренә табигый рәвештә — шагыйрь ихтыярыннан тыш килеп керә кебек. Дөресрәге — халык җырының табигый йогынтысы шагыйрь палитрасының, шагыйрь талантының аерылгысыз бер өлеше булып тора. Мисалга, «Ике малай китә армиягә» шигыреннән бер өзек алыйк:

**Без китәбез инде, соң булыр...**
**Язгы җилләр исәр,**
**Исегезгә төшәр,**
**Бездән сезгә сәлам шул булыр.**

Бу өзекнең гомуми яңгырашы, ритмикасы һәм рифмалары халык лирикасы йогынтысыннан килә дип булмый. Ә инде строфаның соңгы юлы һичшиксез халык җырларыннан алынган һәм әсәрнең матур яңгырашлы табигый өлешенә әверелгән. Әсәргә автор мондый искәрмә бирә: «Яшьләр тарафыннан көй чыгарылган. Авторы билгесез». Димәк, ул билгеле бер дәрәҗәдә халык җырына әверелгән. Ләкин шагыйрь халык лирикасыннан алынган деталь-мотивларны әсәренә өстәп кую белән генә чикләнми. Ул аларны үзенең иҗади максатларыннан чыгып үзгәртә, баета, катлауландыра.

И. Юзеев әсәрләрен тагы бер тапкыр укып чыккач һәм аларны башка шагыйрьләрнең әсәрләре белән чагыштырып карагач, шундый бер бәхәссез нәтиҗәгә киләсең: олы, урта буын һәм яшь шагыйрьләр халык иҗатына, аеруча халык җырларына зур ихтирам белән карыйлар, аларны үз әсәрләре өчен үрнәк, рухландыргыч чыганак дип саныйлар.

Бүгенге поэзия әсәрләренең халык җырлары белән бәйләнеше турында сөйләгәндә мисалларга аптырап торасы юк. һәрбер шагыйрьнең әсәрләре ахыр чиктә кайсы ягы беләндер халык иҗатына, халык эстетикасына барып тоташа.

Безнең көннәрдә халык иҗаты белән профессиональ сәнгатьнең үзара мөнәсәбәте катлаулана. Халыкның тарихы, рухи тормышы бүгенге поэзиянең төп проблемаларыннан берсенә әверелә. Поэзиядә барган әһәмиятле үзгәрешләр халык иҗаты белән мөнәсәбәтләргә дә сизелерлек йогынты ясый. Шагыйрьләребез илдә барган әһәмиятле тарихи-социаль процессларга, заман героеның тирән хисләренә, нечкә кичерешләренә, катлаулы рухи яшәешенә, ил һәм халык бәхете өчен көрәшенә зур игътибар бирәләр. Заман героеның рухи дөньясын гәүдәләндерү өчен шагыйрьләр халык дастаннары, риваять, легенда, бәет һәм тарихи җыр традицияләренә мөрәҗәгать итәләр. Халык иҗатының һәрвакыт заманча яңгыраган гүзәл җырлары шагыйрьләрнең поэтик осталыкларын яңа баскычка күтәрергә ярдәм итәләр.

Флүн Мусин

# ТОРМЫШКА АКТИВ МӨНӘСӘБӘТ

Заман герое...

Болай без аны беләбез, яхшы белергә тиешбез кебек. Чөнки ул безнең арада яши, без сулаган һаваны сулый, аны да безне үк борчыган уйлар били. Кыскасы, ул безнең замандаш. Шуңа да карамастан, һаман бер сорау кабатлана: «Кем соң ул заман герое. Тормышта ничек тә ул, әдәбиятта ничек күрсәтелә?» Сорауга төрле-төрле җаваплар ишетергә туры килә. Җитмәсә, тагын бу мәсьәлә тирәсендә еш кына бәхәсләр кабынып китә, зур-зур сөйләшүләр булып ала. Икенче төрле әйткәндә, замандаш герой, аны әдәбиятта ничек күрсәтү мәсьәләләре һәрвакыт әдәби җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгендә тора, аны уйландыра, тынгылык бирми, бертуктаусыз эзләнергә мәҗбүр итә...

Заманчалык — әдәбиятның яшәү көче һәм нигезе ул. Хәзерге тормышка багышланган әдәбиятның заманчалыгы аның бу чынбарлык белән никадәр тыгыз элемтәдә булуы, аны никадәр тирән белүе һәм күрсәтүе белән бәйләнгән. Ачыграк әйтсәк, сүз биредә заманның рухын һәм сулышын, төп үсеш тенденцияләрен һәм закончалыкларын чагылдыру турында бара.

Соңгы вакытта замандаш геройның тормышка мөнәсәбәтенә яки тормыштагы позициясенә аеруча дикъкать ителә. Чөнки кешенең ничек, нинди уй-омтылышлар һәм мәнфәгатьләр белән яшәве, тормышта үзен ничек тотуы, үзенең гражданлык вазифаларын ничек үтәве безнең көннәрдә үзгә бер актуаль һәм принципиаль төс ала. Катлаулы һәм киеренке заманыбыз кешеләренең мещаннарча битарафлык һәм ваемсызлыктан азат булуларын, иҗтимагый-рухи актив тормыш белән, җәмгыять алдындагы бурычларын тирән тоеп, аларны үтәргә омтылып яшәүләрен таләп итә. Гармонияле шәхес тәрбияләүне партия үзенең программ документларында чорыбызның мөһим идеологик бурычы итеп куя һәм аны тормышка ашыруда әдәбият-сәнгатьнең роле зур булуын күрсәтә.

Бөтен совет әдәбиятындагы кебек, хәзер татар әдипләре иҗатында да заман героен сурәтләүдә үзара тыгыз бәйләнгән ике тенденцияне күзалларга мөмкин. Бер өлеш авторлар бу геройның социаль актив эшлекле шәхес булуын ачуга күбрәк дикъкать итәләр. Еш кына хәзерге хуҗалык җитәкчеләре алына һәм аларның характер сыйфатлары башлыча производство җирлегендә, гомуми эшкә мөнәсәбәттә ачыла. Бу тенденцияләрнең хәзерге рус прозасында да көчәюен искәртеп, тәнкыйтьче Ю. Кузьменко, мәсәлән, андый әсәрләрдә «эш, производство сферасы элек-электән килә торган кеше драмаларын күрсәтү өчен фон гына булып хезмәт итми. Ул уртак эш белән бер коллективка берләшкән бик күп кешеләрнең чын тормышын тәшкил итә. һәм ул шулкадәр кызыклы, шулкадәр киеререшләр һәм борчылулар белән тулган ки, аны һәртөрле гаилә коллизияләре һәм мәхәббәт тарихлары белән бизәүнең бернинди кирәге юк»[1], — дип белдерә.

Хезмәт темасын болай үзалдына яктыртулары, геройны башлыча эшкә мөнәсәбәттә күрсәтүләре белән хәзерге әсәрләр, беренче карашка, утызынчы яки кырыгынчы елларның мәгълүм «производство» романнарын хәтерләтәләр кебек. Чынлыкта исә хәзер «производство» темасын яктыртуның, геройны хезмәттә күрсәтүнең максатлары шактый үзгәргән. Әгәр үткәндә болар еш кына ничектер үзмаксатка әверелсә яисә производство «маягының» хезмәттәге гадәттән тыш батырлыкларына, казанышларына дан җырлау максатын алга сөрсә, хәзерге әсәрләрдә исә хезмәт дөньясы авторлар тарафыннан заманның мөһим иҗтимагый-политик һәм әхлакый мәсьәләләрен яктырту өчен ныклы җирлек итеп карала.

«Производство» темасын яктыртудагы мондый үзгәрешләр татар язучылары әсәрләрендә дә торган саен ачыграк күзаллана. Аларда хәзерге хуҗалык үсеше, бу процесс белән идарә итү мәсьәләләренә игътибар арта. Бу хәл безнең язучыларның тормыш белән бәйләнешләре ныгуын, аның өлгергән мәсьәләләренә һәм конфликтларына дикъкатьләре артуын күрсәтә.

Язучыларны хуҗалык итү мәсьәләләренең әхлакый ягы күбрәк кызыксындыра. Хәзерге хуҗалык җитәкчесе шәхесе аларның игътибарын беренче чиратта аның үз хезмәтенә мөнәсәбәте, аны ничек башкаруы ягыннан җәлеп итә.

Хәзерге эре промышленность производствосы җирлегендә мондый мәсьәләләрне, минемчә, драматург Д. Вәлиев аеруча актив һәм заманча яңгырашлы итеп яктырта. Аның «Дәвам» һәм «Диалоглар» пьесаларында вакыйга безнең көннәрнең иң зур

[1] «Октябрь» журналы, 1979 ел, 2 сан.

төзелешләреннән берсендә бара. Автор игътибары «кеше һәм аның эше» мәсьәләсенә юнәлтелгән. Геройның үз эшенә мөнәсәбәте аша драматург аның иҗтимагый-әхлакый йөзен, тормыштагы позициясен ача. Кешенең үз эшенә карашын ачу ягыннан «Дәвам» пьесасындагы төзелеш начальнигы Байков образы кызыклы.

Пьесада эре төзелешләрдә нигез салуның яңа ысулы тирәсендә туган ситуация игътибарга лаеклы. Аны талантлы инженер Сатынский тәкъдим итә. Геройларның бу прогрессив һәм отышлы ысулны куллануга мөнәсәбәтләре аша автор ахыр чиктә аларның тормышта төрле позицияләрдә торуларын ача. Проект институты директоры Пыпин өчен, мәсәлән, гомум эш түгел, ә үз институтының ялгыш аңланган «намусын» саклау әһәмиятлерәк. Институт маркасына тап төшермәс өчен ул дәүләт интересларын корбан итәргә әзер. Шул нигездә пьесада кешенең үз эше өчен җаваплылыгы мәсьәләсе күтәрелә.

Бу мәсьәлә Д. Вәлиевнең «Диалоглар»ында тагын да кискенрәк төстә куела. Безнең көннәрдә җаваплылык мәсьәләсенең бермә-бер актуальләшүен автор пьесаның үзәк герое — куәтле йөк ташучы машиналар җитештерәчәк яңа эре комплексның генеральный директоры Гладких сүзләре белән болай аңлата: «Фән-техника революциясе шәхеснең җәмгыятьтәге хәлен үзгәртте. Эш шунда ки, минем яки синең дәрәҗәдәге аерым кеше кулына хәзер еш кына бөтен җәмгыять тарафыннан тудырылган гаять зур көч-куәт бирелә. Ә ул бу көч-куәтне шәхси җаваплылыгына яки җавапсызлыгына бәйле рәвештә төрлечә кулланырга мөмкин».

Бу хакыйкатьне тирәнтен аңлау Гладкихта үзенә тапшырылган дәүләткүләм әһәмиятле эш өчен зур җаваплылык хисе тудыра. Бу хис, үз чиратында, геройга мөһим мәсьәләләр турында сүз барганда инициативалы, кыю һәм принципиаль булырга булыша. Гладкихның хәлиткеч сыйфатлары төзелештә туган бик катлаулы һәм киеренке ситуациядә ачылалар. Комплекс гаять зур суммага төшереп төзелә. Әмма проектлаштырудагы җитди хаталар аркасында яңа комплексның җитештерүчәнлеге түбән булачагы, ә ул чыгарачак машинаның инде проектта ук заман таләпләренә җавап бирмәве ачыклана. Әйтергә кирәк, биредә Д. Вәлиев бүгенге көндә бик актуаль яңгырый торган мәсьәләне кузгата. Машина төзелеше өлкәсендәге мондый кимчелекләр турында партия Үзәк Комитетының 1979 елгы Ноябрь Пленумында да җитди сүз булган иде.

Сәбәп нәрсәдә соң? Төп сәбәпләрнең берсе: аерым җитәкче иптәшләрнең үзләренә тапшырылган эшкә тиешле җаваплылык белән карамауларында, диелде Пленумда.

Д. Вәлиев пьесасында да шушы җаваплылык, үз эшенә дәүләт интереслары күзлегеннән чыгып карый алу хәзерге кешенең мораль-политик йөзен билгеләп торган мөһим фактор итеп үзәккә куела. Шушындый сыйфатка ия булган Гладких завод-гигант сафка кергәнче проекттагы кимчелекләрне төзәтү, искергән модельне яңа, камилрәк модель белән алыштыру мәсьәләсен күтәреп чыга.

Бер төркем проза әсәрләрендә эшлекле герой образы авыл материалына нигезләнеп яктыртыла. Әйтергә кирәк, авыл җитәкчесе элек-электән татар әдипләренең игътибарын җәлеп итеп килә. Бу шәхесне төрле буын язучылары тарафыннан сәнгатьчә гәүдәләндерүдә әдәбиятыбызның кайбер үсеш тенденцияләрен чагылдыра торган кызыклы бер эволюция күз алдына килә.

Татар совет прозасында беренчеләрдән булып бу мәсьәләне үзенең «Тирән тамырлар» романында Г. Ибраһимов яктыртты. Әсәрнең үзәк герое Фәхри образында авыл йөген төпкә җигелеп тарткан крестьян юлбашчысы күрсәтелде.

Шул ук вакытта әсәрдә җитәкче геройның масса белән аерылгысыз бәйләнештә яшәвенә дикъкать ителә.

Утызынчы еллар башында, әдәбият коллективлаштыру хәрәкәтенә йөз белән борылгач, күп кенә әсәрләрнең үзәк герое рәвешендә икенчерәк төр җитәкче чыгыш ясый. Хәзерге терминология белән әйтсәк, ул читтән килгән кеше иде. Мәсәлән, Ф. Сәйфи-Казанлының «Өч нарат» романында, М. Әмирнең «Безнең авыл кешесе», Г. Толымбайның «Түбән Елгада» повестьларында һ. б. күптән түгел читтән килгән яңа җитәкченең, яңа гына аякка басучы яшь колхоз яки совхозны ныгыту өчен бик кыю көрәшеп, әкренләп башта кырын караган кешеләрнең ышанычын һәм ихтирамын яулавы, «безнең авыл кешесе»нә әверелүе сурәтләнә. Соңрак язылган әсәрләрендә дә җитәкче геройлар шундый ук юл үтәләр. Аерма тик шунда, боларында (мәсәлән, Ф. Хөснинең «Утызынчы ел» һәм С. Рәфиковның «Беренче яз» романнары) әлеге юл яки процесс психологик яктан төгәлрәк һәм дәлилләбрәк күз алдына бастырыла.

Сугыш чоры авылы турындагы әсәрләрдә (мисал өчен М. Әмирнең «Миңлекамал» драмасында яки Г. Бәшировның «Намус» романында да), Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ындагы кебек, крестьян массасыннан күтәрелгән җитәкче кабат күрсәтелә. Бу хәлне авторлар сугыш чорының кырыслыгы, ил, халык алдындагы җаваплылык хисенең үсүе белән бәйләп аңлаталар.

Колхоз җитәкчесен сурәтләүдәге бу тенденция илленче еллар башында язылган һәм сугыштан соңгы авылга багышланган әсәрләрдә дә өстенлек итте. Күп кенә авторлар күнегелгән гадәт буенча сугыш елларына хас идея-эстетик карашлардан чыгып фикер йөртүләрен дәвам иттеләр. Алар әле һаман геройны реаль мохиттан, тормыш шартларыннан өстен куялар, күбрәк аның ихтыярый сыйфатларын ачу белән кызыксыналар иде. Нәтиҗәдә, җитәкче геройның реаль чынбарлык белән бәйләнеш-

ләре йомшак була, аның образы автор ихтыярына буйсындырылып һәм тормыш логикасыннан аерылган сыман күз алдына китерелә иде.

Алтмышынчы елларда язучылар яңадан сугыштан соңгы авылга әйләнеп кайталар. Бу хәл байтак дәрәҗәдә партиянең авыл хуҗалыгы турындагы карарлары чыгу белән бәйләнгән иде. Ул карарлар язучыларда авыл чынбарлыгын тарихи конкретрак белү теләген көчәйттеләр. Әдипләрнең колхоз җитәкчесен сурәтләүгә дә карашлары үзгәрә төште. Хәзер алар бу геройны объектив чынбарлык белән тыгыз бәйләнештә, тормыш логикасына таянып күрсәтә башладылар. Герой үзе дә авылның реаль хәлен, экономик шартларын яхшырак белеп эш итә. Мондый җитәкче беренчеләрдән булып А. Расихның «Язгы авазлар» романында урын алды. Соңрак бу мәсьәлә белән Г. Ахунов, В. Нуруллин, М. Хәбибуллин, Х. Хәйруллин һәм башкалар якыннан кызыксындылар. Әле соңгы елларда гына язылган әсәрләрдән В. Нуруллинның «Аккан су юлын табар» повесте игътибарны җәлеп итә. «Күлләр чыкканда» повестендагы кебек, биредә дә автор колхоз председателен якыннан, аның тормышына һәм рухи дөньясына үтеп кереп сурәтләргә алына. Әсәрнең хикәяләү формасы да шушы максатка хезмәт итә. Повестьта председатель Булат Вәлиевнең балачактан алып бөтен тормыш юлы колачланса да, авторның игътибар үзәгендә колхоз җитәкчесе. Әйтергә кирәк, бу мәсьәләгә башка әдәбиятларда да дикъкать ителә. Биредә мисал рәвешендә ике әсәргә тукталасы килә. Рус язучысы В. Кожевниковның «Кырым минем» повестенда элекке фронтовик, хәзер колхоз председателе Никитинның үзен бүген дә көрәш кырындагы солдат итеп тоюы күрсәтелә. Колхозчы Мишинның: «Синең тормышың һаман да фронттагы кебек, тынгысыз» — дигән сүзләренә председатель болай дип җавап кайтара: «Ул вакытта без җир өчен сугышкан идек, хәзер аңа үзебезнең бөтен көчебезне бирергә тиешбез».

һәм хәзер икмәк фронтында көрәшүче Никитинның колхоз эшенә, игенче хезмәтенә мөнәсәбәте байтак дәрәҗәдә аның сугышчан үткәне белән билгеләнә. Аның уенча, бу хезмәт һаман да шул солдат намуслылыгын һәм фидакарьлеген сорый.

В. Кожевников геройларының тагын бер сыйфаты игътибарны җәлеп итә. Эшлекле шәхесләр булулары, үз эшләрен яхшы башкарулары белән бергә, алар фикерле дә беләләр, фикер ияләре булып алга басалар. Кыскасы, «Кырым минем» повесте геройларын хәзерге хуҗалык җитәкчесе буларак характерлый торган әһәмиятле сыйфатлар эшлеклелек һәм интеллектуальлектән гыйбарәт.

Үзбәк язучысы П. Кадыйровның «Мирас» дигән повестенда исә җитәкче геройның үз эшенә җаны-тәне белән бирелгәнлеген ачуга басым ясала. Ялкын Атаҗановның гомум эш өчен янып яшәү, үз-үзеңне аямыйча эшләү кебек сыйфатларын ачу өчен автор аның гади механизатордан алып совхоз директорына кадәр тормыш һәм хезмәт юлын күз алдына бастыра.

Ялкын кешенең тормышка иҗади актив мөнәсәбәттә булуын яклый. һәм түбәндәгечә фикер йөртә: «Халыкның көче нәкъ менә шундый үз-үзен аямыйча эшли торган кешеләрдә, аларның тырышлыгы белән тарих алга бара». Атаҗанов үзен тулысы белән гомум эшкә багышлый. Хезмәт сөючәнлек һәм фидакарьлек сыйфатлары белән кешеләрне меңнәрчә еллар буш яткан даланы үзләштерү өчен кирәренкә көрәшкә рухландыра. Кыскасы, П. Кадыйров повестенда халык арасыннан чыккан җитәкченең шәхси энтузиазмы һәм тырышлыгы белән массаларны үзе артыннан ияртүе күрсәтелә.

В. Нуруллин повестендагы Булат Вәлиев күпмедер дәрәҗәдә Ялкын Атаҗановны хәтерләтә. Булат та колхоз өчен, аның эше алга барсын өчен үз-үзен аямый эшли торган кеше. Аның дөньяга карашларын ачуда авылдашы һәм чордашы Шәйхи Шәрифуллин белән үзара мөнәсәбәтләре мөһим роль уйный.

Әйтергә кирәк, колхоз председателе белән райком секретаре арасындагы конфликт безнең проза өчен һич тә яңа нәрсә түгел. Ул моңа кадәр берничә әсәрдә чагылыш тапты. Характерлы мисаллар итеп А. Расихның «Язгы авазлар» романын һәм Г. Ахуновның «Чикләвек төше» повестен алырга була. Аларда әлеге конфликт тормыштан артта калган секретарь белән заман таләпләрен яхшы аңлап эш итүче алдынгы карашлы колхоз председателе арасында туа. Мондый ситуацияне авторлар аерым чор белән бәйләп яктырталар иде. Ә безнең көннәр авылына мөнәсәбәттә моның кебек конфликт инде үзен аклап бетермәс, дөресрәге, чынлыкка туры килмәс иде.

В. Нуруллин моны яхшы аңлаган, күрәсең. Чөнки аның повестенда конфликт башкарак җирлектә туа һәм икенчерәк яңгыраш ала. Бер авылда туып-үскән Булат белән Шәйхи арасындагы каршылык аларның егет чакларында ук барлыкка килә. Төп сәбәпләрнең берсе Шәйхинең яшьтән ук үз-үзен артык сөючән, һәр нәрсәдә башкалардан өстен торырга тырышкан зат булуы белән бәйләнгән. Айсылуның аның ихтыярына буйсынмыйча Булатка кияүгә чыгуы Шәйхинең мин-минлегенә китереп суга. һәм шуннан соң ул Булатны дошман күрә башлый. Шәхси планда башланган шушы каршылык соңыннан, геройлар икесе дә җитәкче булып эшли башлагач, тагын да тирәнәя һәм аларның иҗтимагый мөнәсәбәтләренә дә күчә. Шәйхинең мин-минлеге тора-бара аны түзәлмәс эгоистка әверелдерә һәм ул үзенең эш урыныннан да шушы максатта файдалана башлый. Райком секретаре булып алгач ул Булатка астыртын рәвештә төрлечә аяк чала, аны кимсетергә, кыерсытырга тырыша. Гомумән, шәхси сәбәпләр аркасында барлыкка килгән каршылык соңыннан геройларның тормыштагы позицияләре төрле булуга нигезләнгән принципиаль конфликт дәрәҗәсенә үсә. Бе-

тен җаны-тәне белән гомум эшкә бирелгән, хезмәтчел тормыштан тәм дә, ямь дә табып яшәгән Булат белән мондый сыйфатлардан мәхрүм булган һәм һәркайда шәхси мәнфәгатьләрен беренче планга куйган Шәйхи арасында килешү мөмкин түгеллеген укучы да яхшы аңлый. Аның симпатиясе, әлбәттә, Булат ягында. Чөнки ул аңарда алдынгы замандашыбызны, олы идеалларга хезмәт итеп яшәгән, актив тормыш позициясенә ия булган шәхесне күрә. Әгәр Шәйхи бер төрле сөйләп икенче төрле эшләсә, Булатка сүз белән эшнең берлеге хас.

Булат Вәлиевне чын мәгънәсендә заман герое итә торган тагын бер әһәмиятле момент, аның тормыштагы интереслары күплеге, төрле-төрле уй-борчулар белән яшәвеннән гыйбарәт. Бу яктан ул моңа кадәр безнең прозада тасвирланган кайбер председательләрдән дә аерылып тора кебек. Булат коеп куйган производственник кына түгел. Ул хәзерге тормышның, бигрәк тә авыл чынбарлыгының төрле-төрле мәсьәләләре турында уйланып, борчылып яши. Бервакыт районнан кайтканда беркайда эшләмичә тәртип бозып йөрүче егетләр белән очрашкач, аны мондый уйлар биләп ала: «Тормышыбыз әйбәт хәзер, бер баланы гына түйдырып торырга була дип, инде егермегә җиткәч тә эшләтмичә, эшкә өйрәтмичә асрап яту кая алып барып чыгар икән безнең ул балаларны? Ә бит безнең эшләрне дәвам итәргә һәм безгә караганда яхшырак дәвам итәргә тиешле кешеләр алар. Шунсыз җәмгыятьтә үсеш юк. Шунсыз тормыш алга бара алмый. Ә безнең, шагыйрь Гамил Афзал әйтмешли, өф-өф итеп үстергән, юньле-башлы белем алмаган, яшьтән нинди дә булса берәр һөнәргә өйрәнмәгән ул балаларыбыз ничек итеп башкара алыр икән үз өсләренә төшкән шул тарихи миссияне?...»

Булат мондый күңелсез күренешләр турында уйланып, борчылып кына калмый, бәлки кулыннан килгәненчә алар белән көрәшергә дә тырыша. Чөнки ул бу дөньяда битараф кеше түгел, киресенчә, үзен һәр нәрсә өчен җаваплы сизә.

Кешенең мораль-политик йөзен, тормыш позициясен билгеләүдә аның семья һәм мәхәббәт өлкәсендә үз-үзен ничек тотуы мөһим роль уйный. К. Маркс ир кешенең хатын-кызга мөнәсәбәтендә кешенең кешелек асылы аеруча ачык һәм конкрет чагылуы турында язган иде. Безнең көннәрдә кешене бәяләүдә бу факторның роле тагын да арта.

А. Расих «Сынау» романында үзенең геройларын нәкъ менә семья һәм мәхәббәт җирлегендә сынарга алына. Һәм бу сынау алар өчен бик катлаулы, хәтта фаҗигале төс ала. Сүз биредә әлбәттә, карт профессор Галиәкбәр, Әлфия белән Сафура, Әлфиянең сөйгәне Фәрит турында бара.

Романда Сафураның тормыш драмасы дәлиллерәк ачыла кебек. Аны автор героиняның яшәү максаты һәм принциплары белән бәйләп аңлата. Менә Сафура бервакыт ничек яшәү турында уйлана: «Нәкъ бик күп мәхлуклар кебек бөкереңне чыгарып эшләргәме, яшьлекнең, инде озакламый шиңеп саргаячак яшьлекнең, соңгы көннәрендә матурлык, гүзәллек чорының бары бер генә тапкыр була торган рәхәтеннән ваз кичәргәме?» Әмма бу сорауга аның һич тә уңай җавап бирәсе килми. Чөнки ул кеше «дөнья ни куша» формуласы буенча түгел, ә «ни телим» формуласы буенча яшәргә тиеш диган караштa тора. Сафураның «ни телим» дигәне исә бары бүгенге көн белән, бары үзең өчен һәм тән рәхәте өчен генә яшәүне күздә тота. Күренә ки, Сафура образында хәзерге тормышта әледән-әле очрый торган кеше тибы гәүдәләнә. Шул ук вакытта автор мәсьәләнең икенче ягы белән дә кызыксына. Сафура кебек үз рәхәтен генә кайгыртып, рухсыз һәм мәгънәсез яшәүчеләр каян хасил була соң? Бу хакта бигрәк тә Сафураның әтисе Галиәкбәр уйлана. Башта бик сәләтле булып күренгән кызының соңыннан шундый юлга басуының сәбәпләрен ул семьядан да, мәктәптән дә эзләп карый. Семьяда дияр идең, «барлык гомерләрен хезмәттән ямь табып, дәртләнеп, янып» яшәгән әти-әнисе Сафура белән Әлфияне «үз генә дә аермый кайгыртып, икесен дә яратып, җәмгыятькә файдалы кешеләр булып үссеннәр» дип тәрбияләгәннәр. Галиәкбәр мәктәптә дә кызына кире тәэсир итәрлек җитди сәбәпләр тапмый һәм Сафураның ничек шушы хәлгә төшүен аңларга гаҗиз булып кала. Табигый, бу мәсьәләгә автор да ачыклык кертә алмый. Бары тән рәхәте өчен яшәгән бу чибәр ханымның тормышы соңыннан күңелсез бетәчәгенә ишарә ясау белән тәмамлый.

Романда Фәрит белән, Әлфиянең үзара мөнәсәбәтләрен сурәтләү һәм бәяләү тагын да катлаулырак төс ала. Чөнки биредә бигүк гади булмаган бер мәсьәлә күтәрелә. Семья нинди нигезгә корылырга тиеш? Беренче чиратта, саф мәхәббәткә, дип җавап бирәләр Фәрит белән Әлфия. Семья тормышы саф мәхәббәткә корылырга тиешлеген дәгъва итүне тирә-юньдәгеләр ниндидер бер мәҗнүнлек яки балалык кылануы дип кенә кабул итәләр. Мәсәлән, бу хакта сүз чыккач, Фәрит эшләгән совхоз директоры парторгка елмаеп болай ди:

— Син дә, Җамалиев, яратасың идеализацияне. Нинди мәхәббәт? Ни өчен? Хатыны булган хәлдәме? Сөяркәсе булырга мөмкин, ну нинди мәхәббәт инде ул? Яшүсмер малай што ли ул Фәрит Зарипович?

Фәрит хатынын яратмавын, шуңа күрә аның белән тора алмавы турында сүз башлагач, аның әтисе Зариф та:

— Ә-ә, тагын сафсата! Мәхәббәттә мени эш, тормыш авырлыгын сөйрәргә кирәк. Әллә кеше сөешеп яшәү өчен генә өйләнә, кияүгә чыгамы?! — дип кырт кисә. Аныңча,

Фәрит хатынын яратмаса да, балаларының бәхете өчен түзәргә, семьясын ташламаска тиеш. Герой мондый карашларга каршы чыгарга, семья тормышын яңадан һәм бу юлы инде мәхәббәт законына нигезләнеп корырга тырышып карый, әмма бөтен тырышлыгы бушка китә. Ул сөйгәне Әлфия белән кавыша алмый һәм тормышында бөтенләй юлдан яза.

Гомумән, Фәритнең семья мәсьәләсендә үз-үзен тотышы укучылар арасында бәхәс уятырга, төрле фикерләр тудырырга мөмкин. Берәүләр, һичшиксез, геройның әтисе Зариф абзый карашын якларлар. Фәритнең үз семьясын ташларга теләвен хупламаслар. Чөнки без яхшымы-яманмы семья таркалмаска тиеш, ир белән хатын бер-берсенә түзеп торырга тиешләр дип карарга гадәтләнгәнбез. Мондый караштан чыгып фикер йөрткәндә, Фәритнең семьясын ташларга теләве, әлбәттә, укучылар тарафыннан хөкем ителә ала. Аннан соң биредә геройны семья алдында җаваплылык хисе җитмәүдә дә гаепләргә мөмкин. Белгәнебезчә, шушы хис җитмәү тормышта да кайчак семьяларның җимерелүенә сәбәпче була.

Шул ук вакытта Фәрит белән булган хәлне икенче төрлерәк бәяләргә дә нигез бар. Һәрхәлдә Фәритнең хатыныннан аерылырга теләвен шәхси каприз, җиңел холыклылык билгесе итеп кенә карап булмый. Мондый семьяны тәркатмый яшәтү акланамы икән? Сорауга, минемчә, уңай җавап бирүе кыен. Әсәр ахырында да аңа уңай җавап бирелми. Әтисе сүзен тыңлап һәм балаларны ятим итмим дип Фәрит кабат семьясына кайтып карый, ләкин бушка. Автор бу семья турындагы сүзен «анда тынычлык, татулык һаман тумаган, ир белән хатын дошман булып гомер уздыралар» дип тәмамлый. Кыскасы, А. Расих биредә ахыргача тормыш дөреслегенә турылыклы булып кала, геройлар яшәешен җиңеләйтеп күрсәтү юлына басмый. Алай гына да түгел, ул семья-көнкүреш мәсьәләләренең безнең көннәрдә актуаль төс алуларына һәм аларны хәл итүнең җиңел булмавына басым ясый.

В. Нуруллин повесте белән А. Расих романында замандашларның мораль-политик йөзен, тормыштагы позициясен ачуга аеруча дикъкать ителә. Язучылар бу мәсьәләләрне иҗтимагый хезмәт җирлегендә дә, шәхси-интим өлкәдә дә карыйлар. Авторларның реаль чынбарлыкка якын торырга, геройларның яшәешен бөтен барлыгы һәм катлаулыгы белән күрсәтергә тырышулары сизелә. Боларның барысы нәкъ тормыштагыча, үз кыяфәтендә һәм публицистик пафос белән яктыртыла.

Әлбәттә, бу заман героен сурәтләүнең берденбер алымы түгел. Бу шәхесне сәнгатьчә гәүдәләндерүдә гомумән хәзерге әдәби үсешнең төп тенденцияләре ачык күзаллана. Заман героеның тормыш позициясен идея-әхлакый планда һәм фәлсәфи рухта яктыртуга омтылыш көчәйдә. Бу хәл әдипләрнең иҗат палитрасына да мәгълүм эз сала. Язучылар соңгы вакытта бик төгәл реалистик тасвир чараларын шартлылык алымнары белән тыгыз бәйләргә, аларның синтезына ирешергә омтылалар. Хәзерге күпмилләтле совет әдәбиятында үзен торган саен ныграк сиздерә торган бу тенденциягә характерлы мисал итеп ике әсәр — грузин язучысы Н. Думбадзеның «Мәңгелек законы» романын һәм драматург Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасын аласым килә.

«Мәңгелек законы»ның үзәк герое Бачана Рамишвили больницада ята һәм бер үк вакытта өндә һәм төштә, бүгенге көндә һәм үткәндә күрсәтелә. Хикәяләүнең күп планлылыгы геройның шәхси мөнәсәбәтләрдә гаделлек, дуслык, ярдәмчеллек өчен көрәшен төрле яклап һәм эмоциональ көч белән чагылдыруга хезмәт итә. Бачана бик яшьли башлаган бу көрәш аның тормыш позициясен дә билгели. Бик иртә ятим калган Бачана авыр язмышка дучар була. Шушы язмыш аңа олы бер хакыйкатьне аңларга ярдәм итә, аны автор мәңгелек законы дип атый: «Кеше күңеле аның гәүдәсеннән күп мәртәбәләргә авыррак... Ул шулкадәр авыр ки, аны бер кеше генә күтәреп йөртә алмый. Шуңа күрә без, кешеләр, исән вакытта бер-беребезгә ярдәм итәргә, күңелләребезне мәңгеләштерергә тырышырга тиешбез... Шул вакытта гына кеше үлеме безне тормышта ялгызлыкка дучар итмәс».

Гомумән, әсәрдә чын гуманлылыкка, иптәшлеккә һәм ярдәмчеллеккә корылган мәңгелек законы тарафдарлары белән протекционизмны яклаучылар бер-берсенә каршы куела. Беренчеләрен автор гуманоидлар дип атый, ә икенчеләрен кеше кыяфәтенә кергән дуңгыз белән чагыштыра. Шундый символик образлар язучының шартлылык алымнарына мөрәҗәгать итүе турында сөйли. Шушы максатта Н. Думбадзе тагын Бачананың төшләрен актив файдалана. Үз төшләрендә герой әле яңгырга әверелеп чүлне оазиска әйләндерә, әле шул оазиста мәһабәт имән була һәм имәндә кошлар оя корып үрчиләр. Шуннан «тормышның бөек гимны бөтен дөньяга тарала». Геройның тормыш позициясе, яшәү максаты романда менә шулай төрле яклап, төрле планда ачыла.

Тормышка ике төрле мөнәсәбәт Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасында үзгә бер фәлсәфи көч белән чагылдырыла. Биредә шулай ук шартлылыктан уңышлы файдаланыла. Әсәрдә шартлылык белән реальлек үзара шулкадәр органик бәйләнгәннәр ки, хәтта автор фантазиясендә генә туган гадәттән тыш хәлләр дә тормышта чыннан да булуы мөмкин булган гадәти күренешләрне хәтерләтәләр. Менә ни өчен без инде туксанның өске ягына чыккан авыл карты Әлмәндәрнең Әҗәл белән күп еллардан бирле көрәшеп килүен чынга алып күзәтәбез.

Әлмәндәрдәге оптимизм чыганагын драматург аның туган халкының күп гасырлык рухи-әхлакый тәҗрибәсе варисы булуында, халык акылын һәм яшәү фәлсәфәсен үзендә йөртүендә таба. Герой характеры һәм фикерләү рәвешенең халыкчанлыгы да шушы хәл белән бәйләнгәндер, күрәсең. Аңа бигрәк тә халыкның чая юморы һәм тапкырлыгы хас.

Әйтергә кирәк, соңгы вакытта замандашның тормыш позициясен яктыртканда геройны халыкның күптәннән килә торган күркәм традицияләрен дәвам итүче, әүвәлгеләрдән килгән гасырлар сынавын узган көчле оптимизмын үзендә йөртүче итеп күрсәтүгә игътибар көчәя. Бу нәрсәгә бигрәк тә узган яки хәзерге өлкән буыннар вәкилләрен сурәтләгәндә басым ясала. Моңа яңарак мисалларның берсе итеп М. Мәһдиевнең «Кеше китә — җыры кала» повестендагы Шәяхмәт карт образын алырга була. Башка әсәрләрендәге кебек, бу повестенда да штрихлы язу алымына мөрәҗәгать итеп, М. Мәһдиев үз героен аерым детальләр яки тасвирламалар ярдәмендә күз алдына бастыра. Шулардан Шәяхмәтнең үз гомерендә күпне күреп, күпне кичергәнен чамалыйсың. Укучыны ул үзенең кылган эшләре белән генә түгел, бу эшләргә дәртләндергән көчле күңел көрлеге, рухи оптимизмы белән дә җәлеп итә. Боларның тамырлары еракка һәм тирәнгә китә. Автор «кешеләр беркайчан да эзсез югалмыйлар. Аларның эшләгән эшләре, сөйләгән сүзләре, балалары, ул балаларга тапшырган гадәтләре, әхлаклары кала, дәвам итә», ди. Шәяхмәт буыннан-буынга күчеп килгән халык рухын, халык әхлагын үзендә йөртүче, киләчәк буыннарга җиткерүче буларак күз алдына килә.

Кеше тормышта үзен ничек тота, нинди уй-омтылышлар һәм идеаллар белән яши? Бу мәсьәләләр совет язучыларын һәрвакыт тирәнтен кызыксындырып килделәр. Безнең заманда исә шәхеснең тормыш позициясе мәсьәләсе тагын да актуальрәк төс ала. Аны уңышлы хәл итү өчен әдипләрдән хәзер геройның әхлакый йөзенә, яшәү рәвешенә игътибарны көчәйтү сорала. Чөнки кешенең дөньяга мөнәсәбәте, тормыш позициясе турыдан-туры аның яшәешенең әхлакый принциплары белән бәйләнгән һәм хәтта шулар белән билгеләнә дияргә мөмкин. Инде күргәнебезчә, заман героен бу рәвешле сурәтләүгә соңгы вакытта игътибар арта бара. Әдәби практика бу тенденциянең язучылар алдында киң иҗади мөмкинлекләр ачуын, заман һәм шәхес турында зур исәп белән һәм масштаблы фикер йөртергә булышуын күрсәтә. Шикләнмәскә мөмкин, бу юлда әдипләрне яңа күркәм иҗади ачышлар да көтә.

## Туфан Миңнуллин

# ЯШЬЛӘР КОЛАГЫНА БЕР СҮЗ

Ничек язучы булырга? Беренче тапкыр кулына каләм алган кешеләрнең күңелләрендә һәрвакыт шул сорау ята. Ул сорау инде исеме матбугат битләрендә күренә башлаганнарны да борчый. Хәтта Язучылар союзының тулы хокуклы члены булып алгач та ул сорау эзәрлекләүдән туктамый. Чөнки язучы дигән исем эченә гаять зур җаваплылыкны ала. Әдәбиятны, иҗат эшен һәм, ниһаять, үзен хөрмәт иткән бер генә каләм иясе дә менә мин язучы дип мактанып, әтәчләнеп, күкрәк киереп йөрми. Әгәр дә мин ничек язучы булырга дигән сорауны куям икән, күп белдекләнеп кемнәрнедер өйрәтергә җыенудан түгел. Бу мәкаләм язу эшендә азмы-күпме тәҗрибәсе булган, ул эшнең авырлыгын, кыенлыгын, җаваплылыгын татырга өлгергән, әдәбият кыйбласына карап атлаганда абынган-сөртенгән, ничек язучы булырга соң дигән сорауга мең төрле җавап эзләп газапланган кешенең чираттагы уйлануларыннан гына гыйбарәт. Әгәр дә мин урыны-урыны белән тиеш, кирәк дигән сүзләр ычкындырам икән, ул сүзләр үземә дә кагыла.

Язучы булыр өчен адәм баласына табигать биргән аерым бер сәләт булырга тиеш диләр. Шулайдыр, тумыштан ук колагына аю баскан кешедән композитор, музыкант яисә җырчы чыкмыйдыр. Рәссам күзләренең төсләр спектрын аеру, кушу сәләте «синдәй, миндәй»дән үзгәрәктер. Артистларга да теге яки бу образга кергәндә шуңа ышана белү һәм бүтәннәрне ышандыра алу сәләте тумыштан ук биреләдер. Язучы да образлар белән эш итә. Дөньяны бүтәннәргә караганда икенче төрлерәк кабул итәдер, фантазиягә бүтәннәргә караганда баерак буладыр. Ул инде каен агачына яхшы яна торган утын, балта сабы ясар өчен шәп материал яки мунча себеркесе дип кенә карамыйдыр. Аның матурлыгына чын күңелдән сокланып, яшел шәлен ябынган сылу кыз, сафлык, аклык, мәхәббәт символы итеп тә күрә һәм гомере буе башкаларны шуңа ышандырырга тырышадыр. Мин бу очракта табигать серләрен аңлатырга уйламыйм. Кулымнан да килми. Кемгәдер ниндидер сәләт биргән икән, рәхмәт табигатькә. Габдрахманга яки Габдуллага язучылык сәләте бирү-бирмәү аның эше икән, аңа калсын.

Сүз табигать биргән сәләтне ничек файдалану, үстерү, камилләштерү турында барачак. Анысы инде кешеләрнең үз кулларыннан килә торган эш.

1979 елның май аенда КПСС Үзәк Комитеты «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында» карар кабул итте. Бу олы мәгънәгә ия карарны без барыбыз да дикъкать белән укып, өйрәнеп күңелләрдән кичердек. Шул карар буенча максатларыбызны тагын бер кат ачыкладык. Ул безгә эшебезнең җаваплылыгы турында тагын бер мәртәбә искә төшерде. Чынлап та, безгә — язучы исемен йөрткән һәм йөртәчәк кешеләргә зур миссия тапшырылган — кеше күңелен тәрбияләү бурычы йөкләтелгән. Кеше күңелен тәрбияләү, аның рухын саф, камил итәр өчен без үзебез кемнәр булырга тиеш соң?

**Җаваплылык, фидакарьлектән башлыйк.** Язучының каләме ифрат көчле корал. Кайвакыт ул каләм язган бер җөмләнең дошманга каршы көрәшкәндә тулы бер армияне алыштыруы мөмкин. Борын заманнарда көнчыгыш илләрендә ханнар, шаһлар, солтаннар үз сарайларында махсус шагыйрьләр тотканнар. Шагыйрь үзенең сүзе белән аларның, алар идарә иткән илнең иминлеген сакларга тиеш булган. Чын шагыйрьләр халыкны изүче явыз патшаларга мәдхия җырлаудан баш тартканнар, башларының киселәчәген белгән хәлдә дә халыкны яклаганнар. Рус патшасы Николай бөек Пушкинны «кулга ияләштерер» өчен күпме көч салган. Ачлыкны, ялангачлыкны үз җилкәсендә татымаган, аның ни икәнен дә белмәгән дворян баласы Пушкин «тәти»ләргә алданмаган. Ул рус халкының ирегең үзенең шәхси мәнфәгатеннән югары куйган. Чөнки ул шагыйрь булган, халык, кешеләр алдындагы җаваплылыгын тойган. Сөргенгә сөрелгән, әмма идеалларыннан баш тартмаган. Шуның өчен дуэльдә үтерелгән.

Табигать биргән сәләте белән хаксызлыкны яклап шигырьләр язса, татар байлары Тукайны бал-май эчендә йөздерергән булырлар иде. Затлы фаэтуннарга гына утырып кунактан-кунакка йөрер иде шагыйрь, чахоткадан кибеп-корып үлмәс иде. Ләкин Тукайның шагыйрьлеге залимнәргә баш идермәгән. Халкы изелгәндә тук корсак белән кеef-сафа корып йөрүнең җинаять икәнен аңлаган Тукай, мин коеп куйган шагыйрь генә түгел, мин җәмагать эшлеклесе дә, минем күз күпне күрә, колагым күпне ишетә дип, хаклык өчен янып-көеп яп-яшь килеш дөньядан киткән.

Җәлил үндүрт яшьлек малай чагыннан ук үзендә олы сынауларга әзер булырлык рух тәрбияләгән. Һәм ул рух шигырь язарга сәләте булган Җәлилне шагыйрь иткән. Җәлилнең көчле рухы җәлилчеләргә кү-

чеп, алар барысы да үлемне шагыйрьләрчә, кеше дигән олы исемгә аз гына да тап төшермичә каршы алганнар. Күпләргә мәгълүм, дөнья хуҗалары булырга дәгъва кылган фашистлар үзләреннән өстен дип санаган кешеләрне генә гильотинада җәзалаганнар. Димәк, шагыйрь һәм аның көрәштәшләренең батырлыгын, өстенлеген фашистлар да танырга мәҗбүр булган...

Шагыйрь Муса Җәлилнең батырлыгына бүген бөтен дөнья соклана. Аның мисалында миллионлаган яшьләр тәрбияләнә. Испан шагыйре Гарсиа Лорка, чех язучысы Юлиус Фучик, болгар шагыйре Никола Вапцаровларның йөрәк каны белән язып калдырган сүзләрен кемнәр генә белми.

Илен, халкын, иманын саткан түбән җаннар арасында да шигырь яза белүчеләр булгандыр. Ләкин кайда алар? Тарих хәтерләми. Кешеләр аларның шигырьләрен түгел, исемнәрен дә ишетергә теләмиләр.

Әгәр дә, бүген үзебезне язучы дип әйтергә безнең кыюлыгыбыз җитә икән, без бу хакыйкатьне белергә тиешбез. Белү генә аз, ул хакыйкать безнең йөрәгебездә ятарга, кылган гамәлләребез, язган сүзләребез белән идарә итәргә тиешләр. Әлбәттә, безнең яшәү шартлары Пушкин һәм Тукайларныкыдай түгел. Без алар күрергә хыялланган иркеле җәмгыятьтә яшибез. Тормыш та безне Җәлилне сынаган кебек утка салып сынамый. Әмма җир йөзенең бер генә почмагында булса да кеше хаксызга рәнҗетелә икән, язучы күңеле тыныч була алмый. Җир йөзендә кискен идеологик көрәш бара. Кешенең хезмәтен, акылын эксплуатацияләп, хәтта кешенең үлеменнән байлык тупларга остарган эшем кешеләре халыклар тигез хокуклы булырга тиеш дигән хакыйкатьне танырга ашкынып тормыйлар. Шул хакыйкатьне тормышка ашырган социализм илләренә корал белән яныйлар, идеологик агу белән акылыбызны томалап, күңелләребезне какшатырга бөтен осталыкларын җигәләр. Без шул идеологик атаканы кире кагып, үзебез һөҗүм итәргә әзер булырга тиешбез. Менә нәрсә ул без язган шигырь юллары, менә нәрсә ул без язган һәрбер җөмлә.

Дөньяда сукмаклар, юллар күп. Ләкин язучы булырга җыенган кешегә бер генә юл бар — кешелек бәхете өчен һәр минут, һәр секунд үзеңне җаваплы итеп тою, бөек хаклык өчен туктаусыз көрәшү. Шушы сыйфатны үзендә тәрбияләмәгән шигырь язучы шагыйрь түгел, хикәя язучы прозаик түгел.

**Белем.** Укуның кирәклеген без инде күптән беләбез, аны бәләкәй чактан ук өйрәтәләр. Ялкауланып, мәктәпкә барырга теләмәсәк, әтиләр, әниләр кулдан җитәкләп илтәләр. Мәҗбүри рәвештә ун классны да тәмамлаталар. Югары уку йортларында укып чыгабыз. Уйлап карасаң, язучы булу өчен, шул җитәдер дә кебек. Кызганычка каршы, кайберәүләр шулай уйлыйдыр да. Җөмлә төзергә, рифмалар табарга хәзер тиз өйрәнәбез. Әдәбият белемен дә шактый ук үзләштереп өлгерәбез. Кануннар, кагыйдәләр безгә куркыныч түгел. Әмма бүгенге заманның язучысы булыр өчен болар гына аз. Чөнки без уныны бетергәндә, институтлар тәмамлаганда без язганнарны укучылар да мич башында борчак чүплəп ятмыйлар. Алар да укыйлар, бездән артыграк укып, бездән күбрәк белеп ачуны китерәләр. Ә без еш кына, Тукай әйтмешли, «алты еллык образованиебезне селкетеп», аларга акыл өйрәтергә тотынабыз, «тәрбиялибез». Укучы инде космик корабльнең «эчәге»ләрен сүтеп җыя, без аңа дөрт көпчәкле гап-гади ат арбасы турында шаккатып сөйлибез. Менә ул ичмасам техника дибез. Чөнки белемебезнең чамасы арба чакушкәсе биеклегендә була. Бәлки арттырыбрак җибәрәмдер, әмма кайвакытларда чыннан да белем җитмәү аркасында оятка калырга туры килә. Гади генә булып күренгән берәү белән сөйләшә башлыйсың, ике-өч сүз әйтүдән авыз томалана. Ул сиңа Гегель, Кант исемнәрен әйтә, аларның хезмәтләре турында сөйли. Син, кем икән алар — шайтан алгырлары дип аптырап утырасың.

Билгеле, мең еллар буе тупланган белем хәзинәсенең хуҗасы булу мөмкин түгел. Әмма язучы өчен зарури булганнарын белү мәҗбүри. 1909 елда чыккан «Идел» газетасындагы бер мәкаләдә һәрбер укымышлы татар кешесе белергә тиешле язучыларның исемнәре китерелгән. Менә ул исемнәр: Гомер, Пифагор, Ксенофонт, Сократ, Теофрист, Фукидид, Эсхил, Софокл, Еврипид, Аристофан, Плутарх, Цицерон, Сенека, Марк Аврелий, Тацит, Тит Ливий, Гораций, Шекспир, Локк, Ньютон, Юм, Гиббон, Адам Смит, Маколей, Вальтер Скотт, Лейбниц, Кант, Гегель, Гете, Шиллер, Монтень, Декарт, Боссюэ, Мольер, Корнель, Расин, Монтескье, Жан-Жак Руссо, Гизо, Тьер, Тьери, Вильмен, Местр, Мишле, Жюль Симон, Бартелеми, Тассо, Петрарка, Макиавелли, Данте, Сервантес, Франклин [1].

Ул вакытта шундый таләп куелгач, бүген ничек булырга тиеш инде? Уйлавы да куркыныч. Ләкин нишләмәк кирәк, бүгенге көннең язучысы буласың килә икән, түзәсең, җан кисәгем. Генетикадан да хәбәрдар буласың, кибернетиканы да антропологияне белән бутамыйсың. Җәмгыятьнең үсеш законнарын диалектик күзлектән карарга өйрәнәсең. Ә сезгә, яшь каләмдәшләр, безнең буынга караганда белемлерәк, эрудициялерәк укучылар белән очрашырга туры киләчәк. Сак булыгыз, көлкегә кала күрмәгез. Укымыйча да шагыйрь булып була дип кайсы да булса шигырь язучы сөйләнә икән, ышанмагыз. Яки ул юри кыланып сөйләшә, шаярта, яки ул ни сөйләгәнен белмәүче ярым надан кеше, шигырь язарга тумыштан сәләте булса да шагыйрь була алмаячак адәм.

**Хезмәт.** Көн саен даими рәвештә белемеңне үстерү язучының бурычы дидек.

[1] Мәгълүмат Э. Нигъмәтуллинның «Раздвигая века и границы» исемле китабыннан алынды

Ләкин коры белем, әгәр дә аны эшкә җикмәсәң, файдаланырга өйрәнмәсәң, бер урында торып үле капиталга әйләнә. Мин бер иптәшне беләм. Аның укымаган китабы юктыр. Теләсә кайсы өлкәдә теләсә кем белән бәхәсләшә ала. Бәхәсләшкәндә бәхәсләшә, әмма кырган эшен ташка үлчим. Чөнки ул ялкау, үзен эшкә өйрәтмәгән. Кырын ятып китап укый, утырып эшләргә иренә. Язучы профессиясе югары классл спортсменнар түккән хезмәтне таләп итә. Көн дә тренировка. Язучы һәрвакыт формада булырга тиеш. Илһам килгәнне генә көтеп ятып булмый. Илһам шундый нәрсә, ялындырырга ярата. Ялынып-ялынып та килмәгәч, якасыннан сөйрәп китерәсең дә янына утыртасың, җибәрмисең. Шуннан ул синең ихтыяр көченә буйсынырга мәҗбүр була. Без Толстойның әллә ничә дистә томнарына карап торабыз да гаҗәпләнеп тел шартлатабыз. Ничек өлгергән дибез. Толстой даһи булган, әмма аңа да илһам күп вакыт ялындырып килгән. Бу хакта ул үзе дә әйтә. Хезмәтне илһамнан өстенрәк санаган Толстой.

Ә бездә кайберәүләр эт теле калынлыгы бер китап чыгара да борын чөеп, ике кулын кесәсенә тыгып еллар буе йөри бирә. Эшләмәс өчен үзенә мең төрле сылтау таба. Өстәвенә күп эшләүчеләрне гаепли, талантлы әсәрләр ашыкмыйча язганда гына туа дип, үзенең ялкаулыгын, үшәнлеген акларга маташа. Ашыгу, кабалану, начар нәрсә. Ә эшләмәү аңардан мең тапкыр яманрак. Эшләмәгәннең фантазиясе тутыга, йөрәгенә май баса. Мин мәсәлән, язарга тема юк дип зарланган язучыларны аңламыйм. Ходаем-җаным, бу дөньядагы теманың, бу дөньядагы язарлык нәрсәнең иге-чиге юк. Эзләргә генә иренмәскә кирәк. Ялкаулык, үшәнлек һәркемнең дошманы, ә язучының ул палачы, газраиле. Язучы булырга хыялланган, тумыштан сәләтле яшь иптәшләр әдәбият тавының түбәсенә йөгереп менеп китәргә уйлап ялгышмасыннар. Анда үрмәләп, азаплана-азаплана менәсең. Җитмәсә, көндәлек тормышның миллион төрле мәшәкатьләре асылынган була. Алар артка сөйри. Дөньяның ләззәтле алдавычлары каршыңа килеп өлмәешып үзләренә чакыралар. Күбесеннән ваз кичеп эшеңне дәвам итәсең. Язу рәхәт нәрсә түгел, язу — газап. Әмма язмый тору тагын да газаплырак булганда гына язучы булып буладыр. Язучы эше хобби түгел, ул — профессия. Хобби яратучылар шырпы тартмасының этикеткаларын җыеп кызык тапсыннар.

**Тормышны, кешеләрне өйрәнү.** Шулай ук язучы өчен иң мөһим нәрсәләрнең берсе. Тормышны өйрәнүне кайчак без ялгышрак аңлыйбыз. Авылга барып буталып кайтуны авыл хуҗалыгын өйрәнү диебрәк, заводка кереп чыгуны эшчеләр тормышын өйрәнү диебрәк караучылар да бар. Тормыш — ул кешеләр. Кешеләргә күңел күзе белән карарга өйрәнү, аларның шатлык-кайгыларын йөрәгең белән тоя белү, кеше психологиясенең нечкәлекләренә төшенергә тырышу һәм башкалар, һәм башкалар — болар барысы да язучының эш материалы. Һәрбер елмайган кешене күреп, шатлыгы зур икән моның дип ялгышмыйк. Бәлки ул авыр хәсрәтенә чыдый алмый, нишләргә белмәгәннән елмаядыр, бәлки елмаясы килмәсә дә начальнигына ярарга тырышып авыз ерадыр, бәлки аның елмаюы астында ниндидер мәкер ятадыр. Елмаюлар күп төрле булган кебек күз яшенең дә төрлесе бар — ачысы бар, татлысы бар, күзгә төтен яки суган әчесе кергәннән чыкканы бар, гөнаһлысы һәм гөнаһсызы бар...

Кайвакыт кешенең бер-ике сүзеннән аның кем икәнен белеп була. Мәсәлән, авылда игеннәр өлгергән чак ди. Авыл халкы мул уңыш көтә. Кинәт шул чакта әллә кайдан кара болыт килеп чыга да боз ява башлый. Шул вакыт бер адәм тәрәзәне ачып җибәрә дә ишегалды буйлап тәгәрәшкән, сикерешкән энҗе кебек ап-ак боз бөртекләренең матурлыгына сокланып «какая красота!» дип кычкырып җибәрә. Кем бу адәм? Иген игүче кешеләрнең авыр хезмәтен, аларның өметләрен, кайгы-шатлыкларын аңлыймы ул? Авылга каян килеп эләккән? Ничек көн күрә? Ничек кенә тәти булып күренергә маташмасын, ике сүз белән ул үзенең кем икәнлеген әйтә дә бирә. Әйе, язучының колагы сак булырга тиеш. Гамьсез, битараф кешедән язучы чыкмый.

Язучы өчен вак, әһәмиятсез детальләр юк. Мендәр өстендә бастырык булып сузылып йоклап яткан ялкау мәчегә карап, язучы Аяз Гыйләҗев мәче хуҗаларының кемнәр икәнлеген күрсәтә, ялкау кешеләрнең мәчеләре дә ялкау була ди. Һәм ул шулай да. Һәрбер гаиләнең үз яшәү ритмы була. Шул ритмга өйдәге бөтен җан иясе буйсына. Хәтта чебеннәр дә. Эштән җилләнеп кайтып кергән, капкалап алыр өчен ун-унбиш минут кына вакыты булган өй хуҗаларын күргән чебен рәхәтләнеп өстәл өстендә «гүләйт итеп» йөри алмый. Ул-бу булмагае дип, ышыграк урынга посу ягын карый. Хәер, андый уңган кешеләрнең өендә чебен дә булмый. Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ут чәчәге» исемле повестенда сыер саву процессы сурәтләнгән. Гаҗәеп күренеш икән ләбаса сыер саву. Олы бер тормыш икән. Бер деталь аша язучы авыл кешесенең психологиясен ачкан.

Кайчак шулай була, берәүнең кулъязмасын укып чыгасың да тормышны белеп җиткермисең, агай-эне, дисең. Автор аптырап кала. Ничек инде белмим, мин бит шунда яшим, шунда эшлим, ди. Яшәү генә, эшләү генә җитми язучыга. Тормыштагы һәр нәрсәне, һәр вакыйганы йөрәгең, акылың аша үткәрә белергә кирәк.

Язучы теле дигән төшенчә бар. Теле яхшы, теле начар, теле коры диләр. Әлбәттә, үзең яза торган телне нечкәлекләренә хәтле өйрәнергә кирәк — анысы бәхәссез. Әмма телең булыр өчен сөйләр сүзең, уйлаган уең булырга тиеш. Ул уйсине борчып, бимазалап күңелеңдә ятарга тиеш.

Их! дигән ымлык белән дә күп нәрсә аңлатып була. Яңа гына тел чыга башлаган сабый «әннә», «мәммә» дигән ике сүз белән әллә ниләр кыландыра. Чөнки аның конкрет теләге бар — аңа аны назлаучы әннәсе кирәк тә, тамагын туйдыру өчен мәммә кирәк. Ә без күп вакыт теләгебез булмаган килеш сүз сөйлибез, сүзләрбез ничаклы купшы булса да, берәүне дә ышандырмый. Нәтиҗәдә тәнкыйтьчеләр коры телле дигән кушамат чәпәп куялар.

Язучы өчен **кыюлык** та зарури нәрсә. Сүз әдәби кыюлык турында бара. Болай язсам ярар микән, тегеләй язсам тәнкыйтьчеләр бәйләнмәс микән дип уйлап уңгасулга, алга-артка каранып язу өстәле артына утырсаң, эш кырып булмыйдыр, һәр кешенең үзенә генә хас фикерләү формасы бар. Үзеңчә булудан курыкмаска да, оялмаска да кирәктер. Бүтәннәр язганга ияручеләрне эпигоннар диләр. Язучылар телендә бу сүз — мәсхәрә сүзе. Әдәби канунннарга буйсыну штампка китерә. Чын язучылар әдәбиятка нинди дә булса яңалык алып килә. Кечкенә генә булса да яңалык. Әмма яңалык алып киләм дип кайберәүләр үзенә хәтле язылганнарга кизәнергә тотына. Бу инде яңалык та түгел, кыюлык та түгел, әдәби хулиганлык. Яңалык беркайчан да үзеннән-үзе тумый, аңа җирлек кирәк. Безнең авылда бер абзый бар иде, аның җырлап йөри торган берданбер җыры бар иде. «От ничава не получится ничава, от чава получится чава» дип суза иде ул.

Традицияләрне олылаган, хөрмәт иткән хәлдә заманга тиң яңа фикерләү формасы белән килгән үзенчәлекле язучыларга әдәбият һәрвакыт мохтаҗ. Кыю экспериментлардан курыкмыйча туктаусыз эзләнүчеләрне әдәбият һәрвакыт үз итеп каршы ала.

Димәк, язучы булыр өчен табигать биргән сәләттән башка нинди дер сыйфатлар кирәклеген санап чыктык. Саналмаганнары да шактый. Болар берсе дә «мин чыгарган бәет түгел». Бу хакта бик күп әйтелгән, бик күп язылган. Бүген аларны тагын бер кат исебезгә төшерәбез икән, файдадан башка зыяны тимәс. Борынгылар әйтмешли, кабатлаудан дога искерми. Чөнки, тагын бер кат кабатлап әйтәм, язучы исемен йөрткән һәм йөртәчәк кешеләргә зур җаваплылык йөкләнгән. Алар кеше күңеле белән эш итәләр. Кеше күңелен тәрбияләр өчен, аның рухи сафлыгын саклар өчен без иң элек үзебезне һәрьяклап тәрбияләргә мәҗбүрбез. Заман таләп иткәнчә, заман югарылыгында тәрбияләргә тиешбез.

# КЕЧКЕНӘ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

**Шәүкәт ГАЛИЕВ. ӘЗ-МӘЗ МӘЗӘК.** Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1979

Котбетдин белән Сәйфетдинне без моңарчы фельетоннарда, кемнең дә булса нинди дә булса кыек эше бәян ителгәндә, шаһитлар вазифасында очрата торган идек. Ә менә шагыйрь Шәүкәт Галиевнең «Әз-мәз мәзәк» дигән күңелле китабы аша Котбетдин белән Сәйфетдин безнең каршыбызга нинди генә халәттә дә үзләренең җорлыкларын, тапкырлыкларын җуймый торган зирәк кешеләр булып килеп бастылар.

Кыек эшенне Сәйфетдин сизмәсен, Сәйфетдиннән дә бигрәк Котбетдин күрмәсен! Сәйфетдиннең көлүенә түзәрсең, Котбетдин көлсә нишләрсең? Ни өчен дигәндә, Сәйфетдин борыч телле генә, ә Котбетдин... Котбетдин кылыч телле.

Бервакытны «Котбетдин ферма сарыклары кайтып барганын карап тора да әйтә:

— Начар көткәннәр көтүчеләр, бер хәрефен югалтканнар сарыкларның...

— Ул нинди хәреф тагын? — дигән председатель.

— Сарыкның «с»сын югалтканнар, «арык» кына калган».

Китапка тупланган мәзәкләр дөньясы буенча сәяхәт итүче Сәйфетдин белән Котбетдин үзара әңгәмә корганда һәрвакыт диярлек бер-берсен тулыландыра, берсе икенчесенең тапкыр сүзен үстереп җибәрә. Мондый алым исә авторга көлү объектын алгы планга китереп, зурайтып күрсәтергә, мәзәкнең мәгънәви тәэсирен, кызыклылыгын арттырырга, динамикасын көчәйтергә ярдәм итә.

«Шактый сыек көн тәртибе тирәсендә сүз куерып киткәч, Сәйфетдин:

— Үгезнең мөгезеннән алырга кирәк иде! — дип ачынып утыра.

— Мәсьәләсе мөкләк бит, кай җиреннән эләктермәк буласың? — ди Котбетдин».

Шунысы куанычлы, Шәүкәт Галиевнең геройлары китап битләрендә генә яшәмиләр. Азмы-күпме вакыт үтү белән, китап кысаларын тарсынып, реаль дөньяга чыгалар, кешеләрнең якын дусларына, әңгәмәдәшләренә әвереләләр. Шагыйрьнең Шәвәлие, мәсәлән, хәзер Буратино шикелле киң таралган исем. Инде менә аның шат күңелле ике карты — Котбетдин белән Сәйфетдине Хуҗа Насретдиндай олы мәзәкчеләр йөри торган юлга чыгып килә.

Шәүкәт Галиев мәзәкләре—гади мәзәк кенә түгел. Шәүкәт Галиев мәзәкләре — шагыйрьнең иҗаты, аның еллар буе күңел түрендә йөрткән яки куен дәфтәрләрендә саклаган үткен фикерләре.

Котбетдин белән Сәйфетдин сәяхәтнамәсен шагыйрь иҗат иткән. Һәр битта, һәр бүлектә шагыйрь кулы сизелә бирадә. Китапның исеме үк каламбурга корылуы («Әз-мәз мәзәк»), бүлек башларының канатлы сүзләрдән, шаян рәвешкә китерелеп үзгәртелгән әйтем-мәкальләрдән гыйбарәт булуы («Белмимнең белеме артмый», «эш пешмәсә, эч пәша», «ул таныш-белешләр аркылы эш йөртә»), сүз сөрешләрендәге инверсияләр, эчке рифмалар әнә шуның ачык мисалы.

Шәүкәт Галиев мәзәкләрендә чит кешене тәнкыйтьләсәләр тәнкыйть була (аңысы тәнгә генә тия), ә инде үзеңне тәнкыйтьләсәләр, җанкыйть була, чөнки аңысы җанны кыя. Шәүкәт Галиев мәзәкләрендә әтисен радикулит интектергәндә, малае радиокулит белән чирли (ягъни төне-көне радио җырлата). Шәүкәт Галиев мәзәкләрендә сынамышлар гына түгел, сынатмышлар да еш очрый. Алар да кайберәүләр «йөзек салыш» урынына «йөзлек салыш» уйныйлар.

Китапта Котбетдин белән Сәйфетдин дучар булган кызыклы хәлләр ике йөздән артып китә. Ике йөз шаян фикер, ике йөз көлдергеч. Бәләкәй генә китап өчен шактый күп бу. Котбетдин белән Сәйфетдин мажараларыннан гына тормый бит әле ул. Икенче кисәгенә «хикмәтле сүзләр» тупланган. Алар аерым темаларга бүленеп, билгеле бер тәртиптә урнаштырылганнар. Күбесе халыкчан юмор белән сугарылган. Хәер, юморсыз хикмәтле сүз тозсыз аш сыманрак инде ул. Сүзне, минемчә, хикмәтле иткән дә, канатлы иткән дә — юмор хисе. Шуңа күрә «Җете кызлар тиз уңа», «Күңел күзең булмаса, күңел сүзең юк инде ул», «Этне кем кайда асрый — кем өй эчендә, кем үз эчендә», «Усал этка юаш кеше койрык болгый», «Ат кешнәшеп, адәм сөйләшеп талаша» кебек җөмләләр сокландырып, елмайтып кына калмыйлар, уйландыралар да. Ә инде «Язын бар йөрәкләр дә бер яшьтә», «Кайсы кош үзе матур, кайсының сайравы матур» шикеллерәк, юмор хисеннән мәхрүм җөмләләр күңел кылларын һич кузгата алмыйлар. Кызганычка каршы, китаптагы хикмәтле сүзләр арасына сүзләрнең әнә шулай буш патрон белән корылганнары, ягъни хикмәт сезләре дә кергәләгән.

Ә тулаем, юмор сөючеләргә күркәм бүләк, татлы күчтәнәч әзерләгән Шәүкәт Галиев. Китапның исеме «Әз-мәз мәзәк» булса да, мәзәге (бу очракта файдалы эш коэффициенты) әз түгел. Киләчәктә укучыларга шагыйрьнең тагын да хикмәтлерәк сүзләрен ишетергә, аның тынгысыз, зирәк Котбетдиннен һәм Сәйфетдиннен тагын да кызыклырак, тагын да гайрәтлерәк хәлләрдә очратырга язсын.

**Фаил ШӘФИГУЛЛИН.**

●

Альберт ХӘСӘНОВ. ТУГРЫЛЫК. Хикәяләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980.

Кече яшьтәге балаларга адресланган бу җыентык исеме белән үк үзенә җәлеп итә. Тугрылык... Табигатькә, үзебезне чорнап алган әйләнә-тирәгә, үсемлекләр һәм тереклек дөньясына тугрылык турында сүз кузгатылган китап, берсүзсез, лаек ул игътибарга. Ә инде аның җәмгыятебезнең киләчәк кө не — үсеп килүче буынга юлланган булуын да истә тотсак, хикәяләр җыентыгы чын-чынлап махсус сөйләшү объекты булып тора ала.

Табигать серләренә юл ачып, балаларга аның сокландыргыч дәрәҗәдә мавыктыргыч һәм бай тормышын күрсәтергә омтылуның ни дәрәҗәдә изге максат икәнлеге ачык булса кирәк. Соңгы елларда яшь укучыга бер-бер артлы тәкъдим ителгән китаплары белән язучы Гәрәфи Хәсәнов бу юлда инде сокландыргыч матур хикәяләр, этюдлар тудырды. Һәм менә Альберт Хәсәнов та шушы изге, бер үк вакытта катлаулы да булган өлкәгә мөрәҗәгать иткән.

Укучы бу авторны, хикәяче булудан бигрәк, шактый үзенчәлекле генә иҗат йөзе булган очеркист, документалист буларак белә иде. Прозада да аның үз юлы, әйтергә теләгән җитди сүзе бар икән, әлеге җыентык шул хакта сөйли. «Әрсез өйдәшләр», «Бүләк», «Тормыш мәктәбе», «Ана кадере», «Экземпляр» кебек хикәяләр чын-чынлап укучы күңелендә табигатькә, аның тереклек дөньясына мөнәсәбәттә кешелекле олы тойгылар уятырга сәләтле булып чыкканнар. Урыны-урыны белән авторның әйләнә-тирәбездәге дөньяның сокландыргыч җанлы картиналарын тотып алуы һәм шуны характерлы детальләр аша чагылдырып күрсәтүенә сокланасың. Табигатьне күрә һәм тоемлый белү, ярата һәм яраттыра белү — язучы өчен гаять кирәкле сыйфатлар болар. Әйтик, «Экземпляр» дип исемләнгән (турысын әйтергә кирәк, уңышсыз исем) хикәядәге кыя тау өстендә мәһабәт бер бронза һәйкәл сыман сакта торган тәкә образы ни дәрәҗәдә сокландыргыч штрихлар белән тасвирланган. Бала күңелендә түгел, өлкәннәрдә табигатькә мөнәсәбәттә иң изге тойгылар уятырлык картина. Һич ирексездән, үзеңне дә табигатьтәге гармонияне һәм гүзәллекне саклаучылар сафында итеп тоя башлыйсың, авторның теләктәше буласың... Шундый изге омтылыш, тойгылар уятырга сәләтле образ һәм этюдлар байтак әлеге җыентыкта. Алар белән очрашу бәхетен укучының үзенә калдырып, инде җыентыкны укыганда туган кайбер канәгатьсезлек тойгылары һәм аларны тудырган, мәйданга чыгарган сәбәпләр хакында да сүз катып алыйк.

Жанр тойгысы... Мөгаен, үзенең киләчәк иҗатында А. Хәсәнов иң элек шул хакта уйланырга тиештер. Җыентыкка кергән барлык әсәрләрне автор хикәя дип тәкъдим итә. Миңа калса, анда жанр таләпләренә тулысынча җавап бирерлек дәрәҗәдә өлгергән, камиллеккә ирешкән хикәяләр санаулы гына. Ул әсәрләр югарыда искә алынды инде. Ә китапның төп өлешен публицист язмалары яисә күзәтү формасында тәкъдим ителгән этюдлар тәшкил итә. Хата шуңарда гына булса, авыз тутырып сөйләшер сүз дә булмас иде, әлбәттә. Ә автор исә, әлеге этюд һәм публицистик язмаларын тартып-сузып дигәндәй хикәя итергә тырыша, хикәя язу үзмаксатка әйләнә. Нәтиҗәдә, әйтергә теләгән җитди фикер һәм теләкнең чабуына ясалмалык, әдәби фальшь килеп ябыша, һәм бу үз чиратында укучыны читкә этәрә, язучы белән укучы арасындагы ихласлыкны юкка чыгара. Ихласлык югала икән, инде сүз әдәби булудан туктый, шагыйрь әйтмешли «холостой выстрел»га әйләнә дә кала. Шундый бәхетсезлеккә дучар ителгән әсәрләр байтак, кызганычка каршы: «Куыш эзләгәндә», «Шулай да була», «Качкалак мияубикә», «Наполеон», «Ноябрь чәчешләре», «Шифалы шулпа» һәм башкалар.

Аңлашылса кирәк, публицистика элементлары, публицистик башлангыч хикәяләр өчен чит дип әйтү түгел иде теләк. Дөрес, монда гаять дәрәҗәдә нечкә зәвык һәм чама булуы кирәктер. А. Хәсәнов җыентыгына кергән күпчелек язмаларда публицистика элементлары чынбарлыкны, дөреслекне көчәйтү максатына түгел, ә, киресенчә, шуның җитенкерәмәвен яшерү, ничек әлкәте шулай тутыру өчен хезмәт итә дигәнрәк тәэсир кала. Документальлек белән фантазия арасында яткан упкын — ясалмалылыкка кайтып кала байтак язмаларда сурәтләнгән вакыйгалар. Үгет-нәсихәт һәм нотык сөйләүгә күчүләрне тудырган сәбәпләр дә ерак яшерелмәгән, әлеге дә баягы бушлыкны тутыру максатыннан чыгып эшләнгән ясалмалылыкка барып тоташа.

Вакыт-вакыт авторның мин дип, үз исеменнән сөйләп китүе һәм бу миннең бераз югарырак тонда, мактангандай сөйләргә яратуы да нәни укучыга тәкъдим ителгән әсәрләрне бизәми.

Күп кенә хикәяләргә җыйнаклык һәм динамика җитенкерәми, аларның үзәгенә куеп тасвирланган төп эпизод сүзләр томаны эчендә югалып кала. Әйтик, «Аларны штатка алдык» һәм «Яфрак җыйганда» кебек әсәрләр шушы кимчелектән арындырылган булса ничек яхшы булыр иде.

Инде дә килеп, җыентыкның «кече яшьтәге балаларга» тәкъдим ителүе урынлымы икән(?) дигән сорау куясы килә. Искә алынган дәрәҗәдәге эстетик чатаклыклар, буш сүз һәм ясалмалылыктан арыну бәрабәренә күләм бермә-бер кыскартылган тәкъдирдә дә әле мондый адресның төгәллеге хакында уйланырга кирәк булыр иде. Китапны бизәп торырга тиешле рәсемнәр дә кече яшьтәгеләрне җәлеп итәрме икән? Кыскасы, авторга, нәшриятка, редакторга, рецензентка (әгәр дә ул бар икән) уйланып урын байтак калган әле...

**Ринат МӨХӘММӘДИЕВ.**

**Рашат НИЗАМИЕВ. ЙОЛДЫЗ ЯҢГЫРЫ.** Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980 ел

Язмышлары төрлечә башлана шагыйрьләрнең. Кайсы тиз таныла, тәүге әсәрләре белән үк игътибарны җәлеп итә. Икенчесе исә күңелләргә илтүче юлны озаграк эзли. Аның аерым шигырьләре белән танышасың, әллә ни искитәрлек нәрсә күренми сыман. Бар да гади, табигый, аерылып тормый. Ниһаять, яшь шагыйрьнең беренче китабы чыга. Инде, аерым-аерым шигырьләрне түгел, җыентыкны укыйсың. Менә шунда шагыйрь ачылып китә. Менә шунда ул сиңа сөйли башлый. Шигырьләр телгә килсен өчен, аларны бергә җыйнау кирәк булган икән.

Рашат Низамиевның «Йолдыз яңгыры» исемле китабы миңа шулай тәэсир итте. Электән үк караштырып килә идем аның әсәрләрен, ләкин, дөресен әйтим, күбесе күңелгә ятып бетми иде. Хиссез, төссез юлларда автор мәгълүм хакыйкатьләрне такъкрарлый, газета шигыре дәрәҗәсеннән күтәрелә алмый кебек иде. Китап исә миндә аның иҗатына бүтәнчәрәк мөнәсәбәт уятты.

Укучылар күңеленә үтәрлек, тетрәндерерлек шигырьләре, чын сәнгать әсәрләре байтак икән яшь шагыйрьнең.

Яңгыр юып киткән
тәрәзәгә
Шомырт яфраклары
ым какты.
Тәрәзәне әй ачарга тели
Чүлмәктәге гөлләр
шул чакны!

Бу юлларны укыгач, яңгыр исен тойгандай буласың, җәйге авыл һавасын күкрәк тутырып сулыйсың килеп китә.

Күзәтә белә, шигърияттне тоя яшь шагыйрь. Сурәтли белә, фикерен җыйнак кына әйтә ала:

Күзләрем көлеп торса да,
Сүзләрем җитди минем.

Шул рәвешле матур-матур шигъри детальләр китапны бизи. Бәхәссез табышлары, уңышлары бар авторның. Шигъри сафлыгы, яңалыгы күренеп торган юллары күп. Бу — кечкенә казаныш түгел, әлбәттә.

Татар поэзиясендә хәзер лирика хакимлек итә. Бигрәк тә уйланулар, лирик «мин»нең кичерешләрен ачып салу рәвешендәге шигырьләр аеруча күбәйде. Р. Низамиев китабында да алар күпчелекне алып торалар. Шуңа да карамастан, лирик герой образы бигүк ачык чалымланмый, ул төссезрәк.

Әмма бүтән төр образлар—колоритлы образлар — күңелгә уелып кала: дөньяда үз урынын күптән билгеләп куйган авыл карты, бәйгедә йөрәге ярылып егылган сабантуй тулпары, сүз әйтергә тилмерүче, мәхәббәтен көтүче кыз... Үз күңеле турында түгел, бәлки әйләнә-тирәсендәге күренешләр, кешеләр турында әйбәтрәк яза икән яшь шагыйрь. Саф лирика түгел, ә күпмедер дәрәҗәдә эпиклык элементын, сурәтне, хәрәкәтне үз эченә алган шигырьләр уңышлырак чыккан («Үз бизәге аның...», «Буран», «Сабантуйның моңсу күренеше», «Икәү», «Утлы хәбәр»). Рашатка бу хәл белән исәпләшергә, тиешле нәтиҗә ясарга кирәктер... Фәлсәфә аның стихиясе түгелдер, күрәсең. Йогынтыларга бирешмичә, талантың табигате кушканча язу мәгъкуль бит.

Китаптагы шигырьләрнең сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсе төрлечә. Автор өчен куаныч тойгысы уята торганнары белән янәшә үк кәефне бозарлыклары да очрый. Шагыйрь үзенең иҗат мөмкинлекләрен тулысынча файдаланмаган. Әйтик, җыентыкны ачып җибәргән шигырьләр бәйләменә күз салыйк. Үзәк тема — сугыш—тынычлык проблемасы. Әйбәт кенә табышлары булган әсәрләр бар биредә: «Урман», «Тол хатын». Ләкин китапның биштән бер өлешен алып торган цикл өчен бу әле аз.

Ерак булган сугыш.
Ә ялкыны
Безнең дә бит җанны
ялмаган.

Кемнәр генә әйтмәде икән бу сүзләрне!

Әдәбиятта инде үзләштерелгән темага яңа әсәрләр язу утә җаваплы, кыен. Дистәләрчә еллык тарихка ия теманың үз традициясе, инерция көче була. Шулар белән исәпләшкән халдә яңа сүз әйтү, ай-һай, җиңел түгел. Искә алынган циклда менә шул яңа сүз житешми.

Гомумән, җыентыктагы күп кенә шигырьләрдә төгәллек юк. Сүзгә саксыз мөнәсәбәт күңелгә тия. Кайбер образлар, метафоралар әсәрдән-әсәргә күчеп йөри. Мәсәлән, китапта, «канатлы уй», «канатлы хыял», «канатлы ат», «канатлы көянтә» һәм башка «канатлы» образлар тулып ята. Сугышның, явыз көчләрнең гәүдәләнеше булган атом бомбасы образы да кирәгеннән артык еш очрый. Яки менә бүтән төрле талымсызлыкка мисал: «Чишмә» шигырендә автор, «Биеп торган кызлар килә монда», ди. Кызлар турында түгел, ат турында гына шулай әйтергә мөмкин ич!

Шундый төгәлсезлекләр һәм зәвык чатаклыклары китаптагы әйбәт шигырьләрдән алган тәэсирне киметә, яшь шагыйрь иҗатының уңай, якты якларына күләгә төшерә.

Шигырьләргә аледән-әле фикер оригинальлеге, фикер кыюлыгы җитмәү үзен сиздерә. Мәсәлән, «Эзләр», «Кайтып төштем дә авылга», «Элегия» исемле шигырьләр. Чын шагыйрь бит халык рухиятенә байлык, яңалык алып килергә, тормышта әле беркем дә курмәгән бәйләнешләрне, каршылыкларны ачып, укучылар дикъкатен шуңа юнәлтергә тиеш. Нидер сөйләргә алынгансың икән, укучыга хөрмәт йөзеннән, сүзнең мөһимен, яңасын әйтергә кирәк.

Әйе, Р. Низамиев иҗатында кимчелекләр дә җитәрлек. Ләкин бу иҗат — шагыйрьнең тәҗрибәсе, кыюлыгы бигүк зурдан да булмасын ди — барыбер игътибарга лаек күренеш. Шигырьләр, гомумән алганда, укучы күңелендә яңгыраш табарлык.

**Фәнз ЗӨЛКАРНӘЕВ.**

**Роза ХӘЛИУЛЛИНА. Агыйдел — Аккош иле.** Шигырьләр, поэма. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980.

Җыентыкта лирик шигырьләр һәм «Каенана» поэмасы урын алган. Аларда сугыш еллары авырлыгын, ятимлек ачысын, сөю, аерылу, сагыну сагышларын татыган, әмма авырлыкларга бирешмәгән лирик образ тасвирлана. Ул безнең күз алдында үсә, күзәтүчәнлеге арта, табигать күренешләренә, дөньяга мөнәсәбәте ачыклана, фәлсәфи гомумиләштерүләр ясый, ниһаять, поэзиягә чын күңелдән гашыйк була.

Тар гаилә рамкаларын сурәтләүдән башланган «Каенана» поэмасы Себергә, БАМ төзелешенә алып китә. Зур төзелешкә атлыгып чыгып киткән «чаябаш каен-сеңел», аның йомшак табигатьле мөлаем әнисе һәм лирик герой—килен образлары — илкүләм әһәмияте булган шушы төзелешкә үзләреннән өлеш керткән, һәм шуңа ихластан куана белгән замандашлар буларак күз алдына килә. Поэма геройлары шул ук вакытта гаҗәеп самими, эчкерсез, ихлас күңелле, үз бурычларын, вазифаларын тирәнтен аңлый белә торган чын совет кешеләре.

Халыкның күркәм гореф-гадәтләре, милли колорит, йөгерек тел — әсәрнең бәхәссез уңышлары.

«Каенана» белән янәшә генә «Минем тауларым» шигыре урнаштырылган. Янәшә торган ике әсәрне 35—40 ел вакыт аерып тора. Бөек Ватан сугышы еллары, лирик герой — үсмер кыз бала, яшьлегенә дә карамастан, инде ул бөтен халык мәнфәгате, ил гаме белән яшәргә, үзе тир түгеп эшләргә өйрәнгән. Күкрәгенә медаль, орденнар тагып кайтучылар гына герой түгел, баржаларга икмәк, тимер төягән, көне-төне колхозда эшләгән шул чактагы үсмер балалар да, окоп казыган, орлык ташыган, икешәр смена станок артында торган аналар да чын геройлар. Алар әле дә исән, алар—әниләр, әбиләр. Аларның бәһасе алтын белән генә исәпләрлек түгел. Кайвакыт бу нәрсәләр онытылып китә, бигрәк тә яшьләр онытә. Боларны искә төшергәләп тору файдага гына булачак. Р. Хәлиуллина безгә әнә шуны искәртә кебек.

«Канатлы юл» шигырендә исә тынычлык темасы яңача, заманча яңгыраш тапкан. Бирелә Розаның хатын-кыз гына яза ала торган өлкәләргә үтеп керә алу сәләте («Каенана»да күргән идек инде) кабат сокландыра. Улын солдатка озата баручы ананың күңел кичерешләре зур осталык белән бирелгән.

Шагыйрә халык[*] традицияләренә хөрмәт белән карый һәм аларга игътибарлы. Аның солдатка китүче уллары, «Бер гүзәлен сагынам чишмәнең» дип җырлаучы якташларыбыз булсалар, намаз укучы әбисе дә, «каенана» да бары тик татар карчыклары. Ак батиска ефәк белән чигеп яулык җибәрүче килеңне дә башка һичкем белән бутау мөмкин түгел. Татар хатын-кызларына хас уңганлык, тыйнаклык, сабырлык сыйфатлары өстенә заманыбыз өстәгән яңа, гүзәл сыйфатларны да оста күреп ала автор. «Сихри ил», «Күңел — дулкын», «Ала күрмә», «Әбкәм гаҗәп шигъри җанлы иде», «Бәби мунчасы», «Бер генә ялгышым бар», «Ядкяр», «Актанышым», «Аккош иле» кебек шигырьләр дә әнә шундый уңышлы әсәрләр буларак кабул ителә.

Әмма, кызганычка каршы, җыентыкка кергән байтак шигырьләр турында ниндидәр генә тырышсаң да җылы сүз әйтеп булмый. Иң элек, алар ашык-пошык эшләнгән. Мәгънәсез сүз тезмәләре эченнән шигъри юлларны бары тик аралап, чүпләп алырга мөмкин.

...Эзли генә белик.
Һәркем энҗе.
Кем тирәндә.
Кемдер тирәндә...

Шушы уңышлы юлларга тирән фәлсәфи фикер салынган. Башка бер сүз дә кирәкми. Ә Роза ул юлларның тәмен, мәгънәсен томалардай тагын 16 юл өстәгән.

Китапны ачып җибәрүче беренче шигырь белән дә шул ук хәл.

...Агыйделгә кайтмый яшәп
Саргайдык—сер бирмәдек
Торган җирне туган җирнең
Ямен кушып бизәдек...

Шагыйрә фикерен бер строфада матур, үтемле итеп әйтеп бирә алган. Шунда нокта гына куясы иде дә бит, юк, ул аны әле сузган, чагыштыргысыз зәгыйфь дистәләгән юл өстәгән.

Җыентыкта шигырь булып җитмәгән, автобиографик моментларны гына чагылдырган, көндәлек дәфтәре өчен генә яраклы тезмәләр дә очрый. Мәсәлән: «Кемгә бала», «Рабига», «Шик», «Сагыну», «Юлчы», «Кемнәрдер бер-берен...», «Шигъриятнең иң зур көче»... «Язмыш ул»... һ. б. Мәгънәсез сүз уйнату булып кына калган мондый шигырьләрне укучыга тәкъдим иткәндә автор үзе ни уйлады икән?!

Телгә, аерым тәгъбирләргә талымчанлык җитми, дорфа, мәгънәсез, грамотасыз сүзләр килеп керә: ...«Таш уела — җыр җуелмый», «Уйчанлыгым сукты (?) башка!».

Роза Хәлиуллинаның тормыш тәҗрибәсе аз түгел, әйтер сүзе һәм сәләте бар, әмма урынлы-урынсыз ашыга, кабалана түгелме ул? Тормыштан алган тәэсирләренең күңел түрендә тонып-утырып җиткәнен көтмичә ашык-пошык язарга керешә, үзен дулкынландырган һәр нәрсәне каударлана-каударлана кәгазьгә төшерергә тырыша. Нәтиҗәдә шигырьдә фикер өзгәләнә, логик эзлеклелек җитми. Күп кенә шигырьләрдә матур-матур строфалар бар, уңышлы поэтик фикерләр сизеләнә, әмма алар ахыргача үстерелми.

Уңышлы гына шигырьләр иҗат итә алган шагыйрәгә бераз басынкырак, талымчанрак, үз-үзенә таләпчәнрәк булырга, филологик белемен тирәнәйтергә, «аз булсын — яхшы булсын!» принцибыннан чыгып эшләргә киңәш бирәсе килә.

**Ләлә ХӘЙДӘРОВА.**

Наил Вәлиев

# ЮЛЛАР ЧАТЫНДА

Юллар чатында... Урталыкта... Яңа революцион күтәрелеш елларында татар зыялыларының, гомумән, татар җәмәгатьчелегенең сәяси, әхлакый һәм рухи эзләнүләрен кыска гына итеп шулай бәяләргә мөмкиндер. Яңа тормыш өчен көрәш дулкынында мәйданга килгән Фатих Әмирхан иҗатын исә халык язмышындагы әлеге кискен борылышның бер гәүдәләнеше дип булыр иде. Ләкин язучыга, үз чорының кабатланмас күренешләрен теркәүче көзге генә булып калмыйча, җәмгыять алдында торган бурычларны ачык аңлау, алдагы үзгәрешләрне яхшы сиземләү дә хас. Менә шундый хасиятләре белән ул Л. Толстой, М. Горький, А. Блок, Г. Ибраһимов, Ш. Камал иҗатларының халыкчан нигезенә якыная. Алдынгы карашлы каләм әһелләре белән уртак закончалыклар һәм юнәлешләр, гомум кешелек идеяләре Ф. Әмирхан иҗатының сулышын киңәйтә һәм аның кабатланмас үзенчәлекләрен тагын да калкурак итеп күрсәтә.

Тарихи борылышлар чорында теләсә кайсы милли әдәбиятта күтәрелгән яшь буын язмышы темасын гына алыйк. Ф. Әмирхан иҗатында да ул — төп магистральләрнең берсе («Танымаганлыктан таныштык», «Хәят», «Кадерле минутлар», «Урталыкта», «Тигезсезләр» һ. б. әсәрләр). Язучыны яшь буынның иске җәмгыять нигезләренә каршы баш күтәрүе («Бәйрәмнәр», «Хәзрәт үгетләргә килде» һ. б.), аталар һәм балалар арасындагы конфликт, алдынгы карашлы яшьләрнең бөек идеаллар хакына үзләрен корбан итәргә әзер торуы («Яшьләр» пьесасы) мәсьәләләре дулкынландыра. Аның әсәрләрендә дөнья әдәбиятындагы «әрәм булган буын» мотивлары да чагылып китә. Ләкин Ф. Әмирхан мәгълүм идеяләрне татар җирлегенә күчереп утырту, яисә Европача каһарманнарның башына каләпүш кидерү белән мавыкмый. Аның идеяләре һәм образлары татар халкының мәгълүм чордагы рухи хәләтен, тарихи яктан конкрет, кабатланмас тормышын өйрәнү нәтиҗәсендә туган.

Яшь буынны язучы һәрвакыт үзенең әхлакый идеаллары белән бәйләнештә тасвирлый. Аны максатсыз гыйсъянчылык, киртәдән сикергән хис-дәртләр кызыксындырмый. Татар халкына борын-борыннан хас булган намуслылык, гаделлек кебек сыйфатларны нәкъ менә яшьләр дәвам иттерергә, үстерергә, яңартырга тиеш. Бу — язучының үз иманы гына түгел, инде кешелекле мәгънәләрен җуеп килүче, дини, сәяси, гаилә-көнкүреш төшенчәләре белән чикләнгән иҗтимагый тормышка тирән эстетик тәэсир ясау өчен бердәнбер дөрес юлны табуы.

Ф. Әмирханның яшь буынга багышланган барлык әсәрләре — публицистик мәкаләләрдән башлап драма һәм повестьларга кадәр — лирик җылылык белән сугарылган («Яшьләр колагына бер сүз», «Тигезсезләр», «Хәят» һ. б.). Яшьлек өчен гомумән табигый кичерешләр муллыгыннан гына килми ул лиризм, әдипнең яшь замандашларына зур өметләр баглавыннан торган рухи күтәренкелек шундый рәвеш ала («Яшьләр» пьесасы, «Танымаганлыктан таныштык» хикәясе һ. б.). Кыскасы, Ф. Әмирхан лиризмының чыганаклары, сурәтләү объектыннан да бигрәк, яңа тормыш идеаллары белән бәйләнгән.

Табигый ки, әлеге омтылыш-идеаллар язучы әсәрләрендәге юмористик һәм сатирик башлангычлар ярдәмендә дә раслана, һәм бу үзенчәлеккә әдәбият тарихын өйрәнүчеләр дә еш игътибар итәләр. Бирәдә әдип иҗатының һәм, тулаем, татар әдәбиятының нигез принциплары күренеп китә. Ф. Әмирхандагы юмор-сатира хосусый кимчелекләрне камчылау белән генә чикләнми. Үткен кинаяләр, ягымлы елмаю һәм әче итеп көлү язучының дөньяга карашындагы коямлы яки фаҗигале якларны ачып сала. Комик һәм сатирик башлангычлар, шул рәвешле, киңрәк, тирәнрәк эстетик һәм иҗтимагый төшенчәләрне берләштерәләр.

Әйе, Фатих Әмирхан әсәрләрендә буыннар мөнәсәбәтенә кагылышлы традицион теманың куелышы да, чишелеше дә бик үзенчәлекле. Аның фикеренчә, әлеге

мәсьәлә дә, тарихи яктан конкрет һәм кабатланмас күренеш булу өстенә, тормышның мөһим проблемалары белән аерылгысыз бәйләнештә дә каралырга тиеш. Язучы яшь буын темасын һәрвакыт әдәпнизам кагыйдәләре җирлегендә, күтәренке лирик дулкында хәл итә. Шулай итеп, яшь җилкенчәк тормышын сурәтләгән аерым күренешләр, мәгълүм тарихи чорга нисбәтләнү белән бергә, яшь буынның һәм, тулаем алганда, татар халкының яшәеш кануннары, киләчәге турындагы бөтен бер концепциянең нигезенә ята.

Яшьлек, буыннар алмашыну темасын ачу юнәлешендә әдип бик кызыклы иҗади алымнар куллана. Бу оригинальлек тормышны, юмор һәм сатирага гомумән хас булганча, энәсеннән-җебенә кадәр үткәреп, тәфсилләп тасвирлау һәм әлеге сурәтләрне романтизм яисә мәгърифәтчелек рухы белән баетудан гыйбарәт. Шушы алым капма-каршы күренешләрнең очраклы яки ясалма янәшәлеге булып калырга да мөмкин иде, ләкин, чын мәгънәсендә иҗат кешесе буларак, Ф. Әмирхан аларның гаҗәеп тәэсиргә ия эстетик бердәмлегенә ирешә алган. Язучының иҗади йөзе, талант көче, бәлки, нәкъ менә шушыннан башланадыр. Һәрхәлдә, Габдулла Тукайның аны, язу стиле белән Тургеневка, юмор көче ягыннан Гогольгә, ә кеше күңеленең тирән катламнарын ачу сәләте белән Достоевскийга охшатуы тикмәгә генә түгел.

Фатих Әмирханның рус телендә басылып чыккан беренче сайланма җыентыгы мәгълүм хикәя исеме белән — «Татар кызы» дип атала. Ф. Әмирхан — татар хатын-кызларының революциягә кадәрге авыр язмышын әдәбиятыбызда беренчеләрдән булып сурәтләгән язучы. Бу проблеманы ул бөтен драматизмы, катлаулы һәм каршылыклы яклары белән күтәрүгә ирешкән.

Бер яктан, без бу әсәрләрдә хатын-кызның кешелек горурлыгын таптап-изеп торучы шәригать кануннарына корылган, җаны-тәне белән искелеккә ябышып ятучы татар дөньясының кырыс чыраен күрәбез. «Рәхәт көн» хикәясендәге Гайниҗамалга, мәсәлән, нибары ике-өч сәгатькә (һәм шунда да күзәтү астында) кеше арасына чыгып керү кыз чагының иң бәхетле көне була. Язучының аерым әсәрләрен һәм публицистик мәкаләләрен — нәк шул мәгънәсендә — татар хатын-кызларының егерменче гасыр башында да кешечә яшәүдән мәхрүм ителүе хакында документлар, тетрәндергеч хакыйкать шаһитләры дип атарга мөмкин. Мәгълүм булганча, Ф. Әмирхан белән бергә һәм аннан соң бу тема Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ш. Камал һ. б. әдипләребезне дә дулкынландыра.

Икенче яктан, Фатих Әмирхан тормыш күренешләрен, алар никадәр генә тәэсирле булмасыннар, турыдан-туры сөйләп чыгу белән чикләнеп кала алмый. Ул — үз чорының тирән белемле, югары культуралы, киң карашлы шәхесе буларак, халыкның тарихын, рухи дөньясын һәм теләк-омтылышларын нечкә аңлап, үзенчәлекле иҗат-фикерләү юлын сайлый.

Хатын-кызга кол итеп карау сакланганда, халыкны агарту, азат итү, аның рухи яңарышына ирешү мөмкин түгел. Ф. Әмирхан татар әдәбиятын һәм иҗтимагый карашлар системасын менә шундый мөһим фикер белән тулыландыра. Ж. Санд яки Ф. Достоевский кебек үк, ул хатын-кызда мәхәббәт, кешелеклелек һәм үсеш-яңалыкка омтылу башлангычларын күрә. «Татар кызы» нәсере һәм Ф. Әмирханның әлеге темага язылган башка әсәрләре дә гомум кешелек идеясенең яңа якларын, француз яки рус әдәбиятында әле ачылмый калган төсмерләрен тасвирлавы белән төрле миллә укучыларының илтифатына лаек булды.

Язучы үзенең иҗатында халык тормышының нигезен корытучы тарихи каршылыкларны ача. Татар гаиләсендә хатын-кыз, бер яктан — әхлакый сафлыкны, рухи яктылыкны саклаучы, балаларына да шул якты нурны иңдерүче, икенче яктан — иң кимсетелгән, кыерсытылган, җәберләнгән зат. Татар җәмгыятендә гаиләнең ифрат җитди урын тотуын, аның һәртөрле яңалыкка, хәр фикергә иң тотрыклы киртә булып торуын искә алганда, Ф. Әмирханның «Татар кызы», «Рәхәт көн» кебек әсәрләрендә ни өчен фаҗигале төс өстенлек иткәнлеге ачыграк аңлашыла. Шулай да, хәл никадәр җитди булмасын, каршылыклар никадәр котылгысыз тоелмасын, язучы хатын-кызның рухи һәм социаль азатлыгы темасын күтәргәндә җете лирик буяуларга, өмет-ышаныч белән тулы интонацияләргә таяна төшә. Аның әсәрләрендә язмыш елмаюын күтсәләр дә, шәригать сүзеннән чыга алмаган хатын-кызлар (мәсәлән, «Рәхәт көн» хикәясендәге Гайниҗамал) белән янәшә аек фикерле, залимлыкка җаны-тәне белән каршы торучы героинялар да бар (Хәят).

Адәм баласын мәкерле уйлардан, әчкерлелектән коткаручы мәхәббәт шигърияте исә бу җирлектә аерым урын алып тора һәм бүгенге укучыларга да бик якын («Кадерле минутлар» һ. б.).

Җәбер-кимсетелү күреп кенә яшәсә дә, хатын-кызның кешелекле хисләрен кадерләп саклавына, киләчәктә социаль мөнәсәбәтләрнең тормышны тамырдан үзгәртеп корырлык кодрәтенә ышана язучы. Шуңа күрә аның «Фәтхулла хәзрәт» кебек сатирик повестендагы хыялый күренешләр дә бүген яңа мәгънәләре белән ачылып киткәндәй була.

Фатих Әмирханның рус теле күпереннән бүтән милләт укучыларына килгән әсәрләре үзенчәлекле формалары һәм татар әдәбиятына гына хас язу-хикәяләү алымы белән характерлана. Ул алым реалистик нигезгә рационалистик һәм романтик тенденцияләрнең үрелеп килүе белән игътибарны җәлеп итә. Татар әдәбияты һәм мәдәнияте белән аерым тәрҗемәләр аша гына таныш кешегә Ф. Әмирхан иҗатындагы мәгърифәтчелек чалымнары баштарак коры үгет-нәсихәт уку булып тоелырга да ихтимал. Беренче тәэсир ялгыш-

тыручан була диләр. Ф. Әмирхан иҗатына һәм татар әдәбиятының шул чорына кагылышлы рәвештә үгет-нәсихәтчелек түгел, бәлки зур эстетик куәте булган фикри пафос турында сөйләргә кирәк. Хәзер гади, хәтта беркатлы булып күренгән идеяләр үз заманында кешеләрнең аңын гына түгел, күңелен дә уятырлык, дулкынландырырлык һәм хәрәкәткә әйдәрлек көчкә ия булганнар. Мондый синтез башка чорда, башка тарихи шартларда да — мәсәлән, декабристлар иҗатында да чәчәк аткан. Менә шуңа күрә Ф. Әмирханның публицистик һәм әдәби-тәнкыйть мирасыннан да иң яхшы үрнәкләрне рус теленә тәрҗемә итеп, Бөтенсоюз укучысына тәкъдим итү файдалы булыр иде.

«Татар романы китапханәсе» сериясендә рус телендә басылып чыккан һәм «Урталыкта» дип исемләнгән җыентыкка (Казан, 1979. Г. Хантимерова тәрҗемәсе), ни сәбәпледер, «Урталыкта» дигән роман үзе кертелмәгән. 1912 елда язылган һәм тәмамланмый калган әлеге роман бары бер тапкыр — әдипнең 1957—1958 елларда Казанда басылган ике томлык сайланма әсәрләр җыентыгында гына дөнья күрә.

«Урталык» темасына Фатих Әмирхан татар демократик әдәбиятында беренчеләрдән булып мөрәҗәгать итә. 1909 елда ук «Картайдым» хикәясендә ул «урталыкта» чайкалучы геройның типик йөзен күрсәтә. Хикәянең герое Мостафа аң-белемгә, халыкны тәрәккъый иттерүгә омтыла һәм бу теләгенә инде ирешеп тә килә кебек. Зур кыенлыклар кичеп булса да ул университетка укырга керә. Ләкин егерме тугыз яшендә инде Мостафаның тормыштан гайрәте чигә, ул яшьлегем заяга үтте дип хафага төшә. Егетнең үзен кирәксез һәм бәхетсез адәм итеп хис итүе, әлбәттә, күңеленә ятышлы җитди шөгыль таба алмавы белән бәйле. Ул инде иске җәмгыятьтән аерылган, ләкин яңа тормыш өчен көрәшүчеләр сафына басарга әле дәрманы җитми. Мостафаның бөтен бәласе, «урталыкта» калуының сәбәбе әнә шунда.

«Урталыкта» романында исә үзенең идеалын эзләү юлына зуррак тәвәккәллек белән керешкән герой мәйданга чыгарыла. Ф. Әмирхан ул уңай каһарман тибын Хәсән Арслановның эш-хәрәкәтләре, эчке дөньясы аша гәүдәләндерергә омтыла. Хәсән үзе өчен яңа тормышның рус-Европа культурасын үзләштерү һәм белем-мәгълүмат туплаудан башлануын яхшы аңлый. Шунлыктан ул өлгергәнлек аттестатына имтихан бирергә әзерләнә, гыйлем эстәвен дәвам итеп, игелекле кеше булырга хыяллана. Ф. Әмирхан бу әсәрендә XX йөз башындагы Казан каласының культура тормышын бик оста сурәтли. Аның героена заман тойгысы, зиһен үткенлеге, үзенең эчке дөньясын анализлау хас. Ул үзенең һәр уен, һәр гамәлен кат-кат үлчәп карый, еш кына кылган эшләренә үкенә, борчыла. Хәсән әлегә ике арада калган, яңа тормышка илтүче юлларны күреп бетерми, холкындагы йомшаклык, ихтыярсызлык та шактый комачаулый шикелле. Әмма изге ниятләре, матур омтылышлары аны дөрес юлга алып чыгар дип өметләнергә урын бар. Билгеле, 1912 елларда «урталыкта»гы, юллар чатындагы геройларның кайсы якка авышасын алдан күрү бик кыен булгандыр әле. «Урталыкта» романының тәгәлләнми калуы шул мәсьәлә белән дә бәйле булырга мөмкин.

Юллар чатында калган замандашларын тасвирлау — Фатих Әмирханны даими дулкынландырып торган, аны кыю ачышларга рухландырган һәм иҗатын тагын да тулырак аңларга ярдәм иткән тема. Шунлыктан аның үлемсез мирасы — ике революция арасындагы мөһим чорда татар халкының матди һәм рухи яшәешендә, аңында һәм күңелендә барган үзгәрешләрне тасвирлаган бай иҗаты күпмилләтле әдәбиятыбыз хәзинәсендә лаеклы урын алды.

# СОЦИАЛИСТИК ИДЕАЛЛАР ЧИШМӘСЕ

Татар халкы капиталистик изүгә, буржуаз идеологиягә каршы көрәштә катлаулы тарихи юл узды. Шул чорның иң алдынгы идея коралы — фәнни социализм идеологиясе белән коралланып, ул рухи прогресс юлыннан атлады.

1905 елгы Беренче рус революциясе иҗтимагый-философик фикер үсешенең сыйфат ягыннан яңа чорын башлап җибәрде. Киң катлау татар хезмәт ияләре политик көрәш мәйданына күтәрелде, татар революционерларының, алдынгы карашлы фикер ияләренең яңа бер буыны үсеп чыкты. Бу хәл татар җәмгыяте тормышында социалистик идеологиянең тирән тамыр җибәрүенә этәргеч ясады.

Хәер, халкыбызның алдынгы карашлы аерым вәкилләре, 1905 нче елгы революциягә кадәр үк марксистик һәм социал-демократик идеяләрне кабул итеп, эшчеләр арасында киң аңлату эше алып бара башлаганнар иде инде. Әмма социалистик идеология революция барышында гына халыкның чын-чынлап прогрессив иҗтимагый фикер агымы булып җитлекте. Атап әйткәндә, революцион демократиянең сугышчан программасы Габдулла Тукайның шул чорда язылган «Шартлар» мәкаләсендә ачык күренә. Бу мәкаләдә шагыйрь социализмның иҗтимагый үсешнең төп максаты, кешене, социаль һәм рухи изүдән азат итү шарты дип игълан итә. Социализм идеяләрен халыкның киң катлауларына җиткерү максаты белән бу чорда революцион эчтәлекле китаплар тәрҗемә ителә. Шундыйлардан Г. Тукайның «Ачлык-падишаһ», «Мохарәбә вә Государственная Дума», Ф. Әмирханның «1871 ел Коммунасы», Р. Ракибиның «Француз революциясе» дигән тәрҗемә әсәрләрен күрсәтергә мөмкин. Социалистик идеяләр «Азат», «Азат халык», «Яңа тормыш», «Таң йолдызы», «Әлгасрел-җәдит» кебек газета-журнал битләренә үтеп керә.

Бу яктан алганда, шул чор татар матбугатында «Урал» газетасы бигрәк тә аерылып тора. Ул Идел буе, Урал һәм Казагыстан халыкларына революцион, социалистик идеяләрне җиткерүдә якты эз калдырды. Татар җәмәгатьчелеге тормышына социалистик идеологиянең әнә шулай тиз арада һәм ныклап үтеп керүендә, әлбәттә, беренче татар социал-демократлары куйган хезмәт бәяләп бетергесез зур булды. Монда аларга турыдан-туры юнәлеш биргән һәм җитәкчелек иткән Х. Ямашев, Г. Сәйфетдинов, С. Сагеев, З. Садыйков, З. Сәфәргалиев исемнәрен күрсәтмәү мөмкин түгел. Икенче яктан, социалистик идеологиянең киң таралуы милли иҗтимагый фикернең чагыштырмача шактый җитлеккән булуы турында сөйли.

Татар фикер ияләренең социалистик җәмгыять турындагы карашлары формалашуга татар хәятендәге нинди үзенчәлекләр йогынты ясадылар соң? Беренчедән, XX йөз башында Татарстанда промышленность капитализмы шактый йомшак үскән була, шул сәбәпле татар пролетариаты бик аз исәпләнә һәм ул җитәрлек дәрәҗәдә оешканлык күрсәтә алмый. Халыкның төп өлешен нигездә крестьяннар, ә шәһәрләрдә ярымпролетар масса тәшкил итә. Шуңа да күпчелек социализм турында народникларча гына фикер йөртә.

Царизм төрле милләт халыклары арасында милли-колониаль изү политикасы үткәреп килде. Бу хәл татар халкының да политик һәм культура ягыннан артта калуына китерде. Ә менә 1905 елгы революция прогрессив татар фикер ияләренә шушы артта калганлыкны җиңеп чыгу бурычын алга куярга мөмкинлек бирде. Шуңа күрә әлеге бурычны хәл кылуда социалистик идеология сугышчан идея коралы буларак кабул ителде. Социалистик агитациянең мәгърифәтчелек пропагандасы белән бергә алып барылуы шуның белән аңлатыла. Революцион демократлар: халыкны агарту — социалистик тәрбияләү бурычы, ул үз чиратында массаларны изүчеләргә каршы көрәшкә күтәрүгә китерер дип фикер йөрттеләр. Мәсәлән, Г. Тукай фикеренчә, матбугат, әдәбият һәм сәнгать милләтне ярлылыкка һәм торгынлык хәленә

төшергән төп гаепләләрне күрсәтергә, халыкны аларга каршы көрәшкә өндәргә тиеш. Ул: «...борынгы кыйлган эшләре өчен милләт аларны аяк астына салып изсен»,— дип язды (Г. Тукай. Әсәрләр, 3 том, Казан, 1976, 13 бит).

Татар фикер ияләренең дөньяга социалистик карашы барлыкка килүгә мәгърифәтчелек идеологиясе көчле йогынты ясады. Әйтик, Г. Тукай Шиһап Мәрҗанига «Милләт өчен бәһә җитмәс кыйбат хәзрәт» дип югары бәя бирде (Әсәрләр, 2 том, Казан, 1976, 272 бит). Г. Ибраһимов Ш. Мәрҗанинең үзендә бөтен искелеккә, торгынлыкка каршы дошманлык хисе уятуы турында яза. Гаделлек, әдәплелек, туганлык кебек мәгърифәтчелек идеяләрендә тәрбияләнгән татар фикер ияләре социалистик идеологияне мәгърифәтчелекнең табигый үстерелеше дип кабул иттеләр. Ф. Энгельс: социализм, иҗтимагый теория буларак, иң элек мәгърифәтчелек принципларының тагын да эзлеклерәк үстерелеше ул, дип язды (К. Маркс, Ф. Энгельс. Соч., 20 том,16 бит). Мәгърифәтченең фәлсәфи фикер йөртүләре революцион-демократларның социалистик җәмгыять хакындагы карашларына да йогынты ясады. Мәсәлән, Г. Тукай «Сорыкортларга» дигән шигырендә: «Минем чын мәсләгем — юлым бөтенләй социаллардай», — дип белдерде. Бу шигырендә, үзенең бөтен гражданлык лирикасындагы кебек, шагыйрь социализм идеясен иҗтимагый идеал буларак рациональ күзлектән үткәрә.

Гомумән, Октябрь революциясенә кадәрге чорда революцион-демократик идеологиянең бөтен үсешен, социализмны рациональ җирлектә аңлау хас иде. Г. Ибраһимов 1917 елда болай дип язган: «Социализм үз көче белән яшәгән, хәзерге капитализм тормышында җәһәннәм газабы чиккән бөтен дөнья халкының актык өмиде, актык теләгедер. Социализм хокук вә икътисад фәннәренең дә соңгы сүзе» («Безнең юл» — «Ирек», 1917, 28 май).

Татар рухи тормышының шуннан соңгы үсеш баскычларында да социалистик идеология дөньяга дини күзлектән карауга каршы куелмый. 1917 нче елда Мулланур Вахитов һәм аның көрәштәшләре тарафыннан төзелгән Мөселман социалистик комитеты большевиклар җитәкчелегендә мөселман хезмәт ияләре арасында армыйталмый социалистик идеологияне киң җәелдерде һәм шул рәвешле Татарстанда социалистик революциянең җиңеп чыгуына бик зур өлеш кертте. Татар революцион фикер ияләренең фәнни социализмга килү юлы, В. И. Ленин әйткәнчә, «диннән социализмга күчү формасында» булды (Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 15 том, 403 бит).

Татар революцион фикер ияләренең идея ягыннан үсешен асылда өч этапка бүләргә мөмкин. Аларның беренчесе татар социал-демократиясе һәм революцион демократиясе башында торучылар — Х. Ямашев һәм Г. Тукайларның революцион-иҗтимагый эшчәнлегенә бәйләнгән. Бу чорда татар җәмгыятенә фәнни социализм идеяләре шактый тирән үтеп керә, массаларның киң катлавы социалистик идеаллар тантана итсен өчен самодержавие һәм буржуазиягә каршы революцион көрәш алып барырга кирәклеген аңлый башлый. Шуның белән бергә массалар социалистик идеологияне бөтен хезмәт халкының революцион идея коралы итеп алалар. Күпчелек татар хезмәт ияләре аңында «социализм» төшенчәсе пролетар һәм народниклык социализмы, фәнни һәм утопик социализм төшенчәләренә бүленмәгән иде.

Татар мохитында социализм идеологиясе һәм революция хәрәкәте үсешенең икенче чоры да бик үзенчәлекле. Бу чор, беренчесе кебек, революцион вакыйгаларга бай түгел. Әмма ул давыл алдыннан була торган тынлыкны хәтерләтә иде. Идея көрәше дәвам итте. Политик эзәрлекләүләр, цензура кысулары социалистик пропаганда эшен ачыктан-ачык алып баруны бик нык чикләде. Мондый кыен шартларда демократик көчләр көрәшнең яңа формаларын эзләделәр. Татар иҗат һәм студент яшьләренең легаль булмаган эшчәнлеге көчәеп китү 1913 елга туры килә. Бу эшчәнлек социалистик хәрәкәтнең яңа җитәкчеләре М. Вахитов һәм Г. Ибраһимов исемнәре белән бәйле. Алар тормыштан вакытсыз китеп барган Х. Ямашев белән Г. Тукай эшен турылыклы һәм тайпылышсыз дәвам иттерделәр.

Казанда яңа яшерен түгәрәкләр барлыкка килә. Аларның актив членнары Г. Коләхметов, Г. Кариев, Г. Гобәйдуллин, Г. Ибраһимов фатирларында җыелышлар үткәрелеп, якты киләчәк өчен көрәш максатлары һәм чаралары тикшерелде. Татар интеллигенциясе арасында революция эшчәнлегенең көчәюе власть ияләрен хафага төшерә.

Россиядә яшәгән мөселман студентларының 1913 елның апрелендә Киевта үткәрелергә тиешле булган съездының программа проектында революцион студентлар оешмаларының максаты ачык күренә. Турыдан-туры Г. Ибраһимов катнашында язылган бу проектта: алда торган төп политик бурычларның берсе — яшәп килгән җәмгыятькә каршы илдәге башка революцион көчләр белән берлектә көрәш алып бару шартларын билгеләү диелә. (Карагыз: Г. Мөхәммәдова. Киев вакыйгасы. «Казан утлары», 1972, № 3, 136 бит).

Хәер, бу чорда әле эш алып барган студент оешмаларының составы бик чуар иде. Аларга әзлекле революционер-интернационалистлар белән бергә самодержавиегә каршы көрәштә үз максатын күздә тоткан милләтчеләр дә үтеп керде. Мөселман җәмгыятендә сыйныфлар юк дигән милләтчелек теориясенә каршы М. Вахитовның Петербургта ясаган чыгышлары, татар интеллигентлары даирәсендә интернационалистлар белән милләтчеләр арасында барган бәхәсләр әлеге оешмаларда көрәшнең бик кискен булуын сөйли. Алдынгы татар иҗтимагый-политик фикеренең табигый үсеш баскычы шушыннан гыйбарәт иде. Самодержавиегә каршы гомуми демократия хәрәкәте пролетар һәм буржуаз милләтчелек юнәлешләренә бүленде. Революционер-интернационалистлар М. Вахитов, Г. Ибраһимов, Ш. Әхмәдиев, Ф. Сәйфи-Казанлы һәм аларның көрәштәшләре большевиклар йогынтысында фәнни социализм идеяләре җирлегендә тордылар, ә бүтәннәр, мәсәлән, кайбер «таңчылар», социализм идеалларыннан йөз чөереп, буржуаз милләтчеләр сафына бастылар.

Бу чорда социализм идеологиясенең йогынтысы үсү Казан губернасында эшче һәм крестьяннарның политик активлыгы күтәрелүдә күренде. Большевикларның Прага конференциясе карарлары, «Правда» газетасы чыгарыла башлау, Казан РСДРП комитетының эшчеләр арасында зур аңлату эше алып баруы төбәгебездә революция хәрәкәтен тагын да җанландырып җибәрде.

Беренче бөтендөнья сугышы башлану белән, большевикларның оештыру-пропаганда эшләре яңа баскычка күтәрелде. Сугыш авырлыклары, социаль каршылыклар татар халкының политик һәм сыйнфый аң уянуын тизләтте, яшәп килгән җәмгыятьне революцион үзгәртеп кору зарурлыгын аңлауга китерде.

Кискен эзәрлекләүләргә дә карамастан, татар революцион демократлары һәрвакыт көрәш сафында булды. Көрәшнең яңадан-яңа формалары барлыкка килде.

Татар җәмгыятендә социализм идеологиясе үсешенең өченче чоры Февраль революциясеннән соң башланды. Социализм идеяләрен ачыктан-ачык тарату өчен җирлек барлыкка килде. Буржуазия власть башына менеп утыргач, революционлыгын бөтенләй югалтты һәм үзенең көрәш угын якынлашып килгән пролетар революциягә каршы юнәлдерде. Мондый шартларда уртак бер юлдан бару мөмкин түгел иде. Шуңа күрә вак буржуаз демократиянең уң канаты контрреволюцион милли буржуазия байрагы астына сыенды. Ә суллар большевиклар җитәкчелегендә Мөселман социалистик комитетына берләште. Бу комитет оешу Октябрь революциясе алдыннан татар социалистик хәрәкәтенең идея ягыннан җитлеккәнлеген күрсәтте. һәм ул социализм идеяләрен татар хезмәт ияләренә җиткереп барды.

Мөселман социалистик комитеты органы булган «Кызыл байрак» газетасы бу идеяләрне халыкка җиткергән төп үзәккә әверелде. Ул Ш. Әхмәдиев һәм Г. Ибраһимов җитәкчелегендә чыгып килгән революцион-демократик «Аваз» һәм «Ирек» газеталары белән берлектә социализмның теоретик нигезләрен яктыртты һәм аларны чынга ашыру бурычларын аңлатып бирде. «Кызыл байрак»та чыккан материаллардан күренгәнчә, революцион көчләр марксизмны үзләренә идея коралы итеп алалар. Бу газета сыйнфый көрәшнең канат җәюен, пролетариатның аңы үсүен хәбәр итә, бөтен дөнья хезмәт ияләренең сыйнфый мәнфәгатьләренең уртаклыгы турында яза. Ә бу социалистик җәмгыять строе җиңүенә китерәчәк. («Берләшегез, бөтендөнья эшчеләре» дигән сүз нинди сүз?» — «Кызыл байрак», 1917, 2 август). Октябрь революциясе алдыннан социалистик җәмгыятьнең капиталистик стройдан өстенлекләрен аңлатып бирү зур әһәмияткә ия булды. Мәсәлән, «Социалистлар нинди тәртипләрне булдырырга тырышалар?» дигән мәкаләдә яңа җәмгыятьнең социаль-экономик асылы турында бәян ителә. (Шунда ук, 11 сентябрь).

Мөселман социалистик комитеты эшчәнлегеннән, революцион-демократик матбугат материалларыннан күренгәнчә, татар революцион демократиясе, кайбер ялгышлыклар җибәрүенә карамастан, киләчәк җәмгыятьне асылда дөрес күз алдына китерә һәм халкыбыз язмышын илдәге гомумпролетар хәрәкәт белән бергә бәйли ала.

Шулай итеп, бу чордагы татар революцион демократиясе эшчәнлеге алдынгы милли иҗтимагый фикернең пролетариат идеологиясе, фәнни социализм принциплары белән кушылу процессын күрсәтә. Ләкин бу процессның Октябрьдан соң да дәвам итүен әйтергә кирәк. Ул ягыбызда контрреволюция тар-мар ителеп, совет власте ныгып урнашканнан соң гына тулысынча тәгәлләнде.

Социалистик идеология өчен көрәш үзәгенә татар халкының милли үзбилгеләнү мәсьәләсе, аны уңай хәл итү бурычы килеп басты. Бу мәсьәләдә төп көрәш милли-культура автономиясе турындагы буржуаз-милләтчелек программасы белән милли-дәүләт төзелеше турындагы ленинчыл принциплар арасында куерды. Хәер, Октябрь революциясенә кадәр үк большевиклар милләтләрнең тигез хокуклылыгы принцибын игълан иттеләр, җәмгыятьтә шовинизмга һәм колониаль изүгә юл куелмаячагын бел-

дерделәр, барлык милләт халыкларының сыйнфый теләктәшлеген яклап чыктылар. Шул рәвешчә, Россия халыкларының нык, какшамас союзына китерәчәк күпернең нигез ташлары салынды. «Бер милләтнең пролетариатын белән буржуазиясен берләштерүче, төрле пролетариатны бер-берсеннән аеручы» милли-культура автономиясе лозунгысын фаш итеп, В. И. Ленин пролетариатның сыйнфый мәнфәгатьләре һәм бурычлары күзлегеннән караганда аның яраксыз булуын исбат итте (Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 19 том, 99 бит).

Революцион фикер ияләре милли культура өлкәсендә тамырдан үзгәртеп коруларны чынга ашырырга бурычлы төп социаль көчне халыкта, аның алдынгы карашлы катлауларында күрделәр. Февраль революциясеннән соң татар җәмгыятенең революцион демократик көчләренә җитәкчелек итүне үз өстенә алып, М. Вахитов культура үсешенең иҗтимагый стройга бәйле булуын гына түгел, ә бу культураның сыйнфый табигатен дә бик ачык күз алдына китерде. «Без ышанабыз ки, — дип язды ул, — социализмның тереклек нурлары астында олуг ислам мәдәнияте балкый һәм бу мәдәниятне тудыручы бай түгел, бәлки эшче булачак» («Кызыл байрак», 1917 ел, 19 июль).

Октябрь революциясе алдыннан һәм Татарстанда совет власте урнашканнан соң сыйнфый һәм идея көрәше чиктән тыш кискенләшү, татар җәмгыятендә сыйныфларга бүленү процессы көчәю буржуазия белән пролетариатның интереслары уртак булмавын, социаль-экономик һәм культура бурычларын бер-береннән аерып карауның ялгыш икәнлеген күрсәтте. Һәм шушы көрәш барышында революцион-демократик фикер ияләре милли мәсьәләдә, милли-дәүләт төзелеше өлкәсендә эзлекле пролетар позициягә күчәләр. Мәсәлән, Ф. Әмирхан «Татар пролетариаты җөмһүрияте һәм татар демократия гаммәсе» дигән мәкаләсендә буржуаз-демократик җәмгыятьтә милли мәсьәләне гадел хәл итеп булмаячагын әйтеп бирә, чөнки, ди автор, моңа иң элек бу җәмгыятьнең эксплуататорлык асылы киртә булып тора (Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр, 2 том, Казан, 1958, 527—529 битләр). Ул шушы ук мәкаләсендә социалистик җәмгыятьне буржуаз җәмгыятькә каршы куеп тасвирлый, яңа стройда аның социаль-экономик һәм политик нигезләре үзләре үк милли республика төзергә мөмкинлек бирәләр дигән нәтиҗә ясый. Г. Ибраһимов та бу мәсьәләдә әнә шундый эволюция юлы узды. Ул татар-башкорт буржуаз автономиячеләренең милләтчелек белән сугарылган проектларына каршы төшә, ә үзләре белән арасын бөтенләйгә өзә һәм ул милли-территориаль автономия принципларын яклап чыга. Бик катлаулы бу милли мәсьәлә гражданнар сугышы һәм контрреволюциягә каршы көрәш шартларында хәл ителде. Монда автономия төзүнең пролетар принципларын кискен яклап чыккан татар революцион демократлары кerткән өлеш тә гаять зур булды. Татарстан АССРның 60 еллык тарихы күрсәтүенчә, ленинчыл принциплар татар халкын Октябрь кояшы белән балкытылган олы бәхет юлына алып чыктылар.

**Рашат ӘМИРХАНОВ,**
Г. Ибраһимов исемендәге тел,
әдәбият һәм тарих институты
фәнни хезмәткәре.

Леонид Арсланов,
филология фәннәре кандидаты

# КАРАГАШ ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

Карагашлар дип Әстерхан өлкәсенең Краснояр, өлешчә Харабали районнарында яшәүче кечкенә этник төркемне йөртәләр[1]. Фәнни әдәбиятта карагашларны кундрау татарлары дип атау да бар. Ләкин соңгы атама кариле нугайларының бер төркеменә — Кундрау авылы нугайларына карата гына кулланыла[2].

Карагашлар үзләрен карагаш (нугай), телләрен — карагаш (нугай) теле дип саныйлар, ягъни үзләрен мөстәкыйль этнографик төркем итеп таныйлар. Алар төрле тарихи-социаль сәбәпләр аркасында рәсми кәгазьләрдә, кариле нугайлары кебек үк, татар дип язылганнар.

Карагашларның элеккеге нугай булуы галимнәр арасында бәхәс уятмый, чөнки бу тел фактлары белән дә, халык иҗаты үрнәкләре һәм тарихи документлар белән дә раслана. Әмма карагашларны нугайларның кайсы төркеменә — кубан (черкәс) нугайларынамы, әллә карануигайларгамы — кертү мәсьәләсендә галимнәр арасында уртак фикер юк.

Идел-Актүбә буена карагашлар 1740 елда Биштау, Кубан тирәләреннән күчеп килгәннәр. 1741 елга кадәр, ягъни калмыкларның бер зур төркеме Кытайга күчеп киткәнче, алар, калмыкларга бәйле булып, күчмә тормыш кичергәннәр. Карагашлар XIX гасыр башында казакълар белән культура-экономик мөнәсәбәтләр урнаштыралар, һәм бу хәл аларның теленә сизелерлек тәэсир ясый.

Карагашлар элек-электән татар культурасы йогынтысында булалар. 1962 елларга кадәр карагаш балаларын мәктәптә укыту татар телендә алып барыла. Шул ук вакытта, Әстерханнан шактый ерак булу, озак вакыт ярым күчмә тормышта яшәү һәм башка сәбәпләр аркасында, карагашларда традицион халык авыз иҗаты әсәрләре һәм тел үзенчәлекләре сакланып килә.

Карагашлар сан ягыннан күп түгел. 1974 елда алынган мәгълүматларга караганда, аларның саны, Әстерхан шәһәрендә яшәүче карагашларны да кертеп, 6 меңнән артмый.

Тарихи-этнографик яктан карагашлар шактый җентекле өйрәнелгән. Бу этник төркемнең теленә һәм авыз иҗатына исә әлегәчә бөтенләй игътибар ителмәгән. Шуны истә тотып, карагашларга хас кайбер фольклор үрнәкләрен журнал укучыларның игътибарына тәкъдим итәбез.

Карагаш телендә үзенчәлекле сузык һәм тартык авазлар бар, техник сәбәпләр аркасында алар татарча әйтелешкә якынайтып бирелләр. Лексика өлкәсендә дә шактый аермалар бар. Шуңа күрә фольклор үрнәкләренең татарчага тәрҗемәсе дә китерелә.

---

[1] Карагашлар һәм аларның тарихы турындагы тулырак мәгълүмат «Советская тюркология» журналының 1977 ел, 4 санында басылган «К вопросу о карагашском языке» дигән мәкаләбездә бирелә.

[2] В. Пятницкий. Карагаши. (По материалам поездки в 1927 году). Землеведение. Том 32, вып. 34, 1930, 115 бит.

Карагашларның Кубаннан килүен халык авыз иҗаты әсәрләре дә раслый. Мәсәлән, Красноярь районының Яшен Суккан авылында Аллабердиев Уразгали агадан язып алынган җырда Кубан иле искә алына.

**Тупрагы алтын Кубандың;**
**Икләй шыгар алмасы;**
**Кулын җайып дога итсә,**
**Шырын килер кырмасы.**

**Туфрагы алтын Кубанның;**
**Икмичә чыгар алмасы;**
**Кулын җәеп дога кылса,**
**Мул булып уңар хөрмәсе.**

Ха.абали районының Лапас авылы чәчәне Шамуков Абдулла агадан язып алынган «Озын нугай җыр»дан да бер өзек китерик.

**Туй мәҗлесе коралган**
**Җыр думбыра, бию мән;**
**Нәселемез әзиндә**
**Бүленгән Кубан иленнән.**

**Туй мәҗлесе җыелган**
**Җыр, думбыра, бию белән;**
**Нәселебез әүвәлдә**
**Бүленгән Кубан иленнән.**

Шулай итеп, тел, фольклор, тарихи материаллар карагашларның, чыннан да, Кубаннан күчеп килгәнлеген раслыйлар.

Карагаш халкы мәкаль-әйтемнәргә бай. Укучы балалар да мәкаль, әйтем, табышмакларны яхшы беләләр. Тупланган материалларның байтагында нугай теле белән уртаклык ачык күренә. Кайберләренә татар халык иҗатыннан параллельләр табарга мөмкин. Берничә мисал китерик. 1. Калк каласа, хан төясен суят — Халык бүләк итсә, хан дөясен суяр. 2. Котан кунса, су киләт — Чеһән кунса, су килә. 3. Ат тоягын тай басар. 4. Карт тирәктә бөре бетпиде, җас тирәктә бөре бетәт — Карт агачта бөре бетми, яшь агачта бөре бетә. 5. Адәм күрке — упырак, тирәк күрке — җапырак — Адәм күрке — кием, агач күрке — яфрак. 6. Атты камшы үтерәр, ирде намыс үтерәр — Атны камчы үтерер, ирне намус үтерер. 7. Юл җөргән казнага ошрайды, сүз куган баләгә ошрайды — Юл йөргән хәзинәгә очрый, сүз йөрткән бәлагә очрый. 8. Дагырда бозау имезәт, бозау таяк җейгезәт — Сөйләшү бозау имезә, бозау таяк ашата.

Табышмаклар — балалар арасында аеруча киң таралган жанрларның берсе. 1. Күк шебрәккә байлап, күккә салам җибәрәм — Күк чүпрәккә бәйләп ,күккә сәлам җибәрәм (төтен). 2. Җагалай беткән ак тирәк, суырмага көш кирәк — Яр буйлап үскән ак агач, суырырга көч кирәк (тешләр). 3. Калын тирәк эшендә котырган каскыр улайды — Калын агач эчендә котырган бүре улыйдыр (гөбе). 4. Ормай, сукпай — җылатат — Ормый, сукмый елата (суган). 5. Арбага төяп булмас, өйгә сөяп булмас — Арбага төяп булмый, өйгә сөяп булмый (күләгә).

Тезмә җаваплы борынгы табышмакка бер үрнәк бик кызыклы. Бу табышмак Нәкый Исәнбәтнең «Татар халык табышмаклары»нда (Казан, 1970 ел, 539 бит) китерелгән мисалга якын. Ул Красноярь районының Куянлы авылында Сүнчәләева Фатыймаападан язып алынды.

**Бал каймаклы баллы су —**
**Басып буган бар микән!**
**Төнбоеклы тонык су —**
**Төбен күргән бар микән!**

**Бал каймаклы баллы су**
**Басып буган бар микән!**
**Төнбоеклы тонык су —**
**Төбен күргән бар микән!**

**Борама тимер, чи булат**
**Борып суккан бар микән!**
**Акша каен, кукшәдең**
**Төбен кискән бар микән!**

**Борылган тимер, чын булат**
**Борып суккан бар микән!**
**Ак каен, өянкенең**
**Төбен кискән бар микән!**

**Кунан куйдың кыйкал итен**
**Сайлап җийгән бар микән!**
**Өлкәр менән Чулпандың**
**Туганын күргән бар микән!**

**Өч яшьлек куйның көйгән итен**
**Сайлап ашаган бар микән!**
**Өлкәр белән Чулпанның**
**Туганын күргән бар микән!**

Җавап:

| | |
|---|---|
| Бал каймаклы баллы су | Бал каймаклы баллы суны |
| Басып буган — балыкшы. | Басып буган балыкчы. |
| Төнбоеклы тонык су | Төнбоеклы тонык суның |
| Төбен күргән — сөңгәрше. | Төбен күргән — чумучы. |
| Борама тимер, чи булат | Бормалы тимер, чын булатны |
| Борып суккан — тимерша. | Борып суккан — тимерче. |
| Акша каен, күкшәдең | Ак каен, өянкенең |
| Төбен кискән — иярше. | Төбен кискән — камыт ясаучы. |
| Кунан куйдың кыйкал итен | Өч яшьлек куйның көйгән итен |
| Сайлап җийгән — каракшы. | Сайлап ашаган — карак. |
| Өлкәр менән Чулпандың | Өлкәр белән Чулпанның |
| Туганын күргән — күзәтше. | Туганын күргән — күзәтүче. |

Карагашларда, олылар белән беррәттән, балалар тарафыннан әйтелә торган такмаклардан түбәндәгеләрне күрсәтергә була.

| | |
|---|---|
| Кызым, кызым, кыз тана, | Кызым, кызым, кыз тана, |
| Кызыма килгән җөз тана, | Кызыма килгән йөз тана, |
| Өләстереп килгәндә | Өләшеп килгәндә |
| Өй башына бер тана. | Өй башына бер тана. |
| Кар, кар, каргалар | Кар, кар, каргалар, |
| Канаты ман йүргалар, | Канаты белән юргалар, |
| Озын суда балык бар, | Озын суда балык бар, |
| Ягасында елкы бар, | Яр буенда елкы бар, |
| Кайсы байдың елкысы! | Кайсы байның елкысы! |
| Буякай байдың елкысы. | Буякай байның елкысы. |
| Буякай саган ни бирде! | Буякай сиңа ни бирде! |
| Бер алаша тай бирде. | Бер алаша тай бирде. |
| Уйга, кырга шап, диде, | Үзәнгә, кырга чап, диде, |
| Кымызлы өйгә бар, диде, | Кымызлы өйгә бар, диде, |
| Кымызыннан бирмәсә, | Кымызыннан бирмәсә, |
| Кызын алып каш, диде. | Кызын алып кач, диде. |

Карагашларда традицион фольклорның берничә төре бүгенге көндә дә актив кулланыла. «Озын нугай җыр»ны шундый җырларның берсе дияргә була. Бу җырсыз бер генә туй да, бәйрәм дә үтми. «Озын нугай җыр» шәйдәләр, чәчәннәр тарафыннан башкарыла. Җырчы аны думбырага кушылып та, аккомпанементсыз гына да башкарырга мөмкин. Һәрбер карагаш авылында танылган җырчылар бар. Мәсәлән, әлеге җырны оста башкаручылардан Харабали районының Лапас авылыннан Шамуков Абдулла, Җанай авылыннан Нурмөхәммәтов Абдрахман, Белячное авылыннан Айбулатов Мөхәммәтрәхим, Яшен Суккан авылыннан Үтәгулов Исмаил агаларны күрсәтергә мөмкин.

Структур яктан «Озын нугай җыр» өч бүлектән тора. Башкаручы беренче бүлектә бабаларының кайсы ыруга караганлыгы, бу җирләргә ничек килеп чыгулары, нәрсә белән шөгыльләнүләре турында искә төшереп китә. Җырның төп бүлегендә башкаручының әһәмиятле вакыйга турында сөйли, мәсәлән, туйда җырлана икән, яшьләргә изге теләкләр, туганнарына мактау сүзләре әйтелә. Соңгы бүлектә әйтелгәннәргә йомгак ясала. Һәр җырчы сүзне үзенчә тәмамлый.

«Озын нугай җыр» составында тарихи, лирик җырлар да булырга мөмкин. Аларның кайберләре Бөек Ватан сугышына, космик очышларга һ. б. багышланган. Туйда башкарыла торган җырның Шамуков Абдулла агадан язып алынган үрнәген кыскартып тәкъдим итәбез.

| | |
|---|---|
| Туй мәҗлесе коралган | Туй мәҗлесе җыйнапган |
| Җыр, думбыра, бию мән; | Җыр, думбыра, бию белән; |
| Нәселемез әзилдә | Нәселебез әүвәлдә |
| Бүленгән Кубан иленнән. | Бүленгән Кубан иленнән. |

Карагаш атак тагылган
Кара урман күленнән;
Язылмайды тарихта
Кузгалу сәбәп иленнән.
Урынласкан ил булып,
Ахтуба суын җагалай;
Шарвалыгы — малшылык,
Җәй җайлама — киң тугай,
Басшылык иткән был ил мән
Сентләр мән Хуҗатай [1].
Ил адәте үзеншә
Үткәргән дәвер бер талай;
Рысак, чурга юыртып,
Чаптырган йөгрек көн калай,
Яксылап колак салыңыз:
Үткән тарих монадай.
Азгантай авыл илемез,
Нәселемез — карагаш;
Ата-баба адәтен
Моту безгә йарамас.
Үткәннәрде искә алсаң,
Ил адәте югалмас.
Ийкән бабаларымыз
Булган бәресе кардас,
Бер атадн үркәнләп,
Булган тату авылдас,
Тату тормыш үткәргән
Ага-эне, аданас,
Берсен берсе батыр дип,
Мактаган күңел мән ихлас,
Яслары булган тәртипле
Яманлыкка юламас,
Нәзеллек пән сөйләскән
Уйнап корбы, тиң кәрдас,
Калкымыз үткән адәтен
Айтпай китүгә булмас.
. . . . . . . . . . .
Был донйаның заукысы —
Уйнап-көлү, агай-эн!
Мәҗлес әр көн кизләспәс,
Күңел ашып калаем.
Каерлы булсын туеңыз,
Якшылык пан таныскан,
Татулык пан сееескән,
Туй билгесе алыскан
Рахат тормыш — ясларга.
Туй хуҗасы — тамада
Булса кирәк ыриза,
Без дә рахмәт айтамыз
Күрсәткән хөрмәт-сыйга...
Кусылган яслар тормышы
Татулык пан гөрләсен,
Киләйек солар юлына
Яманлык җибәрмәсен.

Карагаш исеме кушылган
Кара урман күленнән;
Язылмыйдыр тарихта
Кузгалу сәбәбе иленнән.
Урнашкан авыл булып,
Актүбә суы буйлап;
Хуҗалыгы — малчылык,
Җәй җәйләргә — киң тугай,
Җитәкчелек иткән бу авыл белән
Сәетләр белән Хуҗатай.
Авыл гадәте үзенчә
Үткәргән дәвер беркадәр;
Юртак, юрга юырттырып,
Чаптырган юртак көн буе,
Яхшылап колак салыгыз:
Үткән тарих менә мондый.
Аз гына авыллы илебез,
Нәселебез — карагаш;
Ата-баба гадәтен
Оныту безгә ярамас.
Үткәннәрне искә алсаң,
Ил гадәте югалмас.
Өлкән бабаларыбыз
Булган барысы кардәш.
Бер атадан таралып,
Булган тату авылдаш[лар],
Тату тормыш үткәргән
Ага-эне, туганнан-туган,
Берсен берсе батыр дип,
Мактаган ихлас күңелдән.
Яшьләре булган тәртипле,
Яманлыкка юлыкмас,
Әдәплелек белән сөйләшкән
Уйнап яшьтәшләр, тиң кардәш,
Халкыбызның үткәндәге гадәтен
Әйтми китәргә ярамас.
. . . . . . . . . . .
Бу дөньяның рәхәте —
Уйнап-көлү, агай-эне!
Мәҗлес һәр көн туры килмәс,
Күңел ачып калыйм.
Хәерле булсын туегыз,
Яхшылык белән танышкан,
Татулык белән сөешкән,
Туй билгесе алышкан
Рәхәт тормыш — яшьләргә!
Туй хуҗасы — тамада
Булса кирәк риза,
Без дә рәхмәт әйтәбез
Күрсәткән хөрмәт-сыйга...
Кушылган яшьләр тормышы
Татулык белән гөрләсен,
Киләчәк шулар юлына
Яманлык җибәрмәсен!

Традицион халык үрнәкләренә сирәк башкарыла торган «Шың» яки «Әән» әйтүне кертергә мөмкин. «Шың» әйтү, «шыңлау» кода белән кодагый, кыз белән егет арасын-

[1] Сентләр һәм Хуҗатай карагашларның иң беренче авыллары булып санала.

да бәйрәмнәрдә, туйларда ярыш формасында башкарыла. «Әви»нең үрнәге «Ногай халк йырлары»[1] җыентыгында да бирелгән. Румын нугайларында ул «яр-яр» кушымтасыннан башка җырлана. Карагашлардагы «яр-яр» кушымтасы — башка төрки халыкларның фольклоры йогынтысы булса кирәк.

«Әви»нең эчтәлегендә үткен киная, юмор ачык сизелә. Аны күбрәк танылган җырчылар, сүзгә тапкыр кешеләр, чәчәннәр башкара. Элегрәк аларны туй өчен махсус яллый торган гадәт тә булган. Хәзер фольклорның бу жанры онытыла бара.

**Кодагай:**

Яр-яр, хуш килдеңез, кодалар, туемызга,
Сезде алып тора идек уемызга, яр-яр.

**Кода:**

Яр-яр «куш килде» айткән кодагай, кус увыл тап,
Кусагыннан аермай биш увыл тап, яр-яр.

**Кодагай:**

Яр-яр, билемдәге кусагымды үлдем бауга,
Җан кодам айткан сүзенә мендем тауга, яр-яр.

**Кода:**

Яр-яр, «туй бар, туй бар» димәгә туйга килдек,
Туры түбел ат менеп, уйнай килдек, яр-яр,

**Кодагай:**

Яр-яр, тар сукпактан шавып барган бездең куйдыр,
Әрбер туйда сайраган бездең суйдыр, яр-яр.
Яр-яр, кодама билбау, кара түн — бүй төзәтер,
Шыңрау кодам җырласа, туй төзәтер, яр-яр.

**Кода:**

Яр-яр, әр киемде яратып кидем ясыл.
Әр туйларда сайрасың, суең асыл, яр-яр.

**Кодагай:**

Яр-яр, күзәнәктән ал яулык тартысаек,
Якын килше, кодам, җыр айтысаек, яр-яр.

**Кода:**

Яр-яр, кырдан уйга җувырган төлке булар,
Каҗауласып айтаек, көлке булар, яр-яр.

**Кодагай:**

Яр-яр, кил ау, кода, киез кагаек, шаңы шыксын,
Каҗауласып айтаек, даңкы шыксын, яр-яр.

ТАТАРЧАГА ТӘРҖЕМӘСЕ:

**Кодагый:**

Яр-яр, хуш килдегез, кодалар, туебызга,
Сезне алып тора идек уебызга, яр-яр.

**Кода:**

Яр-яр, «хуш килде» дигән кодагый, игез ул тап,
Бер-бер артлы биш ул тап, яр-яр.

[1] Ногай халк йырлары. М., 1969, 114—115 битләр.

Кодагый:

Яр-яр, билемдәге кушогымны әлдем бауга,
Җан кодам әйткән сүзенә мендем тауга, яр-яр.

Кода:

Яр-яр, «туй бар, туй бар» дигәнгә туйга килдек,
Туры кашка ат меңеп, уйнап килдек, яр-яр.

Кодагый:

Яр-яр, тар сукмактан чабып барган безнең куйдыр,
Һәрбер туйда сайраган безнең нәселдер, яр-яр.
Яр-яр, кодама билбау, кара туи — буй төзәтер,
Җырчы кодам җырласа, туй төзәтер, яр-яр.

Кода:

Яр-яр, һәр киемдә яратып киеем яшел,
Һәр туйларда сайрыйсың, нәселең асыл, яр-яр.

Кодагый:

Яр-яр, күзәнәктән[1] ал яулык тартышаек,
Якын килче, кодам, җыр әйтешәек, яр-яр.

Кода:

Яр-яр, кырдан үзәнгә йөгергән төлке булыр,
Шаярышып әйтик, көлке булыр, яр-яр.

Кодагый:

Яр-яр, килче кода, киез катыйк, тузаны чыксын,
Шаярышып әйтик, даны чыксын, яр-яр.

Карагашларда кыска җырлар да бар. Ләкин соңгы вакытта кыска җырлар сирәк башкарыла. Чөнки карагашларда күбрәк татар җырлары (көйләре) яратып җырлана. Карагаш телендәге кыска җырларга берничә мисал китерик.

Яр бышаннан мыя[2] алдым,
Ярык итеп якпага;
Җанакамнан оялдым
Ярның күңелен тапмага.
Тауга тайак тастадым,
Бер балапан увысладым;
Балапандын башы юк,
Алган кыздын касы юк.

Яр башыннан мыя алдым
Якты итеп ягарга;
Әтиемнән оялдым
Ярның күңелен табарга.
Тауга таяк ташладым,
Бер чебине тотып алдым;
Чебинең башы юк,
Алган кызның кашы юк.

...............

[1] Күзәнәк — юрта тишеге.
[2] Мыя — дару үләне (русча солодовник).

Шәүкәт Галиев

# ХИКМӘТЛЕ СҮЗЛӘР

*Күптәннән бирле язылып килгән «Хикмәтле сүзләр»нең бер өлеше «Казан утлары»ның 1979 ел 3 нче санында басылган иде. Бирегә шуларның ишләре тәкъдим ителә.*

Автор

## «Тисә — тиенгә, тимәсә — талга» барыбер табигатькә зыян

Каурый йолкып язды: «Кошларны саклыйк!»
Җил очыртып киткән каурый: «Янадан очам!» — дип сөенде...
Саңгырау сандугачны сагынмас.
Тере чәчәк кәгазь чәчәк кебек салкын чибәр булмый.
Валериан үскән җирдә тынәтмәсен эчмиләр — табигать кочагында йөрәк болай да тыныч.
Имәнне мең ел үсәрдәй җиргә утырт!
Табигатьтән талап алган бер җанлы тиен өчен мең сум түләрлек булырсың.
Помырка табигать уйлап тапкан консерва!
Кояш мул якта — суга кытлык.
Күңелләр саеккан саен күлләр саега.
«Көймә кила — эзе юк»... Бу жыр искерде инде, хәзер майлы эз кала!
Савыттан чыккан химия җене кешелекнең үзенә яный...

## Боз да кояштан туган...

Кар астына су төшә, агачларга сут төшә, тел очына сүз төшә — күңелләргә моң төшә!
Тургай — сайрый торган йолдыз.
Язын кызарган бөредә — туасы җимеш төсе.
Язын яфраклар бөре биләвен чишеп чыга...
Бөре бишегендә «туп» итеп сикереп төшәсе алмалар үсә.
Яз — бергә шатлануга, көз — ялгыз уйлануга тарта.
Җилнең тарту көчендә җирнең тарту көче бар.
«Без атлап вакланмыйбыз, сикереп кенә йөрибез!» — диде Чыпчык Филгә.
Эт йортны саклый, чылбыр — этне...
Яхшы эт — усал эт. Яхшы хуҗа — юаш кеше...
Сарык асраучы бүре бүрек кияр.
Тычкан уты дөньяны яктыртам дип белә...

## Безнең туган якларда таллар бии тальянга!

Сандугачны да, шагыйрьне дә туган җир сайрата.
Туган җиргә тамыр тирәнрәк үткән саен башыбыз өскәрәк күтәрелә!
Күңел читтә дә туган якта яши.
Чит җирнең бердәнбер яхшылыгы — туган җир кадерен ныграк сиздерә...

## Бәхетең халкың белән уртак булсын!

Ирек белән Бәхет — игезәк...
Шатлыкның зурлыгы — шатлана белүдә.
Бәхетсезлек булмый калу үзе бәхет.
Кемгә бәхет елмая, кемнән көлеп уза...
Без үк йөрәкне талыйбыз — михнәт белән дә, рәхәт белән дә!
Яхшырак яшәүче ешрак зарланучан.
Үткәндә калган бәхетен киләчәктән көтә...
Бер күзе җылап бетерми, икенчесе көлә башлый!
Бәхет теләп ишеккә каккан дагага бәреп башын тишкән...

## Батырның үлгән көне — үлемсезлеге туган көн

Җинүчедә көч булса, җиңелгәндә үч була!
Җиңелүне күтәрә белү дә кирәк — җиңүгә әзерләнү өчен!
Батырлар җаны — байракта!
Һәйкәлләр охшаша алмый — һәркайсының үз урыны...
Горурлык хисе йоклаган халыкның рухы төш күрә...
Көрәш җиле өрмәсә, күңел җилкәннәре сүнә...
Мәңгелек йолдызларга да исемне кешеләр куша!

## Кыюлык — биеклек белән, куркаклык түбәнлек белән үлчәнә

Үзен җыя алмаган кеше — иң көчсез кеше.
Р у х сынган — х у р булган.
Качкын куркактан ярала.
Куркак булудан курку — батырлыкка бер адым.

## Сыйфатны санга сукмасаң, сан сыйфатка суга

Ике ялдан соң өч көн эшләп хәл аласың...
Рәхәтләнеп ял иттем — арганчы эшләдем!
Тик торып борчылганчы, эшләп тынычлан.
Өзлексез эшләгән — эзлекле яшәгән.
Эшләп арган саен көч арта!
Шахтерның җиргә ихтирамы тирән...
Теләп эшләгән эш — бүләк, мәҗбүрие — җәза!
Башлыгы уңмаганның ашлыгы уңмас.
Кешенең зурлыгын яшәгән еллар белән түгел, эшләгән эшләр белән үлчиләр.
Алтын кукай көтмим дә, гап-гадие күп булсын.
Кеше үлсә — эше кала. Эше үлсә, ние кала?..
Эшләгән эшенне мактаганда эшләнәселәре борчый.
Эшләмәгән остармый, остармыйча эш бармый.
Осталыкка осталык кирәк.
Хәл белән генә түгел, әмәл белән бара эш.
Йозәргә өйрәткәч, йөздертүчесез дә яшәп була...
Рәсем эшендә буяучы булганчы, буяу эшендә рәссам булсаңчы!

## Ялкауның мускулы корсакка үсә

Ялкау йокы симертә, йокы — ялкауны!
Йокы мичкәсенә сыра тутырганнар...
Ялны ялга ялкау ялгый.
Ялкаулыкның тарту көчен җиңәлмәүче үтә ялкау кеше булыр.
Ялкаулык тутыгы көч тимерен ашый.
Эшсезлекне эшем дип уйлый...
Ялкаулыкның ни икәнен белми — эшләп карамаган!
И юньсез — мич башыннан төшми июньсез!
Кашык зарядкасы бүксәне генә үстерә.
Бер алдынгы яктысында өч хөрәсән күләгә...
Бер эшне теләмәгән бер эшне дә өнәмәс.
Эшләүчегә эш күп, эшләмәүчегә эш юк...
Бәйрәм гомер — вәйран гомер.
Эштә эленке-салынкы, ялда — ялкын!
Ул гомер буе үз корсагының грузчигы булып эшләде...

## Иген кыры — ил табыны...

Игеннәргә рәхәт явым, игенчегә рәхмәт яусын!
Комбайнчы җәен ябыга, кышын тазара.
Эше пыскыганның көшеле яна.
Шәһәрнең мул табыны — авылның мул хезмәте.
Икмәккә СЕЗ дип эндәшү тиеш!

## Шәхес — үз язмышының капитаны

Берәү утыз елда йөз еллык эшли, берәү йөз елда да утызлык эшли алмый.
Артка киткән дә алга бара — яхшылыкка кире кайтса!
«Сабыр төбе — сары алтын» — бәясе күтәрелә тора...
Берәү үзен онытып дөнья өчен чаба. Берәү дөньяны онытып — үзе өчен... .
Җимерергә дә дәрман кирәк — кайчак төзәтү дәрте тулаем шуңа китә...
«Кем булмаска» дип тыелу «кем булырга» дип омтылу кебек үк ныклык сорый.
Үзеңне җиңү — иң зур җиңү — монда җиңелүче юк!
Холык начар булу начар, холыксызлык тагын да начар.
Бүтәннәр уңышына сөенә алуыңа сөен!
Сыныйм диган кешегә уртак сынык биреп бак.
Һәркемгә дә яхшы булырга тырышучы яхшы кеше микән?
Үги гасырда ятим шәхесләр туган...

## Кошның канаты иңендә, кешенең — күңелендә

Күңел тау күтәрә, чүп-чар күтәрү генә авыр...
Кояш томалаганда да күңеленә күләгә төшмәсен.
Тыштагы яра да эчтән сызлый.
Күңел күзенә күзлек яратып булмый.
Ачу дуласа сызлауны баса!
Күтәрелмәгән күңел күтәрәмгә кала.
Исәннәрнең күңел чисталыгы өчен мәрхүмнәрне юып күмәләр...

## Ел танытмаганны юл таныта

Көткән юллар — серле, озатканнар — моңсу...
Туктаган флюгерда — тынган җил юнәлеше...
Унга китеп уңмаган, сулга китеп соңлаган...
Гомер юлын кабат үтеп булса, ул гаҗәеп юл булыр иде.
Атом гасыры атына ялшау җиңел түгел.

## Табип — тәнне, әдип җанны дәвалый

Шагыйрь — йөрәк тылмачы.
Шахтер күмер тирәнлегеннән, шагыйрь күңел тирәнлегеннән нур ала...
Җыр — шагыйрьнең пароле.
Җырны шагыйрь тудыра, халык яшәтә.
Чын җыр үзә зынҗырны!
Шагыйрь — халык күңеленең барометры!
Илһамның да фамилиясе була — әгәр дә ул атаклы җырчы булса!
Тансыклап караган иске урында да яңалык күрә.
Яхшыны якты күзләр күрә.
Иҗат кешесе кыска гомердә дә үзен раслап яки инкарь итеп өлгерә...
Фикерең үзеңнән озын гомерлерәк булсын!
Күңел дәфтәре яхшы хәтерле кешегә кирәк: начар хәтерле язарга онытa.
Эчтәлек кыюлыгы булмаганда, форма кыюлыгы бик юаш...
Сай темада тирән йөзеп булмый.
Аксиомалардан теш камашкан — гипотезалар тансык!
Яхшы язу турында сөйләшә торгач, начар язарга да вакыт калмый...
Әсәрне ничек бәяләве белән тәнкыйтьче үзенә дә бәя бирә.
Бию — тәннең җырлавы, җыр — күңелнең биюе!
Балерина аяклары белән «сөйли» — кайбер акыллы башлардан үтемлерәк.
Укучысы акыл биргәндә укытучы сөенсен — бу аның үзен-үзе җиңеп үсүе...
Кил, яңа шагыйрь, мин әйтә алмаганны әйтеп бир, син әйтә алмаганны бүтәннәр әйтер!
«Минемме үз тавышым юк!?» — дип тавышлана ди бер шагыйрь.
Киштә-куначада гомер кичергән канатсыз китаплар да бар...
Популяр шагыйрь: үзен таныйлар, әсәрләрен белмиләр...

## Тәпи йөрергә өйрәтәләр, фикер йөртергә үзең өйрәнәсең

Беренче хәрефләрне укый-яза белмәүче уйлап чыгарган.
Иртәгәге көн кешеләрен кичәгеләр бүген укыта...
Институт бусагасы ашалган — белем бинасын аяклар да кимерә...
Фикерле кеше йөз елдан соң да замандаш!
Үзеңне аңларга да белем кирәк.
Җирнең уңдырышлы катламы юка. Уңган кешеләр катламы да калын түгел.
Акыл тешен дә сындыралар...
Үзе машинада бара, культурасы җәяү тилаклый...

## Чын хыялның яшьлек икәнен киләчәктә генә беләбез...

Яшьлек — чәчәк чак. Җимеш чәчәге дә, кысыр чәчәк тә бердәй матур.
Яшьлек чилләсендә сусаганнар мәхәббәт чишмәсе эзли.
Кызлар сайлый димәгез, яшьлек бит ул разведка!
Гашыйк булган мизгелгә күпме гомер сыя!
Гашыйкларның сүзсез чагы да җыр.
«Яратам»ны йөз дә беренче ишетүе дә рәхәт. «Яратмыйм»ны бер мәртәбә дә ишетәсе килми...
Яратканның ярасы яхшырак ямала.
Беренче мәхәббәтне сагындырып соңгысы килде...
Үкенечле мәхәббәт булмаса, чын мәхәббәтнең көче беленмәс иде.
Күңелгә яз булып киләсең, күздән яшь булып китәсең...
Мәхәббәт кояшы үткән гомердә дә баемый!
Күңел кошлары яшьлек дигән җылы якка оча...
Мәхәббәт арифметикасы: «Берсе белән язылам, икенчесе күңелдә...»
Бер кеше яратуына лаек түгел, ә бөтен халык мәхәббәтен даулый.

## Ирәйгән ирне дә хатын-кыз тудырган

Хатыннар ирләрдән иртәрәк картая һәм озаграк яши.
Кыргый кызлар да йорт хатыннарына әйләнә...
«Без өйләнгәч төн... озын» — дип әйтә икән яшь хатын алган абзый.
Гаилә химиясе: Әминә — кислота...

## Тәрбиясе кырысның — баласы тырыш

Чыпчык буйлы ана бөркет җанлы балалар үстергән!
Ата-ана — тормыш көрәшенә әзерләүче тренерлар.
Ана мәрхәмәте белән ата кырыслыгы — балаларга булган мәхәббәтнең ике канаты.
Вакыты узгач, бишек тә кысан, биләү дә тышау...
Әби белән онык елмаешып килә: икесенең дә авызында берәр теш...

## Хисләр нечкәргән саен дуслык ныгый

Каурыйны җил очыра, канат — кошларны очыра!
Дус яктырганда дошман кара яна.
Берәү дуссыз яши алмый — күңел җылысын кемгә бирсен!
Берәү дошмансыз яши алмый — зәһәрен кая куйсын!
Эчкерсезлек битлеге кигән мәкер дә була...
Күңел сыну — сөяк сыну гына түгел...

## Гомер фасыллары кабатланмый

Тормыш — бер очы янып көлгә әйләнеп, икенче очы чәчәк атып җимеш бирүче мәңгелек агачы.
Кеше дөнья куа-куа дөнья куя...
Үкенү — үткәннәр җимеше.
Чәчәк коелу — җимешкә, чәч коелу ни эшкә?
Тансыклап өлгергәнче бәйрәм җитә, татып өлгергәнче гомер үтә...
Карт күздән дә яшь килә.
Туңган күңелләр истәлек учагында җылына...
Мөмкинлеге кимегән саен күбрәк алмакчы!..
Кеше картая, көчсезләнә, ә кимчелекләре яшәрә, көчәя...
Өлкәннәрнең данына гына кызыгалар, яшеннән көнләшмиләр...
Хыялына ирешсә дә, картлык — югалтулар чоры...
Бер генә кеше үлә дә, ничә кеше кемнәрен югалта: ананы, әбине, хатынны...
Үлгәннәр күңелгә күмелә...
Картлык булырдайны «Булмастыр...» ди, яшьлек булмастайны да булдыра!
Яшьлек картлыкны үз киләчәгем дип уйламый.
Яшь чакта төш тә истә, картайгач өн дә онытыла...
Яшьләр дөньясында картлар чит ил кешеләре...
Хәтер яхшы чаклар хәтер начарлангач та онытылмый...
Яшьлек гадәтләрең искелек калдыгы булып кала...
Яшьлек килә дә китә, картлык килә дә кала...
Яшьләр көрәшә килә, картлар хушлаша китә...
Картлыктан көлү — киләчәгеңне мыскыллау.
Кешенең киләчәге — картлык, кешелекнең киләчәге — яшьлек!
Балачак тәэсирләрен гомер буе конфеттай суырып йөрибез...
Ерак бабайларның кайтавазы сез, оныклар!
Онык — киләчәктә чәчәк атар орлык.
Бала тапмаган хатын оныкларын да югалткан...
Оныгым яхшы — үзем кебек, малаем яман — бабасы күк...

## Озак яшәүнең серен гомер кыскарткан сәбәпләрдән эзлә

Йөрәк — гомер сәгате...
Төш күрү — борынгы кино.
Заманында ябыклык — авыру иде, хәзер симезләр ябыгып тазармакчы.

Саулык — байлык икәнне саулыгыңны туздырып бетергәч кенә беләсең.
Үзенең кайчан үләсен белсә, кеше алданрак үләр иде...
Сангыраулык күзгә чыга, сукырлык тавышка...
Авыруның дөньясы — авырткан урыны...
Хәле авыр «хәлем авыр» дип тә әйтә алмый.
Гомереңең соңгы сабан туенда кеше әҗәл белән аркан тартыша...
Җәяү йөргән озак яшәр диләр дә, озатучылар машинада...
Чебеннәр плакаты: «Чисталыктан саклан!»

## Дөньяны үзгәртәм дисәң, үзеңнән башла

Җыелышта кала җыен эш.
Үз эшен ул җыелышлар арасында эшләштергәләштергәләп ала иде...
Кай кеше трибунада үзен ДОТтагы кебек хис итә...
Культура житмәү турында йодрык төя-төя сөйли...
Бозылган компас теледәй трибунада чайкала — кыйбласы кайда моның?
Җыелышта үткән вакытны эшкә бирсәк, җыелып торуның кирәге калмас иде.
Юри мактасаң да кабул итә, чынлап тәнкыйтьләсәң дә кире кага.
Хак сүз әйтергә хакың булсын.
Пычракны чисталык белән генә җиңеп була!
Табигать безне яратканда ук канга тоз салган...
«Бик кыю фикер әйттең!» — дигәч, куркып калган...
Бер җылы сүз — ике канат!
Сүз кылчыгы озак борчый.
Тешле тел!
Кайчакта — дәшмәү җинаять, кайчакта — дәшү хыянәт.
Иш — ишен таба, сүзлектә дә янәшә: наган, нагайка, нахак...
Сүзлек миниатюралар китабы, кайсы битеннән укысаң да кызык!
Язучы өчен СҮЗ — Архимед әйткән таяну ноктасы.
Эшлексез сөйләр өзлексез.
Бәйдән ычкынган тел.
Тел чыбыркысы шартлатма!
Кайчакта җырның да сүзсезе тансык...
Кайсы кешегә гомер кичәр өчен берничә сүз җитә.
Бик озак дәшми торганнан соң ул бер сүз дә әйтмәде.

## Аракы әчесенә ияләшкән тормыш тәмен югалткан

Исерек агай аек чагына аяк чала.
Салган агай — салулы юлдан баргандай...
Акча туздыра-туздыра үзен туздыра.
«Ефәк бездә мунчала!» — ди торгач, «йөрәк... мунчала»га калган.
Аракы дигән эт йөрәкне талый.
Шешә дигән снаряд дусларны ега...
Шешә авызы бәләкәй дә, әзмәвердәй ирләрне йота!
Алкоголик алфавиты аракыдан ачыла.
Битенә чиртсәң — аракы чәчрәп чыгарга тора!
Күзе кызарган, борын зәңгәрләнгән, йөз саргайган — тәмам өлгерүе җиткән!

## Юньсезнең остазы күләгәдә кала...

Алтын тешле агач кеше.
Кыйммәтле хушбуйга сыланган буш буй...
Синтетик сарык тиресе ябынган бүре.
Тозлы итеп сүгенгәнне тозсыз диләр.
Аның турында сөйләсәң, авыз пычраныр сыман...

Оятсызның оятсызлыгыннан оялаcың, ә ул оялуыннан оялмый!
Начарлыгын яшерер иде дә, яхшының ниндилеген белми.
Явыз ният белән эшләнгән яхшылык...
Икеләнсәң — өчләтерләр!
Цифрблат — танышлык белән алынган сәгать.
«Әйтмә!» дигән сүз тизрәк җитә...
Елан үз агуыннан үлми.
Күзләре ике төпле чемодан...
Көнченең көннәре төн.
Үзләрен зурга куйганнарны сөйләп вакланмыйк!
Койрык болгау да алга илтә, мәсәлән, балыкларны.
Чәч алдырырга чират көтеп чәче агарган да, буятып чыгарга мәҗбүр булган.
Саранның бар нәрсәсе булыр, шатлыгы гына булмас!
Хәленнән килсә, маяга су киптереп куяр иде...
Чебен бозаулаган!
«Роза чәчәге миңа охшаган, — дип әйтте ди Кәбестә. — Яшел да булса!»
«Филгә атланып йөрим!» — дип мактанды Борча.
Югары шүрлеккә куюдан китапның эчтәлеге үзгәрми.
Тычкан уты үзен җир йолдызы дип уйлады.

## Гасырны мизгелләр тудыра һәм мизгелләр тутыра

Гаскәр ала алмаган ныгытмаларны вакыт ала...
Фәкыйрь еллардан бай истәлекләр кала. Бай елларның хатирәсе ярлы.
Киләчәккә х а т л а р барсын, х а т а л а р бармасын.
Ялгышлар үткәннәрдә генә була дип ялгышма!
Техника заманында да җәяү биниләр...

# ГЕННАДИЙ ПАУШКИНГА 60 ЯШЬ



Язучы үзе катнашкан, үз кичергән вакыйгаларны сурәтләгәндә, әсәрнең әһәмияте, ышандыру көче бермәбер арта. Башыннан кичкән хәлләр турында сөйләгәндә, автор тормышның аерым якларын колоритлы һәм җанлы итеп тасвирлауга ирешә. Геннадий Паушкинның хикәяләре һәм кыска-кыска повестьлары укучыны нәкъ әнә шул ягы белән җәлеп итә. Аларда лирик геройның бала вакыты, үсмер чагы, яшьлек еллары сурәтләнә. Чынында, бу — тулы бер буынның биографиясе башланган чак. Зур сугышның бетмәс-төкәнмәс авырлыкларын үз җилкәсендә күтәргән, сугыштан соң ил хуҗалыгын аякка бастыру кыенлыкларын җиңеп чыккан буынның юл башы.

Паушкин китапларын укыганда, Казанның бер читендә яшәгән Гошка һәм аның дуслары — малайлар һәм кызларның характеры үсешен зур дулкынлану белән күзәтеп барасың, ә күз алдыңнан үзеңнең малай чакларың, яшьлек елларың уза. Язучы сурәтләгән буын революцион рух белән көчле. Саф әхлак, коллективизм, киләчәккә өмет һәм зур ышаныч аның аңына сеңгән. Бу яшьләрнең күңел түрендә янган рыцарьлык уты Бөек Революциядән алынган иде. Октябрь казанышларын яулаган әтиләренең һәм абыйларының эшен дәвам иттерүчеләр итеп тойган хәлдә үсте, чыныкты, көч җыйнады ул буын. Язучы үз яшьтәшләренең батырлыкка өйрәнеп, кирәк була калса, революция казанышларын саклап калу өчен утка да керерлек көрәшчеләр сафына басарга әзерләнеп үсүен сурәтли.

Лирик героеның бала чагын тасвирлаганда Г. Паушкин якты, ачык буяуларны күп куллана. Бу табигый да. Балачакның «зәңгәр һәм яшел дөньясын» шатлык кояшы балкыткан көннәр аз түгел шул!

Язучының әсәрләрен укыган һәр кешегә уйланырлык нәрсәләр күп. Иң әлек, ул сәхифәләрдә укучы үткән сугышның утлы сулышын тояр. Паушкин повестьларында һәм хикәяләрендә сугыш малайларның һәм кызларның җанлы образлары аша бирелә. Вакыт тиз үтә, ул үсмерләр сугышчы булып җитешә, Бөек Ватан сугышы солдаты булып, фашизмга каршы көрәшчеләр сафына баса...

«Эшелон» хикәясендә, мәсәлән, укучы инде җитлеккән, үзенең ил алдындагы бурычын яхшы аңлаган кешеләр белән очраша. Хикәядә фин сугышы тәмамланган чак сурәтләнә. Яшь солдатлар утырган эшелонның юлы үзгәрә — ул көньяк-көнбатышка борыла һәм Казан егетләре берничә көннән ил чикләрен сакларга постка басалар. Нәкъ бер елдан соң алар шушында ук беренче булып фашист илбасарларының һөҗүменә каршы торалар...

Бервакыт чик сакчылары отрядның элемтә ротасында минем каршыма кара-тут йөзле, кара кашлы, чәче машинка белән алынган сугышчы егет килеп басты. Аның кулында бик пөхтә итеп язылган блокнот битләре иде.

Шигырьләр! Шундук карап чыктым. Ярыйсы күренә. Исеме дә нәкъ безгә кирәгенчә: «Егерме яшьлек часовой». Отрядта күп тиражлы газета чыга, мин аның редак-

торы идем. Газетаның чираттагы санында Геннадий Паушкинның әлеге шигыре басылып чыкты. Соңыннан ул, газетаның хәрби корреспонденты, полк шагыйре булып танылды һәм сугыш тынып торган араларда язган шигырьләрендә сафташларының батырлыгын һәм кыюлыгын зурлады, яңа батырлыкларга өндәде. Кырыс сугыш шартларында иҗат ителгән ул шигырьләр, зур таләп белән караганда, тулысынча камил булып та җитмәгәндер, мөгаен. Ләкин, Г. Паушкинның полкташлары белә иде: ул шигырьләрнең авторы — рядовой солдат, дошман белән бәрелешләрдә үзен батыр итеп таныткан сугышчы. Шунлыктан аның шигырьләрен солдатлар көтеп ала, яратып укый, үзешчән солдат сәхнәсеннән декламация итеп сөйли.

Бөек Ватан сугышы тарихта ераклаша барган саен аңа игътибар кимеми, киресенчә, кешеләрнең ул сугыш турында күбрәк беләсе килә. Данлы үткәннәрне хәтерләү — бүгенгенең рухи ихтыяҗы. Хәтер — безнең рухи байлыгыбыз, киләчәккә әйдәүче көч. Сугышта кешеләр ничек яшәгән һәм яраткан, ничек дошманга каршы көрәшкән һәм үлгән? Ул чор кешеләренең рухи дөньясы нинди булган? Аларның җиңелмәслеге нәрсәдә? Замандашларыбызга сугыш чорының әхлак нормалары кай ягы белән кадерле һәм кыйммәтле? Сугыш турындагы әдәбият нәкъ менә шундый сорауларга җавап бирергә омтыла. Хәтердә утлы елларга әйләнеп кайта-кайта без сугышның үзебез өчен бик авыр булган беренче айларына күз салабыз. Чик сакчылары йөрәкләренең соңгы тибешенә чаклы үз постларында калып, дошманга каршы баһадирларча сугыштылар. Шул чорда, кырык беренче елның июнь аенда ук инде, бөтен җир йөзе безнең булачак Җиңүнең алшартларын күрде.

«Кагул заставасында» дигән повестенда язучы әнә шул вакыйгаларны төп геройның кичерешләре аша сурәтли. Ул — яшь чик сакчысы радист — Полынин. Укучы аның йөзендә авторны бик ачык таный. Полынин, тирә-юньдә дошман солдатлары мәш килеп йөргән шартларда, застава начальнигының сугышчан приказын үти. Бу хакта укыганда искә төшә: 1941 елның 22 июль таңында 12 нче застава радисты кече сержант Геннадий Паушкин күрсәткән батырлык турында бөтен отряд сокланып сөйләгән иде. Озак та үтми, Паушкин Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнде. Ул чагында әле беренче бүләкләр иде болар.

Г. Паушкинның хәрби темага язылган башка хикәяләрендә дә безнең полкның сугышчан юлы яктыртыла. Болар — Көнбатыш Кавказ тауларында, Балкан буйларында һәм Альп тарлавыкларында барган сугышлар. Автор аларның һәркайсында үзе катнашкан, сугыш авырлыгын үз җилкәсендә татыган.

«Ул көннең ахыры булмастай тоелды,— дип яза автор.— Кояш тукталып калган шикелле, ә вакыт бер дә узмый кебек... Төн җиткәч, король дивизиясе частьлары Прут аръягына тәгәрәделәр. Ә яңа көн таңы тугач, барысы да яңабаштан башланды...»

Әйе, нәкъ менә шулай булды. Мондый хәлне кырык беренче ел солдатлары үз башларыннан кичерделәр һәм бу күренеш безнең әдәбиятыбызда күп тапкырлар чагылыш тапты. Шулай да Г. Паушкинның хәрби темага язылган әсәрләрен укыганда икенчеллек, кабатлану тойгысы тумый: повесть та, хикәяләр дә — һәркайсы үзенчә үзенә генә хас алымнар белән, чик сакчыларының сугыш шартларында ничек яшәвен, ничек эшләвен сурәтли, яшел фуражкалы сугышчыларның образын көндәлек гадәти эшләрдә, геройларның хис кичерешләре аша гәүдәләндерә. Болар — сугышның бөтен авырлыгын үз иңнәренә алган рядовой солдатлар. Алар сугышның асылда көндәлек эшләрдән гыйбарәт булуын аңлыйлар. Дөрес, бу эшләрнең һәркайсы зур хәтәр астында, үлем янәшәсендә башкарыла. Шул эшләрне намус белән үтәү — булачак җиңүгә өлеш кертү ул.

Г. Паушкин әсәрләрен укыганда, күз алдыннан авторның сугышчан дуслары, коралдаш иптәшләренең образлары уза. Язучы аларның психологиясен, рухи дөньясын, характерын ачарга омтыла. Бу җәһәттән, истә калырлык образлар аз түгел. Батыр, оста куллы Алексей, геройларча һәлак булган старшина Наумов, сугышта салкын канлы, солдатларга якын кеше лейтенант Ветчинкин, сугышчылар коллективына җан кертүче политрук Лепешкин, офицер хатыннары, аларның балалары — барысы да истә кала. Язучы сугышны көтелмәгән хәлләр тезмәсе итеп сурәтли. Сугыш кешеләр язмышын үзенчә хәл итә.

Сугыш юлларында кайгылы-хәсрәтле хәлләр дә, көлкеле ситуацияләр дә күп. Бик пөхтә эшләнгән новеллаларның берсендә — «Яшка»да — Геннадий Паушкин бер ишәк

турында сөйли. Солдатлар аны «Яшка — пулеметчы» дип атаганнар. Ул, ни сәбәпледер, немецлардан качып, безнең якка чыккан. Сыртындагы иярга пулемет станы да беркетелгән булган. Күр күңелле, тапкыр егет ефрейтор Зарубин аны тотып алган, ияләштергән. Яшка-ишәк элемтәчеләрнең булышчысына әверелә, батальон рациясе өчен кирәкле аккумуляторларны йөртә.

Беренче карашка, бу — гадәти булмаган бер эпизод кына шикелле. Ләкин язучы шул очрак аша да фронтовик егетнең җанлы характерын, аңа хас булган типик халәтне — яшь сугышчының күңел күрлеген бирә алган.

«Зәңгәр Дунай аръягында»— күләме белән кечкенә генә хикәя, анда сугышның соңгы чорындагы хәлләр тасвирлана. Бу хикәядә мәхәббәт темасы романтик яңгыраш таба. Алыптай гәүдәле сержант Алексей Горюнов элемтәче кыз Юлия Беловага гашыйк. Алар Дунай аръягындагы калкулыкта очрашалар. Гаскәрләр елга аша кичә, ә элемтәчеләр телефон линиясенең өзеклеген тикшереп йөриләр. Очрашу да кыска вакытлы, эш арасында гына. Ләкин яшьләр аңлашырга барыбер өлгерә. Алексей белән Юлия табигать матурлыгына сокланып сөйләшәләр, хыялланалар. Сугыш беткәч, Алексей кызны үзенең туган якларына — ак төннәр белән матур төньякка алып китәчәк... Ләкин сугыш әле бетмәгән. Алексей һәлак була, аның үлеме күңелне тетрәтә. Хикәя, шулай итеп, сугыш фаҗигасен искә төшерә, совет кешесенең рухи матурлыгын җырлый.

Геннадий Паушкин сугышта үзе күргәннәрне, үзе кичергәннәрне яза. Аның әсәрләре шуның белән үзенчәлекле дә. Аларның һәркайсы язучыга бик яхшы таныш булган реаль геройларга багышлана. Ул геройларның туган илгә мәхәббәте әсәрләренең төп пафосын тәшкил итә.

Язучы фронтта күргәннәрен, сугышларда һәм поход юлларында кичергәннәрен полкташларына мәхәббәт белән типкән йөрәге аша үткәреп яза. Аның әсәрләрендә күп кенә геройлар үз исемнәре белән алынган. Советлар Союзы Герое Кузьма Федорович Ветчинкин, мәсәлән, хәзер отставкада, подполковник, Одессада яши. Солдат Алексей образында язучы рядовой Михаил Егорович Тимушев батырлыгын сурәтли. Бу баһадир солдат сугышның беренче көнендә күрсәткән батырлыгы өчен Ленин ордены белән бүләкләнгән иде. Хәзер ул Ленинградта яши, металлургия заводында эшли.

...Кисловодск санаториенда дәваланганда минем бүлмәдәшем Казаннан иде. Мин аңардан: «Геннадий Александрович Паушкинны белмисезме?»— дип сорадым.

«Беләм, Казанда бу исем бик билгеле, безнең язучы ул»,— дип җавап бирде бүлмәдәшем.

Чик сакчысы, хәрби корреспондент, беренче сугышлар батыры, башта сержант, соңыннан старшина булган Геннадий Паушкин — Прут ярларыннан Кавказга, Кавказдан Альп тауларынача сугыш юлларын узган солдат. Бөек Ватан сугышы давылларын башыннан ахырынача кичеп, ул язучы булды. Әдәбият фронтында да тылда ятмый Паушкин. Кичәге солдат яңадан алгы сызыкта — хәзер инде хезмәт, индустрия фронтының алгы сызыгында. «Комсомолец Татарии» һәм «Комсомольская правда» газеталарының корреспонденты сыйфатында язучы нефть промыселларында була, «кара алтын» чыгару осталары турында яза, Урал белән Идел арасындагы төбәктә яткан җир асты хәзинәләрен үзләштерүче хезмәт батырларының образларын тудыра.

Яхшы хәтерлим, мин «Пограничник» журналының редакторы булып эшләгәндә, редакциягә Паушкинның очерклары килде. Язучы аларда Кама автогигантында эшләүче кичәге чик сакчылары турында язган иде. Мин сөенеп куйдым, полкташым иңатында моңарчы да яңгыраган хәрби-героик тема бик табигый рәвештә тезелеш, хезмәт батырлыгы темасы белән очрашты!

Г. Паушкинның «Чаллы җирендә» дигән китабы камазчылар турында язылган беренче китап булды бугай. Аның ВЛКСМ Үзәк Комитеты тарафыннан диплом белән бүләкләнүе дә табигый. Хөкүмәт бүләкләре белән бүләкләнгән камазчылар исемлегенә бу китап авторының исеме дә кергән икән — бер дә очраклы түгел: язучының иҗади хезмәтен ил шулай бәяләде.

Степан СИДОРОВ.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## САЛИХ СӘЙДӘШЕВНЫҢ ЮБИЛЕЙ ТАНТАНАСЫ

1 декабрьда республикабыз җәмәгатьчелеге татар совет профессиональ музыкасына нигез салучы композитор Салих Сәйдәшевнең туууна 80 ел тулуны киң билгеләп үтте.

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында композиторның юбилеена багышланган тантаналы кичә булды. Президиумда — КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Р. М. Мусин, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев, ТАССР Министрлар Советы Председателе Г. И. Усманов, КПСС өлкә комитетының икенче секретаре В. С. Дергунов, партия өлкә комитеты секретаре Ф. А. Садыйков, КПССның Казан шәһәр комитеты беренче секретаре М. К. Рәмиев, республикабызның партия, совет һәм җәмәгатьчелек оешмалары вәкилләре, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, юбилей тантанасында катнашырга килгән кунаклар.

Кичәне КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова ачты.

Композиторның тормышы һәм иҗат юлы турындагы докладны ТАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе М. З. Яруллин ясады. РСФСРның һәм ТАССРның Дәүләт премияләре лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким, Башкортстан АССР Композиторлар союзы идарәсе председателе композитор Р. Х. Газизов, Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры РСФСРның халык артисты М. Х. Сәлимҗанов Салих Сәйдәшевнең музыка культурабызны үстерүгә керткән өлеше турында сөйләделәр.

Аннары Татарстан сәнгать осталары катнашында С. Сәйдәшев әсәрләреннән төзелгән зур концерт булды.

## МӘҖИТ ГАФУРИНЫҢ ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

Татар һәм башкорт әдәбиятлары классигы Мәҗит Гафуриның 100 еллыгы бөтен ил күләмендә киң һәм тантаналы итеп билгеләп үтелде.

Бу бәйрәмнең финалы Мәскәүдә Союзлар йортының Колонналы залында зур тантана рәвешендә үздырылды. Кичәдә илнең зур әдипләре, СССР Язучылар союзы җитәкчеләре, партия, совет һәм җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты. Мәскәү, Казан, Уфа әдипләре белән беррәттән, бу кичәдә Украина, Таҗикстан, Үзбәкстан һәм башка тугандаш Союз республикаларыннан да вәкилләр бар иде.

Кичәне кереш сүз белән РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе Сергей Михалков ачты. Соңыннан Мәҗит Гафуриның тормыш һәм иҗат юлы турында доклад тыңланды. Шагыйрьнең иҗаты һәм күпмилләтле совет әдәбияты үсешенә керткән өлеше турында Мәскәүдән — Н. Доризо, А. Борщаговский, Киевтан — Б. Олейник, Нукустан — И. Йосыпов, А. Мирзаһитов, Казаннан Г. Ахунов иптәшләр чыгып сөйләделәр.

Соңыннан Башкортстан сәнгать осталарының зур концерты булды.

## КОМПОЗИТОРНЫҢ ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

26 ноябрьда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Татарстанның халык артисты, Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты композитор Заһит Хәбибуллинга 70 яшь тулуга багышланган юбилей кичәсе булды.

Кичәне кереш сүз белән ТАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе Мирсәет Яруллин ачты. Аннары юбилярның тормыш һәм иҗат юлы турында доклад белән РСФСРның М. Глинка исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты композитор Фасил Әхмәтов чыкты.

Котлаулардан соң Заһит Хәбибуллин әсәрләреннән төзелгән концерт куелды.

Юбилей кичәсендә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

## ШӘРИФ КАМАЛ МУЗЕЕ

Казанның Островский урамындагы 15 нче йортта татар совет әдәбияты классигы Шәриф Камалның музей-йорты эшли башлады. Аны ачу тантанасында шәһәрнең партия, совет, җәмәгатьчелек оешмалары вәкилләре, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, әдипнең туганнары, күп санлы казанлылар катнашты.

Татарстан культура министры урынбасары М. Т. Низамиев, СССРның халык артисты Г. Р. Шамуков, Татарстан Язучылар союзы идарәсе секретаре М. М. Хәбибуллин, әдипнең кызы З. Ш. Байгильдиева, ТАССР Дәүләт музее директоры Л. Г. Вәлиева иптәшләр чыгышыннан соң

казанлылар музей-йортка күтәреләләр, андагы экспонатларны карадылар.

Музей-йорт экспозициясе әдипнең шәхси әсбапларыннан тыш, шул чорның кайбер әйберләре белән дә тулыландырылган. Биредә Ш. Камалның китапханәсе, язу машинкасы, рояль. Алгы бүлмә стенасына эленгән «Без җиңәрбез!» очеркының кулъязмасы, керосин лампасы куелган язу өстәле, чәй чынаягы, кечкенә генә мич (аны язучы үзе чыгарган) әдипнең Бөек Ватан сугышы елларындагы иҗат чоры турында бик матур сөйли.

Бу йорт бөек рус совет язучысы Александр Фадеев, патриот-шагыйрь Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, күренекле композитор Салих Сәйдәшев һ. б. эзләрен кадерләп саклый. Стенада — аларның фоторәсемнәре.

Язучының кызы З. Ш. Байгильдиева, экспозиция авторы — ТАССР Дәүләт музееның әдәбият бүлеге мөдире Д. Б. Бәһаветдинова, художестволы бизәү авторы — рәссам А. П. Леухинның зур тырышлыгы нәтиҗәсендә музей-йортны караганнан соң татар совет әдәбияты классигы, Ленин ордены кавалеры Шәриф Камалның тормыш һәм иҗат юлы, киң җәмәгать эшчәнлеге тулы булып күз алдына килә.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Ноябрь аенда Язучылар союзы каршында эшләп килгән проза һәм тәнкыйть секцияләренең берләштерелгән утырышы булды. Көн тәртибенә бүгенге татар прозасының теле турында сөйләшү куелган иде.

Утырышны кереш сүз белән проза секциясе председателе А. Расих ачты. Аннан соң әдәбият белгече И. Бәширова проза теле хакында доклад белән чыкты. Докладтан соң фикер алышулар булды. Фикер алышуларда язучылар Г. Бәширов, Ә. Еники, Г. Ахунов, Ф. Хөсни, М. Мәһдиев, Ә. Баянов, И. Юзеев, Р. Мостафин, Т. Миннуллин, Ф. Миннуллин, М. Галиев, Ф. Мусин, Ф. Сафиуллина, М. Вәлиев, Ә. Гаффар, Ф. Ганиева һ. б. иптәшләр катнашты.

* * *

Балалар әдәбияты секциясендә эшчә язучы Нурислам Хәсәновның эшчеләр тормышыннан алып язылган хикәяләр җыентыгы тикшерелде. Тикшерүдә язучылардан Б. Камалов, Ш. Рәкыйпов, А. Тимергалин, Ә. Гаффар, Р. Кукушкин, К. Кәримов, Р. Миннуллин иптәшләр катнашты. Авторга файдалы киңәшләр бирелде, кулъязма нәшриятта даими чыга торган «Минем профессиям» сериясендә җыентык итеп чыгарырга тәкъдим ителде.

## ЮГАРЫ ӘДӘБИ КУРСЛАРДА

Мәскәүнең М. Горький исемендәге әдәбият институты каршындагы икееллык Югары әдәби курслар былтыр үзенең 25 нче уку елын башлап җибәргән иде. Анда илебезнең төрле республикаларыннан һәм өлкәләреннән килгән кырык язучы белемнәрен күтәрәләр. Уку елы башлануга курслардагы коммунист язучылардан башлангыч партия оешмасы төзелде. Күптән түгел генә оешманың узган бер еллык эшенә йомгак ясаган отчет-сайлау җыелышы булып үтте. Сайлауларда татар язучысы Гәрәй Рәхим партбюро составына керде һәм бюро тарафыннан Курсларның башлангыч партия оешмасы секретаре урынбасары итеп билгеләнде.

## ЯҢА ЛАУРЕАТЛАР

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премияләрен бирү комитеты тәкъдимнәрен тикшергәннән соң, ВЛКСМ өлкә комитеты бюросы премияләрне түбәндәге иптәшләргә тапшырырга карар кылды:

композитор Рәшит Фарукович Абдуллинга — 1978—80 елларда язган эстрада җырлары циклы өчен;

Казан кинохроника студиясе кинематографистлары — режиссер Наил Камилович Вәлитовка һәм оператор Авис Гершович Привинга — Татарстанның киноелъязмасын тудыруга һәм Идел буе халыклары арасында туганнарча дуслык тәрбияләү эшенә керткән зур өлешләре өчен.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Оешманың утырышында Әдип Маликовның нефтьче якташларына багышланган шигырьләр циклы укып тикшерелде. Циклда, аерым геройлар аша, Татарстан нефтьчеләренең үткәне һәм бүгенгесе, аларның батыр хезмәте сурәтләнә. Фикер алышуларда Гамил Афзал, Клара Булатова, Шамил Бикчурин, Хәниф Хәйруллин, Рафаил Төхфәтуллин, Энже Мөэминова, яшь язучылардан Нур Әхмәдиев, Роберт Рәкыйпов, Илдар Әхсәнов, Әсрар Галиев, Фәрит Гыйльметдинов, Һава Сафина, Альберт Хәсәнов иптәшләр катнашты. Алар заман кешеләренә багышланган бу шигырьләргә уңай бәя биреп, әсәрне тагын да камилләштерү өчен авторга файдалы киңәшләр әйттеләр.

* * *

Лениногорск шәһәре «Чишмә» әдәбият-сәнгать берләшмәсе членнары Разил Вәлиуллин, Илдус Тархапов, Фәйзи Хөснуллин Мәскәүдә халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә чыгыш ясадылар. Алар үз шигырьләрен, үзләре язган көйләргә җырлар башкардылар. Тамашачылар яшь авторларны җылы каршыладылар. Чыгыш ясаучылар ВДНХ дипломы һәм медальләре белән бүләкләнделәр.

* * *

Әлмәт шәһәренең Максим Горький исемендәге клубында яшь талантлар кичәсе уздырылды. Моннан егерме биш ел элек бу клуб китапханәсе каршында «Әлмәт» әдәбият берләшмәсе эшли башлаган иде. Кичә нәкъ шул юбилейга багышланды.

Кичәне кереш сүз белән Әлмәт язучылар оешмасының җаваплы секретаре ша-

гыйрь Әдип Маликов ачты. Ул әдәбият берләшмәсенең үсеш юлы турында сөйләде, яшь язучылар алдында торган бурычларга тукталды.

Нефть районнарындагы яшь иҗат көчләрен тәрбияләү өлкәсендә актив эшчәнлеге өчен Әлмәт язучылар оешмасы ВЛКСМ Үзәк Комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләнгән иде. Комсомолның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре Мәхәббәт Гарифуллина язучылар оешмасына әлеге грамотаны тапшырды. Юбилей уңае белән, КПССның Әлмәт шәһәр комитеты һәм халык депутатларының шәһәр советы башкарма комитеты «Әлмәт» әдәбият берләшмәсен Мактау грамотасы белән бүләкләде. Кичәдә шулай ук Татарстан Язучылар союзы идарәсенең котлау телеграммасы укылды.

Кичәнең әдәби өлешен шагыйрә Клара Булатова алып барды. Нефть районнарында яшәүче яшь шагыйрьләр Нур Әхмәдиев, Венера Туктарова, Роберт Рәкыйпов, Разим Вәлиуллин, Илдар Әхсәнов һәм башкалар үзләренең шигырьләрен укыдылар.

Юбилей кичәсендә шулай ук үзешчән коллективларның Бөтенсоюз фестивале лауреаты — Р. Вәлиуллин җитәкчелегендәге ирләр вокаль квартеты, Әлмәт шәһәренең яшь җырчылары һәм музыкантлары чыгыш ясады.

Фойеда нефть ягы язучыларының әсәрләреннән күргәзмә һәм китап сәүдәсе оештырылды.

* * *

Әлмәт язучылар оешмасы җыелышында Азнакайда яшәүче яшь шагыйрь Нур Әхмәдиевның иҗат отчеты тыңланды.

Н. Әхмәдиев — актив иҗат итүче яшьләрнең берсе. Үткән ел аның «Аһаң» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Н. Әхмәдиев проза өлкәсендә дә көчен сыный, балалар өчен повесть язды.

Җыелышта чыгып сөйләгән язучылар Гамил Афзал, Юныс Әминов, Клара Булатова, Энже Мөэминова, Шамил Бикчурин, Хәниф Хәйруллин, Җәмит Рәхимов, Әдип Маликов һәм әдәбият берләшмәләре членнары яшь шагыйрь иҗатындагы уңай сыйфатларны билгеләп үттеләр, аңа теләк һәм киңәшләрен белдерделәр.

Җыелыш бертавыштан яшь шагыйрь Н. Әхмәдиевне СССР Язучылар союзы членлыгына тәкъдим итәргә дигән карар кабул итте.

* * *

«Татнефть» берләшмәсенең генеральный директоры урынбасары Үзбәк Саттаров нефть төбәгендә яшәүче язучылар һәм әдәбият берләшмәләре членнары белән очрашты. Ул Татарстан нефтьчеләре алдында торган бурычлар, аларның киеренке хезмәтләре, батырлыклары турында сөйләде.

Ш. Бикчурин, Ә. Маликов, Җ. Рәхимов, Ю. Әминов, Р. Вәлиуллин һәм башкалар үзләренең чыгышларында хезмәт кешесе турында заманга лаек әсәрләр тудыру өчен язучыларның нефть предприятиеләре белән тыгыз бәйләнештә яшәргә тиешлекләрен әйттеләр, киләчәккә иҗат планнары белән уртаклаштылар.

* * *

Әлмәт язучылар оешмасы җыелышында Илдар Әхсәновның ике поэмасы һәм яңа шигырьләр циклы тикшерелде.

Фикер алышуларда язучылар К. Булатова, Г. Афзал, Ә. Маликов, Ш. Бикчурин, Э. Мөэминова һәм әдәбият берләшмәләре членнары катнашты. Алар И. Әхсәнов әсәрләренә нигездә, уңай бәя бирделәр, нефтьчеләр дөньясына үтеп керә һәм образлы фәлсәфи фикер йөртә белгән авторның әле тел мәсьәләсендә талымсызлык очраклары күрсәтүенә борчылып сөйләделәр.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

Шагыйрьләр Әхсән Баян, Рөстәм Кутуй, Роберт Миңнуллин Казанның Ленин исемендәге Культура сараенда, «Сәнгать сөючеләр клубы» членнары белән очраштылар, бүгенге әдәбият, «Казан утлары» журналы турында сөйләделәр, яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

Язучы Гариф Ахунов һәм шагыйрь Роберт Миңнуллин Казан сәүдә-кулинария училищесы студентлары белән очрашу уздырдылар. Гариф Ахунов аларга язучылык хезмәте турында сөйләде, Р. Миңнуллин үзенең яңа язылган шигырьләрен укыды.

## ЯҢА ГАЛЕРЕЯ

Чаллы шәһәренең Тынычлык проспектында бөтен бер кварталга сузылган яңа йортның беренче катында картиналар галереясы ачылды.

Бирелә һәркемне матурлык дөньясы каршылый. Экскурсовод, картиналар янында тукталып, аларның тарихы, авторлары турында сөйли.

Яңа галереяга картиналар Татарстан АССР сынлы сәнгать музее коллекциясеннән алынган. Галерея ике бүлектән гыйбарәт. Революциягә кадәрге рус сәнгате. Монда XVIII-XIX йөздәге һәм XX гасыр башында иҗат иткән рус рәссамнарының әсәрләре куелган. Портретлар күп, академист-рәссамнарга зур урын бирелгән.

Совет сәнгате бүлеге аеруча бай. Бирелә рәсем сәнгате белән беррәттән скульптура һәм декоратив сәнгать әсәрләре киң урын алган. Республикабызның танылган рәссамнары СССРның халык художнигы Х. Якупов, РСФСРның халык художнигы Л. Фәттахов, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Н. Кузнецов һәм башкаларның әсәрләре куелган. Башка картиналарда эшчеләр һәм колхозчыларның батыр хезмәте, космик очышлар, культура темалары.

Чаллыда Татарстан сынлы сәнгать музееның филиалы ачылу — КамАЗ төзүчеләрнең, шәһәр кешеләренең тормышында якты сәхифәгә әверелде.

## КАЗАН РӘССАМНАРЫ — МӘСКӘҮДӘ

Мәскәүнең үзәк күргәзмә залында «Советская Россия» дип исемләнгән республика күргәзмәсе ачылды. Ул «Россия рәссамнары партиябезнең XXVI съездын каршылый» дигән девиз белән уза. Күргәзмәгә 7 меңнән артык графика, скульптура сынлы сәнгать әсәрләре куелган.

Биредә Казаннан РСФСРның атказанган художнигы Виктор Кудελькин иҗатын күрсәтүгә дә урын бирелә. Казан художнигының Советлар Союзы Герое Н. А. Якупов портретында совет халкының батырлыгы гәүдәләндерелә.

Илдар Зариповның «Язгы көн», Фәрит Якуповның «Кызыл туй» дигән әсәрләре дә биредә урын алган.

## «ЛӘЙСӘН» ҖЫРЛАРЫ

Республикабыз кибетләренә «Ләйсән» балалар вокаль ансамбле җырлары язылган пластинка сатуга чыкты.

«Ләйсән» — гади ансамбль генә түгел. Анда 9 яшьтән алып 15 яшькә кадәрге кызлар чыгыш ясый. Шунысы да кызык, бу — ялгыз башкаручылар ансамбле. Ансамбльнең теләсә кайсы члены аерым гына да чыгыш ясый ала.

Азнакай эшчеләр поселогындагы талантлы оештыручы Алсу Гарифуллина җитәкләгән бу ансамбль илебез тамашачыларына Бөтенсоюз телевидениесе аша күрсәтелгән чыгышлары белән билгеле.

Ансамбль программасында совет һәм чит ил авторларының әсәрләре урын алган. Әмма коллектив татар халык җырларын, татар совет композиторларының әсәрләрен аеруча зур уңыш белән башкара. Сатуга чыккан пластинкада, башлыча, татар халык көйләре һәм республикабыз композиторлары әсәрләре язылган.

## ТАТАР АШЛАРЫ МУЗЕЕ

Октябрь бәйрәме алдыннан Татар ашлары йортында гадәти булмаган музей ачылды. Аның экспонатлары — милли ашлар. Биредә бодай көлтәләре дә куелган.

Музейны оештыруга Татар ашлары йортының шеф-повары, Ленин ордены кавалеры, РСФСРның атказанган сәүдә работнигы Юныс Әхмәтҗанов зур өлеш керткән.

Кулинария музее яшь поварлар һәм кызыксынган бөтен кеше өчен осталык мәктәбе булачак.

## ДУСЛЫК КИЧӘСЕ

Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге сәхнә ветераннары советы һәм Актерлар йорты РСФСР шәһәрләрендә «Татар мәдәнияте учаклары» циклыннан кичәләр үткәрү турында хәстәрлек алып баралар. Беренче кичә ноябрь азагында Актерлар йортында үткәрелде һәм ул Уфа шәһәренә багышланды. Кичәдә чыгыш ясаучы күренекле татар язучысы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Нәкый ага Исәнбәт, сәнгать фәннәре кандидаты Хәсән Гобәйдуллин, Башкортстанның атказанган артисты Мәхмүт Хәбибуллин һ. б. Уфа шәһәренең тарихы, татар мәгърифәтчелек хәрәкәте, Уфада яшәп татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүгә өлеш керткән кешеләр, «Нур» труппасының тарихы, эшчәнлеге, башкорт һәм татар халыклары арасындагы гасырлардан килгән дуслык, культура бәйләнешләре турында сөйләделәр.

Кичәнең икенче бүлегендә татар сәнгать осталары һәм үзешчән түгәрәкләрдә катнашучылар көче белән куелган һәм Уфа шәһәренә багышланган зур концерт булды. Күренекле сәнгать остасы габойчы С. Алиев, Татарстанның атказанган артистлары Р. Сәхәбиев, Р. Мостафин, яшь артистлар Л. Хәсәнова, И. Бикташиров, Р. Маликов, сәләтле һәвәскәрләр Г. Гаязова, А. Гайнуллина һ. б. татар, башкорт халык җырларын, татар, башкорт композиторларының әсәрләрен зур осталык белән башкардылар. В. Маяковский исемендәге клуб һәвәскәрләренең чыгышы да алкышлар белән кабул ителде.

Актерлар йортының фойесында Уфа шәһәренә, «Нур» труппасының эшчәнлегенә багышланган бай күргәзмә оештырылган иде.

Кичә тамашачыларда матур тәэсир калдырды. Шушы циклдагы кичәләр киләчәктә Оренбург, Астрахань, Мәскәү, Уральск, Троицк һ. б. шәһәрләргә багышлап үткәреләчәк.

## ЯҢА КИТАП

Татарстан китап нәшрияты татар әдәбияты классигы, галим һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның иҗаты, идея-эстетик карашлары, революцион эшчәнлеге һәм гыйльми хезмәтләре турында «Язучы, революционер, галим» исемле җыентык бастырып чыгарды. Рус телендә дөнья күргән әлеге җыентык СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан 1977 елның мартында уздырылган фәнни конференция материаллары нигезендә төзелгән. Мәкаләләрнең авторлары Мәскәү, Казан, Баку, Уфа, Ташкент шәһәрләреннән күренекле тарихчы һәм философлары, әдәбият һәм тел белгечләре, тәнкыйтьчеләр тәшкил итә.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солистлары **Хәйдәр Аббасович Бигичевка** һәм **Зилә Даяновна Сөнгатуллинага**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1980 ел, 26 сентябрь Указы белән «Татарстан АССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге Татар

дәүләт филармониясенең художество җитәкчесе һәм симфоник оркестрларының баш дирижеры Ренат Салаватович Салаватовка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1980 ел, 26 сентябрь Указы белән, «Татарстан АССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисткасы **Люция Абдулловна Фарсинага**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1980 ел, 12 сентябрь Указы белән «Татарстан АССРның халык артисткасы» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татарстан АССР дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисты — баянчы **Рәшит Шәкурович Мостафинга**, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең симфоник оркестры артисты **Альберт Гыйлемханович Гыйльфановка**, Татарстан АССР дәүләт җыр һәм бию ансамбле хоры солисты **Юрий Иванович Самарскийга**, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисты **Рафаэль Әхәтович Сәхабиевка** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1980 ел, 4 октябрь Указы белән «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

## ҮЗӘК НӘШРИЯТТА БАСЫЛЫП ЧЫКТЫ

«Советская Россия» нәшрияты язучы Гариф Ахуновның Арча районы хезмәтчәннәренә, аларның эш һәм уйларына багышланган очеркын аерым китап итеп бастырып чыгарды. «Язучы һәм вакыт» сериясендә басылган бу китап «Тукай җирендә» («На земле Тукая») дип атала.

Очерк район җитәкчесенең партиячел эш стилен, кешелекле сыйфатларын ача торган тәэсирле мисалларга бик бай. Аның геройларын бүгенге көннең мөһим проблемалары, бигрәк тә авыл яшьләрен тәрбияләү мәсьәләләре дулкынландыра. Очеркны русчага В. Залещук тәрҗемә иткән.

## ТЕАТРЛАРДА ЯҢА СЕЗОН

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры 1980-1981 ел сезонын «Банкрот» спектакле белән ачып җибәрде. Бу әсәр татар әдәбияты классигы Галиәсгар Камалның тууына 100 ел тулу уңае белән куела башлаган иде.


В. И. Качалов исемендәге Казан зур драма театры яңа сезондагы беренче тамашачыларына А. Штейн пьесасы буенча куелган «Астория» кунакханәсе» спектаклен күрсәтте.

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры быелгы сезонны Нәҗип Җиһановның «Җәлил» поэма-операсы белән башлады. Спектакльне сәхнәгә Казагыстан ССР һәм Татарстан АССРның халык артисты Ф. Мансуровның музыкаль җитәкчелегендә режиссер А. Почиковский куйган. Җәлил ролен яшь җырчы, Татарстан АССРның халык артисты Хәйдәр Бигичев башкара.

*Муса Җәлилнең 75 еллыгына багышлыйбыз*

# Юллар җыры

ӘНВӘР БАКИРОВ музыкасы　　　　ЗӘКИ НУРИ шигыре




Җырлап тибә, дөрләп тибә йөрәк
Картаерга һич тә ашыкмыйм.
Күгем якты, җитәр җирем ерак —
Зур юлларга илдә гашыйк мин.
Җырлап тибә, дөрләп тибә йөрәк
Картаерга һич тә ашыкмыйм.

Кыю менәм биек үрләргә мин,
Маякларым — йөрәк утыннан.
Кирәк икән — диңгезләрне кичәм,
Ярда тормам куркып дулкыннан.
Кыю менәм биек үрләргә мин,
Маякларым — йөрәк утыннан.

Болытлардан өстә очар өчен
Канат җилпеп күңел ашкына!
Бу җырларга безнең кушылмыйча
Түзсә түзәр бары таш кына.
Очар өчен өстә болытлардан
Канат җилпеп кү[illegible]ашкына!

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫ!

«Казан утлары» журналының киләсе айда чыгачак 3 нче санында нинди әсәрләр басылачагын әйтеп үтик. Соңгы елларда бер-бер артлы иҗат ителгән повестьлары белән укучыга шактый ук таныш язучы Миргазиян Юныс бу санда яңа әсәрен тәкъдим иткән. «Биектә калу» дип аталган бу повестьта Бөек Ватан сугышының соңгы көннәре тасвирлана. Автор аны Советлар Союзы Герое Сәләховка багышлаган.

Мәгълүм булганча, март аенда халыкара хатын-кызлар көне билгеләнә. Шул бәйрәм уңаеннан журнал үзенең бу санында хатын-кыз авторларның әсәрләренә урынны аеруча мул биргән. Алар арасында күп санлы шагыйрәләр дә, прозаиклар да бар. Мәсәлән, яшь язучы Нәбирә Гыйматдинованың «Бердән-берем хакына» исемле яңа повесте, мөгаен, укучыны шатландырыр. Әсәрнең үзәк образлары да — хатын-кызлар, күтәрелгән проблемасы — әхлак мәсьәләләре.

Шагыйрьләр Р. Гатауллин, Ш. Анак та яңа әсәрләре белән катнашалар.

Март — язучы Афзал Шамов туган ай. Быел аңа 80 яшь тулачак. Юбилей уңаеннан тәнкыйтьче Ф. Мусин «Керәшчеләр токымыннан» исемле мәкалә язган. Әдип үзе исә «Соры мәче» исемле хикәясен тәкъдим иткән.

Очерклар һәм публицистика бүлегендә язучылар Р. Кутуй, Р. Вәлиев, яшь язучы Ф. Әһлиуллина язмалары бар. Монда Татарстанның яңа бишьеллыкта башкарачак эшләре турындагы мәкаләләр дә урын алган.

Болардан тыш журналның өченче санында «Китап күзәтү», «Яшь тәнкыйтьче сүз ала», «Сәнгать», «Елмаеп та, көлеп тә...», «Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары» рубрикаларына караган язмалар бар.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА